MIRAS
ميراث

МИРАС

2/2000

ISSN 0869-3536

БУ САНДА:

Баш мөхәррир сүзе

Гаяз Исхакый. Зиндан. Повесть

Каим Шәйхетдин. Сөннәтчеләр. Повесть

Фирдәвес Зариф. Агымсу. Хикәяләр

Махсус сәхифәләр

Халык медицинасы

КҮРЕНЕКЛЕ ШӘХЕСЛӘРЕБЕЗ



АКАДЕМИК

ФӘРИТ ХАТИПОВ

ЯШӘ МӘҢГЕ, ХӨР МӘМЛӘКӘТ — ГҮЗӘЛ ТАТАРСТАН!

Бөтендөнья татарларының халыкара фәнни-популяр, иҗтимагый-сәяси һәм әдәби-нәфис айлык журналы

МИРАС 2 (99) 2000

АССОЦИАЦИЯ ӘГЪЗАЛАРЫ:

Халыкара «Мирас» журналы редакциясе хезмәт коллективы, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, Татар «Мирас» Фонды, Казан шәһәр хакимияте, Бөтендөнья татар конгрессы

Баш мөхәррир
ӘХМӘТ СӘХАПОВ

Халыкара редакция советы:
Раиф Әмиров *(Башкортстан)*
Равил Әмирхан *(Казан)*
Азат Әхмәдуллин *(Казан)*
Мәхмүт Әхмәтҗанов *(Казан)*
Марсель Әхмәтҗанов *(Казан)*
Хәнәфи Бадыйков *(Казан)*
Әгъдәс Борһанов *(Мәскәү)*
Наил Вәлиев *(Алабуга)*
Рәмзи Вәлиев *(Казан)*
Мөнәвир Галимуллин *(Түбән Кама)*
Фоат Галимуллин *(Казан)*
Тәлгат Галиуллин *(Казан)*
Фердинанд Галәмиев *(Казан)*
Зариф Дулат *(Кытай)*
Фирдәвес Зариф *(Казан)*
Рәшит Исламшин *(Казан)*
Камил Исхаков *(Казан)*
Дамир Исхаков *(Казан)*
Фәрит Йосыпов *(Казан)*
Әбрар Кәримуллин *(Казан)*
Нәфис Кашапов *(Чаллы)*
Хәлиф Курбатов *(Казан)*
Хатыйп Миңнегулов *(Казан)*
Темимдар Мохит *(Япония)*
Флүн Мусин *(Казан)*
Ринат Мөхәммәдиев *(Казан)*
Рөстәм Садри *(Австралия)*
Әсгат Салахов *(Әлмәт)*
Фәндәс Сафиуллин *(Казан)*
Гаяз Сәхапов *(Түбән Кама)*
Булат Солтанбәков *(Казан)*
Марсель Таишев *(Казан)*
Рифат Таби *(АКШ)*
Илдус Тарханов *(Казан)*
Энгель Таһиров *(Казан)*
Индус Таһиров *(Казан)*
Окан Таһир *(Финляндия)*
Фаил Фәтхетдинов *(Уфа)*
Равил Фәхретдинов *(Казан)*
Фарис Харисов *(Казан)*
Рәфыйкъ Хәмидуллин *(Казан)*
Мансур Хәсәнов *(Казан)*
Энәс Хәсәнов *(Казан)*
Әнвәр Хуҗиәхмәтов *(Казан)*

© «Мирас», 2000 ел

БУ САНДА:

БАШ МӨХӘРРИР СҮЗЕ 3

Әдәби мирас

МАРСЕЛЬ ӘХМӘТҖАНОВ. Татар кульъязма китабы *(Монография)* 5

Шигърият антологиясе

ВАКЫЙФ ҖӘЛАЛ. Җан теләкләре *(Шигырьләр)* 11

Татар әдәбияты тарихы

ФЛҮН МУСИН. Милли яңарышның алгы сафында 19

АЛСУ КӘРИМОВА. Күңел сафлыгы . . . 34

Тел белеме

МАЛИК ХӘЙРУЛЛИН. Галимҗан Шәрәф һәм татар тел белеме 36

Милли шигърият

ФӘРИДӘ ХАҖИЕВА. Күңел канатым *(Шигырьләр)* 38

Милли сәнгать

ЭЛФИЯ АЙДАРСКАЯ. Сәнгатьтә янган гомер 43

Тарихи мирас

ЭНГЕЛЬ НИГЪМӘТУЛЛИН. Европа һәм татарлар *(Тарихи парчалар)* 48

Алтын Урда тарихы

РАВИЛ ФӘХРЕТДИНОВ. Татардагы дәүләтчелек тарихының төп этаплары һәм рәвешләре 59

Төрки халыклар дөньясы

НӘКЫЙП КАШТАНОВ. Чуваш исеме каян килгән? 63

Рухи мирас

НАСРЕДДИН БИНЕ БОРҺАНЕДДИН

РАБГУЗИ. Пәйгамбәрләр тарихы *(Кыйсса)* 67
ҖӘГЪФӘР МӨБАРӘК. Кыямәт көне *(Вәгазь-нәсыйхәт)* 72

«Мирас» китапханәсе

ГАЯЗ ИСХАКЫЙ. Зиндан *(Повесть)*. . 77
БАРЛАС КАМАЛОВ. Дулкынлана хәят *(Повесть)* 95
ВАКЫЙФ НУРУЛЛИН. Хыянәтчеләр *(Повесть)* 108
КАИМ ШӘЙХЕТДИН. Сөннәтчеләр *(Повесть)* 116
ФИРДӘВЕС ЗАРИФ. Агымсу *(Хикәяләр)* 126
РАДМИР ФАЯЗ-УРАЛЛЫ. Соңгы шаһит *(Тарихи хикәя)* 133
ДАНИЯ ГАЙНЕТДИНОВА. Хәтер *(Нәсерләр)* 136
ДМИТРИЙ СТАХЕЕВ. Кырым бакчаларында *(Хикәяләр)* 141

Халык иҗаты

ЛЕНАР ҖАМАЛЕТДИНОВ. Җен кызы Гөлбану 153

Халык медицинасы

ӘБҮ ГАЛИ СИНА. Табиблык фәне нигезләре *(Трактат)* 156

«Мирас» почтасы

Укучы хатлары 159

Резюме

Журналның инглиз һәм урыс телләрендәге кыскача эчтәлеге 160

Редакция коллегиясе

Татьяна Афонина, Марсель Әхмәтҗанов, Мәхмүт Әхмәтҗанов, Тәнзилә Бәйрәмова, Хәнәфи Бадыйков, Фердинанд Галәмиев, Әлфия Галимҗанова, Айгөл Гарипова, Дилбәр Гарифуллина, Флера Гыйниятуллина, Фирдәвес Зариф, Хатыйп Миңнегулов, Ринат Мортазин, Флүн Мусин, Энгель Нигъмәтуллин, Миңнәхмәт Сәхапов, Дания Фәтхуллина, Зөфәр Хәкимов, Лилия Шафигуллина.

Редакциянең фикере журналда басылган язмаларда чагылган фикерләр белән һәрвакытта да туры килмәскә мөмкин. Журнал авторлары язмаларындагы фактларның, аргументларның һәм фәнни дәлилләрнең төгәллеге, рәсми мәгълүматларның, саннарның, цитаталарның дөреслеге, бәхәсле фикерләрнең корректлылыгы өчен шәхсән җавап бирәләр. Журнал татар телендә чыга. Аның кыскача эчтәлеге урыс һәм инглиз телләрендә басыла. Кулъязмалар кире кайтарылмый һәм рецензияләнми. Машинкада басылмаган текстларны редакция кабул итми. Борынгы текстлар хәзерге әдәби телгә күчерелеп бирелә. «Мирас» журналының индексы — **73955.** Аңа Бәйсез Дәүләтләр Бергәлегенә кергән илләрнең барлык элемтә бүлекләрендә һәм башка дәүләтләрдә урнашкан БДБ илчелекләренең матбугат атташатларында чикләнмәгән күләмдә язылырга мөмкин. Безнең адрес: **420066. Казан, Чистай урамы, 5 *(2 кат)*, Халыкара «Мирас» журналы редакциясе.** Бәйләнешкә керү өчен телефон һәм факс: ***(8432)* — 49-35-54 *(Баш мөхәррир)*.** Хатлар өчен: **420066. Казань, а/я № 227, редакция журнала «Мирас» *(«Наследие»)*.** «Мирас» журналы 1991 елның августыннан башлап чыга. «Мирас» үз вакытында килмәгән очракта әбүнәчеләр моның сәбәбен **38-59-78** һәм **43-25-42** номерлы телефон ярдәмендә ачыклый алалар. Басмаханә гаебе белән журналның сыйфаты түбән булганда дәгъваны **49-36-62** номерлы телефон белән шалтыратып белдерергә була. Журнал идеясенең һәм исеменең авторы М. Сәхапов. Нәшир итүче: «Халыкара «Мирас» журналы» ассоциациясе.

Халыкара «Мирас» журналының кодлары: ОКПО — 13012772, СООГУ — 7794, СОАТО — 1192401365, ОКОНХ — 87100, 72200, салым түләү буенча идентификация номеры (ИНН) — 1654002833.

Үзенчәлекле милли энциклопедия булган «Мирас»ка ярдәм итәргә теләүчеләр акчаларын журналның түбәндәге счетларына күчерә алалар:

1. Расчетный счет № 40603810062262000144 в Банке Татарстан Сбербанка России № 6672/0253. Корр. счет № 30101810600000000603 в РКЦ НБ РТ г. Казани. БИК 049205603.

2. Валютный счет: а) UNION BANK OF SWITZERLAND ZURICH, for. corr. acc. Nr 69.023.79 W of TATSOTSBANK in favour of acc. 100070521 *(в долларах США)*; б) COMMERZBANK AG FRANKFURT/MAIN for. corr. acc. 400/8866790/00 of TATSOTSBANK in favour of acc. 100070521 *(в немецких марках или в долларах США)*.

Халыкара «Мирас» журналы 1994 елның 3 августында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетында *(теркәү номеры 2)* кабат теркәлде.

Производствога бирелде 26.11.1999 ел. Басарга кул куелды 3.02.2000 ел. Кәгазь форматы 70×108 1/16. 2 номерлы офсет кәгазе. Күләме 10,0 басма табак. 18,80 нәшер-хисап табак. Заказ З-641. Тиражы 3200 данә. Ваклап сатуда ирекле бәя. Татарстан газета һәм журналлар нәшрияты басмаханәсе. 420066. Казан шәһәре, Декабристлар урамы, йорт номеры 2.

БАШ МӨХӘРРИР СҮЗЕ

Мәгълүм булганча, 1999 елның 29 ноябрь — 6 декабрь көннәрендә Төркия Республикасы башкаласы Әнкара шәһәрендә ТӨРЕКСОЙ Халыкара оешмасына әгъза һәм күзәтүче булып кергән төрки дәүләтләр мәдәният министрлары Даими Советының XIII утырышы булды. Әлеге мәртәбәле халыкара форумның эшендә Төркия Республикасы, Әзәрбәйҗан Республикасы, Казахстан Республикасы, Татарстан Республикасы, Башкортстан Республикасы, Татарстан Республикасы, Төньяк Кипр Төрек Республикасы, Саха-Якутия Республикасы, Хакасия, Тува Республикасы рәсми хөкүмәт делегацияләре катнашты. Татарстан Республикасы хөкүмәт делегациясе составына Татарстан Премьер-министрының мәдәният, сәнгать һәм матбугат эшләре буенча дәүләт советнигы, тарих фәннәре кандидаты Марсель Таишев, Татарстан мәдәният министры урынбасары, тарих фәннәре кандидаты Рафаэль Вәлиев, «Европа-Азия» Халыкара Гуманитар академия президенты, ЮНЕСКО институты ректоры, академик Энгель Таһиров, халыкара «Мирас» журналы баш мөхәррире, академик Миңнәхмәт Сәхапов кертелгән иде.

Төрки халыкларның мәдәниятен, сәнгатен, фәнен, матбугатын үстерү һәм бер-берсенә якынайту максатларында төзелгән Халыкара оешма — ТӨРЕКСОЙ Даими Советының XIII утырышын аның ярты елга сайланган Вакытлы Координаторы, Төркия Республикасы мәдәният министры Истемихан Талай бәй ачып җибәрде һәм рәислек итте. Башта ТӨРЕКСОЙ әгъзалары булган илләрнең беркетмәдә каралган чыгышлары булды. Татарстан делегациясе исеменнән мәдәният министры урынбасары Рафаэль Вәлиев тирән эчтәлекле һәм төпле чыгышы белән абруйлы форум әгъзаларын сокландырды. Аннан соң ТӨРЕКСОЙның узган ярты елдагы эшчәнлеге хакында аның генераль директоры, Әзәрбәйҗан Республикасы мәдәният министры Полад Был-Был оглы сөйләде. Әлеге оешманың узган чордагы финанс эшчәнлеге хакында генераль директор урынбасары Зыя Йылмазер чыгыш ясады. Хисап нотыклары фикер алышудан соң расланды. Шулай ук «ТӨРЕКСОЙның XXI гасырга мөрәҗәгате» дип исемләнгән документ та тикшерелде һәм кайбер өстәү-төзәтүләрдән соң бертавыштан кабул ителде. Моннан соң ТӨРЕКСОЙның сәнгать өлкәсендә Халыкара премиясен булдыру, интернетка аның әгъзалары булган дәүләтләрнең мәдәниятләре һәм сәнгатьләре хакында мәгълүматлар кертү кебек мөһим мәсьәләләр каралды һәм фикер алышулардан соң алар нигездә хупланды.

ТӨРЕКСОЙ генераль дирекциясе тәкъдиме белән бу Халыкара оешманың үз басма органын булдыру мәсьәләсе дә җентекләп тикшерелде һәм әлеге авыр, җаваплы эшне башкарганда «Мирас» журналының уңай тәҗрибәсен искә алырга тәкъдим ителде.

Шулай ук ТӨРЕКСОЙ генераль дирекциясе белән «Европа-Азия» Халыкара Гуманитар Академиясе арасында үзара хезмәттәшлек итү турында Шартнамә текстын тикшерү һәм аны кабул итү дә югары дәрәҗәдә башкарылды. Әлеге мөһим документка Полад Был-Был оглы белән академик Энгель Таһиров кул куйдылар.

ТӨРЕКСОЙ Генераль дирекциясенең 2000 елга эшчәнлеге хакындагы Программа тикшерелгәч һәм кабул ителгәч, чираттагы XIV утырышның Вакытлы Координаторы сайланды. ТӨРЕКСОЙның чираттагы XIV утырышы Башкортстан Республикасы башкаласы Уфа шәһәрендә узачак. Вакытлы Координатор итеп Башкортстан мәдәният министры расланды. ТӨРЕКСОЙ Даими Советының XIII утырышында катнашучы мәдәният министрлары, эш Беркетмәсенә һәм Декларациягә кул куйганнан соң, пресс-конференция уздырдылар.

ТӨРЕКСОЙ Даими Советының XIII утырышында катнашучы рәсми хөкүмәт делегацияләрен Төркия Республикасы Президенты Сөләйман Дәмирел, хөкүмәт һәм парламент җитәкчеләре, сәяси фирка һәм җәмәгать оешмалары лидерлары кабул итте.

ӘХМӘТ СӘХАПОВ.

ادبی میراث هم صنعت صحیفه‌سی
Әдәби мирас
һәм
сәнгать
сәхифәсе

ТАТАР КУЛЪЯЗМА КИТАБЫ*

(МОНОГРАФИЯ)

«ХУРЛУГА БЕЛӘН ҺӘМРА» ДАСТАНЫ

«Хурлуга белән Һәмра» дастанының татар телендә басылу-басылмавы хакында матбугатта хәбәрләр юк иде. Дастанның басылу тарихы белән шөгыльләнүчеләр нигездә төрекмән фольклорчылары булдылар. Аларның язуына караганда «Хурлуга белән Һәмра» дастаны беренче мәртәбә академик В. В. Радлов тарафыннан 1870 һәм 1886 елларда казакъ һәм уйгур телләрендә язылып алынып, басылып чыккан[1]. Шуннан соң дастанның 1898 елда Казанда литография ысулы белән «Һәмра» исемендә казак телендә басылуы хәбәр ителә[2]. Әлеге басманы табып, укып карагач, бу информациядә төгәлсезлекләр барлыгы ачыкланды. Казанда 1898 елда басылып чыккан китапның исеме «Һәмра» түгел, ә «Кыйссаи Һәмра Хөсрәү падишаһ» (40 битлек) дип аталган. Аның теленә килгәндә, ул татарча катыш казакъ тел элементлары белән язылган. Казан басмасының тел үзенчәлеген тулырак күз алдына китерү өчен 39 битеннән бер өзек китерелә:

Андин соң куанды Һәмра гариб,
Куанды шад булды да күңле тыныб.
Касина хезмәтчеләр ияртӗб алып,
Барады Хурлуканы Мисырга алыб.
Хөсрәүнең күңле тулды диде.
Алтын өй Мисырга киб кунды диде.
Хурлуканың алтынлы сарайы минән
Бары күркәм Мисырның булды,— диде.

Әлеге текстка аңлатмалар биреп тору артык булыр. Андагы татар әдәби телендәге кашына (каршысына) сүзен касына, куанадыр урынына куанады, иске әдәби телдәге минән (белән) формасын минән итеп алып кына татар әдәби теленнән бөтенләй аерып бетереп булмый.

Әлеге китапның типографиядә хәреф җыю юлы белән Түбән Курса авылы татарының — хаҗи Шәмсетдин бине Хөсәен акчасына басылуын да искә алсаң, дастан татар-казакъ телләре контакт зонасында яшәгән Байчыгави, Курмаши, Минзәләви, Юмачыков, Сабирҗан акын кебек берәр татар авторы тарафыннан язылган ахры, дигән фаразга нигез кала. «Кыйссаи Һәмра Хөсрәү падишаһ» дастаны Казанда 1898 елдан соң да басылып чыккан. Археографик экспедицияләр вакытында беренче басма тексты белән

* Дәвамы. Башы журналның 1998 елгы 4, 5, 6, 7, 8 һәм 1999 елгы 1, 2, 3, 4, 6, 7, 8, 9, 10, 11 һәм 2000 елгы 1 саннарында.

туры килгән башка бер басманың да фрагменты табылды[3]. Димәк, дастан Казанда кимендә ике тапкыр басылган.

«Хурлуга белән Һәмра» дастаны, белгечләрнең язуына караганда, Һиҗри 1326 (1907 руми) — 1914 елларда Ташкент шәһәрендә ташбасма ысулы белән алты мәртәбә «Һәмра» яки «Хурлука» исеме белән янәдән басылган[4]. Төрекмән версиясе фәкать 1941 елда гына нәшер ителә башлый һәм бу елдан соң берничә басмалары дөнья күрә.

Югарыда искә алынган басмалар татар укучысының «Хурлуга һәм Һәмра» дастаны белән инде шактый күптән таныш булуын күрсәтәләр. Ләкин, сорау туарга мөмкин, басылып чыкканчыга кадәр дастан кульъязмалары татарда мәгълүм булганмы соң?

Археографик экспедиция материаллары бу четерекле сорауга уңай җавап бирергә мөмкинлек бирделәр.

1978 елгы экспедиция барышында Татарстанның хәзерге Менделеев төбәге Татар Сарсазы авылында яшәгән һәвәскәр археограф Мирза Тарханов белән очрашканда, аннан туфракка уралып, тузып беткән кульъязма битләре алынган иде. Аларны авырлык белән чистартып, битләрен (сакланган кадәресен) тәртипкә китерүдән соң, текстны укып чыгу мөмкин булды. Кульъязма XVII—XVIII гасырларда язылган. Аның язулары XVII гасыр татар эпиграфик истәлекләрен хәтерләтәләр. Текст коңгырт төстәге имән каерысыннан эретелеп алынган кара белән язылган. Кульъязма 325х210 мм зурлыктагы алты кәгазьдән гыйбарәт. Һәр биттә 20—23 юл язу бар.

Әлеге кульъязманың башы-ахыры юк. Аның тексты белән танышкач, битләрендә «Хурлуга белән Һәмра» дастаны фрагментлары икәне аңлашылды. Бер битенең кырында «1869 нчы елда, майның 15 йәүмендә Коңгыра илтер бүрек алдым». Коңгыр хәзерге Перьм өлкәсендәге бер шәһәр исеме икәнлеге аңлашыла (урысча Кунгур). Коңгыр шәһәрендә татарлар да яшәгән. Шулай ук татарда Коңгыр кеше исеме буларак та мәгълүм.

Татар кульъязмасындагы текст хәзерләнгәч, аның җитмәгән сәхифәләрен, сюжет бөтенлеген, башка төрки версияләр ярдәмендә реконструкцияләргә мөмкин булды. Соңгы елларда дастанның төрекмән һәм уйгур версияләре кабаттан басылып чыктылар[5]. Башка төрки дастан текстлары белән чагыштырып караганда, татар версиясенең алар белән күп текстологик уртаклыклары барлыгы һәм аермаларга да ия булуы ачыкланды. Уйгур, төрекмән текстларында сюжет сызыгында охшашлык, персонаж исемнәрендә тәңгәллек, охшаш шигъри урыннар барлыгы күренде. Ләкин аерым шигъри строфалар саны берсендә озын, берсендә кыска итеп бирелгәннәр. Уйгур һәм төрекмән версияләренең прозаик өлешендә вакыйгасюжет барышы гомумән уртак булса да, тасвирлау, хикәяләү ягыннан берберсеннән шактый аерылалар. Бу санап кителгән аермалар, уйгур һәм төрекмән дастаннары версияләре арасында нинди нисбәттә булса, татар һәм төрекмән версияләре чагыштырмасындагы аермалары шундый ук күләмдә күренә, тик татар тексты алдагы һәр ике милли версиядән үзенең кыскалыгы белән дә аерыла. Татар версиясе үзенең сюжет төзелеше белән төрекмәннекенә якынрак. Дастан текстологик яктан эшләнеп, тикшеренү мәкаләсе белән бергә матбугатта бастырылды[6].

Өйрәнелә торган әлеге ядкяр узган гасырларда татар халкы арасында ни дәрәҗәдә популяр булган соң, ул укылганмы? Чөнки бер данәдә сакланган кульъязма һәм басма текстларның тарихи тирәнлеге укучыларны да, әдәбият галимнәрен дә кызыксындырырга мөмкин.

Галимҗан Ибраһимов исемендәге институт Мирасханәсе фондларында саклана торган, әмма әлеге фәнни әйләнешкә кертелмәгән бер кульъязма чыганак куелган сорауга уңай җавап табарга нигез бирә[7]. Атаклы татар әкиятчесе Минһаҗ Хәмидуллиннан фольклорчы Михайлов 1941 елда «Нурга зарлы кош» әкиятен язып алган булган. Ул әкиятнең сюжеты «Хурлуга һәм Һәмра» дастанына бик якын:

Мәхмүт патша төшендә «Нурга зарлы кош» исемле бик матур бер кош күрә. Аның өч улы була, ул аларның өчесен дә шул кошны эзләргә җибәрә.

Озын-озак юллар үткәч, әлеге өч егет, өчесе өч якка китеп аерылышалар. Кече малай Мәрһәм (Һәмра исеменә бик охшаш) «Кайтмас» дигән юл белән китеп, күп авырлыклар күреп, диюләр патшасы Сәхибҗамал яшәгән җиргә килеп җитә. Сәхибҗамал тылсымлы кошның иясе була. Мәрһәм, кыз патша йоклаган чагында әлеге тылсымлы кошны алып, кайтырга чыга. Юлда туганнары белән очраша. Ике агасы, Мәрһәм йоклаган чагында аның аяк-кулларын бәйләп, тирән коега салалар. Үзләре белән «Нурга зарлы кош»ны алып, этиләренә кайтып, таптык, дип мактаналар. Ләкин шул вакытта, Сәхибҗамал йокысыннан уянып, Мәрһәм артыннан аның этисенә килеп җитә. Мәрһәмне таптырып, аны терелтә. Ялганчылар фаш булалар. Бу сюжет Һәмраның башыннан кичергәннәре белән туры килә. Ләкин экияттә шигъри урыннар юк, ул кыскарак.

Димәк, татар халкы фольклор репертуарында «Хурлуга һәм Һәмра» дастаны борынгыдан ук мәгълүм булып экият рәвешендә сөйләнеп йөртелгән.

Бу дастан татар халкына Урта Азия халыклары әдәбиятыннан әдәби бәйләнешләр юлы белән бик күптән кергән булса кирәк. Аның татар кульязмасы әлегә мәгълүм булган барлык төрекмән, уйгур, казакъ текстларына караганда бик күпкә борынгырак. Әлеге дастанны кардәш төрки халыклар белән мәдәни һәм әдәби бәйләнешләр истәлеге итеп карарга мөмкин, чөнки татар версиясендәге аерым шигъри юллар еш кына төрекмән тексты белән тәңгәл киләләр.

«ГҮР УГЛЫ» ДАСТАНЫ

Төрки телләрдәге һ. б. язма әдәбиятларда, фольклорда киң таралган сюжетлардан берсе — Гүр углы турындагы дастан. Ул аеруча төрекмән, әзәрбәйҗан, таҗик, үзбәкләрдә фольклор әсәре буларак мәгълүм.

«Гүр углы» дастанының бер версиясе узган гасырда атаклы тюрколог В. В. Радлов тарафыннан Көнбатыш Себер татарлары арасында да телдән язып алынган. Әлеге версия татар халык иҗаты материаллары антологиясенә кертелеп, басылып чыкты[8].

Татар фольклор вариантындагы дастан «Күр углы» (ягъни «Сукыр улы») дип бирелә. Аның татар дастаннары арасында тоткан урыны турында фольклорчы Фатих Урманчеев хезмәтендә фикерләр әйтелә[9].

«Гүр углы» дастанының татар язма әдәби версияләре хакында әлегә фәндә фикер әйтелгәне юк. Гомумән, проблема өйрәнелмәгән әле.

1980 елларда вакытсыз арабыздан киткән фәнни хезмәткәр Салават Мөхәммәтнуров (1954—1995) Татарстанның Балык Бистәсе төбәгендә фольклор экспедициясе белән йөргәндә бер төргәк гарәп имлясындагы кульязмалар алып кайткан иде. Алар Мирасханәгә тапшырылып, тасвирланды[10]. Шул кульязмалар коллекциясеннән ике биткә гарәп хәрефләре белән язылган «Гүр углы» дастаны фрагменты да килеп чыкты. Текст шәмәхә кара белән 14,5x21 см зурлыктагы 1920 нче елларда эшләнгән кәгазьгә язылган.

Кәгазьләрнең беренчесенә 13, 14 саннары сугылып, аның бит тәртибе билгеләнә, икенче бит исә беренченең дәвамы булып тора, анысында бит саны куелмаган. Икенче биттә дастанның күчерелеп бетмәгәнлеге күренеп тора, зур гына урын язылмаган.

Фрагменттагы текст хәзерге татар графикасына күчерелде.

Тулы булмаган «Гүр углы» дастаны кыйпылчыгы буенча әлеге дастанның башка милләтләрдәге яшәгән версияләргә мөнәсәбәтен ачыкларга кирәк иде. Моның өчен төрекмән, таҗик, әзәрбәйҗан милли версияләре белән танышырга туры килде[11]. Ләкин татар кульязмасындагы текст тел һәм эчтәлеге ягыннан аларга туры килми иде.

Казан шәһәрендә татар телендә берничә мәртәбә нәшер ителгән «Хикәяте Гүр углы солтан» исемле дастан белән кульязма фрагментны чагыштырып өйрәнү кызыклы нәтиҗәләр күрсәтте. Кульязма фрагмент әлеге басмага бик якын текст буларак ачылды. Ул 1894 елда басылып чык-

кан басманың 13—15 битләрендәге текст белән күп урыннарда юлга-юл туры килә[12]. «Хикәяте Гүр углы солтан» Петропавел (Казагыстан) шәһәрендә китап төпләүче Мөхәммәтрәхим Мөхәммәтвәли углы заказы буенча мелла Хәсән Мирбаба углы тарафыннан 1880 елның 28 мартында язылып тәмамланган. Китапханәләрдә дастанның 1889, 1890, 1894, 1895, 1901, 1903, 1911, 1915, 1916 елларда чыккан басмалары да сакланган.

Дастанның татар версиясе төрекмән, таҗик, әзәрбәйҗан дастаннарыныкыннан нык кына аерылып тора. Мәсәлән, төрекмән дастанында Гүр углының бала чагыннан алып егет булганчыга кадәрге гомере бик тәфсилле бәян ителә һәм аның атының да могҗизалы тууы, үсүләре сурәтләнә. Гаваз ханны эзләп табу, аның өчен көрәшләр, Гаваз ханның хыянәте, аның кичерелүе һ. б. тасвирлана.

Таҗик варианты төрекмәннекеннән нык кына аерыла. Анда персонаж исемнәрендә үк төрекмән версиясеннән ераклык күренеп, вакыйгалар да башкачарак тасвирлана. Гүр углы, дастанның таҗик версиясе буенча, төрекмән ханы Әхмәтҗанның сеңлесе Хилал белән Райхан патша никахыннан туа. Хилал баласын үзе үлгәч, кабердә таба һәм сабый кабердән үрмәләп чыга. Аңа илнең аксакалы, кабердә тугангa күрә «Гүр углы» дип исем куша.

Таҗик варианты үзенең сюжет төзелеше белән татар дастанына якынрак. Анда да Гүр углы башта Хәсән ханны, аннан соң Гаваз ханны алу өчен көрәшә һ. б.

Әзәрбәйҗан версиясендә Гүр углы Хәсән ханның елкычысының улы рәвешендә тасвирлана. Анда төрекмән варианты белән уртак эпизодлар да бар. Уртаклык аеруча Гүр углының кыр аты туу, үсү тарихындагы хикәяләрдә күренә.

Төрекмән, татар дастаннарында Җыгалы хан образлары бирелә, әзәрбәйҗан версиясендә ул Галы дип алынган. Ләкин һәр версиядә дә охшаш образлар, бер үк исемнәр очраса да, аларның дастаннардагы урыннары төрлечә. Димәк, «Гүр углы» дастанының һәр милли версиясе уртаклыкларга һәм аермаларга бай булып, алар бер-берсен кабатламыйлар.

Казанда татар телендә XIX—XX гасыр башларында күп тапкырлар басылган «Хикәяте Гүр углы солтан» әсәрен дастанның татар милли-әдәби версиясе итеп карарга мөмкин. Әлеге әдәби дастан тел ягыннан фольклор әсәреннән нык аерыла, анда күп кенә гарәп-фарсы алынмалары, борынгы төрки лексика үрнәкләре шактый күп очрый. Ләкин «Гүр углы» дастаны иске кульязма китапларда очрамагач, басманы соңрак дәвердә берәр кешенең иҗади хезмәт җимеше түгелме икән,— дигән шөбһә, аның татар әдәбиятына нисбәтән билгеләргә мөмкинлек бирми иде. Чөнки татар телендә басылган һәрбер әсәрнең милли кыйммәткә катнашы булмый. Дастанның кульязма хәлендәге фрагментын табу гына аның татар әдәбиятындагы урынын тәгаенләргә дәлил булды.

Татарча «Гүр углы» дастаны басмасының кайбер үзенчәлекләренә тукталып үтү кирәк булыр. Төп үзенчәлек — татар версиясендә Гүр углының туу, үсү, җитлегү, аның могҗизалы аты тарихлары бик кыска рәвештә бирелүдә:

«Әмма равиан әхбар[13] вә нәкылән асар[14] андаг ривайәт кылырлар кем. Заман заман булганда Җәмбил бил-абад[15] булганда, Җәмбилнең әүвәлге хакиме Агалык хан булды, андыйн Җыйгалы хан булды, андыйн соң унбиш йәшендә Тала җагасы[16] башында, кырык егете кашында Гүр углы солтан хаким булды».

Гүр угылына утыз яшь булганда Хозыр галәйһиссәлам, кырык изге җан һәм унике имам киләләр һәм аны бөтен бәлаләрдән саклаган дога кылалар. Кырык яшенә җиткәндә Хозыр, кырык изге җан, унике имам аның янына кабаттан киләләр һәм бездән ниләр теләр идең диләр. Гүр углы үзенә озын гомер, дан, даныма зыян килмәсен,— дип теләк тели, ләкин балам булсын дими.

Гүр углы унике хатынга өйләнә, ләкин берсеннән дә баласы булмый. Ул йөз яшенә җиткәндә Исфаһан шәһәреннән Хәсән ханны алып кайтып, аны үзенең улы дип игълан итә, һәм нүкәр егетләренә баш итеп куя.

Көннәрдән бер көнне Гүр углы Хункар хан илендә Булдырык исемле итченең бер бик чибәр улы бар икән, аның матурлыгын күргән кеше атыннан егылып төшә икән,— дигән хәбәр ишетә. Ул егет Гаваз хан исемле була. Гүр углы Гаваз ханны күрәсе, аны үзенең варисы итәсе килә, ләкин күрергә барырга үзенең дәрманы булмый. Ул Хәсән ханны кырык егете белән Гаваз ханны алырга Хункар иленә җибәрә. Егетләргә, Хәсән ханны тыңлап, буйсынып торыгыз,— ди. Хункар дәүләте Гөрҗестан җирендә була. Хәсән хан һәм кырык егет Гөрҗестандагы Бәдбәхет тавына килеп җитәләр. Ул таудан Хункарның иксез-чиксез зур башкаласын күреп, каушап калалар. Алар каланың күпләгән капкаларын күреп гаҗиз булалар, Гавазны алу фикереннән ваз кичәләр. Шул вакыт Хәсән хан аларга шелтәле сүзләр әйтә.

Татарстанда табылган дастанның фрагменты шул шелтәле сүзләр белән башлана:

Җан барыйча, орышыңыз егетләр.
Тигенме[17] сезләргә бикләрнең туны.
Гүр углы бик безне илдин озатты,
Гаваз хан килер дип җаен төзәтте.
Бу йирдә барыңыз кайтмак ирерсез,
Шундай кыл дип безгә бирдеме атны.
Без барамыз кандаг Чембил йортыга,
Тапмаен Гаваз ханны затыга.
Бу җирләргә җандин кичкән килә ди
Үз башыны канҗыгалап атыга.
Кырык егет бошалмый атка мен имди.
Бер нимә булса тәкъдирдән бел имди.
Һәр ни дисәм фәрманымны кыл имди,
Киң улмаеп бу көн орыш кыл имди.
Алла дип ат-җан аямай куең,
Игәм әсрар һәр бәладин бел имди.
Хәсән хан дир, тапшыр хакка үзеңне
Кыяммәттәй була торган көн имди.
Фәрамуш[18] булмасын имди хатерләр.
Корыңызлар сара пәрдә[19] чатырлар.
Ак керүгә савыт кигән[20] батырлар,
Йа алыңлар, йа үләңләр егетләр.
Йулымызда күзе Гүр углы солтан,
Гаваз ханны килтерер дип кырык арыслан.
Ук үтмәгәй кирек тиресе[21] бу калкан,
Йа үлеңләр, йа алыңлар егетләр һ. б.

Кулъязма текстның бу юллары 1894 елгы басмадан ничек бирелгәнлеген карап үтик.

Җан барыйча орышыйңлар егетләр,
Тигенме сезләргә бикләрнең туны.
Гүр углы бик безне илдин озатты,
Гаваз килер диеп җаен төзәтте.
Бу йирдә барчаңыз кайтмакчы булдың,
Шундай кылып безгә бирдеме атны?![22]
Барамыз без ничек Җембил йортыга,
Ил-йорт канда[23], Гаваз хан ни затыга.
Бу йирләргә җандин кичкән килә ди,
Бер башыны канҗыглап[24] атыга.
Кырык егет бошанмай[25] атка мен имди,
Киңглəл[26] булмай бу көн тел имди.
Һәр ни дисәм, фәрманымны кыл имди.
Аллаһ,— дип ат-җан аямай куең,
Игәм(?) әсрар[27] һәр бәладин бел имди.
Хәсән хан дир, тапшыр хакка үзеңне,
Кыяммәттәй була тугун[28] көн имди.
...
Фәрамуш булмасын имди хатерләр,
Корыңызлар сара пәрдә чатырлар.
Ак керүгә савыт кигән батырлар,
Йа алыңлар, йа үлеңләр кырык егетләр,
Йулымызда күзе Гүр углы солтан,
Гаваз ханны килтерер дип, кырык арыслан,
Йамылкан[29] ук үтмәс кирек тиресе калкан,
Йа алыңлар, йа үлеңләр кырык егетләр.

Китерелгән өзекләр ике чыганакта да бер үк төсле юллардан тора, ләкин аларда лексик аермалар күренә. Шунлыктан бу фрагментларның протографлары бер үк булса да, «Гүр углы» дастаны атаклы «Кыйссаи Йосыф» кебек текстта лексик, морфологик, орфографик үзгәрешләр кичерә килгәнлегенә игътибар юнәлә.

Сюжет тарихына килгәндә «Гүр углы» дастаны һичшиксез угыз төркиләре арасында туган. Татар версиясендә очрый торган Исфаһан, Гөрҗестан географик-топонимик төшенчәләре дә дастанның каядыр төрки-иран контактлары зонасында туганлыгына ишарә итә. Угыз төркиләре инде ерак антик гасырлардан ук Көнчыгыш Европа кыйтгасында яшәгәннәр. Алар XV—XVII гасырлардагы Нугай урдасы татарлары этник тарихында әһәмиятле компонент булганнар. «Гүр углы» дастаны татар әдәбияты тарихына Нугай урдасы татарлары мирасы буларак кергән.

ИСКӘРМӘЛӘР

[1] Хурлукга и Хемра. Саят и Хемра. Туркменский романический эпос.— М.: Изд-во «Наука»,— 1971.— С. 11.
[2] Шунда ук.— 11 б.
[3] Фрагмент авторның шәхси архивында саклана.
[4] Хурлукга и Хемра. Саят и Хемра...,— С. 15.
[5] Хурлукга и Хемра. Туркменский романический эпос.— М.: Главная редакция восточной литературы, 1971.— С. 415; Уйгур фольклорининг антологияси.— Алмута: «Казакстан ССР «Наука» нәшрияти, 1988.— 141—190 б.
[6] Әхмәтҗанов М. И. «Хурлуга һәм Һәмра» дастанының татар версиясе//Әдәби мирасның яңа катламнары.— Казан, 1990.— 23—42 б.
[7] Мирасханә: 41 фонд.— 1 тасвир.— № 24 эш.
[8] Татар халык иҗаты. Дастаннар.— Казан: ТКН, 1984.— 89—93 б.
[9] Урманчеев Ф. И. Героический эпос татарского народа.— Казань: ТКИ, 1984.— С. 164—170.
[10] Мирасханә: 39 кол.— № 5013 эш.
[11] Гер оглы. Туркменский героический эпос.— М.: Главная редакция восточной литературы, 1983.— С. 804; Гур углы. Таджикский народный эпос.— М.: Главная редакция восточной литературы, 1987.— С. 702; Кoроглу//Азәрбайчан әдәбияты инчиләри.— Бакы «Йазычы», 1987.— 273—420 б.
[12] Хикәяте Гүр углы солтан.— Казань: Типо-литография Императорского университета, 1894.— С. 90.
[13] Равиан әхбар — хәбәрләр сөйләүчеләр.
[14] Нәкылән асар — әсәрләр күчерүчеләр.
[15] Абад — шәһәр.
[16] Җагасы — яры.
[17] Тигенме — тиешме.
[18] Фәрамуш булмасын — онытылмасын.
[19] Сара пәрдә — пәрдә корып, сарып.
[20] Ак керүгә савыт кигән — ак түгәрәк көбә күлмәк (кольчуга) кигән.
[21] Кирек тиресе — киргегә тирене тарттырып эшләнгән калкан.
[22] Атны — исемне.
[23] Кандай — нинди.
[24] Канҗыглап — кан-яшь түгеп.
[25] Бошанмай — пошынмый.
[26] Киңгләл — кинәле.
[27] Әсрар — сер.
[28] Тугун — туган.
[29] Йамылкан — атылган.

МАРСЕЛЬ ӘХМӘТҖАНОВ,
филология фәннәре докторы.

(Дәвамы бар.)

XX ГАСЫР БАШЫ ТАТАР ШИГЪРИЯТЕ

Вакыйф Җәлал

ҖАН ТЕЛӘКЛӘРЕ*

(Шигырьләр)

Мөхәммәтвакыйф Җәлал (әл-Җәлали) 1887 елда Казан губернасының Спас өязе Суыксу авылында (хәзер Татарстанның Әлки районы) туа. Бәхет эзләп, яшьтән үк казакъ далаларын гизә, Әстерханда яши, Урта Азиядә була.

В. Җәлалның беренче шигырьләре 1907 елларда «Бәянелхак» газетасы һәм «Дин вә мәгыйшәт» журналы битләрендә басылган. Ул аеруча «Идел» газетасында еш күренә. Биредә аның иллеләп шигыре, шулай ук хикәяләре, Ташкенттан, Бохарадан, төрекмәннәр арасыннан, Бакудан, туган төбәгеннән җибәрелгән юлъязма һәм очерклары чыккан. Аның «Кояш», «Аң», «Йолдыз» кебек матбугат органнарында да шигырьләр бастыруы билгеле.

В. Җәлал — «Садаи мәдәният» (Әстерхан, 1908), «Сәгадәт моңнары» (Казан, 1912), «Күз нурларым» (1913), «Күңел ялкыннары», «Күңел чәчәкләре» (Казан, 1913), «Вакыйф Җәлал шигырьләре» (Казан, 1913), «Яңа гөлстан» (Казан, 1917), «Вакыйф Җәлал шигырьләре» (Казан, 1919) исемле шигъри җыентыклар, «Кара тормыш» дигән хикәя китабы авторы.

В. Җәлалның тормыш юлы, иҗаты өйрәнелмәгән. Истәлекләрдә аның 1921 елгы ачлык вакытында Урта Азиягә китүе һәм басмачылар тарафыннан һәлак ителүе әйтелә (М. Әхмәтҗанов. Татар әдәбияты тарихына яңа исемнәр.— Кит.: Мәгърифәт һәм азатлык өчен көрәш. Казан, 1187—87—89 бб.). (Шигырьләр М. Гайнетдинов катнашлыгында әзерләнде.)

ТУГАН ИЛГӘ[1]

Әй авыл син, матур авыл, моңсу авыл!
Нинди нурлы, нинди якын Суксу[2] авыл!

Гаклым үсте, буем үсте туфрагыңда,
Артык мәддах[3] булыр идем сәфатыңда.

Атам-анам, кардәшләрем синдә минем,
Белгәннәрем, дуст-ишләрем синдә минем.

Синең миңа һәр җирдән дә кадрең зур;
Синдә генә бар рәхәтлек — синдә бар нур.

Өстендерсең шәһәрдән дә табигатьтә,
Гыйбадәттә, саф күңелдә, хәмиятьтә[4]...

Чын каһарман булып мактыйм, сине мактыйм!
Синең өчен моңланганым бар да хак дим.

Чишмәләрең, сахраларың, болыннарың —
Синең бардыр нинди ямьле урыннарың!

Сайрыйм сиңа, синең өчен кыйламын зар,
Нинди матур, нинди күркәм кызларың бар!...

НАЗЫМЧЫГА[5]

Кайрама үтмәс кылычны — үтми ул кайрау белән;
Карга былбыл булмыйдыр былбыл кебек сайрау белән.

---

* Ахыры. Башы журналның 1998 елгы 3—6, 8—11 һәм 1999 елгы 1—12 саннарында.

Җир казудан көчләнеп тә чыкмый алтын-энҗеләр;
Чикмә зәхмәт, җирдән энҗеләр табалмассың, җуләр!

Син кояшлы күккә очмак булган идең көчләнеп,
Остарып эчтән генә, белгеч булып, белгечләнеп,—

Кайт бу фикреңнән, чыгалмассың бәлөнд[6] күкләргә дә,
Һәм керешмә гаршидән[7] дә зур исем йөкләргә дә.

Син батарсың, гаркъ улырсың[8], кермә диңгезләргә дә,
Һәм табылмас — барма туфрактан шигырь эзләргә дә.

Үтмәсен гомрең һавага, син түгел былбыл, түгел!
Бик мөкатдәстер, нәзектер, нечкәдер былбыл-күңел!

АВЫЛ КЫЗЫНА[9]

Әй матур кыз, әй матур таң йолдызы, нурлы кояш!
Бик нәзек моңнар белән аһ әйләде гыйшкыңда баш.

Син юашсың, белмисең һичбер усаллыкларны син,
Гадәтеңчә күп сөйлисең һәрвакыт юк-барны син!

Гомрең үткәрсәң дә, дилбәр[10], буш фикер, юк-бар белән,
Син сәляхиятлесең[11] ләззәтләнергә яр белән...

Күкрәгеңдә бар синең алсу мәхәббәт гөлләре,
Җырлыйсың, күңлеңдә хисләрнең дә бар былбыллары.

Күрнешеңдә садәлек бардыр — вәләкин ул җәмал![12]
Ай яраткандыр йөзеңне Хакъ Тәгали — За-л-җәлял![13]

Күз карашыңнан синең, бел, нинди илһамнар килә?
Әй матур! Мактар өчен сине шигырьханнар[14] килә.

Хәл күзем күрде бу көн, кайттың судан ялгыз үзең;
Атлыйсың акрын гына, белмим, нигә төшкән күзең?

Чын мәхәббәт мәгъдәнесең[15], бел, шагыйрь мәфтүн[16] сиңа!
Шигыреңең иң нечкәсе берлән тәмам Мәҗнүн сиңа!

МИН КҮРӘМ...[17]

Мин күрәм: Җирнең шарында һәрбере ялган кебек,
Җир йөзе золмәт вә дәһшәтләр белән янган кебек.

Мин карыйм читтән генә җир халкына, хәятенә,
Зәһре гафләт[18] берлә күкрәкләр агуланган кебек.

Нинди хикмәт, нинди сер бар бәндәләрдә, әй Ходай?
Бу хәляикъ[19] һич көтелмәс фетнәгә тарган кебек.

Ни гөнаһы шомлыгыннан без — караңгы, бездә — төн?
Санкә[20] дөнья безгә ләйл[21] каһренә салган кебек.

Бу күңел җырлый тәрәкъкый һәм тәгали[22] моңнарын...
Бу фәләк бездән тәгали хисләрен алган кебек.

Кичте гомрем моң белән, хәсрәт белән, күз яшь белән;
Һәр шигырь язсам, күземнең тамчысы тамган кебек.

Әй Ходай, фазлың[23] белән җу керле күкрәкләрне син!
Юкса эчләр мәңге ак булмас, караланган кебек.

ЭСӘРЛӘНГӘЧ[24]

Торам дөньяда сулган бер агачдай,
Телем бар — сайрый анчак сандугачтай.

Мине читтән карап торган фикерләр:
Гаҗәп! Авәрә иткән нинди дилбәр?[25]

Дөрест сүз бу, шулай мин Мәҗнүн улдым
Вә Ләйләгә агач сулгандай сулдым.

Мине син күрмәсәң дә, мәгълүм инде,
Эчемне белмәсәң дә, мәгъмүм[26] инде.

Өмид итмим бай улмакны вә малны,
Булыйм анчак әмәлле[27], идеаллы.

Фараз иттек: синеңчә мин бай улдым,
Синең каршыңда яктырдым — ай улдым.

Мин инде маддәтән[28] гыйззәтле бәндә,
Синең төсле фәкыйрь миннән түбәндә.

Вә ләкин монда бер сер бар, караңгы;
Боз өстендә мәхәббәт уты янмый!

Адәм мәгънән өчен килгән торырга,
Нифакъ тохмы[29] өчен ләгънәт орырга.

Минем гаклым мәхәббәтләрне көтми,
Монафикъ[30] җир йөзендә акча бетми.

Тәмам армый вә һич талмый-ялыкмый,
Әгәр тикшерсә вөҗданым халыкны,

Күңел хәсрәт тула, шатлыкка җир юк,
Миңа юлдаш вә чын сердәш бер ир юк.

Мәхәббәт багъламыйм ташка вә бозга,
Буламын мөнтазар[31] рәхмәтле кызга.

Миңа ул көч, миңа ул хис, миңа нур —
Шуның берлән булам мәсгуд вә мәсрур[32].

Матур кызлар да мөмкин булгаларга,
Табигатьтә вафасызлык аларда.

Күренгәндәй була кайчан, вә кайчан
Беләсең, фитъратында[33] ул зәгыйфь җан!

Минем һәр илһамым җирнең хурыннан,
Мәгәр яктырды эч төшкән нурыннан.

Кояш ул — күктә торганда нурлы,
Вә ләкин бик горурлы соң, горурлы!..

ДОШМАНЫМА[34]

Башым тоттым синең миңа һәр аткан ташыңа каршы,
Күләрмен мин дә бер көн, тукта, һәр күз яшеңә каршы.

Кояшым капланып калмас кара болтыңның астында,
Изелсәң дә ничә кәррә минем гайбәт җафасында.

Миңа дошман икәнсең җаһиләнә[35] — мин дә дошманмын,
Хәбәрдар бул: әгәр син шоңкар улсаң — мин арысланмын!

Синең һәрбер яман касдың[36], һөҗүмеңнән әсәрләнмим;
Каһәр ит — һәммә зәһреңнән вә бер зәррә зәһәрләнмим.

Пычак булсаң — кылычмын мин, әгәр киссәң — кисәм мин дә;
Болыт булсаң — куармын, чөнки җил чаклы исәм мин дә.

Өреп торма аяк астында, әй рәзил[37], түбән бер эт!
Синең шанең[38] — түгел эшләр, җир өстендә түгел бөркет.

АКЧА[39]

Әй җәһәннәм, чык җиһанга, ал җиһаннан акчаны,
Тарт, йолык, яндыр барын, ал барча җаннан акчаны.

Та кыямәт[40] булганынча җирдә акча падишаһ!
Хандыр ул, солтандыр ул, булган бөтен инсанга шаһ!

Шулкадәр өрткән хакыйкать нурларын алтын-көмеш;
Бәйләнеп беткән, чуалган акчага һәр сүз, һәр эш...

Ул имансыз да ерткандыр кешелек пәрдәсен,
Һәр урында үстерә безгә җинаять зәрдәсен[41].

Һәр батыйльлекләр[42] вә ялган, җинаять — акчадан;
Һәр золым, һәрбер мөнафикълык вә гайбәт — акчадан.

Каплаган йолдызны, айны, көн кояшын каплаган;
Телне кискән, һәр кешенең күз вә яшен каплаган.

Акча бетми та кыямәт, һич тумас хаклык абы[43],
Ай була безнең җиһанда шул гавамнарның бае.

ФӨЗУЛИ ХӘЗРӘТЛӘРЕНӘ[44]

Әй олугъ остаз! Фазыйләт[45] йолдызы, олугъ шагыйрь!
Син идең серләр вә хикмәт йолдызы, олугъ шагыйрь!

Күп заманнар моннан әүвәл күкрәгең моңландырып,
Киттең үтеп, кап-караңгы дөньяны нурландырып.

Һәр шигырьләрдән синең шигъриң мөкатдәс һәм бәлэнд[46];
Белмимен, инсанмы булдың яки син булдың мәләк?

Һәр шагыйрьләрнең атасы синсең инде, сүз дә юк,
Әмма яшьрен сер белән бу дөньяга аткансың ук.

Җөмлә-җөмлә мисрагыңда[47] сер вә хикмәтләр тулы,
Гарше әгъля[48] гәүдәсен күз күрде шигъриң аркылы.

Күкрәгеңдә тулган илһам берлә кодсият[48] синең,
Җан белән җисмеңне өреткән хис вә шигърият синең.

Нинди хуш ис аңкыса, анчак диваныңнан чыга,
Күктән иңмәс булса, ул моң нинди җаныңнан чыга?

Хак Тәгалә дәрья иткән, әй олугъ остаз, сине!
Тәкъдир итә мильон инсаннар да мең әлфа[50] сине!

Та кыямәт калды мәңге бу олугъ исмең синең;
Ни зарар бар, китте килгән урнына җисмең синең.

Пакь җаның күкнең йөзендә асрала гыйззәт[51] белән,
Ашкан ул күкләргә ушбу дөньядан гозләт белән[52].

Мин, гаҗиз кол, йөгрәм артыңнан синең җитмәк булып,
Бозлы диңгезләргә бар аһымны бер сипмәк булып.

ЯРЛЫЛЫКТА[53]

Җиһанда ни авырлык булса — аны ярлылыктан күр;
Әгәр син ярлысың — тормыш синең кабрең, сиңа ул гүр.

Әзалардан[54], җәфалардан вә хәсрәттән буш улмассың,
Гомер үткәнчә янмактан да чыкмассың, котылмассың.

Янар ут һәр дәкыйкаңдә[55] синең күңлең учагында,
Ятасың чөнки тормышның зәһәрләнгән кочагында.

Синең әһле гыялыңда[56] — тынычсызлык, тавыш, гауга;
Күңелсездер, күңелсездер, күңелсездер бу эш әмма!

Зан итмә[57] бер кешедән: мәрхәмәт бар, ярдәм, ихсан[58] бар;
Беләмсең, бездә ихван хәленә күз салмас ихван[59] бар.

Котылмак чарасын күр ярлылыктан, төрле михнәттән,
Һәмишә эшлә һәм кәсеп ит вә һич куркъма мәшәкатьтән.

АВЫЛЫМА КАРАП[60]

Нинди золмәт каплаган сине, авыл — мескин авыл;
Әй бәхетсезлек, фәкыйрьлек берлә яткан син, авыл!

Кап-кара бәхтен әзәһәрләп ташлаган дөнья сиңа;
Зәррә нурың юк — күмелгәнсең кара җир астына.

Рухың үлгән: хиссиятең юк синең, юк тәдбирең[61],
Аһ дәрига![62] Һәр карадан да карадыр тәкъдирең!

Изде рухыңны фәкыйрьлек матдәтән, мәгънән[63] синең;
Сиңа түккәндер җиһан, белмим, нидән гафләт силен?[64]

Йорт саен эзләп йөрим: сүнгән тәгали[65] утлары,
Һәр тараф саф-саф тора гафләт, җәһаләт йортлары...

Икътитсад юк монда, һәм дә мәгърифәт юк монда һич,
Монда таң атмый, кояш чыкмый — караңгы монда кич.

Монда гайбәт. Монда зыйдлык[66], монда дошманлык бара!
Ни гөнаһтан, (әй) авыл, булдың түбән, булдың кара?

Синдә — гауга, синдә — оршыш, синдәге тормыш та вак;
Бер булыр микән синең кальбең бәлэнд[67], кальбең бер ак?

Кызганам мин син авылны, син — шагыйрьнең һәмдәме[68].
Әй гаҗәеп! Нинди эш: авылым — җәһаләт мәгъдәне![69]

ТӘӘССЕФ[70]

Янә кайтармы бу «Гасры сәгадәт?»[71]
Булырбызмы сәфаләттән[72] сәламәт?
Бүгенгедән хәят бер үзгәрерме?
Бетәрме безгә дошман суи[73] гадәт?

Бәли[74], шатланган булдык аз бер эшкә —
Бу эшләр иске гафләттән гыйбарәт.
Янып дүзәхтә[75], ялгыш эзләдек без
Җәһаләт тәэсире астында җәннәт.

Туар, ахры, тәәссеф, арты белән
Гаребтә парлаган шәмсе кәмаләт.[76]
Гараибтер[77], калырмы мәңге әллә,
Китәрме яки, раббем, ушбу халәт?!

Йөзен чөрде мөселман бар хәердән,
Итеп шәрнең ләвасына[78] итагать.
Кыймылдыймыз һәнүз үлми, терелми,
Терелмәбезме әллә та кыямәт?!

Гаҗәптер, ихтыяр иттек төшүне,
Менеп торганда күккә һәр виляять.
Тәмам зыйд[79] кемсәләрдән без ишеттек
Күтелмәс чаклы микъдарда иһанәт[80].
Моны күтмәс идек, җәбран вә каһран,[81]
Ходая, нинди җирдән килде афәт?!

ШАГЫЙРЬ ХАТИРӘСЕ[82]

Исмидер җилләр бу көн, әкрен генә тынган җиһан —
Ваҗ-выҗ итеп шаулаган, җилләр исеп торган җиһан.

Ялтырап тормый кояш та, күк йөзендә нурланып,
Нурлары сүнгән, тора хәсрәтләнеп һәм моңланып.

Балкыган ай берлә йолдызлар да моңланган кебек,
Бу кара җир өстенә күз яшьләре тамган кебек.

Бездәге һәрбер матәмнәрне күреп эчтән генә,
Һәммә тау-ташлар да сыкранган кебек эчтән генә.

Сайрамый кошлар да, былбыллар да шатлык җырларын,
Җырлыйлар анчак хафа, хәсрәт вә госса[83] моңнарын.

Мин күрәм: саф һәм табигый якшылыкта тормый көн;
Төн катышкан төсле көнгә, һәм (дә) күргәндәй төтен.

Шылтырап аккан суларның да эче пошкан кебек,
Ниндидер буннарга да хәсрәт вә гамь төшкән кебек.

Күк йөзендәге болытлар бар да качканнар бу көн —
Гарше әгъләдән бу җиргә юлны ачканнар бу көн.

Әллә кайда шаулыйлар... моңлы авазлар ишетелә...
Әйтә һатиф[84]: «Бер заман инсан үлә, инсан үлә!»

Мин бу көн күрдем табигатьнең тәмам үзгәргәнен,
Иске төсләр юк булып, бер үзгә төскә кергәнен.

Шул заман калдым тәхәйердә[85], дидем: «Ник соң болай?»
Бер аваз килде һатифтән: «Күчте дөньядан Тукай!»

ҖАН ТЕЛӘКЛӘРЕ[86]

Җан тели җирдә мәхәббәт орлыгын,
Хурлана күрмәккә зыйдлык[87] хурлыгын.

Җан тели: һәрбер кеше булсын тигез,
Булмасын берсе арык, берсе симез.

Ут яна милләт күгендә, боз тели.
Утның урнында матур йолдыз тели.

Бу гомернең икмәгенә тоз тели,
Мәңгегә юлдашлык өчен бер кыз тели.

Ул тели һәр яхшылыкны... ул тели...
Зикер итеп[88] һәр нәрсәне йомшак «тел»и.

ШАГЫЙРЬ МӘХӘББӘТЕ[89]

Сөя шагыйрь үзе торган җиһанны,
Сөя өстендә җирнең барча җанны.

Шагыйрьгә чит түгел дөньяда һич ни,
Сөя күркәм холыкны, күркәм эшне.

Болыт, җил, күк, кояш, ай, йолдызы һәм
Була шагыйрьгә бер шатлык вә бер гамь.

Кара җир, тау, ачык сахра, болыннар
Була шагыйрь өчен ярдәмче моңнар.

Мәһабәттер шагыйрь күңле, мәхәббәт!
Вәләкин бар эчендә кайгы-хәсрәт!

Шагыйрь мәфтүн — матурлык мәфтүне[90] ул,
Шуңарга сайрыйдыр көн һәм төне ул.

ШИГЫРЬЧЕГӘ[91]

Язма мең юл, яз бер-ике юл гына —
Күкрәгеңдә көзге булсын шул гына.

Нинди файда бар — тегермән тартмаса,
Арытасың мең юл язып кул гына.

Чыкмыйдыр он, буш тегермән әйләнеп,
Җилне истермәс борын бик мул гына.

Киссә кайчы, иссә җил — тарта күңел,—
Шунда тирмән әйләнә, балкый күңел.

АҢЛАТМАЛАР ҺӘМ ИСКӘРМӘЛӘР

[1] **Туган илгә.** В. Җәлалның «Сәгадәт моңнары» исемле китабында (1912) чыккан. Текст шуннан алынды.

[2] Суксу — Суыксу, шагыйрьнең туган авылы.

[3] Мәддах — мактаучы.

[4] Хәмият — дәртлелек.

[5] **Назымчыга.** «Идел» газетасының 1912 елгы 1 февраль (424 нче) санында «Вакыйф әл-Җәлали» имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.

[6] Бәләнд — биек.

[7] Гарши — күк.

[8] Гаркъ улырсың — суга батарсың.

[9] **Авыл кызына.** «Идел» газетасының 1912 елгы 31 июль (474 нче) санында «Вакыйф әл-Җәлали» имзасы белән басылган. «Сәгадәт моңнары» китабында (1913) бар. Текст шуннан алынды.

[10] Дилбәр — сөекле (кыз).

[11] Сәляхиятле — сәләтле.

[12] Җәмал — матур, ямьле.

[13] За-л-җәлял бөеклек иясе (Алла эпитеты).

[14] Шигырьхан — шигырь сөйләүчеләр.

[15] Мәгъдәне — байлыгы.

[16] Мәфтүн — үз-үзен онытып соклана.

[17] **Мин күрәм...** «Идел» газетасының 1912 елгы 25 сентябрь (488 нче) санында «Вакыйф» имзасы белән басылган. Шагыйрьнең «Күңел чәчәкләре» (1913) китабында чыккан. Текст шуннан алынды.

[18] Зәһре гафләт — гамьсезлек зәһәре.

[19] Хәляикъ — халыклар.

[20] Санкә — чөнки.

[21] Ләйл — төн.

[22] Тәгали — бөеклек.

[23] Фазлың — өстенлегең.

[24] **Әсәрләнгәч.** «Идел» газетасының 1912 елгы 2 октябрь (490 нчы) санында «Вакыйф әл-Җәлали» имзасы белән басылган. Шагыйрьнең «Күңел чәчәкләре» китабында чыккан. Текст газетадан алынды.

[25] Дилбәр — яраткан кыз.

[26] Мәгъмүм — кайгылы, сагышлы.

[27] Әмәлле — өметле.

[28] Маддәтән — асылда.

[29] Нифакъ тохмы — җәнҗал сәбәбе (яблоко раздора).

[30] Монафикъ — ике йөзле.

[31] Мөнтазар — көтеп алучы.

[32] Мәсгуд вә мәсрур — бәхетле һәм шат.

[33] Фитьратында — яратылышында.

[34] **Дошманыма.** «Идел» газетасының 1913 елгы 11 январь (518 нче) «В. Җ.» имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.

[35] Җаһиләнә — наданлык белән.

[36] Касдың — теләгең, ниятең.

[37] Рәзил — начар, яман.

[38] Шаның — дәрәҗәң.

[39] **Акча.** «Идел» газетасының 1913 елгы 12 февраль (527) санында «Вакыйф әл-Җәлали» имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.

[40] Та кыямәт — кыямәткәчә.

[41] Зәрдәсен — бирейдә: үсемлеген.
[42] Батыйльлек — бозыклык.
[43] Абы — суы.
[44] **Фөзули хәзрәтләренә.** «Идел» газетасының 1913 елгы 14 май (553 нче) санында «Вакыйф Җәлал» имзасы белән басылды. «Вакыйф Җәлал шигырьләре»ндә (1914) бар. Текст шуннан алынды.
[45] Фазыйләт — өстенлек, кешелеклелек.
[46] Бәләнд — югары; бөек.
[47] Мисрагъ — шигырь юлы.
[48] Гарше әгъля — күкнең иң югары катлавы; биеклек.
[49] Кодсият — изгелек.
[50] Әлфаз — сүзләр.
[51] Гыйззәт — кадер, хөрмәт.
[52] Гозләт белән — ялгызлыкка бирелеп.
[53] **Ярлылыкта.** В. Җәлалның «Күңел чәчәкләре» китабында (1913) басылган. Текст шуннан алынды.
[54] Әзалардан — җәбер-золымнардан.
[55] Дәкыйкандә — минутында.
[56] Әһле гыялында — гаиләндә.
[57] Зан итмә — уйлама, өметләнмә.
[58] Ихсан — булышлык, ярдәм.
[59] Ихван — туганнар.
[60] **Авылыма карап.** В. Җәлалның «Күңел чәчәкләре» китабында (1913) басылган. Текст шуннан алынды.
[61] Тәдбирең — чараларың.
[62] Дәрига — үкенеч.
[63] Матдәтән мәгънән — матди, мәгънәви (эчке) яктан.
[64] Гафләт силен — гамьсезлек ташкынын.
[65] Тәгали — бөеклек (югарыга күтәрелеш, үсеш).
[66] Зыйдлык — капма-каршылык, тискәрелек.
[67] Бәләнд — бөек.
[68] Һәмдәме — юлдашы.
[69] Мәгъдәне — шахтасы; чокыры.
[70] **Тәәссеф.** В. Җәлалның «Күңел чәчәкләре» китабында (1913) басылган. Текст шуннан алынды. Тәәссеф — үкенеч.
[71] «Гасры сәгадәт» — сәгадәт гасыры, үткәндәге мифологик тулы бәхетлелек заманы («золотой век»), мөселман мифологиясе буенча, Мөхәммәд пәйгамбәр һәм беренче дүрт хәлифә — Әбүбәкер, Гомәр, Госман, Гали идарә иткән вакыт.
[72] Сәфаләт — түбәнлекләр.
[73] Сүи — яман, явыз.
[74] Бәли — әйе.
[75] Дүзәх — тәмугъ, җәһәннәм.
[76] Гаребтә парлаган шәмсе кәмаләт — Көнбатышта балкыган камиллек кояшы.
[77] Гараиб — ишетелмәгән хәл.
[78] Шәрнең ләвасына — явызлык (яманлык) байрагына.
[79] Зыйд — тискәре.
[80] Иһанәт — кимсетү, хурлау.
[81] Җәбран вә каһран — ирексезләп һәм каһәрләп.
[82] **Шагыйрь хатирәсе.** «Вакыйф Җәлал шигырьләре» китабында (1913) басылган. Текст шуннан алынды.

В. Җәлалнең Г. Тукай үлеме уңае белән язылган тагын ике шигыре бар. «Мәрхүм Тукаевка матәм» исемлесе «Кояш» газетасының 1913 елгы 4 апрель санында, икенчесе — «Тукай кабере янында» — «Вакыйф Җәлал шигырьләре» (1913) китабында басылган.
[83] Госса — кайгы.
[84] Һатиф — яшерен тавыш, күк тавышы (дини).
[85] Калдым тәхәйердә — хәйран булып калдым.
[86] **Җан теләкләре.** «Вакыйф Җәлал шигырьләре»ндә (1913) басылган. Текст шуннан алынды.
[87] Зыйдлык — дошманлык.
[88] Зикер итеп — искә төшереп.
[89] **Шагыйрь мәхәббәте.** Шунда ук басылган.
[90] Мәфтүн — үз-үзен онытып сокланучы.
[91] **Шигырьчегә.** Шунда ук басылган.

Текстларны, аңлатмалар һәм искәрмәләрне журналга филология фәннәре кандидаты **ЗӨФӘР РӘМИЕВ** әзерләде.

(Тәмам.)

Милли яңарышның алгы сафында

Хәзерге эпохаль әһәмиятле иҗтимагый-сәяси һәм социаль-рухи күчеш вакыты күп нәрсәгә тарихи яссылыкта, бүгенге белән үткәнне күчемле бәйләнештә карауга этәрә. Шул сәбәпле, татар дөньясында безнең көннәрдә бара торган иң мөһим процессны — милли яңарыш хәрәкәтен дә без үзалдына гына түгел, бәлки бу өлкәдә үткәндәге тәҗрибә белән бәйләп алып барырга тиешбез. Инде билгеле булганча, мондый яңарыш бездә XIX һәм XX йөзләр аралыгында күзәтелгән иде. Ул вакытта заман үзе тудырган һәм мәгърифәтчеләр әйдәп барган әлеге хәрәкәттә төп көчләр булып мәгариф белән мәдәният торган иде. Ягъни милли яңарышны тәэмин итүдә мәгърифәтчеләр шушы ике өлкәгә аеруча басым ясадылар. Бу күренешнең иң характерлы мисалы итеп тора-бара татарның милли идеологына һәм лидерына әверелгән Гаяз Исхакый эшчәнлеген алырга була. Милли яңарыш хәрәкәтенең үзәгендә торган милләтпәрвәр әдипнең әлеге эшчәнлеге бу яктан хәзер дә принципиаль әһәмияткә ия. Әйтергә кирәк, 70 елдан артык төрле сәяси-идеологик мөһерләр сугып онытылуга дучар итеп киленгән Исхакый мирасының нәкъ менә хәзерге тарихи күчеш һәм милли яңарыш вакытында кабат торгызылуы үзенә бер символик мәгънә ала. Ул, бер яктан, әлеге яңарыш тарафыннан кире кайтарылса, икенче яктан, шушы хәрәкәтне әйдәп бару чарасына әверелә.

Шундый тарихи-милли әһәмияткә ия булган бу мирасны өйрәнгәндә һәм бәяләгәндә беренче чиратта моңа кадәр аңа булган мөнәсәбәтне ачыклау кирәклеге аныклана.

Исхакыйга мөнәсәбәт тарихын берничә, якынча өч чорга бүлеп карарга мөмкин.

Беренче чор революциягә кадәрге дәверне эченә ала. Матбугат битләрендә Исхакый турындагы хәзергә мәгълүм беренче сүз аның мөгаллимлек эшчәнлегенә карата әйтелгән. Биредә «Казанский телеграф» газетасының 1898 ел 15 январь санында «Н. П.» имзасы белән бирелгән «Из мусульманского мира» дигән мәкалә күздә тотыла. Анда яшь мөгаллим Гаязның Яңа бистәдәге Әмирхан мәдрәсәсендә шәкертләрне җәдитчә укыта башлавы уңай бәяләнә. Исхакыйның әдәби иҗаты турында да хәзергә билгеле булган беренче җитдирәк фикер шулай ук рус матбугатында әйтелә[1].

Татар дөньясына килсәк, анда әдәби тәнкыйть фикеренең формалашуы һәм үсеп китүе күбрәк Исхакый иҗатын анализлау һәм бәяләү белән бәйләнгән дияргә мөмкин. Бу иҗат турында беренче җитди фәнни чыгышлардан булган Й. Акчураның «Гаяз әфәнде» дигән мәкаләсендә үк («Казан мөхбире», 1906, 5 ноябрь) яшь әдипнең беренче әсәрләре нигезендә аның әдәби сәләте һәм татар әдәбиятында тотачак урыны хакында шактый төпле фикер әйтелде. Бу уңайдан Й. Акчура болай язды: «Ул заманнан игътибаран фикеремдә тәмамән урнашкан иде: милләттәшләрем арасында ике әдип җитешә, берсе — хәссас (сизгер), атәшле (ялкынлы) милләтпәрвәр, идеалист вә романтик Гаяз, икенчесе — гасабый (көчле) тешләүчән, милләтен чеметеп сөя торган рационалист вә реалист Фатих (Ф. Кәрими)[2].

Бу мәкалә Исхакыйны бәяләүдәге беренче чорга нигез сала дияргә мөмкин. Бу вакытта әдипне милли позициядән торып бәяләү һәм тәкъдир итү өстенлек ала. Ягъни төп игътибар Исхакыйны милләтпәрвәр әдип дип карауга, аның иҗатында милләтнең хәл-әхвале һәм язмышы мәсьәләләренең ничек яктыртылуына юнәлтелә. Әдип турында сүз күбрәк аның аерым әсәрләре тирәсендә алып барыла. Киң җәмәгатьчелек игътибарын аеруча Исхакыйның «Кәләпүшче кыз», «Ике йөз елдан соң инкыйраз», «Алдым-бирдем», «Мөгаллим» һәм «Зөләйха» кебек әсәрләре җәлеп итә. Болар турында матбугат битләрендә дә байтак языла. Мисалларга килсәк,

«Кәләпүшче кыз» турында Й. Акчура, Н. Гасрый[3], «Ике йөз елдан соң инкыйраз» турында Г. Гобәйдуллин, Җ. Вәлиди[4], «Мөгаллим» турында Г. Камал, Г. Баттал, К. Бәкер, И. Биккулов, Ф. Әмирхан[5], «Мөгаллимә» турында Г. Гыйсмәти, Ш. Әхмәдиев, Г. Кәрам, Ә. Мөхетдиния, Җ. Вәлиди, С. Рәмиев, Г. Ибраһимов, А. Бикташев[6], «Зөләйха» турында Ф. Әмирхан, Ш. Әхмәдиев, Г. Кәрам, Р. Тюменев[7] мәкаләләре күбрәк игътибарга лаеклы. Биредә фикерләрнең төрле булуына карамастан, әдип турындагы күпсанлы чыгышларда аңа югары бәя бирелүен, аның әдәбияттагы урыны һәм роле объектив бәяләнүен әйтергә кирәк. Аларда Исхакый феноменының асылы аның милләтпәрвәр әдип булуыннан, милләт язмышы мәсьәләсен әдәбиятта аеруча калку һәм җитди итеп күтәрүеннән, аны хәтта әдәби иҗатның төп проблемасына әверелдерүеннән, заман тормышының төрле-төрле күренешләрен шушы төп мәсьәлә белән бәйләп каравыннан гыйбарәт икәне ассызыклана. Кайчак әдипнең иҗат методына да дикъкать итеп аның күбрәк реалистик планда фикер йөртүе күрсәтелә.

Гомумән алганда, XX йөз башы тәнкыйте Г. Исхакыйны ул дәвер әдәбиятының төп фигураларыннан һәм әйдәп баручыларыннан берсе дип бәяләде.

Ә минә күрәшче әдипне бәяләүдәге икенче чорда, ягъни 1917 елдан соң аңа мөнәсәбәт кискен рәвештә үзгәрә. Биредә аның милли азатлык хәрәкәте тарафдары буларак яңа хакимиятне кабул итмичә колчакчыларга ияреп башта Себергә, аннан чит илгә мөһаҗирлеккә китеп баруы хәлиткеч роль уйнады кебек. Ул совет системасының һәм идеологиясенең килешмәс дошманы итеп каралды һәм шулай булды да. Шунлыктан бу әдип совет шартларында күптөрле мөһерләр сугып тулысынча кире кагылды, аның исемен уңай яктан искә алу да җинаять итеп карала башлады. Хәзер аны тулысынча диярлек иҗтимагый-сәяси планда, совет идеологиясе кысаларында бәяләү китте. Нәтиҗәдә Исхакыйга рәсми әдәби даирәләрдә дә караш кискен үзгәрде. Шушы гомум үзгәреш аерым әдипләр мисалында тагын да тәэсирлерәк булып күренә. Мәсәлән, революциягә кадәр Г. Ибраһимов, Г. Исхакыйның кайбер әсәрләренә шактый тәнкыйтьчел караштa булса да, бу әдипнең татар әдәбиятында тоткан урынын югары бәяләп болай язды: «Әдәбият мәйданында хәзер иң шәүкәт илә вә иң бөек урында карт реалист Гаяз әфәнде тора. Бу мөхтәрәм зат татар әдәбиятына башлап реализмны кертүче иде. Әле һаман да аның мәүкыйгысы (урыны) ялгыз диярлек дәрәҗәдәдер. Без аның хикәяләре кадәр реальный бер әсәргә матбугатыбызда очрый алганыбыз юк әле»[8].

1917 елдан соң исә яңа заман идеологиясенә бирелеп, Г. Ибраһимов та Исхакыйны күбрәк иҗтимагый-сәяси планда бәяләүгә күчә һәм аны башлыча совет дошманы итеп карый, ягъни аңа кире бәя бирә. Әдипнең Исхакыйга һәм революциядән соң мөһаҗирлеккә киткән башка татар язучыларына да шундый үтә тенденциоз карашы аның «Кара маяклар, яки ак әдәбиятлар» дигән хезмәтендә (1924) тулырак чагылды.

Исхакый совет системасының ата дошманы дип игълан ителгән, шунлыктан аны төрлечә гаепләү гадәти хәлгә әверелгән шартларда әдипне моңа кадәр хөрмәт иткән кешеләр дә кайчак аңардан ваз кичәргә мәҗбүр булалар. Моңа гыйбрәтле мисал итеп К. Тинчуринны алырга мөмкин. Революциягә кадәр «Сәйяр» труппасында эшләп, ул Г. Исхакый пьесалары буенча куелган спектакльләрдә катнаша. 1917 елда герман сугышына алыну куркынычы тугач, К. Тинчуринны армиягә алып китүдән коткарып калу өчен Г. Исхакый аны үзе чыгара торган «Ил» газетасы редакциясенә эшкә урнаштыра. Шул вакытларда икесе арасында барлыкка килгән танышлык-дуслыкны күздә тотып һәм, большевикларның милли сәясәте белән килешә алмыйча мөһаҗирлеккә китәргә мәҗбүр булса да, туган иле белән иҗади бәйләнешне сакларга омтылыптыр ахры, 20 еллар башында Г. Исхакый Германиядән К. Тинчуринга хат җибәрә, анда совет татар театрында куярлык пьеса язуын хәбәр итә. Җавап булмауга карамастан, мөһаҗир әдип бераздан әлеге пьесаны төгәлләп ул вакытта Татар дәүләт драма театрының баш режиссеры булган К. Тинчуринга җибәрә. Әлеге пьеса театрда артистлар белән бергә укылып кире кагыла һәм шуннан юкка чыга. Ә инде бераздан Г. Исхакыйдан үзе мөһаҗирлектә чыгарган «Милли юл» журналы да килеп төшкәч, К. Тинчурин аны тизрәк «Кызыл Татарстан» газетасы редакциясенә илтеп бирә һәм язучыларның бер җыелышында бу көтелмәгән күчтәнәчкә үзенең кире мөнәсәбәтен дә белдерә. Ягъни ил-

ле яше тулган көннәрдә (ул 1887 елның 15 сентябрендә туа) К. Тинчурин «халык дошманы» мөһере белән кулга алына. Бер ел да ике айга сузылган тикшерүдән соң К. Тинчуринга җиде пункттан торган гаепләү акты игълан ителә һәм аларның дүртесе Исхакый белән бәйләнгән була. Алар түбәндәгедән гыйбарәт:

1. 1917 елда, вакытлы хөкүмәт дәверендә «Ил» газетасы редакциясендә эшли; контрреволюцион милләтче буржуазия органы булган бу газетаның редакторы Гаяз Исхаков кулы астында коммунистлар партиясенә каршы көрәш җәелдерә.

2. 1918 елда Казанда ак бандаларны куган чакта, алар белән бергә Тәтешкә, аннан соң Самарага Г. Исхаков, З. Вәлиди, Ф. Сәйфи-Казанлы һәм башкалар янына чигенә.

3. Буржуаз милләтче, ак эмигрант Гаяз Исхаков белән хат алыша, аннан ак эмигрантларның «Милли юл» журналын алып тора һәм Советларга каршы көрәштә махсус йөкләмә ала.

4. Япон шпионы Хәсән Исхаков белән бәйләнештә була, аның аркылы театрда куяр өчен Германиядәге Гаяз Исхаковның пьесаларын ала[9].

Һәм шундый нигезсез гаепләүләр нигезендә К. Тинчурин 1938 елның 15 ноябрендә атып үтерелә. Икенче төрле әйткәндә, Исхакый белән кайчандыр таныш булганы өчен генә, бу танышлыктан ваз кичүенә дә карамастан, тоталитар система К. Тинчуринны үлемгә хөкем итә.

Бездә Исхакый иҗаты тулысынча тыелган, аның исеме дә каһәрләп искә алынган дәвердә көрәшче-әдипнең күпкырлы эшчәнлеге чит илләрдә азмы-күпме өйрәнелеп килә. Мисал өчен ул үзе 1951 елда төрек телендә «Гаяз Исхакыйның әдәби әсәрләре библиографиясе»н төзи һәм анда 58 исемдәге әсәрен искә ала. Төркиядә Исхакый мирасын ачыклау, җыю һәм саклау белән озак еллар милләттәшебез М. Таһир шөгыльләнә. Әдипнең дөнья күрә алмаган, кульязма хәлендә калган әсәрләренең, аерым алганда, мөһаҗирлектәге иң күренекле иҗат җимешләреннән берсе булган «Олуг Мөхәммәд» тарихи драмасының сакланып калуында һәм туган иленә кайтуында да без шушы фидакарь шәхескә бурычлыбыз. Мөһаҗирлектә әдипнең күпкырлы эшчәнлеген колачлабрак яктырткан хезмәт «Милли көрәшче һәм милли әдип Гаяз Исхакый» дип атала. Ул Исхакый үлеменнән соң аның истәлегенә багышлап 1955 елда Истанбулда төрек телендә дөнья күрә.

Әдипнең туган илендә исә аны төрлечә каралтып татар дөньясыннан читләштерү, онытылуга дучар итү кампаниясе 80 еллар уртасына кадәр сузыла. Бары шушы унъеллыкның икенче яртысыннан гына СССРда башланган мәгълүм үзгәрешләр тәэсирендә мөһаҗирлектә туган җирен бер күрергә зар булып фани дөньядан китеп барган милләтпәрвәр әдипкә караш үзгәрергә тотына һәм шуннан аңа мөнәсәбәттә өченче чор башлана. Бу эшкә башлап аерым энтузиастлар алыналар. Аерым алганда, И. Нуруллин, Ә. Еники, Р. Мостафин кебек әдип-галимнәр язучылар җыелышларында һәм матбугат битләрендә беренчеләрдән булып Г. Исхакый исемен һәм мирасын кире кайтару мәсьәләсен күтәреп чыгалар. Шул ук вакытта бу бик катлаулы мәсьәләдә аерым энтузиастлар тырышлыгы гына җитмәгәнлеге дә ачыклана. Исхакый турында дөреслекне торгызу хәрәкәтен башлап җибәрүчеләрдән буларак, без бу өлкәдә беренче адымнардан ук мондый эшне оештырырдай һәм җитәкләрдәй бер оешма кирәклеген аңладык. Ул вакытта рәсми даирәләрнең Исхакый кебек шәхесләрне объектив бәяләргә әле әзер булмауларын искә алып, без әлеге максатта бер җәмәгать оешмасы булдыру фикеренә килдек һәм бу хакта төрле инстанцияләргә мөрәҗәгать иттек. Бу идея, аерым алганда, ул елларда Татарстан Министрлар Советы рәисе урынбасары булып эшләгән профессор М. Х. Хәсәновта яклау тапты. Һәм аның тәкъдиме белән 1987 елның 10 ноябрендә СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында «Татар халкының күпгасырлык рухи мирасын туплау, өйрәнү, саклау һәм пропагандалау белән шөгыльләнүче комиссия төзү турында» боерык игълан ителде. Безнең тәкъдим буенча ул комиссия 17 кешедән төзелде һәм аны җитәкләү безгә тапшырылды. Беренче чиратта Г. Исхакый исемен һәм мирасын кире кайтару максатында төзелгән һәм бераздан «Республика рухи мирас комиссиясе» исемен алган бу җәмәгать оешмасының игътибар үзәгендә алга таба да әлеге олуг зат торды. Киң фәнни-мәдәни җәмәгатьчелек катнашында без Комиссиянең Г. Исхакый мәсьәләсенә багышланган берничә

киңәйтелгән утырышын үткәрдек. Аларның һәркайсы үзенә бер фәнни-гамәли конференция төсен алды. Болардан тыш күпгасырлык тарихыбызның һәм мирасыбызның моңа кадәр күтәрелмәгән бик мөһим мәсьәләләренә багышланган дистәдән артык киңәйтелгән утырыш үткәреп, әлеге комиссия ул вакытларда безнең тарихыбызга һәм мирасыбызга мөнәсәбәттә үзгәреш-яңарыш рухын көчәйтеп җибәрде. Шуның белән бергә, мондый оешманың статусын күтәрү кирәклеге дә сизелә барды. Шул максатта без Татар «Мирас» фондын төзедек. Бер үк вакытта халкыбызның күпгасырлык тарихындагы һәм мирасындагы җитди «ак таплар»ны бетерү теләгебез сүздә генә калмасын өчен без Татар «Мирас» фондының үз матбугат органын булдыру фикеренә килдек һәм безнең җитәкчелектә «Мирас» журналы оештырылды, аның башлангыч саны 1991 елның октябрь аенда дөнья күрде. Әйтергә кирәк, башлангыч санны типографиядә бастыруның ГКЧП көннәренә туры килүе чын мәгънәсендә милли рухтагы бу басманың дөнья күрүен зур куркыныч астына куйган иде. Мондый куркыныч тууның төп сәбәпләреннән берсе — әлеге санда Г. Исхакыйның бездәге идеологиягә чит булган һәм моңа кадәр Төркиядә кулъязма хәлендә сакланган «Олуг Мөхәммәд» пьесасы бирелү белән бәйле иде. Мөһим башлангычыбыз харап булмасын өчен җаваплылыкны үз өстебезгә алырга туры килде. Мәгълүм ки, бу матбаганың башлангыч саны ук җәмәгатьчелектә зур кызысыну тудырды. Шуның ачык мисалы — Г. Камал исемендәге театрда яңа журналны җәмәгатьчелеккә тәкъдир итүгә багышланган кичәнең уңыш белән үтүе. Журналның башлангыч саныннан алып бүгенге көнгә кадәр аның игътибар үзәгендә Г. Исхакый мирасы тора. Шунлыктан бу мирасның күпчелек өлеше шушы басмада дөнья күрде. Бу хәзинә белән ныграк таныша бару безне милләтпәрвәр әдипнең максат-хыялларын да ачыграк күзаллауга китерде. Болар алга таба Татар «Мирас» фонды белән «Мирас» журналының максатларына әверелделәр.

Республика рухи мирас комиссиясенең Исхакый мирасын торгызу һәм объектив бәяләү башлангычы тора-бара киң яклау тапты һәм ул фәнни-мәдәни җәмәгатьчелекнең уртак эшенә әверелде. Икенче төрле әйткәндә, бу мирасны торгызу, өйрәнү һәм пропагандалау белән шөгыльләнүчеләр саны артканнан-арта барды. Исхакыйның моңа кадәр укучылар массасына билгесез әсәрләре, аның турындагы чыгышлар матбугат битләрендә дөнья күрделәр, радио-телевидение аша яңгырадылар. Ниһаять, 1991 елда әдипнең «Зиндан» исеме астында ул мөһаҗирлеккә китеп барганнан соң безнең илдә беренче тапкыр сайланма әсәрләре басылып чыкты. Алга таба, 1993 елда Татарстан Министрлар кабинетының Г. Исхакый хәтерен мәңгеләштерү турында махсус карары булды һәм анда төп пунктларның берсе итеп әдип әсәрләренең 15 томлык басмасын әзерләү кертелде, бу басманың академик М. Х. Хәсәнов рәислегендәге Баш редколлегиясе расланды. Хәзер Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында шушы күптомлыкны матбугатка әзерләү буенча эш алып барыла.

Г. Исхакыйның иҗади мирасын җыю һәм бастыру, матбугатта бу шәхескә багышланган күпсанлы һәм күптөрле чыгышлар белән беррәттән, әдипнең күпкырлы эшчәнлеген системалы рәвештә фәнни өйрәнү буенча да эш җәелдерелде. Әдип иҗатының төрле аспектлары буенча дистәдән артык кандидатлык диссертациясе языла (аларның берничәсе якланды да инде). Ә. Сәхаповның «Исхакый һәм XX йөз татар әдәбияты» дигән темага беренче докторлык диссертациясе дә шулай ук уңышлы рәвештә якланды.

Г. Исхакыйның күпкырлы эшчәнлеген киңрәк монографик планда яктырткан фәнни хезмәтләр дә дөнья күрә башлады. Шулар исәбенә Ә. Сәхаповның «Исхакый иҗаты» (1997) һәм «Исхакый һәм XX гасыр татар әдәбияты» (1998), Ф. Мусинның «Гаяз Исхакый. Тормышы һәм эшчәнлеге» (1998), «Гаяз Исхакыйның революциягә кадәрге иҗаты» (1999), Х. Миңнегуловның «Исхакый мөһаҗирлектә» (1999) дигән хезмәтләрен кертергә була.

Шул ук вакытта көрәшче әдип эшчәнлеген һәм мирасын торгызу һәм өйрәнүнең хәзер киң фәнни-әдәби җәмәгатьчелек эшенә әверелүен дә әйтергә кирәк. Бу эш белән шөгыльләнүчеләр географиясен һәм санын ачыклау ягыннан 1998 елда әдипнең 120 еллыгына багышлап «Гаяз Исхакый һәм татар дөньясы» дигән темага (бу исем безнең «Шәһри Казан»ның 1998 ел 9 январь санында басылган мәкаләбездән алынган иде) үткәрелгән халыкара фәнни-гамәли конферен-

ция игътибарга лаеклы. Анда Төркиядән, Башкортстаннан, Казанның төрле фәнни оешмаларыннан һәм югары уку йортларыннан 40 тан артык фән докторы, фән кандидаты һәм аспирантлар докладлар белән чыгыш ясаганнар иде. Исхакый мирасын кабат бастырып чыгару һәм фәнни өйрәнү белән күпләр гомуммилли әһәмиятле эшкә үз өлешләрен кертү ниятеннән чыгып шөгыльләнгән бер вакытта, кызганычка каршы, бу эшкә гүя монополиягә омтылып, үзләренә мораль һәм матди капитал тупларга теләп алынучылар һәм шунлыктан Исхакый мирасын кайтару мәсьәләсендә ыгы-зыгы тудыручылар да табылды бугай. Бу бик күңелсез хәлнең ничек башланганын профессор И. Нуруллин «Үзенә лаеклы булып кайтсын иде» дигән мәкаләсендә («Социалистик Татарстан», 1991 ел, 6 март) күрсәткән иде. Анда шул вакытта Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында Гыйльми совет карары белән Г. Исхакый әсәрләре күптомлыгының план-проспекты, редколлегиясе раслануы, бу эшне башкару институтның кульъязмалар һәм текстология бүлегенә тапшырылуы турында белдергәннән соң И. Нуруллин алга таба болай яза: «Лена ханым Гайнанованың язмасыннан аңлашылганча (сүз Л. Гайнанованың «Шәһри Казан»ның 1991 ел, 30 январь санында бирелгән «Сикәлтәләр аша» дигән язмасы турында бара.— Ф. М.), ул Гыйльми совет карарын да, совет раслаган коллективны да бар дип тә белми. Фәнни редакторы филология фәннәре докторы М. Х. Хәсәнов, урынбасарлары шулай ук докторлар Нил Юзиев һәм Ибраһим Нуруллин булган редколлегияне, Ф. Әмирхан һәм Г. Камал кебек классикларның гыйльми басмаларын чыгарып тәҗрибә туплаган һәм төп эше шушы булган бөтен бер бүлекне Г. Исхакыйга якын да җибәрмичә, бер үзе чыгармакчы була». Шундый зур һәм мәртәбәле гыйльми коллективны кире кагып, әлеге басманы чыгаруда кичәге лаборантка өстенлек бирелсә, бу хәлнең нинди нәтиҗәгә китерәсен И. Нуруллин болай фаразлый: «Яки тиешле таләпләргә җавап бирмәгәнлеге ачылып китеп, кире кагылачак, яки... биш томы әштер-өштер китереп чыгарылачак. Ул чагында инде чын мәгънәсендәге гыйльми басмасын тагын 15—20 елга кичектерми булмый». Ә мондый гыйльми басманы, И. Нуруллин фикеренчә, иң яхшы белгечләрдән тора торган зур коллектив кына башкарып чыга ала. «Үзенә лаеклы булып кайтсын иде» мәкаләсе чыкканнан соң үткән вакыт Исхакыйны яхшы белгән күренекле галимебезнең әлеге фаразлары, кызганычка каршы, нигездә аклануын күрсәтә. Аерым алганда, Исхакый күптомлыгының шәхси-үзешчән рухта әзерләнеп, гомум кабул ителгән процедураны үтмичә, ягъни бүлек һәм Гыйльми совет утырышларында каралмыйча төрле оешмалар исеменнән чыгарыла башлаган беренче томнары әле белгечләрнең уңай бәясен ала алганнары юк. Киресенчә, белгечләр аларда Исхакый текстларын дөрес укый һәм аңлый алмаудан туган күңелсез хаталар табалар. Мәсәлән, Г. Исхакый әсәрләрен текстологик яктан өйрәнү белән актив шөгыльләнгән һәм бу өлкәдә зур тәҗрибә туплаган профессор Р. Ганиева, беренче томга кертелгән «Тәгаллемдә сәгадәт...» хикәясен оригинал белән чагыштырып карагач, аны матбугатка әзерләгәндә Л. Гайнанова тарафыннан «күп мәгънәви хаталар һәм төгәлсезлекләр җибәрелгәнен» ачыклый. Мондый хаталарның кайчак бик җитди мәгънәви ялгышларга китерүенә гыйбрәтле мисал итеп танылган галимә Л. Гайнанованың хикәядәге «комари» сүзен дөрес укый алмавын күрсәтә. Шушы бер сүзне дөрес укымау «Тәгаллемдә сәгадәт...»нең беренче томга кертелгән вариантында Исхакыйның бөтен яшәве һәм эшчәнлегенең төп максатын кире кага торган нәтиҗәгә китергән.

«Тәгаллемдә сәгадәт...» хикәясенең беренче томдагы вариантында гына да профессор Р. Ганиева очраткан күпсанлы текстологик һәм мәгънәви хаталар (ул әлеге текстны төзәтә-төзәтә гомумән чуарлап бетергән иде), тулаем алганда, Л. Гайнанова исеменнән дөньяга чыгарып килгән торган биштомлыкның, ягъни күптән зарыгып көтелгән гомуммилли әһәмиятле басманың исеме җисеменә туры килмәячәген искәртмиләр, аның дәрәҗәсен төшермиләр микән? Булачак унбиштомлыкның Г. Исхакыйның әдәби иҗатын колачлаган томнарын текстологик яктан бер үзе һәм, гүя И. Нуруллин әйткәнчә әзерләсә дә, әлеге иптәш икенче бер өлкәдә үзен бермә-бер активрак күрсәтүен дәвам итә икән. Бу уңайдан Исхакый тирәсендәге күңелсез ыгы-зыгы тарихын яхшы белгән доцент Р. Нуруллина болай яза: «Ибраһимның мәкаләсе (И. Нуруллинның алда телгә алынган мәкаләсе күздә тотыла.— Ф. М.)... басылып чыгуга да дистәгә якын ел узган, ә бәхәс, шау-шу һаман шул яссылыкта бара: Лена Гайнанова Гаяз Исхакый мирасына монополия

даулый. Имеш, ул бөек язучының исемен илгә кайтаруда хәлиткеч роль уйнаган да, аның мирасына ул гына хуҗа, ул гына аның белән эш итәргә хаклы»[10]. Р. Нуруллина бу бөек мирасны «галимлектән ераграк» торган кешеләрдән бигрәк «аны чын мәгънәсен аңлый торган чын галимнәр ихтыярына тапшыру лазем» булуын белдерә. Әлеге мирасны кайтару тарихы үзе бу фикернең хаклыгын раслый кебек һәм, Исхакый әсәрләренең Л. Гайнанова исеменнән әзерләнә торган томнарын бераздан башка белгечләрдән сыйфатлырак итеп эшләтеп кабаттан чыгару мәсьәләсен көн тәртибенә куярга кирәк булырга мөмкин. Шул чакта гына бу мирасны халыкка үзенең асыл мәгънәсендә кайтаруга ирешеп булыр кебек.

Тагын да зуррак мәсьәләгә — Г. Исхакыйның күптөрле эшчәнлеген һәм мирасын фәнни өйрәнүгә килсәк, бу эш белән чын фәнни мәнфәгатьләрне алга куйган белгечләр шөгыльләнү сәбәпле, анда, бәхеткә каршы, югарыда искә алынган күңелсез хәлләр күзәтелми. Чөнки биредә монополия даулаучылар юк, һәркем үзе теләгәнчә һәм булдыра алганча эшли. Шулай да бу өлкәдә дә әле эшләнгәннәрдән эшлисе эшләр күбрәк. Әлеге мирасны фактик яктан тулырак яктырту белән бергә, аны хәзер фәнни-теоретик планда өйрәнүгә игътибарны арттыру сорала. Биредә минем бу мирастагы татар дөньясында хәзерге милли яңарыш хәрәкәте шартларында актуаль төс һәм киң яңгыраш ала торган кайбер мәсьәләләргә тукталасым килә.

Алдарак әйтелгәнчә, XIX һәм XX йөзләр аралыгында татарлар арасында күзәтелгән әлеге хәрәкәттә мәгариф белән мәдәнияткә аеруча зур игътибар бирелгән иде. Шушы хакыйкатьне шәкерт елларыннан ук аңлаган Исхакый үзенең милләткә хезмәт итүен параллель рәвештә мәгариф белән әдәбият өлкәләрендә башлый һәм аларны үзара тыгыз бәйләнештә карый. Яшь Гаязның милли яңарыш хәрәкәтендә беренче планга куелган мәгариф өлкәсендәге эшчәнлегенә килсәк, ул мөгаллимлек итүен, инде әйтелгәнчә, Әмирхан мәдрәсәсендә җәдитчә укытудан башлый. Аның бу башлангычы хәтта рус матбугатының да игътибарын җәлеп итә. Мисал өчен «Казанский телеграф» газетасында бу уңайдан болай языла: «Күптән түгел Яңа бистәдә татар балалары өчен Әмирхан мәдрәсәсе ачылды. Яңа мәдрәсә тиз арада җирле мөселманнарның игътибарын җәлеп итте, аңа беренче атнада ук җитмеш укучы җыелды. Бу хәл укытучы Гаяз Исхакый җәнабләренең грамотага өйрәтүдә яңа аваз методын кертүе белән аңлатылса кирәк, юкса безнең мәдрәсәләрдә һаман да иске, тапталган хәреф методы яшәвен дәвам итә. Исхакый җәнабләре бу башланган эшен киләчәктә тагын да киңәйтсен һәм бер нәрсә алдында да тукталып калмасын иде»[11].

Мәдрәсәдә укыткан вакытта язылган программ характердагы беренче күләмле әсәре — «Ике йөз елдан соң инкыйраз»да (1902) милләт язмышын иң әүвәл мәгариф эше белән бәйләп карап, Г. Исхакый беренчеләрдән булып мәктәп-мәдрәсәләрнең үткәндәге шәкертләргә гомуми характердагы традицион дини-әхлакый аң-белем һәм тәрбия бирүләреннән шактый аерылган милли вазифасы мәсьәләсен күтәрә. Бу вазифаны ул мәгарифнең яшь буынга милли аң-белем һәм тәрбия бирергә тиешлегендә күрә һәм моңа ирешүнең төп чараларыннан берсе итеп мәктәп-мәдрәсәләрдә татар әдәбиятын укытуны саный. «Тукай мәктәптә» дигән мәкаләсендә (1914) ул бу уңайдан программ мәгънәдә болай яза: «Безнең яңа борынлап килә торган яшь буыныбызны үстерер өчен дә, яшь буыныбызны үзебез теләгән рәвештә тәрбия итәр өчен дә, яшь балаларга киләчәктә тарихи вакыйгаларны үтәрлек иттереп олыгайтыр өчен дә мәктәпләребездә әдәбиятка әһәмият бирергә мәҗбүрбез. Әдәбият аркасында без балаларыбызның күңелләрен нечкәртәбез, әдәбият аркасында балаларны уйларга, төшенергә, кеше хәлен, кеше кайгысын үз кайгысы иттереп уйлатырга өйрәтәбез, әдәбият аркасында балада тәнкыйть хисен үткерлибез, чарлыйбыз, әдәбият аркасында баланың күңелендәге матурлыкка маилне куәтләндерәбез, ул гына да түгел, әдәбият ашасыннан, милли әдәбият ашасыннан балага үз рухыбызны, милли рухыбызны сеңдерәбез, кабер ташына кадәр андан купмаслык иттереп аның күңеленә милли рухның иң кирәкләрен кадаклыйбыз, аны мәңгегә татар итеп куябыз»[12]. «Яңа әдәбият» дигән хрестоматияләрендә (1914) Г. Ибраһимов белән Г. Баттал да, мәгарифнең миллилеге турында сүз алып барганда, «үз әдәбияты мөкәммәл рәвештә укылмаган бер мәктәп, мәдрәсәнең милли мәктәп дип аталырлык хакы юклыгы — фәлән тугрысында сөйләп торырга да лязем кирәкми»[13],— дип язалар.

Мәктәп-мәдрәсәләрнең шулай беренче чиратта туган әдәбиятың ярдәмендә яшьләргә милли тәрбия бирергә тиешлекләрен раслау белән бергә, Исхакый һәм аның фикердәш-замандашлары әлеге тәрбиянең асылын һәм максатын билгеләүгә дә игътибар итәләр һәм бу мәсьәләгә төрле яклап ачыклык кертәләр. Шул ук Г. Ибраһимов, мәсьәләгә күбрәк шәхси-интеллектуаль яктан килеп, «Тәрбиядә хөррият вә шәхсыять нигезләре» дигән мәкаләсендә (1914), мәсәлән, милли тәрбиянең нигезендә яшьләрдә «шәхси тапкырлыкка, тәвәккәллеккә, инициативага сәләтлелек, омтылыш һәм ихтыяр көчләрен үстерү»[14] торырга тиешлеген күрсәтә. Икенче төрле әйткәндә, ул яшь буында халкыбыз табигатенә һәм яшәү рәвешенә күптәннән хас булган асыл сыйфатларны тәрбияләүне күздә тота. Г. Исхакый исә, гадәтенчә, мәсьәләгә гомуммилли планда карап, «Яшь көчләрнең бурычы» исемле мәкаләсендә (1916) әлеге тәрбиянең асылын һәм максатын беренче чиратта «милли хәйәтнең төрле мәсьәләләре хакында баланың башындагы сөальләргә милли рухта җавап»[15] бирүдә күрә. Ягъни ул «милли тәрбия» дигәндә яшьләргә милләт яшәеше турында милли рухтагы мәгълүмат һәм җавап бирүне күзаллый.

Иң әүвәл Исхакый күтәргән мәсьәләгә — мәгарифнең милли вазифасын тормышка ашыруда әдәбиятка зур өмет баглап, XX йөз башында мәктәп-мәдрәсәләр өчен татар әдәбияты буенча дәреслек-хрестоматияләр чыгарыла башлый. Бу юлда беренче адымнар булган Г. Тукайның «Мәктәптә милли әдәбият дәресләре» (1910), Г. Сәгъдинең «Әдәбият мөгаллиме» (1913), Г. Ибраһимов һәм Г. Батталның «Яңа әдәбият» (1914) хрестоматияләрен бер момент үзара якынайта, ягъни аларда Г. Исхакый әсәрләре үзәккә куела. Бирердә, күрәсең, үзе мөгаллим булган әдипнең иҗатында да милли мәгариф ихтыяҗларын канәгатьләндерергә омтылуы, бигрәк тә аның үз әсәрләрендә әдәбият яшь буын «күңеле омтылган бөтен мәсьәләләргә җавап табар дәрәҗәдә бай булырга тиеш»[16] дигән таләбен канәгатьләндерергә теләве билгеле бер роль уйнагандыр.

Кыскасы, XX йөз башында татар мәгарифенең Исхакый инициативасы белән күпмедер дәрәҗәдә әдәбиятыбыз ярдәмендә дә милли идея байрагы астында миллиләшүе мәктәп-мәдрәсәләрдә милли рухлы шәкертләр тәрбияләнүенә булыша. Нәтиҗәдә шәкертләр арасыннан милләткә хезмәт итәргә әзерләнгән күпсанлы шәхесләр чыга һәм алар алга таба татарның күренекле милләтпәрвәр кешеләренә — җәмәгать һәм сәяси, фән һәм әдәбият-сәнгать, мәгариф эшлеклеләренә әвереләләр. Мәсәлән, Казандагы «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә генә дә Х. Ямашев, М. Дулат-Али, Г. Камал, Ф. Әмирхан, М. Гафури, Ф. Бурнаш, К. Тинчурин, З. Бәшири, Г. Шәрәф, Х. Бәдигый, Г. Рәхим, Г. Газиз, С. Вахиди, С. Сәйдәшев, С. Габәши, Б. Урманче кебек шәхесләр укый. Шундый затларны тәрбияләве белән дә узган гасыр башындагы татар мәгарифе аның алдына Г. Исхакый, Г. Тукай, Г. Ибраһимов һәм башкалар куйган бурычларны үти алды дип әйтергә мөмкин. Әйтергә кирәк, яшь буынга милли аң-белем һәм тәрбия бирүдә үткәндәге мәктәп-мәдрәсәләр туплаган тәҗрибә бүген дә игътибарга лаеклы, ул хәзер милли мәгарифне үстерүдә актив файдаланылырга тиеш. Шул тәкъдирдә генә хәзерге мәгариф милли яңарыш хәрәкәтендә үткәндәгечә нәтиҗәле катнаша һәм үзенең гомуммилли әһәмиятле вазифасын уңышлы башкара алачак.

Милли яңарыш хәрәкәтендә икенче әйдәп баручы көч итеп Г. Исхакый, әлбәттә, әдәбиятны санады һәм бөтен аңлы гомерен байтак дәрәҗәдә әдәби иҗатка багышлады. Хезмәт юлын мөгаллим-тәрбияче эшеннән башлап, ул, табигый, әдәбиятның зур тәрбияви көчкә ия булуын аңлап иҗат итте. Шунлыктан аның әсәрләрендә гадәттә милләтне саклауга яки аңа файдалы булуга, хезмәт итүгә кагылышлы мәсьәләләр күтәрелә. Аларны яктыртуда билгеле бер эволюция дә күзәтелә. Беренче әсәрләрендә («Тәгаллемдә сәгадәт...» тә һәм «Кәләпүшче кыз»да) мөгаллим Исхакый үзәккә яшь буынны тәрбияләү мәсьәләсен куя. «Тәгаллемдә сәгадәт...»тә әлеге мәсьәлә яшьләргә белем бирү аша аларны халыкка, милләткә кирәкле һәм файдалы кешеләр итеп тәрбияләү рәвешендә хәл ителә. Үзәк герой Хәлимнең этисе Габдрахман каршылыгын җиңеп мәдрәсәгә укырга керүенең, анда тырышып укып күп белемле кешегә әверелүенең сәбәбен автор хәтта Аллаһе Тәгаләнең бу шәкерткә әлеге белемнәрне үзе өчен генә түгел, бәлки кавемен, ягъни туган халкын аң-белемле итү өчен дә бирүе белән бәйләп аңлата. Икенче төрле әйткәндә, Хәлимнең мәдрәсәдә алган белемнәрен халыкка хезмәт итүгә багышлавы, аны алга җибәрүгә сарыф итүе Ходай үзе хуплаган изге гамәл дип бәяләнә.

Әгәр Хәлим образында аң-белемле булуы милләт өчен табышка әверелгән яшь кеше күрсәтелсә, «Кәләпүшче кыз»да исә тормышта белемлелектән ерак торган юлга кереп киткән Камәрнең ачы язмышы милли югалту рәвешен ала. Шунлыктан автор үзенең героинясы фаҗигасенә киң яңгыраш та бирә. Повестьның хатимәсендә, ягъни эпилогында ул фахишәгә әверелеп вакытсыз дөньядан киткән Камәр фаҗигасенең күпләр өчен гыйбрәтле һәм сабак алырлык булуына басым ясый. Һәм мондый нәтиҗәгә килә: «Камәрнең бу дәрәҗәдә бөтен галәме инсанияттә мәнфур (җирәнгеч) улып, мөселманлыкка һич ярамаган хәлләрдә булуы өчен һәр мөселман еглап кына калмаенча, шул начарлыктан милләтемезнең башка кызларыны сакламак өчен һәркем кулыннан килгән куәтне сарыф кылмак тиеш, бәлки лаземдер». Камәр язмышына әдипнең шулай киң яңгыраш бирүенең, бу мәсьәләдә милләттәшләрен чаң сугып уятырга теләвенең сәбәбе аның бу героиня хәлендә калган хатын-кызларны татарлар арасында аеруча күп күрүе, «бөтен дөнья мөселманнары арасында сатлык кызлар тәрбия кылу безнең Казан халкында гына чыкмыштыр вә бу вакытка кадәр дә шул халыкта гынадыр» дип уйлавы белән бәйләнгән. Шуннан автор татар кызларын Камәр фаҗигасеннән саклау — милләтнең, аның җан сакчысы булган зыялыларның изге бурычы дигән нәтиҗәгә килә.

Й. Акчура әйткәнчә, милләтнең «иң агулы бер чуанын» ачып салган «Кәләпүшче кыз» повестеның дөньяга чыгуы татар әдәбиятында вакыйгага әверелә. Бу әсәрнең әһәмиятен билгеләп, Н. Гасрый, мәсәлән, 1910 елда болай язды: «Бу хикәя чыгар-чыкмас, хаклы рәвештә, татар әдәбиятында мөһим бер вакыйга буларак кабул ителә. Яшь әдәбият куәтләнә... «Кәләпүшче кыз» мөхәррире белән яңа әдәбиятка яңа бер көч килеп керүе беленде»[17]

Бер үк вакытта «Кәләпүшче кыз» Г. Исхакыйның киләчәк иҗат йөзен билгеләгән әсәргә дә әверелә. Чөнки алга таба ул иҗатында татар дөньясында милләт яшәешенә һәм язмышына куркыныч янаган, зыян китергән «чуанлы» күренешләргә игътибарын арттыра. Мондый «авыру» күренешләрне ачып, автор милләт тормышын сәламәтләндерергә тели. Моны «Кәләпүшче кыз»дан соң язылган «Бай угълы» повестенда да ачык тоярга мөмкин. Ул полемик рухта язылган. Анда яшь автор милләтнең авыру якларын яшерергә, аны бары матур яктан гына күрсәтергә тырышучы ялган «патриотлар» белән бәхәскә керә. Бу бәхәс повестьның 1903 елгы беренче басмасына кереш сүздә ачык сизелә. Анда «үземезнең милләтнең гаебене башка кешеләргә күрсәтүдән ничек оялмыйсың?» — дип гаеп ташлаучыларга Г. Исхакый үзенең иҗат кредосы рәвешендәрәк болай җавап бирә: «Минем бу эшем, милләттәшләрем арасында бик күп вакыйгъ була (очрый) торган мөдһиш (куркыныч) бер хәлне язып мәйданга куюым, башка кешеләргә үз гаебемезне белдерер өчен түгелдер, кирәк бер кешенең булсын, кирәк бер милләтнең булсын, бар гаебене юк итеп күрсәтү яки яшерергә тырышу хаер хаһлык түгелдер. Чөнки бу эш шул кешенең яки шул милләтнең шул начар хәлендә дәвам итүене теләү буладыр. Билгакес (киресенчә), гаебене күрсәтеп, шуннан котылыр өчен юл күрсәтү хаер хаһлыктыр. Милләтемездә шул мәсьәләне ислях фикере уянмасмы дип, мин шул эшләремезне булдыра алдыгым кадәр күрсәтмәк эстәдем.

Җәнабе хак (Алла) һәрберемезгә хак фикерләр биреп, хәмияте миллиямезне (милләтне саклау хисен) уяндырып, ватанымыз, милләтемезнең файдасына тырышырга насыйп итсен![18]»

Әсәрдә татар дөньясындагы авыру күренешләрнең берсе рәвешендә автор кайбер яшьләргә дөрес тәрбия бирелмәүне ала һәм үзәк герой Кәрим образында бу хәлнең кешене нинди фаҗигагә китерүен күрсәтә. Ата-анасының битарафлыгы аркасында урам «тәрбиясенә» юлыккан Кәрим тормышта бозык юлга кереп китә һәм эчүчелеккә бирелеп вакытсыз дөньядан да китеп бара. Әсәрдә Кәрим үлеменә икенче бер яңгыраш та бирелә. Аның дөньядан китүен автор хәятның кайбер кирәксез күренешләрдән арынып, ничектер чистарып, сафланып калуы төсендәрәк тә бәяли кебек.

Әле генә каралган һәр ике әсәрдә уртак бер мотив яңгырый, ягъни аларда милләтнең киләчәге булган яшь буынның язмышын билгеләүдә гаилә тәрбиясенә зур әһәмият бирелә. Шунлыктан яшь Гаязны бер үк вакытта татар гаиләсендәге хәлләр дә кызыксындыра. Биредә дә ул игътибарын гаилә тормышындагы күңелсез хәлләргә, аны эчтән көчсезләндерә, тарката торган күренешләргә юнәлтә. Үзе-

нең драматургия өлкәсендәге беренче тәҗрибәсе — «Өч хатын берлән тормыш» пьесасында автор тарафыннан татар гаиләсенә зур зыян китерә дип уйланылган күпхатынлылык мәсьәләсе үзәккә куела. Әсәрнең үзәк герое Кәрим язмышы аша күпхатынлылыкның кешене фаҗигале язмышка дучар итүе чагылдырыла. Күпхатынлылыкны яклаган һәм шуны тормышка ашырырга алынган Кәрим ахыр чиктә хатыннарын да, үзен дә бәхетсез итә һәм вакытсыз дөньядан да китеп бара. Ә менә автор идеалы булып торган Риза, киресенчә, бердәнбер яраткан хатыны белән матур гаилә кора һәм тормышта бөтен теләкләренә ирешә. Героеның тормыштагы мондый казанышларын автор, әлбәттә, аның тиешле гаилә тәрбиясе алуы белән бәйләп аңлата.

Аерым шәхесләрнең генә түгел, бөтен милләт язмышы турында уйланганда да Г. Исхакый алгы планга аң-белем һәм тәрбия мәсьәләсен куя. Татар язмышы мәсьәләсен киң планда һәм аеруча кискен итеп күтәргән программ характердагы «Ике йөз елдан соң инкыйраз» әсәрендә, мәсәлән, ул милли инкыйразга бару сәбәпләрен күбрәк мәгариф белән бәйләп аңлата. Аны бигрәк тә мәктәп-мәдрәсәләрдә уку-укытуның торышы борчый. Татарда бу эшнең һич тә канәгатьләнерлек булмавын ачынып күрсәтү белән бергә, милләт яшәеше һәм язмышы өчен үтә мөһим дип исәпләнгән әлеге шөгыльнең, аның уенча, аянычлы хәлдә булуының төп сәбәпчеләре итеп ишан-муллаларны карый. Аларның белем ягы бик чамалы булуын күрсәтә. Әйтик, Әфләтун (Платон) фәлсәфәсен, Аристотель логикасын белмәү-аңламау аркасында, алар бу гыйлемнәрне шәкертләргә дә төшендерә алмыйлар. Алай гына түгел, алар еш кына аң-белем бирү өлкәсендә һәртөрле яңалыкны кире кагалар, шәкертләрне заманча укытуга каршы чыгалар. Милләтне саклап калу һәм алга җибәрү өчен беренче чиратта аның мәгариф системасын яңартырга кирәклегенә басым ясап, автор мондый яңарышка ирешүдә һәм яшьләргә заманча, төпле аң-белем бирүдә төп юлны рус мәктәпләрендә укуда күрә: «Милләтемезне инкыйраздан коткарасымыз килсә, мотлакан, рус мәктәпләрендә укырга тиеш!» Милли мәгарифне үстерү мәсьәләсендә яшь Исхакыйның шушы рәвешле фикер йөртүе аның ул вакытта Татарская учительская школада укуының йогынтысы белән дә бәйләнгән булгандыр, күрәсең.

Инкыйразга дучар ителгән дип уйланылган татарны саклап калуда һәм яшәтүдә Г. Исхакый тагын милли әдәбиятка зур өметләр баглый. Аныңча, «әдәбиятсыз милләтемезнең тәрәккъые мөмкин түгеллеге беленсә дә, илтифатка алынмастыр».

Татарларның милләт буларак яшәвендә Г. Исхакый әдәбият белән бергә сәнгатьнең башка төрләренә дә зур гына урын бирә. Шул сәбәпле, аны, аерым алганда, татарда музыканың миллилеген югалта һәм аның халык арасында әһәмияте бетә баруы борчый. Икенче бер очракта әдип ишан-муллаларның рәсем сәнгатенә кире караштa булулары аркасында, халыкның сәнгатьнең бу төренә мөнәсәбәте үзгәрүе, бу хәлнең бездә рәсем сәнгатен юкка чыгуга китерү мөмкинлеге турында борчыла.

Программ характердагы әсәр булгач, Г. Исхакый анда татар милләте яшәешенә һәм язмышына кагылышлы башка мәсьәләләрне дә күтәрә. Алга таба исә әлеге мәсьәләләрне әсәрләрендә аерым-аерым карый башлый. Мәсәлән, «Ике йөз елдан соң инкыйраз»дан соң язылган «Теләнче кызы» романында ул кабат шундый мәсьәләләрнең берсе булган хатын-кыз язмышына әйләнеп кайта, әмма аны хәзер «Кәләпүшче кыз» дагыдан аермалырак рәвештә яктырта. Баштарак Камәр кебек үк фәхешлек юлына көчләп бастырылса да, роман героинясы Сәгадәт бераздан әлеге афәттән котылырга үзендә көч таба һәм аң-белем белән бәйле башка юл сайлый: Казандагы кызлар гимназиясендә тырышып укып имтихан тота һәм аны бетерү турында шәһадәтнамә алуга ирешә. Моннан соң ул «тәмам ялгыз көченә, үз көченә таянып алга таба барырга тели торган бер татар хатыны»на әверелә. Сәгадәтнең дөньяга карашларындагы һәм яшәү рәвешендәге мондый үзгәрешне әдип, беренче чиратта, аның белемгә омтылуы белән бәйләп карый. Әсәр ахырында героиняның тагын да зуррак белем алырга теләп Петербургка китүе автор һәм аның фикердәш геройлары тарафыннан югары бәяләнә. Чөнки алар Сәгадәткә мәгърифәтчеләрнең күптәнге хыялларын тормышка ашырырга алынган татар хатыны итеп карыйлар. Сүз монда аң-белем алып халыкка хезмәт итү юлына баскан татар хатын-кызы идеалы турында бара. Шушы идеалны аңлау һәм аны

гамәлгә ашырырга алыну героиняның үзенә дә нык тәэсир итә. Моңа кадәр гаиләдә иренең көнчелен күрүче итебрәк сизгән Сәгадәт хәзер үзен киңрәк тормышта башка күпләргә иптәш булырлык кеше итеп тоя башлый. Күңелендәге һәм тормышындагы мондый үзгәрешләр турында ул үзен вокзалга Петербургка озатырга килүчеләрдән берсенә болай ди: «Беләмсез, Мансур әфәнде, мин хәзер үземне яңа анадан туган кебек хис итәм, әллә нинди күңелгә җиңел кебек, хәзер очам кебек торам, эчтә әллә никадәр көч, гайрәт сизәм. Аннан тагы, менә элгәре сез безгә барганда минем берлә күрешкәндә миңа иптәш дип карамый идеңез, бикә дисәк, бикә түгел, әллә нәрсә инде дип карый идеңез, ул эш мине хурландыра иде. Хәзер менә сезнең барыңызның да дуст, иптәш итеп каравыңызны күзеңездән күрәм, шуның өчен шатланам».

Милли уяну һәм яңарыш хәрәкәтенең күркәм бер нәтиҗәсе итеп бәяләнгән күренешне — белем алу ярдәмендә милләт хадимәсе булырга җыенган хатын-кыз образын тудыру белән бергә, Г. Исхакый алга таба шундый вазифаны башкарырга тиешле шәхесләрнең, беренче чиратта мәгариф кешеләренең төрле язмышлары белән кызыксына. Аерым алганда, «Мөгаллим» һәм «Мөгаллимә» пьесаларында шундый ике төрле язмыш күз алдына бастырыла. Беренче пьесадагы Салих образында башта яшәү максатын мәгърифәт ярдәмендә халыкка хезмәт итүдә күргән һәм шул максатта авыл балаларын җәдитчә укыта башлаган мөгаллимнең соңрак көндәлек тормыш ыгы-зыгысына чумып әүвәлге идеалларын онытуы, ә ахырдан шәкерт елларындагы иптәше Фазыл йогынтысында үз хатасын аңлавы чагылдырыла. Шул ук вакытта биредә бишенче елгы революция елларында «иттифакчылар» белән «таңчылар» арасында барлыкка килгән идея аерымлыгы да сизелә. Башта «иттифакчылар» позициясен яклаган, ягъни милләткә хезмәт итүнең мәгърифәтчел юлын сайлаган Салих, «таңчылар» рупорын хәтерләткән Фазыл тәэсирендә әлеге мәгърифәтчел идеалы белән генә канәгатьләнмичә, башка, күрәсең, Исхакыйның яңа омтылышлары рухындагы хыялларына бирелеп, пьеса ахырында каядыр китеп бара. «Мөгаллимә»дәге Фатыйма исә иҗтимагый тормыш белән шәхси яшәеш арасында барлыкка килгән каршылыкка очрый. Иҗтимагый планда, ягъни Ерак Себердәге бер шәһәргә барып чыгып, ул андагы милләттәшләрен аң-белемле итү юлында зур эш башкара һәм моңардан канәгатьләнү ала. Ә менә шәхси тормышында героиня бәхетсезлеккә очрый. Эш шунда: Себердәге мәктәпкә килгәч аңа мөгаллим Габдулла гашыйк була һәм Аллага табынгандай табына башлый. Кыз исә яшь мөгаллимнең бу илаһи мәхәббәтен кабул итә алмый, чөнки ул Казан ягында калган егете тарафыннан кире кагылган мәхәббәте утында яна, аңардан башка кешене ярата алуны күз алдына да китерми.

Мәгариф эшен милләтне саклап калуда, яңартуда һәм үстерүдә иң мөһим чараларның берсе дип карап аңа бик зур өметләр баглаганына күрә, Г. Исхакый бу гомуммилли әһәмиятле мәсьәләгә үз иҗатында кабат-кабат әйләнеп кайта һәм аны төрле яклап яктырта. «Тормышмы бу?» һәм «Мулла бабай» романнарында ул тагын бер мөһим аспектта карала. Төп идея проблематикасы буенча бер-берсеннән шактый аерылган бу ике әсәрне шул ук вакытта мәгариф эшенә мөнәсәбәтле бер мәсьәлә үзара якынайта. Ул мәсьәлә мәктәп-мәдрәсәләрдә укытуның сыйфатына, аларны бетереп чыгучыларның аң-белем дәрәҗәсенә карый. Мәдрәсәләрдә укытутәрбия эшенең торышына үтә тәнкыйтьчел карап, әлеге әсәрләренең үзәк геройлары — «Тормышмы бу?»ның исемсез лирик герое белән «Мулла бабай»дагы Хәлим образларында автор мәдрәсәләрдә шәкертләргә алга таба тормышта нык терәк булырлык төпле белем бирелмәвенә басым ясала. Бу хәл геройларның киләчәк язмышына шактый күңелсез йогынты ясый. «Тормышмы бу?»ның герое алга таба дөньяга төпле карашы, яшәвенә мәгънә бирерлек һөнәре һәм олы максаты булмаган, «ат та түгел, ишәк тә түгел» бер җан иясенә әверелә. Шунлыктан авылга кайтып мулла булгач, аның яшәвенең мәгънәсе һәм асылы хезмәтчесенең хатыны һәм күрше килене белән качып-посып үзенең ирлек теләген канәгатьләндерүгә, күршеләре белән бер йомырка, бер тубал кибәк, бер кочак салам, биш-алты кисәк утын өчен сугышып, судлашып көн итүгә кайтып кала. Шушы рәвешле гомер кичерүен чагылдырган көндәлекләре белән олыгая төшкәч кабат танышу герой күңелендә: «Шулмы гомер? Тормышмы бу?» — дигән сорау тудыра. Әлбәттә, әсәрдә аңа уңай җавап бирелә алмый. Киресенчә, бу роман анда

сурәтләнгәннәрдән гыйбрәт алу, укучыларын гомум идеаллар һәм гамәлләр белән яшәргә чакыру максатында язылган кебек тәэсир кала.

«Мулла бабай»дагы Хәлимне автор мәдрәсәдә шулай ук төрле фәннәр буенча аз-маз гына мәгълүмат алган, аларның берсен дә рәтләп белмәгән кеше итеп күрсәтә. Әмма яңа роман герое хәзер шул аз-маз белгәненнән канәгать. Ул күбрәк икенче нәрсә — «шул мәгълүмат, шул рухани азык белән бер авылны, бер мәхәлләне агартырга хәзерләнә, берничә мең кешегә үрнәкче булырга уйлый иде. Шул халыкны үзе кеби үк итә алмаса да, үзе кебирәк уйларга өйрәтергә, үзе кебирәк күздән дөньяга вә ахирәткә карарга өйрәтергә хәзерләнә вә шул өйрәтүдә чынында әллә никадәр файда, әллә нинди зур эш дип игътикад итә иде». Ягъни «Тормышмы бу?» героеннан аермалы буларак, Хәлимнең яшәү максаты бик гади. Ул күктән йолдызлар тотмый, бәлки гади крестьян баласы булып кала, шәһәрдә алган азмы-күпме белеме белән туган авылы кешеләренә хезмәт итү турында уйлый. Дөрес, роман төгәлләнмәгән булу аркасында кичәге шәкерт Хәлимнең язмышы алга таба ничек буласын әйтүе кыен. Әмма авторның хәзердән үк героеның аң-белем дәрәҗәсеннән канәгать түгеллеген чамаларга мөмкин.

1917 елдан соң мөһаҗирлеккә киткәч төрле илләрдә булып күпне күреп-кичерү нәтиҗәсендә Г. Исхакыйның дөньяга карашлары тагын да киңәя. Бу хәл аңа революциягә кадәрге күпкырлы эшчәнлегенең төп максаты булган милләтне саклау һәм яшәтү өчен көрәшнең колачын һәм юнәлешләрен киңәйтергә булыша. Мөһаҗирлектәге әдәби иҗатында ул, аерым алганда, татарның милләт буларак яшәвенә зур зыян китергән тенденцияләрнең берсе рәвешендә татарлыктан качуга игътибарын арттыра һәм «Җан Баевич» пьесасы белән «Көз» повестенда әлеге күренешне төрле яклап анализлый һәм бәяли. Беренче әсәрдә татарлыктан качу күренеше кичәге авыл сәүдәгәре Шакирҗанның шәһәргә күчеп килгәч заман модасына сукырларча ияреп, ягъни Европача тәрәккыйпәрвәр булып үзенең үткәндәге яшәү рәвешеннән ваз кичәргә, руслашырга маташуы рәвешендә алга бастырыла. Шәһәрдә Шакирҗаннан Җан Баевичка әверелгән геройның әлеге омтылышын автор бары бер юләрлек итеп кенә карый һәм шуңа күрә бу омтылышны көлке планда, комедия жанрында яктырта.

«Көз» повестенда исә әлеге күренеш инде бөтенләй башка пафос белән, ягъни бик җитди драматик яссылыкта карала һәм бәяләнә. Чөнки анда революциягә кадәр татар дөньясында киң таралган һәм аңа зур зыян китергән күренеш — милләтнең интеллектуаль катлавын тәшкил иткән мирзалар яки морзалар арасындагы руслашу хәрәкәте турында сүз бара. Бу хәрәкәт заманында киң җәмәгатьчелекнең дә игътибарын җәлеп иткән һәм аңарда борчу уяткан иде. Матбугатта бу мәсьәләгә караган күп кенә чыгышлар була, ул әдәбиятта да шактый киң чагылыш таба. Моңа характерлы мисаллар итеп Г. Ибраһимовның «Яшь йөрәкләр» һәм Г. Рәхимнең «Идел» романнарын, С. Җәлалның «Дим буенда» повестен яки Ф. Әмирханның «Бер хәрабәдә» хикәясен китерергә мөмкин.

Инде Г. Исхакыйның «Көз» повестена килсәк, әле генә искә алынган әсәрләрдән соңрак һәм башка иҗтимагый-сәяси шартларда, ягъни мөһаҗирлектә язылган бу әсәрдә уртак проблеманы яктыртуда элгәреләре белән күпмедер аваздашлык та, зур гына аерма да табарга мөмкин. Мисал өчен повестьның исеме үк очраклы түгел, бәлки символик мәгънәгә ия. Башка авторлар кебек Г. Исхакый да руслашуга йөз тоткан мирза нәселләрен киләчәге булмаган кавем итеп карый. Бу фикерен сәнгатьчә чагылдырырга алынып, автор андый мирзаларны тормышының көзе килгән, ягъни киләчәге булмаган кавем дип күрсәтә. Мирзаларның мондый язмышы әсәрдә яшәү перспективасы булган, шунлыктан тормышта үзен ышанычлы сизгән икенче бер кавем белән чагыштырып карала. Болар барысы әсәрнең үзәк героинялары Гөлсем белән Нәфисә образлары һәм язмышларында чагылыш таба. Милләтеннән йөз чөергәне өчен бетүгә дучар ителгән мирза катлавыннан чыгуы сәбәпле, Гөлсем бу дөньяда бөтен яктан бәхетсез кешегә әверелә. Татар хәятында көчәеп, үсеп килүче сәүдәгәрләр гаиләсендә дөньяга килгән Нәфисә исә мөселманча тәрбия ала, үзе яраткан кешегә кияүгә чыга һәм бәхетле гаилә тормышын кора.

Повесть аның идеясен куәтли торган символик тасвирлар белән тәмамлана. Инкыйразга дучар ителгән мирзалар катлавы вәкилләре булган Гөлсем белән аның исерек ире атка утырып киткән юлда «көзге җил өермә куптара», «шайтан туе,

сары яфраклар, сары саламнар, иске тузаннарны җыеп», Гөлсемнәрне куа китә, бераздан аларның атының дугасы гына күренә, «әнә ул да югалды, әнә ул да юк». Гөлсемнәр ниндидер билгесез һәм куркыныч киләчәккә юл тотсалар, Нәфисә белән аны бу дөньяда иң бәхетле кешеләрнең берсе иткән доктор ире исә шатланып конкрет максатка — авылдагы яңа сатып алынган «җылы вә ягмурсыз, җилсез өйгә» таба ашыгалар.

Мөһаҗирлектә дә милләт язмышы турында кайгыртуын дәвам итеп, Г. Исхакый бу бик катлаулы мәсьәләне хәл итүнең төрле юлларын эзли. Шуларның берсе рәвешендә ул замандашларын тарих белән тәрбияләүне ала һәм татар тарихы мәсьәләләренә мөрәҗәгать итә. Әдәби иҗатында Г. Исхакый шундый тәрбияви максатларда тарихи үткәндәге аерым күренешләрне яки вакыйгаларны яктыртырга алына. «Өйгә таба» повестенда, мәсәлән, үткәндә Россиядә татарларны төркиләргә каршы көрәштә файдалануның бер мисалы тасвирлана. Ягъни анда рус-төрек сугышларының берсендә рус армиясендәге мөселман дивизиясе белән булган хәл турында сүз бара. Тагын да конкретрак әйтсәк, авторның төп игътибары әлеге дивизия командиры татар полковнигы Мирхәйдәр Тимергалиевнең сугыш кырындагы гыйбрәтле иҗтимагый-сәяси эволюциясен ачуга юнәлтелә. Башта рус патшасына турылыклы хезмәт итәргә ант биргән Тимергалиев фронтта дөрестән дә бик гыйбрәтле эволюция кичерә. Ягъни ул сугыш кырында рус хакимиятенең күпгасырлык дөнья-күләм гегемонлык итү планнарын тормышка ашыруда катнашырга, шушы юлда Россия өчен иң зур каршылыкларның берсе булган канкардәш төрек халкының канын коярга тиешлеген аңлый һәм бу ачыш аның моңа кадәрге икеләнү-шикләнүләреннән арынып, катгый бер карарга килүенә булыша. Алга таба әсәрдә Тимергалиевнең төрек канкардәшләренең башын кисәргә әзерләнгән рус балтасының сабы булудан котылырга теләвенең башка сугышчы милләттәшләрендә дә хуплау табуы, аның үз гаскәре белән төрекләр ягына чыгарга әзерләнүе һәм бу операцияне уңышлы башкарып чыгуы сурәтләнә. Үзәк героеның мондый гамәленә Г. Исхакый киң иҗтимагый-сәяси мәгънә бирә. Ягъни ул төркиләрне бердәм булырга, аларны уртак ватаннары булган халыклар итеп сизәргә чакыра. Чөнки шул юл белән генә аларның һәркайсы үзенең милли язмышын уңай хәл итә алачак. Икенче төрле әйткәндә, төрки халыкларның бердәмлеге әсәрдә аларны яшәтүнең һәм үстерүнең мөһим факторы итеп карала. Ә үзәк герой Тимергалиев үз гомерен шушы идеяне тормышка ашыруга багышлаган милләтпәрвәр каһарман булып алга баса. Төрекләр ягына чыкканда каты яраланган героеның үлемен дә әдип әлеге идея рухында тасвирлый: «Шул милләтемне саклыдым кәефеннән чыккан көлү, елмаю аның рухын күкләргә кадәр озатты — елмаеп җаны чыкты».

Татарның үткәне турында фикер йөрткәндә Г. Исхакый үз заманының таләпләрен дә искә ала. Эш менә нәрсәдә. Безнең халыкның тарихы хакында озак вакытлар Россиядә дә, чит илләрдә дә ялган һәм яла ягулы мәгълүматлар һәм карашлар таратылып киленде. Аерым алганда, татарлар рус сәясәте рухында, ягъни бик каралтып бәяләнгән монголлардан килеп чыкканнар, шунлыктан үткәндә кыргый, баскынчы булганнар дигән караш киң таралыш алды, ул бүгенге көнгә кадәр яшәвен дәвам итә.

Совет илендә рәсми төс алган мондый тенденциоз карашларга каршы тору мөмкин булмаган бер вакытта эмиграциядә Г. Исхакый әлеге ялганнарны кире кагу, чын дөреслекне аякка бастыру эшенә алына. Бу эшне ул башлап фәнни планда башкара. Бу өлкәдә аның иң күренекле хезмәте — «Идел-Урал» дигәне. 1933 елда язылып, ул шул ук елны Берлинда татар телендә, Парижда рус һәм француз телләрендә, алга таба Токиода япон (1934), Варшавада поляк (1938) телләрендә дөнья күрә. Бу хезмәттә татар фәнендә беренче мәртәбә диярлек безнең халыкның бик борынгыдан килә торган озын тарихы күз алдына бастырыла. Шул ук вакытта бу тарихның укучыларда халкыбызның үткәне белән горурлану хисе тудырырлык итеп, ягъни зур тәрбияви әһәмияткә ия итеп чагылдырылуын әйтергә кирәк.

Татарларның төп ватаннарындагы тарихы белән беррәттән, Г. Исхакый төрле илләрдә булып, андагы милләттәшләренең үткәне һәм бүгенгесе белән дә актив кызыксына. Мисал өчен Варшавада яшәгәндә ул, бу илдәге милләттәшләре тарихын махсус өйрәнеп, «Польша татарларының милли бурычлары» дигән күләмле

мәкалә яза һәм ул 1932 елда «Ләһестан төркиләре тарихы, хәяты буенча гыйльми, әдәби вә иҗтимагый мәҗмуга» дип күрсәтелгән «Рочник татарски» («Татар елъязмасы») җыентыгында дөнья күрә. Анда Польша татарлары тарихы турында сөйләгәндә Г. Исхакый аларның бу илгә хезмәт итүдә «рухларының вә холык табигатьләренең иң яхшы сыйфат-хасиятләрен» ачуларын белдерә. Шул ук вакытта әдип бу илдә биш гасырдан артык яшәү дәвамында поляклашкан татарлардан Польшаның кайбер күренекле шәхесләре чыгуын да искәртә. Моңа мисал итеп ул мәшһүр язучы Г. Сенкевичны, генераллар Александр һәм Мацей Сулькевичларны һ. б. ала.

Польша татарларының үз заманы буынына килгәндә, Г. Исхакый аларга интеллектуаль мөмкинлекләре белән бәйле рәвештә үзгәрәк миссия йөкли. Ягъни Европа мәдәниятен үзләштерүләре сәбәпле, алар Европа белән төрки халыклар арасында арадашчы була алалар. Бу миссияне уңышлы башкару өчен, Г. Исхакый фикеренчә, Польша татарлары «үзләренең туган телләрен җанландырырга вә сихәтләндерергә, үзләренең бөек төркиләр милләтеннән булу горурлыкларын онытмаска тиешләр». Әйтергә кирәк, Г. Исхакыйның бу теләге бүген дә һәм башка илләрдәге милләттәшләребез өчен дә әһәмиятен саклый һәм хәзер һәркайда милләттәшләребез арасында, тарихыбызны яхшырак белә бару сәбәпле, милли үзаң үсү күзәтелә.

Тулаем татар халкының яки аның мөһаҗирлектәге аерым өлешләренең тарихын фәнни-публицистик планда яктырту белән бергә, Г. Исхакый әлеге тарихның аерым чорларын әдәби иҗатында да чагылдырырга алына. Бу яктан аны аеруча Казан ханлыгы дәвере кызыксындыра. Әлеге мәсьәләгә караган фәнни хезмәтләрне дә (аерым алганда, күренекле рус тарихчысы М. Г. Худяков хезмәтләрен) өйрәнеп, ул 1944—1947 елларда Истанбулда «Олуг Мөхәммәд» дигән тарихи драмасын яза. Анда Казан ханлыгы, аның тарихка кергән хакимнәреннән берсе турында объектив сүз әйтергә алына. Биредә объективлыкка омтылу авторга Казан ханлыгы, аның сәясәте хакында моңа кадәр берьяклы, тенденциоз караш-бәяләрне кире кагарга, башка төрлерәк фикер йөртергә мөмкинлек бирә. Әсәр гәрчә ерак үткәнгә мөрәҗәгать итсә дә, ул заман рухы белән сугарылган. Г. Исхакый анда да төрки бердәмлеге идеясен алга сөрә һәм бу максатын татарларның борынгы төрки цивилизациясенең варислары булулары белән бәйләп аңлата. Казан ханлыгын тарихи бәяләү дә әсәрдә башкачарак яңгыраш ала. Әгәр элегрәк елларда бу дәүләтне баскынчы сыйфатында күрсәтү киң таралган булса, Г. Исхакый аны, киресенчә, баскынчылардан үз азатлыгын саклап калу өчен көрәшүче итеп сурәтли. Күпме вакытлар гел каралтып күрсәтеп киленгән бу дәүләтне хәзер шул рәвешле күз алдына бастыру ахыр чиктә әсәрнең тәрбияви әһәмиятен арттыра, чөнки ул укучыларда милли горурлык хисен үстерүгә булыша.

Г. Исхакыйның мөһаҗирлектәге актив җәмәгать эшчәнлеге дә шул ук милли яңарыш хәрәкәтенә хезмәт итә. Шушы максатта ул бигрәк тә төрле илләрдә берберсе белән аралашмыйча бик таркау хәлдә яшәгән милләттәшләрен берләштерү белән шөгыльләнә. Шундый ният белән көрәшче әдип 20 елларда «Идел-Урал» комитетын төзи. Үзенең бу төр эшчәнлегендә ул Ерак Көнчыгыш илләрендә яшәүче милләттәшләрен берләштерүгә аеруча игътибар бирә. Чөнки әлеге регионда татар мөһаҗирләренең иң зур һәм хәлле өлеше яши. Бу илләрдәге татарларның Харбинда, Мукденда һәм Токиода өч зур үзәге барлыкка килә. Ерак Көнчыгыштагы милләттәшләребезне үзара якынайту һәм берләштерүне оештыру өчен ул 1933—1937 елларда Польша хөкүмәтенең матди ярдәме белән әлеге регионда дәвамлы командировкада була. Бу сәяхәте вакытында ул 1934 елның маенда Кобе шәһәрендә җирле татар оешмаларының бөтеняпон корылтаен үткәрә. Һәм анда Г. Исхакый үзе җитәкләгән «Идел-Урал» комитетының Япониядәге үзәге оештырыла. 1935 елның февралендә исә шундый ук татарларны берләштерү корылтае Мукден шәһәрендә дә үткәрелә һәм анда да «Идел-Урал»ның Кытайдагы үзәге булдырыла.

Ерак Көнчыгыштан, ике елдан артык вакытны эченә алган командировкадан, Европага арып-талып кайтса да, Исхакый ял турында уйламый, бәлки мөһаҗирлектәге милләттәшләрен берләштерү эшен дәвам итә. Шушы максатта ул эмиграциядәге бөтен татар конгрессын үткәрүне планлаштыра һәм шуңа әзерлек эшләрен башлап җибәрә. 1937 елның 22 маенда Берлиннан исем-фамилиясе

күрсәтелмәгән бер поляк дәүләт чиновнигына язган хатында әлеге конгрессны шул елның көзендә Варшавада, Берлинда яки Констанцада үткәрергә планлаштыруын, ә делегатларның Япониядән, Маньчжуриядән, Кытайдан, Мисырдан, Гарәбстаннан, Германиядән, Польшадан, Финляндиядән, Төркиянең Истанбул, Анкара һәм Анадоло шәһәрләреннән чакырылачагын хәбәр итә.

Г. Исхакыйның әлеге хатында күздә тотылган конгресс соңрак, ягъни 1938 елның 4—6 февралендә Варшавада Милләт мәҗлесе төзелүнең 20 еллыгына багышлап үткәрелгән, күрәсең.

Бөтен дөньяга сибелгән милләттәшләрен берләштерү өчен төрле илләрдә милли оешмалар төзү, корылтайлар үткәрү һ. б. белән бергә, Г. Исхакый шундый ук максатта мөһаҗирлектә милли матбугат булдыруга да зур игътибар бирә. Бу өлкәдә аның иң зур казанышы — 1928—1930 елларда Берлинда «Милли юл» исеме астында чыгарылган журнал. Бу матбаганың максатын һәм программасын Исхакый «Милли юл»ның 1928 елның 29 декабрендә басылып чыккан беренче санындагы «Элек сүз»дигән кереш мәкаләсендә билгели. Анда яңа басманың төп бурычы итеп татар милләтенең бүгенге хәле һәм киләчәге турында кайгырту карала. Эш шунда, Г. Исхакый баштан ук Россиядә большевиклар хакимиятен вакытлы һәм узгынчы күренеш дип карый. Чөнки аныңча, Россиядә «бу көн иске падишаһлар заманындагы чаклы да хөррият юк. Анда большевик булмаган һичбер кемгә, һичбер горуһка (төркемгә) җыйналып сөйләшергә иркенлек юк. Анда большевик такмазасыннан башка бер нәрсә дә язарга рөхсәт юк. Большевик тоткан юлдан башка бер юлның барлыгын исбат итү түгел, төшенү вә уйлау гына да сөрелү вә үтерелү берлә җәза кылына торган зур гөнаһтыр. Шуңа күрә хәзер ул мәмләкәт эчендә һичбер төрле мәсләки җәрьяннар (агымнар), фиркаи хәяты вә сәяси бер тормыш юктыр»[19]. Мондый режимның гомере чикләнгән булуын искә алып, Г. Исхакый большевиклар властьтан төшерелгәч, татар белән нәрсә булачагы турында бүгеннән уйларга кирәклеген искәртә. Аның фаразынча, «большевик егылу берлә бөтен Русиядә анархия башланачактыр. Бу дәвердә русларның кырык төрле партияләре бер-берсе берлә сугышачак, кырылышачаклар вә шул гаугаларына башка милләтләрне дә катыштырырга тырышачаклардыр»[20]. Әйтергә кирәк, Исхакыйның бу фаразы белән безнең хәзерге чынбарлык арасында аваздашлык барлыгын күрүе кыен түгел. Әдип үзе фараз кылган әлеге күңелсез хәлгә тарымас өчен бүгеннән татарның азатлыгын яклардык көчле милли оешмасын булдырырга, төрле җирләргә сибелгән милләттәшләрне шул оешма кул астында берләштерергә, моның өчен ахыр чиктә татарның үз милли юлын билгеләргә кирәклеген искәртә. Яңа матбаганың төп бурычын да Исхакый шушы мәсьәләләр белән бәйләп карый: «Менә бу мәҗмуга шул фикергә хезмәт итәчәктер. Шул юлда яшьләремезгә юлбашчылыгы итәргә вә милләт байрак астында бөтен аңлы милләтчеләрне җыйнарга тырышачактыр»[21]. Һәм журнал башта «Милли юл», аннары «Яңа милли юл» исемнәре астында шушы юнәлештә эш итә дә.

Җыйнап әйткәндә, Г. Исхакыйның 60 елга якын вакытны эченә алган күпкырлы эшчәнлеге тулысынча бер максатка — татар дөньясында милли яңарышны булдыруга, шул юл белән милләтне саклауга һәм үстерүгә хезмәт итте. Мондый мәгънәсе һәм роле белән ул хәзерге яңару хәрәкәтенә турыдан-туры килеп керә һәм аның рухи чыганакларыннан берсенә әверелә. Һәм без хәзер татар дөньясында бара торган үзгәреш-яңарышта Исхакый мирасының актив катнашуын күрәбез. Мисал өчен иҗтимагый өлкәне алсак, анда Исхакыйның төрле илләргә сибелгән милләттәшләребезне берләштерү өчен конгресслар үткәрү башлангычы безнең заманда дәвам ителеп Бөтендөнья татар конгрессы корылтайларын уздыру төсен алды. Аның әдәби-фәнни эшчәнлегендә, беренчеләрдән булып татарның чын тарихын яктыртырга алынуы хәзер безнең әдәбият-сәнгатьтә дә, фәндә дә әлеге тарихка игътибар бермә-бер артуда үзенең дәвамын таба. Мөгаллим һәм әдипнең мәгариф белән мәдәниятны яшь буынга милли аң-белем һәм тәрбия бирү максатында файдалану һәм үстерү башлангычы да хәзерге мәдәни-педагогик процесска килеп керә. Әдәбиятыбызның да безнең көннәрдә үткәндәге милли вазифасын тулырак башкара башлавында Исхакый «эзләре» шактый ачык күзаллана.

Болар барысы XX йөз башында милли идея нигезендә барган яңару хәрәкәтенең үзәгендә торган Гаяз Исхакыйның хәзер бер гасырдан һәм меңъеллыктан

икенчесенә күчкәндә татар дөньясында шул ук идея рухында кабат барлыкка килгән әлеге хәрәкәтнең янә алгы сафына басуы турында сөйли.

ИСКӘРМӘЛӘР

[1] Ашмарин Н. Несколько слов о современной литературе казанских татар.— Журнал Министерства народного просвещения, 1905, № 9.
[2] Акчура Й. Гаяз әфәнде. Мирас, 1992, № 6, 26 б.
[3] Акчура Й. Гаяз әфәнде.— Казан мөхбире.— 1906.— 5 ноябрь; Гасрый Н. Шимали төрки әдипләреннән Гаяз Исхакый.— Истанбул: «Тәнин» матбагасы, 1910.
[4] Гобәйдуллин Г. «Ике йөз елдан соң инкыйраз» (Гаяз Исхаков әсәре).— Казан: «Гасыр» китап нәшрияты, «Мәгариф» типографиясе, 1911; Вәлиди Җ. Гаяз әфәнде.— Вакыт — 1913.— 5 март, 3 апрель.
[5] Камал Г. Яңа китаплар: («Мөгаллим» драмасы басылу уңаеннан).— Йолдыз.— 1909.— 2 июнь; Баттал Г. «Мөгаллим» китабы вә өйләнү мәсьәләсе.— Вакыт.— 1909.— 27 июнь; Бәкер К. Яңа китаплар. «Мөгаллим».— Йолдыз.— 1907.— 13 октябрь; «Әкмәли» (И. Биккулов). Татарча театр («Мөгаллим»).— Кояш.— 1913.- 14 октябрь; Ф. Ә. (Ф. Әмирхан).— «Мөгаллим».— Кояш.— 1914.— 27 январь.
[6] Гыйсмәти Г. «Мөгаллимә» (Гаяз әфәнденең яңа әсәре).— Йолдыз.— 1914.— 12, 28 январь; Әхмәдиев Ш. «Мөгаллимә».— Йолдыз. 1914.— 3 октябрь; Әхмәдиев Ш. «Мөгаллимә» — сәхнәдә.— Йолдыз.— 1914.— 26 ноябрь; Кәрам Г. Казанда «Шәрекъ» клубы сәхнәсендә «Мөгаллимә».— Аң.— 1914.— 31 октябрь; Мөхетдиния Ә. Кем ул мөгаллимә Фатыйма? («Мөгаллимә» пьесасындагы мөгаллимә тибына тәнкыйть).— Аң.— 1914.— 24 декабрь; Вәлидов Җ. «Мөгаллимә» (Гаяз Исхакый әсәре).— Вакыт.— 1915.— 10 январь; Татарча театр («Мөгаллимә»). Ил.— 1915.— 15 февраль; Рәмиев С. Татарча театр («Мөгаллимә»).— Тормыш (Уфа).— 1915.— 18 февраль; Ибраһимов Г. «Мөгаллимә»нең Уфада уйналуы мөнәсәбәте белән;— Тормыш.— 1915.— 26—27 февраль; Бикташев А. Тәнкыйть тирәсендә.— Кояш.— 1915.— 13—14 август.
[7] «Ф» (Ф. Әмирхан). «Зөләйха».— Кояш.— 1917.— 19 март; «Ш. Ә». (Ш. Әхмәдиев). «Зөләйха».— Йолдыз.— 1917.— 22 март; Кәрам Г. «Зөләйха»ның өченче мәртәбә уйналуы.— Аң.— 1917.— 3—4 саннар; Тюменев Р. «Зөләйха» — Мәскәүдә.— Ил.— 1917.— 10 май.
[8] Габди (Г. Ибраһимов).— Татар матбугаты.— Йолдыз, 1910, 12 январь.
[9] Баһаветдинов Ф. Кәрим Тинчуринның соңгы көннәре.— Казан утлары.— 1990.— № 2.— Б. 150.
[10] Мирас, 1999— № 9.— Б. 32.
[11] Н. П. Из мусульманского мира.— Казанский телеграф.— 1898.— 15 января.
[12] Гаяз. Тукай мәктәптә.— Мәктәп.— 1914.— № 6.— Б. 125—126.
[13] Ибраһимов Г., Баттал Г. Яңа әдәбият.— Казан: Лит. типогр. И. Н. Харитонова.— 1914.— Б. 3—4.
[14] Ибраһимов Г. Сайланма әсәрләр, 8 томда. Т. 6.— Казан: Татар. китап нәшр.— 1986.— Б. 106.
[15] Исхакый Г. Яшь көчләрнең бурычы, 73 б.
[16] Шунда ук.
[17] Гасрый Н. Шимали төрки әдипләреннән Г. Исхакый.— Мирас, 1994, № 10, 40—41 б.
[18] Мөхәммәтгаяз. «Бай угылы»ның беренче басылуына мөкатдим.— Мирас, 1996, № 9, 32 б.
[19] Исхакый Г. Элек сүз. Мирас, 1992, № 2, 40 б.
[20] Шунда ук, 41 б.
[21] Шунда ук, 41 б.

ФЛҮН МУСИН,
Бөтендөнья татар конгрессы
Башкарма комитеты бюросы
әгъзасы, Татар «Мирас» Фонды
президенты, академик.

КҮҢЕЛ САФЛЫГЫ

(Исхакыйның «таңчылык» чоры иҗатында мәхәббәт, никах проблемаларының чишелеше)

Г. Исхакыйның икенче чор иҗатын (1905—1911) әдәбият тарихында «таңчылык» чоры дип атыйлар. «Таңчы» Исхакый әсәрләре күбесенчә көрәш-тартыш идеяләре белән сугарылган. Бу әдипнең карашлары яңа баскычка күтәрелүе хакында сөйли. Язучының иҗтимагый-сәяси эшчәнлеге аның әсәрләрендә дә чагылмый калмый. Мәгърифәтчелек идеяләре белән бергә пролетарь әдәбият өчен хас карашлар да килеп керә. Социалистик-марксистик эстетиканың тәэсире дә сизелә.

Әдипнең бу чордагы иҗаты аеруча уңдырышлы. Бу вакыт аралыгында язылган «Теләнче кызы», «Тормышмы бу?», «Көтелгән бикәч» әсәрләрендә җәмгыятьнең байларга, ярлыларга бүленешеннән туган гаделсезлекләр, каршылыклар гына ачылып калмый, җәмгыятьне үзгәртергә чакырган сәяси лозунглар да очрый. Әдип кеше психологиясен, «күңел диалектикасы»н нечкә сурәтләү дәрәҗәсенә күтәрелә, аның сәнгатьчә фикерләвендә рус классиклары Гоголь, Толстой, Тургенев, Горький йогынтылары ныграк сизелә башлый. Тургеневның гыйшык психологиясен ачып салучы, Толстойның фәлсәфи фикерләре, шул фикерләрнең «галилеге, табигыйлеге», изелгән халыкның хәятын сурәтләүче Горькийның «гавам психологиясе»н бирүе кебек алымнар барысы да Исхакый әсәрләрендә әдипнең милли фикерләре, дини инанулары, гомумкешелек мәсьәләләренә карашлары белән тыгыз үрелеп, аның иҗатын кабатланмас үзенчәлекле итәләр. Бу чорда язучының Көнбатыштан кергән фрейдистик карашларга таянып сурәтләнгән геройларының эчке дөньясы тулылана, хис-кичерешләре, тормыш фәлсәфәсе байый.

Таңчылык чоры әсәрләрендә «Тартышуда гына табарсың үз бәхетең» лозунгысы беренче планга куела. «Теләнче кызы» романындагы Сәгадәт тә шул максатка буйсындырылып, халыкка хезмәт һәм көрәш юлына баса. Бу әсәрдә «көрәш» сүзе берничә мәгънәгә ия. Беренчедән гади татар хатыны аңында барган феодализм калдыкларына каршы көрәш, халыкны агарту, европалаштыру өчен көрәш идеясе — татар революциясе алга сөрелә. Икенчедән, Русия масштабында көтелгән иҗтимагый-сәяси революция күз алдында тотыла. Дин тәгълиматыннан яхшы ук хәбәрдар булган Исхакыйның ике революция ясау идеясе ислам динендәге «кече җиһад» (җәмгыятьтәге гаделсезлекләргә каршы сугыш), һәм «олы җиһад» (күңелдә иман өчен, күңел сафлыгы өчен инсанның иске гадәтләре белән көрәше) төшенчәләре белән бик тә аваздаш.

Әдип кешеләрнең, аеруча хатын-кызның шәхси азатлыгы мәсьәләсен күтәреп чыга. Татар әдәбиятында беренче буларак, хатын-кыз герой үз ирен, гаиләсен ташлап чыгып китә, һәм дә халык бәхете өчен көрәш юлын сайлый. Бу урында автор бездә әле хәзер дә аз өйрәнелгән «халыкчылык» (народничество) мотивларын китереп кертә.

«Теләнче кызы»ндагы төп герой Сәгадәтнең язмышын тасвирлап, Исхакый татар хатынының үткән юлын, аның үзаңы уянуын, үзгәреш кичерүен күрсәтте. Бу — феминистик проблемаларны яктыртуда язучы иҗатындагы яңа әдәби-эстетик караш иде.

Исхакыйның икенче чор хатын-кыз геройлары бигрәк тә актив, кыю. Автор тормыш төбенә төшереп тә, фаҗигале язмышка дучар итеп тә аларның чыдамлыгын, дөньяның мәрхәмәтсезлеген күрсәтә. Шуның белән параллель рәвештә бу олы затларга тиң караш, зур ихтирам кирәклеген искәртә. Шушы идеясе белән генә дә әдип Көнбатыш феминистлары күтәреп чыккан хатын-кызның юридик, гражданлык хокуклары турындагы таләп-лозунгларга якын тора. Әмма хатын-кызны иҗтимагый азат итү белән аңа караш, ихтирам арта дип санаган феминистлар ялгыштылар. Аларга караш һаман шул килеш кала бирде. Исхакый исә, ир-атны һәм хатын-кызның физиологик, анатомик, гносеологик үзенчәлекләрен инкарь итмәгән хәлдә, соңгыларының социаль генә түгел, гаиләви роленең дә зурлыгын исбатлады, аларның иң эчкерсез хөрмәткә лаек икәнлеген яклап чыкты.

Язучы феминистик проблемалар яктылыгында әдәп-әхлак мәсьәләләренә дә, мәхәббәт кебек гомумкешелек проблемага да, гаилә, никах кебек социаль төшенчәләргә дә зур игътибар бирә. Бу сорауларга җавап социаль, фәлсәфи, әдәби, тарихи аспектларга таянып кына түгел, психологик факторлар яссылыгыннан чыгып та аңлатыла.

Язучылык сәләте арта барган саен, кеше күңеленең башкаларга билгесез, караңгы, серле почмакларына Исхакыйның очлы каләме тагын да тирәнрәк үтеп керә, геройларның эчке хис-кичерешләрен, күңелнең катгый диалектикасын бирүдә осталыгы тагын да камилләшә.

Соңрак әдип иҗатында психологизм милли хосусиятләрне, татар халкының фаҗигасен ачучы көчле корал рәвешен ала (аеруча «Тормышмы бу?», «Остазбикә» әсәрләрендә).

Г. Исхакыйның татар әдәбиятына алып килгән әлеге яңалыклары аның иҗтимагый үзаңы үзгәрү, үсүе хакында сөйли.

Әдип үзен бу чорда чын тәнкыйди реалист итеп таныта. Татар дөньясының, капиталис-

тик җәмгыятьнең иң тирән җирләреннән — тормыш төбеннән мисаллар китереп, үз замандашларын таң калдыра, пролетар реализмның беренче үрнәкләрен бирә. «Тартышу» драмасында «ирләр белән бертигез революцион хәрәкәттә катнашучы хатын-кыз образы Шакирәне иҗат итә»,— дип күрсәтте әдәбият галиме, профессор Р. Ганиева.

Исхакыйга бу чорда булган тагын бер йогынты Н. В. Гоголь иҗаты белән бәйле. Гогольнең «кечкенә кешеләр»дән күз яше аралаш көлүен оста файдаланып, Исхакый аны татар милләтенең, аның егет-кызларының фаҗигасен, яшәү үзенчәлекләрен ачуга юнәлтте. Мәсәлән, «Тормышмы бу?», «Көтелгән бикәч» әсәрләрендә гади бер егетнең шәхси фаҗигасе иҗтимагый афәтләр белән чагыштырганда гаять мөһим икәнлеге, шул гади күренгән проблеманың чишелеше инсанның бөтен тормышына тәэсир итүе — аның үзенең дә, хатынының да бәхетле-бәхетсез булуында җитди рольне уйнавы хакында чаң сукты.

Тормыштагы ир-хатын, егет-кыз арасындагы мөнәсәбәтләрне артык реаль итеп тасвирлаганда язучы психоаналитик З. Фрейд өйрәтмәләренә, Дарвинның табигый сайланышына, Бергсонның интуиция теориясенә мөрәҗәгать итә. Шул рәвешле Европа һәм рус фәлсәфәсе, эстетикасы белән танышу язучының психологик осталыгын тагын да баетты, татар әдәбиятына яңа алым — күңел монологы алымы үсеп китүгә этәргеч ясады. Бу алымга мөрәҗәгать иткәндә Исхакый аурупалылардан Аң-Аңсызлык бәрелешен алса, күз яше түгү, вөҗдан газабы кичерү кебек Шәрекъ әдәбияты традициясе элементларын да кертеп җибәрә, шул рәвешле аның иҗатында Көнчыгыш әдәбияты һәм Көнбатышның фәнни тәгълиматы синтезлана.

«Таңчы» Исхакый хатын-кызны мәхәббәт, никах, гаилә төшенчәләренең уртасына куеп, аларга башкача күзлектән якын килә. Мәгърифәтчелек чорында бер-берсен яратып өйләнешкән кеше юк ул, дигән караштa торган язучы бу дәвердә мәхәббәтнең гаилә корудагы хәлиткеч ролен исбатлый.

Мәгърифәт күзлегеннән хатын-кызның котылу урыны дип кенә билгеләнгән «никах» сүзенең эчтәлеге киңәя, яңа мәгънә төсмерләре дә ала.

Беренчедән, Сәгадәт-Габдулла бәйләнешендә («Теләнче кызы» романы) никах — Сәгадәт өчен котылу урыны гына түгел, кешене үтерә торган гайбәтләргә каршы торырлык калкан да. Габдулла өчен башта гөнаһларын ярлыкау ысулы булса, соңыннан үзенчә яшәргә теләгән ирнең иреген кысучы, Исхакыйча әйткәндә, «шпион»га әверелә.

Икенчедән, «Тормышмы бу?» романындагы шәкерт егет өчен өйләнү-никах үзен коллыкка бирү белән бер. Яратмыйча өйләнү, сөймәгән кеше белән тору инсанның күңелендә йөрткән идеалларын тормышка ашыруга киртә була, аларны җимерә. Ә инде хатын-кыз геройлар яратмаган кеше белән гаилә корганчы кешелек бәхете өчен көрәш юлын сайлыйлар («Мөгаллимә»дәге Фатыйма).

Өченчедән, белмәгән-күрмәгән кешегә өйләнү үлем белән бер. Никах көнне кыз катына кергәч, кәләшне күреп җан тәслим кылган герой күпертелеп сурәтләнә, әлбәттә. Ләкин «Көтелгән бикәч» әсәрендә кулланылган бу алым геройның физик үлеменнән бигрәк, рухи үлемен күрсәтә. Рухи дөньясы яшәүдән туктаган адәм ашау, эчү кебек табигый теләкләр, җенси ихтыяҗлар белән яшәүче бәндәгә әверелә. Инсан күңеленең чәчәк ату-атмавын, идеалларын тормышка ашырырлык теләк, көч булу-булмауны Исхакый без абстракт бер төшенчә, бик үк җитди түгел, вакытлыча бер халәт дип караган бөек Сөю, Мәхәббәт төшенчәсе белән бәйләп аңлата. Инсаннарның күбесе аның рухи ягын татымыйча, бары җисми ягын — «тән ләззәтен» генә тату белән канәгатьләнә. Чын-чынлап ярату өчен кешедән гаять зур җаваплылык, үзенә карата таләпчәнлек, яраткан кешегә хисләренне генә түгел, күңелеңне бирү сорала. Әмма адәм баласының күбесе мондый таләпләр алдында чигенә. Шул сәбәпле гомер буе мәхәббәтнең иллюзиясе, «күләгәсе» белән, яисә, гомумән, тән ләззәте белән генә яши.

Тагын бер кызыклы күзәтү: Исхакыйның бу чор ир-ат геройларына ихтыяр көче җитми. Алар үз физиологик теләкләренә, иске гадәтләренә, тормыш сынауларына каршы тора алмыйлар. Бу хәл аларның гаиләдә тормыш дулкыннарына каршы торырлык дөрес тәрбия алмаулары белән дә, мәдрәсә белеменнән тыш, җәдитчә укымаулары белән дә бәйле. Әмма алар тормыш корганда «мәхәббәт» дигән хиснең мөһимлеген тоя башлыйлар. Әдипнең ир-ат турындагы идеалы — укымышлы, камил тәрбияле, эстетиканы, мәдәниятне аңлый торган, иҗтимагый тормышын милләткә хезмәткә багышлаган, ләкин шул ук вакытта хатынына иптәш тә, балаларының анасы итеп тә, сөю алиһәсе итеп тә караган ир кеше. Тик ул чорның бөтен бер татар җәмгыяте моны аңлау дәрәҗәсеннән ерак тора иде әле.

Гомумән, әдип күтәргән гомумкешелек мәсьәләләре турында уйлыйсың да: «Без мәхәббәтнең рухи асылын, аның кешене яшәтә торган иң бөек хис кенә түгел, иң бөек көч булуын аңлыйбызмы соң?!» — дигән фикергә киләсең. Чыннан да, ярату бит ул — кешеләргә яхшылык, изгелек теләү, аларны ярату, башка инсанның да индивидуаль, автономияле — хөр булырга хакын тану. Шәхес үзаңының гуманистик сыйфатларга нигезләнеп формалашуы кечкенәдән башлана. Шуңа күрә Аналарга балаларыгызны кечкенәдән үк яратырга өйрәтегез диясе килә.

АЛСУ КӘРИМОВА,
Казан Дәүләт университеты аспиранткасы.

Галимҗан Шәрәф һәм татар тел белеме

Җәмгыятебезнең демократизацияләшүе шартларында милли мөнәсәбәтләрне камилләштерү, милли телләр үсеше, телләрнең функциональ-структур үсеше, телләрнең фонетик, грамматик, лексик системалары, терминологияләре камилләшүе мәсьәләләрен тикшерү көнүзәк проблемаларга әйләнеп китте.

Җәмгыятебездә бара торган интеграль-дифференциаль үзгәрешләр тел системасы үсешенә дә йогынты ясамыйча калмый. Шул җәһәттән киң әтрафлы галим Г. Шәрәфнең татар тел белеменә бәйләнешле кайбер эшчәнлек сәхифәләренә тукталып китик. «Галимҗан Шәрәф, Тукай әйтмешли, коеп куйган профессор-педагог кына түгел, тарихчы-этнограф, филолог һәм картограф та, дәүләт эшлеклесе һәм шагыйрь дә. Аның 300 дән артык шигырьләре бар. «Зодчий» дип аталган поэмасы гына да ни тора! Анда урын алган фикерләрдә ачыктан-ачык Сталинга һәм аның гамәлләренә киная сизелә». (Кара: Советская Татария, 1991, 28 декабрь.) Г. Шәрәф балалар өчен дә күп язган, үзенең язмаларын «Гаенша бабай» исеменнән чыгарган. Моннан башка ул татар мәктәпләре өчен язылган күп кенә дәреслекләр, методик кулланмалар авторы да». (Рәмзи Вәлиев. Фаҗига. Казан: Татар. кит. нәшр., 1996, 7 бит.) Башта Галимҗан Шәрәфнең тәрҗемәи хәленә тукталып китик.

Галимҗан 1896 елның 29 декабрендә Тәтеш өязе (хәзерге Буа районы) Аксу авылында укымышлы, зыялы гаиләдә дөньяга килгән. Әтисе Шәрәфетдин Хөснетдин улы, әнисе Гайнелнәвәл Нигъмәтулла кызы һәрвакыт аң-белемгә омтылучан, укырга яратучан кешеләр булалар, шуңа күрә алар улларында да белемгә омтылыш тәрбияләргә омтылалар (Р. Вәлиев. Фаҗига. Казан, 1996, 8 бит).

Галимҗан башлангыч белемне гаиләдә ала. Аннан ул укырга Казандагы Мөхәммәдия мәдрәсәсенә китә. Биредә абыйлары да бик тырышып укыйлар. Мәдрәсәдә Галимҗан Шәрәкъ халыклары мәдәниятен татар, гарәп, фарсы, госманлы төрек телләрен үзләштерә, ә мәдрәсәнең икенче баскычын тәмамлагач, үзлегеннән хәзерләнеп Казанның икенче реаль училищесына укырга керә һәм аны 1915 елда тәмамлап чыга. Аннан булачак галим Петроград шәһәрендәге тимер юл инженерлары институтына укырга керә, анда да 1917 елга кадәр укый-укуын, әмма институттагы белгечлек аның рухи халәтенә бик үк туры килеп бетми. Галимҗан Шәрәф Петербургта мәшһүр фән әһелләре, рус язучылары, шагыйрьләре белән танышa, аралаша, аларның лекцияләренә йөри, шагыйрьләрнең, язучыларның иҗатларын өйрәнә. Г. Шәрәфнең университет профессорлары һәм академиклары Бартольд, Тураев, Смирнов, Щерба, Платонов, Владимиров, Жуковский, Самойлович, Крачковскийлар белән аралашуы, аларның фәнни иҗаты белән кызыксынуы аның киләчәк язмышын, фәнни карьерасын билгеләүгә зур йогынты ясый. Февраль һәм Октябрь инкыйлабларыннан соң Г. Шәрәф укуын ташлый һәм яңа сәяси вакыйгалар эченә кереп китә. 1917 елның маенда Мәскәүдә Бөтенрусия мөселманнарының беренче корылтае булып уза, делегатлар арасында Г. Шәрәф тә була. 1917 елның 22 ноябрендә Уфада Милли Мәҗлес сессиясе булып уза, депутатлар арасында шулай ук Г. Шәрәф була. «Идел-Урал штатларын» төзү һәйәте Казанга күчкәч, аның рәисе И. Алкин булса, урынбасары Г. Шәрәф була. Мондый характердагы сәяси вакыйгаларны, андагы Г. Шәрәфнең эшчәнлеген күпләп санап китәргә мөмкин булыр иде.

Г. Шәрәфне башта Казан педагогия институтында уңышлы гына эшләп китә, экспериментал фонетика лабораториясендә эшләп, зур уңышларга ирешә, әмма ул озакка сузылмый, аны 1937 елның 23 мартында кулга алалар, аннан озакка сузылган зиндан газаплары.

Г. Шәрәф гаепсезгә хөкем ителеп 8 ел гомерен Свердловский төрмәсендә үткәрә, 1950 елның 13 гыйнварендa Казанда вафат була.

Кыскасы, Галимҗан Шәрәф универсаль галим булган, ул төрле өлкәләрдә үзенең җуелмас эзен салып калдырган тарих, экономик география, филология, этнография, фонетика һ. б. өлкәләргә караган хезмәтләре үз заманында зур популярлык казанган, республика, ил чикләрен үтеп чыгып, дөнья аренасына юл тоткан. Зур галим фәндә, тормышта, сәясәттә, иҗтимагый тормышта зур һәлакәтләр, фаҗигаләр, Сталин төрмәләре аша үтеп, ачы хакыйкатькә ирешкән.

Галимҗан Шәрәф Казан лингвистик мәктәбенең актив әгъзаларыннан берсе була. Ул И. А. Бодуэн де Куртене, Н. В. Крушевский, бигрәк тә остазы В. А. Богородицкийларның фәнни идеяләрен дәвам иттереп, татар тел белеменә, гомуми тел белеменә зур өлеш керткән. Аның фикерләре, хезмәтләре, фонетика, морфология, синтаксис һәм типология өлкәсендәге фәнни идеяләре бүгенге көндә дә үз әһәмиятләрен югалтмаганнар.

Энциклопедист галим Г. Шәрәф татар телен рус, көнбатыш Европа телләре, көнчыгыш телләре белән чагыштырып карап, татар тел белеме үсешенә, бигрәк тә аның фонетик системасының үзенчәлекле үсешенә ярдәм итә. Аның тарихи-генетик һәм типологик чагыштыру ысулы тел үсешенең барлык өлкәләренә дә кагыла. Әмма күбесенчә алар эксперименталь фонетика сферасына кайтып кала. 1929 елда Г. Шәрәф эксперименталь фонетика буенча халыкара ассоциациягә хакыйкый әгъза буларак кабул ителә (академиклар В. А. Богородицкий, Л. В. Щерба, А. И. Томсон һәм Р. И. Шордан, СССР буенча). Бу үзәк башта Вена шәһәрендә була, аннан Лондонга күчерелә.

Г. Шәрәф аеруча 30 нчы елларда фән өлкәсендә рухланып, дәртләнеп эшли башлый. Ул, мәсәлән, «Кешелек дөньясындагы телләрне иҗтимагый-икътисади формацияләргә бәйләнештәге үсешләре» дигән тема өстендә фәнни тикшеренүләр, эзләнүләр алып бара. Аның фәнни эшчәнлегенә атаклы француз лингвисты А. Мейе, мәшһүр рус галимнәре И. И. Мещанинов, А. Н. Самойлович, Л. В. Щерба зур бәя бирәләр һәм аны, докторлык диссертациясе якламаган хәлдә, профессор исеме алырга лаек дип табалар.

Г. Шәрәфнең фәнни иҗат итү чорында Казан лингвистик мәктәбенә нигез салуга киң эрудицияле, универсаль галим, полиглот И. А. Бодуэн де Куртене фонетика фәне, бигрәк тә чагыштырма фонетика фәне өлкәсендә зур ачыш ясый: кардәш һәм кардәш булмаган бик күп телләрне чагыштырып, аларның фонетик системаларын чагыштырып, анализлап, уртаклыкларны, аерымлыкларны ачыклап, мәгълүм фонетик закончалыкларны ача.

Аның тарафыннан иң беренче булып теоретик планда фәнни эшләнгән фонема теориясе заманында дөнья аренасында «атом»ны ачуга тиң булып яңгырый. Бодуэн де Куртене шәкерте В. А. Богородицкий Казанда эксперименталь фонетика лабораториясен ача. Ә В. А. Богородицкийның иң яраткан, иң турылыклы шәкертләреннән берсе Г. Шәрәф фонетика өлкәсендә остазының фәнни эшен уңышлы дәвам иткән хәлдә, татар теле фонетика системасын эксперименталь рәвештә тикшерүен дәвам иттерә. Аерым алганда Г. Шәрәфнең «Татар авазларының рус авазлары белән чагыштырганда платограммасы» дигән хезмәте авазлар ясалышы фәнни тикшерүгә багышлана. Биредә автор татар теленең сузык, тартык авазларын җентекләп өйрәнеп, мәгълүм фәнни нәтиҗәләргә килә. Бу нәтиҗәләр телнең специфик үзенчәлекләре белән дә тыгыз бәйләнештә тора. Ә икенче «Татар сузыкларының сонор озынлыгы» дигән хезмәтендә галим сузыклар озынлыгын приборлар ярдәмендә язып алу нәтиҗәсендә, аларны төрле хәлләрдә тикшерә, басымның ни дәрәҗәдә сузыклар озынлыгына тәэсир итүен ачыклый. Бу тикшеренүләрнең нәтиҗәсе үз заманы өчен зур фонетик ачыш була.

Энциклопедист галим Галимҗан Шәрәф морфология, синтаксис, лексика һ. б. өлкәләрдә дә, типологик ысулдан файдаланып, уңай фәнни нәтиҗәләргә ирешә. Аның бигрәк тә типологик идеяләренең урал-алтай телләренә кагылганнары зур әһәмияткә ия булып тора, чөнки алар күпмедер дәрәҗәдә татар теле үсешенә дә карыйлар.

Г. Шәрәф тел системасын типологик планда чагыштырып караганда, һәм теоретик, һәм гамәли яктан көнбатыш Европа, көнчыгыш телләренә, шул телләрдә чыккан фәнни чыганакларга мөрәҗәгать итә, шуңа да аның фәнни фикерләре, тикшеренү нәтиҗәләре зур ышандыру көченә, объектив фәннилеккә ия булып торалар.

Дөньядагы мәшһүр лингвист «А. Сомерфельт Ф. де Соссюр һәм Бодуэн де Куртене хәзерге структурализмны рухландыручылар булдылар» дигән булса, В. А. Богородицкий һәм Г. Шәрәфләр эксперименталь фонетика өлкәсендәге фәнни эзләнүләргә нигез салып калдырдылар дисәк, фикеребез һич тә ялгыш булмас кебек тоела.

Г. Шәрәф үз заманының төрле фаҗигале, сикәлтәле юллары аша үтеп, үз халкына зур әһәмияткә ия фәнни мирас калдырды. Ул шулай ук татар тел белеменә дә зур өлеш кертте, аның фонетик системасын фәнни өйрәнүне яңа баскычка күтәрде.

Тормыш галимне какса, сукса да, хәтта зинданнарга илтеп тыкса да, аның саф йөрәге, күңеле туган, яраткан халкына тугрылыклы булып калды. Бу уңайдан бөек галимнең гарәп графикасын алыштыруга каршы булуын искә алу да җитә, чөнки ул халыкны мирасыннан, борынгы мәдәниятеннән аеруга теше-тырнагы, бөтен вөҗүде белән каршы булган.

Озын сүзнең кыскасы, Г. Шәрәф үз халкының кыю, батыр, милләтпәрвәр фән каһарманы булып җитлекте, ул һичкайчан да үз Иманына, үз фәнни Кыйбласына хыянәт итмәде, тугрылыклы булып калды.

МАЛИК ХӘЙРУЛЛИН,
филология фәннәре кандидаты.

МИЛЛИ ШИГЪРИЯТ

Фәридә Хаҗиева

КҮҢЕЛ КАНАТЫМ

(Шигырьләр)

Мин юлбарыс елының бизмән йолдызлыгы астында, Амур өлкәсенең Райчихинск шәһәрендә, шахтерлар гаиләсендә дөньяга килгәнмен. Әнием вагоннар арасына кысылып имгәнгәч, Татарстанның элекке Подберезье (хәзерге Апас) районы, Багыш авылына кайтып, 8 нче яшемдә татар мәктәбенең 1 сыйныфына укырга кердем. 16 яшем тулгач, кулыма 25 сум акча тотып, үги әни биләмәсеннән Урал якларына китеп, тимер юлда эшли башладым. Яшьлегемне Урал таулары арасында адаштырып калдырып, 1971 елда Казанга кайтып егылдым. Шул көннән гомеремне Казан трамвай депосына багышладым. Үпкәләремне шигъри юлларга салып юанып, шигырьләрдән көч алып яшим.

Автор.

НИГӘ ӨЗГӘЛӘНӘМ

Тамагым тук әле,
Нигә өзгәләнәм —
Кайберәүләр ач та утыра.
Дөньялар үзгәрде
Диеп, ул кадәрле,
Өзгәләнми яшәү ни тора.

Габдулла Тукаймы
Әллә рәхәт күргән,
Исхакыйны аңлаганнармы?
Минем язмышымны
Аларныкы белән
Чагыштырып караганнармы?

Килер Алла боерса,
Килер әле бер көн:
Искә алмый гына үтмәсләр;
Мине дә әле бәлкем,
Амурда тусам да,
Татарларым үги итмәсләр.

Әби-бабам йорты —
Чуваш дуслар чиге,
Караңгы авылы татарның
Көчле, горур рухым,
Татар дигән атым
Чит җирләрдән тартып кайтарды.

Туган телне сөю —
Шушы яктан килә,
Шушы җирдә анам кабере.
Язмышым чит телдә
Язылганмы әллә?..
Тапмадым ла монда — кадерне.

Мин барыбер әле
Илем горурлыгы —
Татар кызы булып калырмын.

КАЙТЫП КИЛӘМ

Зифа каен кызларына
Серем сөйләп,
Нәселемнең асылына
Кайтып киләм.

Акбүз атына атланып
Оча йөрәк,
Канатына былбылдан бер
Кауры́й кирәк.

Хыялымның офыклары —
Алсу ефәк,
Нәкышләре уңмас өчен
Сөю кирәк.

Язмышны гөлләргә төрү
Серен өйрәт,
Я булмаса, кыл бер дога,
Теләк теләп.

Туган ягым, миннән сиңа —
Җырым — бүләк!

* * *

Табынырга кыйблам — туган ягым!
Кыямәттән чыксам, кодрәт табып,
Күрми күзем: нигә җәүһәр-алтын
Вәхши дөньям, ничек түзим тагын.

Чүп үлән дә үсми янган җирдә,
Йөрәк яна — күңел туган илдә.
Минем өчен тәмуг уты сипкән
Бу дөньяга дәшим кайсы телдә.

Шайтан таягына төшми кырау,
Бәхеткә юл эзлим, юллар урап.
Тик күңелдән чыкмый һаман сорау —
Кем кулында бүген кызыл олау?

Бу якларда исми Саба җиле,
Кайтырмын мин сиңа туган илем!
Яшәсен тик минем туган телем,
Нәселем нигезе булсын имин!

«АРДЫМ» — ДИСЕҢ

«Ардым» — дисең, бирешмәскә кирәк,
Томан таралыр да, таң атар.
Хәсрәтләрең булса, сал иңемә,
Пар канатым җилгә таратыр.

«Ардым»,— дисең, бирешмикче иркәм,
Җилләр тынар, туктар бураннар...
«Бу сукмактан бәхетлеләр үткән»,—
Диеп искә алсын туганнар.

«Ардым» — дисең, бирешмибез әле,
Рухи байлыгыбыз булганда.
Күз яше дә кайчак җиңеләйтә
Өзелеп-әрнеп күңел тулганда.

«Ардым» — дисең, менә җылы кулым,
Җиде ят күңелне җигә алмас.
Каф тавының Дию пәрие дә
Мәхәббәт ялкынын җиңә алмас.
Әҗәл үзе генә килмәгәндә,
Фани дөнья мине җиңә алмас!

ЧЫҢ

Көй чыгара алмагач соң,
Күңел кылын ник чирттең.
Гомер буе бер чың булып,
Әрнергә мәҗбүр иттең.

Күңел һаман чыңлап тора,
Әрнүе күзләремдә...
Үзем бернәрсә көтмим дә,
Эзеңне эзләмим дә.

Узып барышлый бер чиртеп,
Мәңгелек чың калдырдың.
Моңсыз-көйсез узмас гомер
Үзем җиңә алырмын!

Көйсез ничек яшәү кирәк,
Гомерлек кургаш булып.
Сүрелмәс моңга әйләндем
Җиләнгә юлдаш булып!

КҮҢЕЛ КАНАТЫМ

Чәчләремдә шомырт тәлгәшләре,
Сагынуым һаман ешая.
Булган сагышларны җилгә сибик,
Сер бирмәек әле дошманга.

Көтеп алган минем тансык ярым,
Үрнәк алып яшик кошлардан.
Шомырт чәчәк аткан якты мизгел
Безнең күңелләргә охшаган.

Күңелемнең йөгәнсез атларын
Күптән инде куйдым тышаулап.
Язмыш сукмагымның синсез көнен
Гөлләремә карап бушанам.

Син китергән гүзәл ак чәчәкләр:
Бәхет юлы — каян башлана.
Ак канатлы күңел учагыма
Кара утын гына ташлама.

КАЙТТЫМ

Кайттым, туган ягым, назга сусап,
Сагындырды назлы җилләрең.
Әнә, Кояш үзе кулын сузган
«Исән-иминме,— дип,— сөйгәнем».

Җилферди җилләрдә болынымның
Аллы-гөлле чуар күлмәге.
Бу сафлыктан, гүзәллектән нәүмиз
Чит җирләрдә туар көннәрем.

Нәни эзләремне эзләп йөрим,
Саклагандыр бәбкә үләне.
Итәк җәеп балык тоткан инеш
Челтер-челтер миннән көләме?

Бала чагым чуер ташларының
Чишмә суы юа битләрен.
Кичерегез, тиле яшьлегемдә
Бәхет эзләп читкә киткәнмен.

Биш дистә ел яшәп балалыктан
Хаятем бит әле чыкмаган.
Өянкеләр хәер-дога укый,
Өмет уты яна чыкларда.

Керфегемнән үбә ай нурлары
Алар да бит мине сагынган.
Һич картаймый күңел, туган якка
Чын күңелдән шулай табынсаң.

ЙӨРӘК ТИБЕШЕҢНЕ СИЗЕП ЯШИМ!

Тәрәзәңә искән җил кагылса,
Миннән сәлам диеп каршы ал...
Язмыш сынавына бирешмичә,
Хыялыңа тугры булып кал.

Йөрәк тибешеңне сизеп яшим,
Оныткандыр диеп уйлама.
Искән җилгә салып сәлам юллыйм,
Башка чарам юк бу дөньяда.

Ак болытлар йөзә зәңгәр күктә,
Ак хыялым шәүләсе булып.
Кар бөртеге кунып керфегеңә,
Назлап үбәр сине мин булып.

АҢЛАДЫМ

Тугач «бердәнберем булсын»,— диеп,
Әти исем кушкан, яратып.
Әмма язмыш җиле каршы исте,
Чарасыздан сынды канатым.

Беренче булырга язды Ходай,
Мин бердәнбер була алмадым.
Шуышырга туган — оча алмый,
Мин бит шуны бик соң аңладым.

Хыялларым изге юлда иде,
Тормыш ай-һай кыйнап карады.
Үрмәләп булса да адашмадым,
Җыр төзәтте йөрәк ярамны.

РӘНҖЕМӘ ӘНИ

Элек авыл юлы шатлык иде,
Кайта идек сагынган саен.
Күчтәнәчкә алып кайта идек:
Конфетларын, шикәрен, маен.

Әни карчык тилмерә ялгызы,
Авыл юлы кыйммәт шул хәзер.
Яртышар ел акчаны бирмиләр,
Очып кайтырга да без әзер.

Кайтыр идек, замана үзгәрде,
Ничек якынайтыйк араны.
«Сагынмыйдыр, күңеле — далада»,— дип,
Рәнҗеп ятма әни балаңны.

ҖӘННӘТ

Нинди рәхәт, нинди ләззәт,
Баш очымда сайрый тургай.
Нәни кошым, мин килгәнгә
Тантана кыласың бугай.

Бытбылдыкның да үз җыры,
Алар да бит монда туган.
Миңа шатлык биргән бакча
Аларның болыны булган.

Кәккүк тә нәрсәдер саный,
Үз ярын эзлидер шулай.
Салмак кына лачын оча,
Аңа да таныш бу тугай.

Юанычым изге җирдә,
Бар шатлыгым — күңел күрке:
Кошчыкларым сайрашыгыз,
Оя корып, бакчам иркен.

Бакчамда үсә йөзем дә,
Карлыган да, бөрлегән дә.

Ходай! Гөлләреңә күмеп,
Миңа җәннәт бирдең мәллә!

ТАУ САКЧЫСЫН КЕМ ТАНЫМЫЙ

Трамвайлар килә-китә йөриләр,
Ашарга да, эчәргә дә бирмиләр...
Һәрбер болтын, шпилен дә санап кал,
Шул арада дугага да күзең сал,
Тормоз, башмак, ком сибүен күреп кал,
Трамвай тирәли йөгереп арсаң ни, ар!
Бу заманда эшсез йөреп кара, бар!

Гомеремне шушы тауга багышлап,
Медаль түгел, бирде киңәш нәчәлник:
— Эштән кумаганга рәхмәтең әйт,— дип.
Фатирны алырсың дөньядан киткәч,
Әгәр дә Сират күпереннән үтсәң,
Бу җирдә яшәп күзеңдә яшь кипкәч,
Күз яшьләреңне Ходай кабул итсә.

Түрәләр артын ялаучы ялагай —
Гаебеңне эзләп торалар, малай.
Кайсы чатта посып мине күзлидер,
Берәр этлек эшләргә һич түзмидер.
Басып торам, утлы энә бәгырьдә,
Менә шулай үтеп бара гомер дә.

Тау сакчысын бу якта кем танымый,
Без икәү: Мулланур Вахитов, тагын мин.
Миндә әле йөрәк дигән нәрсә бар
Һич сер бирмим кояш булып елмаям.
Мине барыбер тез чүктерә алмаслар,
Сезнең кебекләрне генә күргән бар!

Ясалмаганмын мин куркак камырдан,
Нәчәльникләр алышынып торалар.
Үпкәләрне шигъри юлларга салып,
Яшим — вентилятор гүләвеннән көч алып.

АДАШТЫМ

Күңелемдә язгы ташкын,
Тышта сыерчык бураны.
Көпә-көндез мин адаштым,
Сиңа китерде юлларым.

Бөреләр уяныр вакыт,—
Җитми кояш нурлары,
Күз карашың маяк булып,
Яктырта иде юлларым.

Күңелемдә язгы ташкын,
Суынган инде кулларың.
Җылы хисләр көткән җаным
Үртәлеп кайтты нибары.

СӘНГАТЬТӘ ЯНГАН ГОМЕР...

Хатирәләр, хатирәләр... Иске, инде саргаеп беткән көндәлек битләре... Язмаларның бер өлеше — гарәп имлясында, икенче өлеше — урыс телендә. Газиз Айдарский кулы белән ачык һәм матур итеп язылган бу көндәлек битләрендә тарихчылар һәм сәнгать белгечләре өчен бай мәгълүматлар тупланган. Әлеге язмаларда авторның фикер тирәнлеге, кичерешләре дә ачык чагыла һәм күңелне тетрәндереп, дулкынланулы мизгелләр кичерергә мәҗбүр итә. Бигрәк тә гомеренең соңгы айларына караган язмалары тирән кичерешле, фаҗигале. Әйе, татарлардан беренче профессиональ режиссер һәм күренекле актер Газиз Айдарскийның язмышы, фаҗигале булуы ягыннан, башка олуг шәхесләребезнең язмышына охшаш...

Газиз Айдарский (Газиз Исхак улы Вәлитов) 1899 елда Татарстанның хәзерге Яшел Үзән районына караган Айдар авылында (бу төбәк халык телендә Тау ягы дип йөртелә) күп балалы ярлы гаиләдә туа. (Сүз уңаеннан шунысын да искәртеп үтү урынлы булыр: әнием Сара Садыйкованың этисе Гарифҗан да шушы Айдар авылында туган.) Аның әнисе милләте буенча төрек кызы булган. Гаиләнең матди хәле авыр булу сәбәпле, Газизне бик яшьли (10 яшьтә) Әстерхан губернасының Красный Яр шәһәрендәге бер китап кибетенә хезмәтче малай итеп җибәрәләр. Гаиләдән аерылып, яңа урынга күнегү кыен булса да, Газизгә китаплар белән танышу өчен киң мөмкинлекләр ачыла. Ул буш вакытларын китаплар укуга багышлап, тормыш дигән киң дөньяга кереп китә. Гаҗәеп сәләтен һәм тырышлыгын күреп, аны бу кибеттә приказчик итеп калдыралар. Газиз өчен бу еллар беренче «тормыш университетлары» була.

Газиз Вәлитов 1917 елдан башлап Әстерхан шәһәрендәге татар яшьләре арасында мәдәни-агарту эшләре алып бара. Архангельск краеның Мөселман эшләре буенча комиссариатында коллегия әгъзасы булып тора. 1918—1920 елларда эшчеләр комитеты секретаре, инструктор, режиссер була һәм башка эшләр башкара.

Күренекле сәхнә осталары — Касыйм Шамил, Зәйни Солтан һәм башкалар, Әстерхандагы гастрольләре вакытында бу егетнең талантын күреп, аны Казанга чакыралар. 1920 елда Газиз Казанга күчеп килә һәм Татар драма театрына артист булып урнаша. Туган авылына ихтирам йөзеннән, ул Айдарский псевдонимын ала. Биредә Газиз Айдарский күбрәк фаҗигале язмышлы рольләрдә уйный.

Рәсемдә: Газиз Айдарский «Таһир-Зөһрә» спектаклендә Таһир ролендә. (1920 ел.)

Газиз Айдарскийның актерлык сәләте һәм кешелек сыйфатлары нигездә замандашлары истәлекләре һәм җылы хатирәләре аша килеп иреште. Бу хатирәләрне без аның белән бергә уйнаган артистлар, режиссерлар, аның сәхнәдәге эшчәнлеген яхшы күреп белүчеләрнең сөйләвеннән, хатыны Сара Садыйковага язган хатларыннан, артистның көндәлек язмаларыннан, шул чор матбугатында чыккан хәбәрләрдән тупладык.

Газиз Айдарскийны чордашлары җыйнак гәүдәле, төз буйлы, гаҗәеп чибәр, тыйнак һәм шул ук вакытта горур артист буларак хәтерлиләр. Ул сәхнәдә гомергә онытылмаслык образлар тудыра. Газиз Айдарский уйнаган Таһир («Таһир-Зөһрә»), Незнамов («Гаепсездән гаеплеләр»), Кассио («Отелло»), Хлестаков («Ревизор»), Лаэрт («Гамлет») һәм башкалар тамашачыларда соклану һәм тирән кичереш-тойгылар уяталар. Замандашлары искә алуы буенча, ул рольләрне артист буларак кына башкармаган, ә кыска гына вакытка булса да, шул образларга кереп, сәхнәдә алар тормышы белән яшәгән. Газиз Айдарский уйнаган спектакльләрне тамашачылар тын да алмый карап, тормышның үзе кебек кабул итеп, тамаша беткәч тә хисләреннән арына алмый торганнар.

Сәнгать өчен туган, гаҗәеп хисчән кеше булса да, Газиз Айдарский бу елларда зур оештыру, җәмәгать эшчәнлеге дә алып бара: Наркомпросның сәнгать бүлеге мөдире, ачыгучыларга ярдәм оешмасының җәмәгать вәкиле, Казанда корылып ятучы Татар театры бинасы төзелеше җитәкчесе (хәзерге Яшь тамашачылар театры бинасы) һәм башка хезмәтләрне башкара. (Ачлык фаҗигасен ул тетрәнеп, бөтен күңеле белән кабул итә. «Та-

тарстан хәбәрләре» газетасының 1921 елгы 25 август санында басылган «Ачларга ярдәм көне» дигән мәкаләсе — моның ачык дәлиле.)

Газиз Айдарский 1922—1926 елларда Мәскәүдә Дәүләт театр сәнгате институтының режиссерлык факультетында укый. Шунда укыган вакытта (1924 елда) татарның талантлы җырчысы Сара Садыйкова белән таныша һәм алар озакламый гаилә тормышы да корып җибәрәләр. Сара Садыйкова ул елларда консерваториядә укып йөри торган була. Авыр студент тормышын яшьләр «Эшче» Татар драма театрында эшләү белән бергә алып баралар, ләкин зарланмыйлар.

Ул елларны әнием Сара Садыйкова еш искә алып: «Авыррак булган саен, әтиең белән бер-беребезгә ныграк сыендык»,— дип әйтә иде.

1925—1926 елларда Казан сәхнәсендә беренче татар операсы «Сания»не (авторлары Солтан Габәши, Газиз Әлмөхәммәтов һәм Василий Виноградов) куюны режиссер Газиз Айдарский оештыра. Сара Садыйкова бу операда Сания партиясен башкара. Әлеге вакыйга уңаеннан, «Советское искусство» газетасының 1925 елгы алтынчы санында Газиз Айдарскийның «Беренче татар операсы» дигән мәкаләсе дөнья күрә.

Татар театр сәнгате тарихына ул талантлы актер һәм режиссер буларак кына түгел, ә сәләтле оештыручы һәм җитәкче буларак та кереп калган. Мәскәү Татар дәүләт драма театры белән җитәкчелек итү өстенә (Газиз Айдарский бу театрны оештыручыларның иң активы була һәм бөтен талантын, белемен, мәхәббәтен һәм сәламәтлеген шушы театрга бирә), ул «Красный Богатырь» заводы эшчеләренең драма түгәрәген дә җитәкли. Мәскәү «Эшче» Татар драма театры, 1933 елга кадәр эшләп, бөтен ил буйлап гастроль тамашалары күрсәтеп шөһрәт ала.

Мәскәүдәге беренче татар театры хакында Газиз Айдарский үзе болай яза: «Эшче» театры квалификациясе, куелышы белән билгеле бер юл, билгеле бер стильдә, мәгълүм бер тамашачыга юнәлеш тотып эшләргә тиеш. Автономияле җөмһүриятләргә кермәгән Донбасс, Урал, Мәскәү, Ленинград татар эшче массасын үз телендәге, сәнгатьчә нәфис эшләнгән спектакльләр белән тәэмин итәргә тиеш. Менә шул бурычларны үтәүчеләр Мәскәүдә төрле театр, музыка мәктәпләрендә укучы һәм аларга кушылып драма түгәрәкләренә йөрүче яшьләр була. Квалификация ягыннан югары торган театр өчен иң элек артистлар кадрын җитештерү кирәк иде. Менә бу кадр, 1924 елдан бирле Мәскәү сәхнәсендә җитеште. Хәзер Үзәк театр татар пролетариатының үз театры булып әверелде. 1924 елгы Донбасс гастролендә Үзәк Татар театрының караучылары чыннан да татарларның шахтер, металлчы, төзүче эшчеләреннән торган иде.

Мәскәүдәге татар театрын, обыватель, мещан караучылардан коткарып, аны чын эшче театры ясарга, шуның өчен артистлар, репертуар әзерләргә кирәк иде. Инде шулар эшләнде.

Театрыбызның төсен, сыйфатын күрсәтерлек репертуар өчен Үзәк Татар театры күп тырышты һәм күп тикшеренүләрдән соң, әсәрләрне хәзерләүдә мәгълүм бер фәнни юл тотуны кирәк тапты. Рус театр дөньясында танылган Станиславский системасын үзләштереп һәм татарның табигый тормыш кануннарына сыярлык итеп эшләүне өстебезгә йөкләдек. Шул Станиславский методы белән әзерләнгән «Организатор» пьесасы (авторы Салих Баттал.— Ә. А.) Донбасс эшчеләре арасында зур уңыш белән узды. Шул ук Үзәк театр, үткән дәвернең театрларына охшамыйча, коллектив театр булып һәм аның һәрбер художнигы ирекле рәвештә иҗат итеп, шуны авторның биргән идеясенә китереп теркиләр. Шуның өстенә Үзәк театр этнограф, музей да түгел, бәлки ул дөнья пролетариатына хезмәт итүче, көне-төне эзләнүче, илдә социализм төзүгә актив катнашучы, эшчегә тиешле тәрбия бирүче булып, аның алдында коммунизм рухында сәламәт ял иттерү, аңа аң-белем бирү, киләчәк олы көрәшләргә хәзерләү бурычы тора.

Менә Үзәк театрның йөзе шундый...»

Режиссер буларак, Айдарский Станиславский методына таяна, бу театр остасы белән шәхсән таныш була. МХАТның 25 еллык юбилеена Үзәк Татар театры милли бүләкләр белән котларга килә һәм Станиславскийның үтенече буенча, Сара Садыйкова аның өчен борынгы халык көе

«Шәүрәкәй»не башкара (алдан җырның драматик эчтәлеге белән таныштырып куя). Константин Сергеевич актриса янына килеп, кулын үбә һәм: «Сезнең киләчәгегез зур»,— дип әйтә.

Газиз Айдарский премьераларга күренекле сәнгать осталарыннан, режиссерлардан Мейерхольд, Михоэлс һәм башкаларны чакыра һәм алар бу куелышларга, артистларның уенына югары бәя бирәләр. Газиз Айдарский белән эшләгән татар сәхнәсенең күренекле осталары бертавыштан аның намуслы, әдәпле, киң, шигъри нечкә күңелле, зыялы кеше булуын, югары профессиональ дәрәҗәдә эшләвен аерым билгеләп үттеләр. Татар театры тарихында якты эз калдырган сәхнә осталары Хәким Сәлимҗанов, Фатыйма Ильская, Камал III, Фатыйма Янбарисова, Габдулла Йосыпов һәм башкалар, әтием Газиз Айдарский хакындагы җылы хатирәләре белән уртаклашып, күп мактау сүзләре әйттеләр. Мин моның белән горурланам. Әтиемне бик аз хәтерлим, чөнки балачагым әнием ягыннан әби-бабаларым янында — Казанда үтте. Ул миңа гомерем буе кирәк булды. Радиодан «Таһир-Зөһрә» спектакле язмасын ишетсәм, әткәем Газизнең фотосын алдыма куеп, аны күз алдыма китереп, тавышын хәтерләп «терелтә» идем. Хәзер архивка барып, кәгазьләре белән танышам. «Сараны, нәни кызым Әлфияне бәхетле тормышта яшәтә алмадым»,— дип ачыргаланып язган юлларны укып, йөрәгем телгәләнә. Сагынам, бик сагынам әткәемне...

Газиз Айдарский 1930—1931 елларда Казан театр техникумында укыту-тәрбия эшләре алып бара. Мәскәү шәһәрендә нәшер ителгән «Коммунист» газетасы һәм Казанда басылган газета-журнал битләрендә үсеп килүче милли сәхнә сәнгате хакында дулкынланып язган мәкаләләре бербер артлы дөнья күрә. Шушы елларда редакцияләрнең берсендә Газиз Айдарский яшь шагыйрь һәм журналист Муса Җәлил белән таныша. Аларны уртак идеаллар һәм максатлар якын дуслар итеп берләштерә. Соңыннан, 1928 елда Газиз Айдарский шагыйрьне үзенең хатыны Сара Садыйкова белән таныштыра.

Әйе, Газиз Айдарский татар театр сәнгатен аякка бастыру, үстерү өчен вакыты һәм сәламәтлеге белән исәпләшми эшли, гомере шушы изге максатларны тормышка ашыру юлында яна. Ул моны үзе дә яхшы сизеп-тоеп тора һәм мөмкин кадәр күбрәк эшләп калырга омтыла: «Миңа, гаиләдән читтә яшәсәм дә, киләчәк хакына эшлим кебек тоелды, ә ул һаман килмәде, мин эшләдем дә эшләдем һәм үпкә туберкулезы алдым. Һәм кайнап торган, ялкынлы яшь гомер өзелде. Миңа башлап та тәмамлап өлгерә

Рәсемдә: Газиз Айдарский хатыны Сара Садыйкова белән. (1929 ел.)

алмаган барлык эшләр кызганыч... Соңгы көннәр калды... Инде агачлар чәчәк атып бетерде диярлек. Сәрви куаклары, ясмин чәчәк ата...»

1933 елның 30 октябрендә (иртәнге 6 сәгатьтә) Мәскәүдә Газиз Айдарскийның сәнгать өчен янган йөрәге тибүдән туктый. Аны соңгы юлга озату эшләренә Муса Җәлил җитәкчелек итә.

Газиз Айдарскийның театр сәнгате өлкәсендәге эшчәнлегенә дусты Муса Җәлилдән дә тулырак бәһа бирүче булмады: «Газиз Айдарскийның вакытсыз вафаты татар совет сәнгате өчен авыр һәм хәсрәтле югалту булып тора. Мәкерле үлем безнең арадан талантлы театр остасын тартып алды. Аның, моннан тыш, 15 еллык бай сәхнә тәҗрибәсе дә безнең өчен зур югалту булды.

Газиз Айдарскийның иң кадерле сыйфатларыннан үз хезмәтенә фидакарьләрчә бирелгәнлек, шуңа зур мәхәббәт һәм туктаусыз сәнгать өчен яну иде.

Артист сәхнә эшчәнлеге белән генә канәгатьләнеп яшәмәде. Ул, тынгысыз җәмәгать эшлеклесе буларак, үзенең бурычы итеп театр тамашалары куюны гына түгел, ә театрны күтәрүгә хезмәт иткән барлык эшләрдә армый-талмый эшләде. Аның сәхнәләрдә кую өчен пьесалар тәрҗемә итүе мәгълүм. Аның тарафыннан тәрҗемә ителгән «Көннәр агышы», «Әлмәк» кебек пьесалар бик күп татар сәхнәләрендә уйналдылар.

Газиз Айдарский татар театр сәнгате теориясе буенча эш алып барган аз санлы белгечләрнең берсе булып санала иде. Мәскәү шәһәрендә уздырыла торган киңәшмәләрдә татар театры вәкилләре һәм язучылар алдында ул тирән эчтәлекле докладлар белән чыгышлар ясады. Аның тарафыннан «Театр сәнгате» хакында» исемле хезмәте нәшер ителгән. Күренекле артист, Мәскәүдәге язучылар оешмалары белән тыгыз бәйләнештә булып, аларның эшчәнлегендә бирелеп катнаша килде. Ул Мәскәү Пролетар язучылар берлеге татар секциясенең театр сәнгате буенча тәгаенләнгән эшләренә ярдәм итеп торды. Мәскәүдә татар эшче театрын оештыру, зур сәнгать отряды итеп үстерү юлында аның хезмәте биниһая зур булды. Эш өчен янып яшәү ялкыны Газиз Айдарскийда чиксез иде. Замандашлары аның татар эшче театрын, һәм, гомумән, мәдәни казанышларын үстерү юлындагы эшчәнлегенә зур өметләр баглыйлар иде. Шунлыктан аның үпкә чире нәтиҗәсендә килгән вакытсыз үлемен бик авыр кичерделәр. Газиз Айдарскийның шәкертләре аннан үзеңне багышлаган хезмәтне башкару, фидакарьләрчә бирелеп эшләү сыйфатларын мирас итеп алырлар. Безнең яхшы эшләребез сөекле дустыбызның истәлегенә кадерле бүләк булыр».

Тормыш дәвам итә... Бүгенге көндә Мәскәүдә Газиз Айдарскийның сеңлесе Зөбәрҗәт һәм аның балалары яши. Алар барысы да нәселдән килгән фамилия йөртәләр — барысы да Вәлитовлар.

Күптән түгел миңа әтиемнең туган авылы Айдарга кайтырга да насыйп булды. Айдарга сәфәремне оештыруда ярдәм иткән «Яшел Үзән» газетасының баш мөхәррире урынбасары (хәзер инде баш мөхәррир) Люция Шәрәфиевага, Гариф бабам ягыннан туганым, танылган журналист, «Өмет» («Выбор») газетасының баш мөхәррире урынбасары Фәния Әхмәтҗановага, авыл һәм хуҗалык җитәкчеләренә, мәктәп коллективына, әтием турындагы хатирәләре белән уртаклашкан туганым Хәфәзә апа Гарифуллинага, гомумән, Айдар һәм Күгеш авылларының киң күңелле, кунакчыл кешеләренә чиксез рәхмәтлемен.

Авылдашларым Газиз Айдарскийның игелекле эшләре белән горурланып, биредә музей ачу, әтиемнең истәлеген мәңгеләштерү теләге белән яшиләр. Бу өлкәдә беренче зур эш башкарылды да инде: Газиз Айдарскийның тууына 100 ел тулу уңаеннан, Яшел Үзән район хакимияте вәкилләре, танылган язучылар, шагыйрьләр, артистлар һәм журналистлар катнашында, истәлекле кичә үткәрелде. Моның өчен дә мин авылдашларыма олы рәхмәтле. Шундый кешеләребез булганда милләтебез дә яшәр, буыннар бәйләнеше дәвам итәр дип өметләнәм.

ӘЛФИЯ АЙДАРСКАЯ,
балет сәхнәсе ветераны.

<u>ТАРИХИ МИРАС</u>

ЕВРОПА һӘМ ТАТАРЛАР

(ТАРИХИ ПАРЧАЛАР)

ТАТАРЛАР ЕВРОПА ИЛЛӘРЕНӘ БАРА

Ныклап карасаң, татар кешесе Шәрекъ илләренә генә түгел, бәлки Европа җирләренә дә аяк баскан булган икән. Татар тормышына мөнәсәбәтле күп кенә вакыйгалар турында хәбәрдар булып торган «Вакыт» газетасы мөхәррире Фатих Кәрими болай дип яза:

«Татарлар ялгыз Русиянең үзендә генә түгел, чит мәмләкәтләргә китеп тә сәүдә итәләр. Германиядә, Төркиядә, Иранда, Кытайда вә Америкада даими торып, сәүдә итүче татар фирмалары бар. Германиянең Лейпциг ярминкәсе вакытында Касыйм вә Сибирия мөселманнарыннан икешәр йөз кеше була. Ел буенча Берлинга әллә ничә дистәләп татарлар барып кайта. Италия, Франция, Җәзаир, Тунис, Испания вә Португирләрне (Португалияне) үтеп, Инглетерага (Англиягә) барып чыгучы татар сәүдәгәрләре дә юк түгел[1].

Бертуганнар Габделхәмит һәм Мөхәммәтрәхим Казаковларның Берлинда конторалары булган. Алар 1908 елның 1 январенда «Торговый Дом, братья Казаковы и К°» исемендә ширкәт оештырганнар; 2500 сумлык күләмдә устав капиталы билгеләнгән. Габделхәмит әфәнде җәдитчелек хәрәкәтенең күренекле вәкиле булган, әлеге хәрәкәткә даими рәвештә матди ярдәм күрсәткән.

Гобәйдулла Яушев Ливерпуль һәм Нью-Йорк шәһәрләрендәге биржалар белән мөнәсәбәткә кереп, мамык саткан, елына 10 миллион сум чыгарган.

Троицк шәһәрендә Швеция һәм Австрия фирмалары эшләп торган. Казанда татарлар «Эрман, Кильб һәм К°» сату фирма конторасы белән эш иткәннәр. Бу фирма Казанда күп товарлар сатып алып, чит илләргә озаткан. Мәгълүм булганча, Мир-Якубов дигән кеше кабул итеп торучы булып хезмәт иткән[2].

Мәшһүр алтын приискасы хуҗасы Шакир Рәмиев Германиядәге Ланс һәм Кеппель фирмалары белән эш алып барган. Уральск купецлары Гаделшин һәм Гобәйдуллин Берлин фирмалары белән эш бәйләнешләрендә булганнар, алар өчен күн, йон хәзерләп куйганнар, ярым фабрикатлар җитештергәннәр.

Татар сәүдәгәрләре һәм промышленниклары бөтендөнья күргәзмәләрендә катнашалар. Мәсәлән, Казан сәүдәгәре Гайнетдин Сабитов Лондонда зур алтын медаль (1884 ел), Парижда зур көмеш медаль белән бүләкләнә (1888 ел).

Фатих Кәриминең хатирәләре дә безнең өчен бик кыйммәтле. Алар Финляндиядә төпләнгән татар сәүдәгәрләре турында язылган. 1917 елның язында Фатих Кәрими, Муса Бигиев һәм Һади Максуди Финляндияне күреп кайтырга булдылар. Әлек Финляндиянең башкаласы Һельсингфорска (Һельсинкига) бардылар. Шул башкалада егерме биштән артык мөселман фирмасы сәүдә белән мәшгуль икән. Шулар арасында Гомәр Габдерәхимов мануфактура һәм галантерейный товарлар белән, Хәсән Кану-

---

* Ахыры. Башы журналның 1999 елгы 8, 9 һәм 2000 елның 1 санында.

ков каракүл һәм мех әйберләре белән, Габделфәттах Хаҗаев, Фәтхулла карый, Гайсә Мөхәммәтов һәртөрле ефәк, атлас, келәм кебек кыйммәтле Азия маллары белән, бертуган Галиевләр җиләк-җимеш белән сәүдә итәләр. Сәфәрчеләр кайберәүләрнең кибетләренә кереп сәлам биреп чыктылар. Күренә ки, кибетләрен бик әйбәт итеп җыйганнар, товар күп, алучылар тулып тора. Хезмәткә һәм кассага фин хатын-кызлары куелган. Хуҗалар үзләре дә фин телен беләләр һәм күбесе Финляндиядә беренче дәрәҗә урын тоткан швед телендә сөйлиләр икән.

Мондагы татарларның күбесе Нижгород губернасыннан булып, элек бик аз гына булган төп капиталларын үзләренең үткенлеге һәм тырышлыклары аркасында яхшук күбәйтергә муафыйк булганнар, эшләрен яхшы куйганнар, зур файдалар хасил иткәннәр. Кайберәүләр шунда йорт-җирләр алганнар.

Гомәр Габдерәхимов кунакларны үзенең дачасына чакырды. Дачасы башкаланың бер читендә, матур нарат урманнары арасында. Кыш та шунда торалар, чөнки монда иртәдән төн уртасына кадәр электрик трамвай йөреп тора.

Бер якшәмбе көнне Һади Максуди белән Фатих Кәрими Териоки каласына бардылар. Анда зур сәүдә итүче, аңлы яшь сәүдәгәрләрдән Гыймадетдин Җәмалетдинов аларны каршы алып, үз йортына кунакка чакыра һәм шунда сәүдә белән торучы башка татарлар белән күрештерә. Монда да татарлар күп булып, сәүдә эшләрен яхшы юлга куйганнар. Байтагысы үзләренә махсус йорт-җир алганнар. Күбесе Нижгород губернасы, Актук авылыннан булып, авылларын онытмыйлар, анда һәрвакыт иганә җибәрә торалар, җәмгыяте хәйрияләренең 10 мең сум кадәр акчалары бар. Иганә эшләренең башында бертуган Җәмалетдиновлар тора.

Финляндиядә торучы татар сәүдәгәрләре үзара бик тату, бер-берсенә ярдәм итеп торалар. Фатих Кәрими Териоки сәүдәгәрләре арасында Әхмәт Төхфәтуллин, Зиннәтулла Вафин, Камалетдин Байбулатов, Галә Шәмсетдинов кебек аңлы һәм ачык фикерле кешеләрне күрсәтә. Галә әфәнде Галимҗан хәзрәт Галиев (Баруди) шәкертләреннән булып, элек Таммерфорста имамлык иткән. Хәзер Териокидә сәүдәгә керешкән һәм имамлык вазифасын да үти икән.

Күргән-белгәннәрен бергә җыеп, Фатих әфәнде шундый нәтиҗәгә килә: «Финляндиядәге мөселман сәүдәгәрләренең тырышлык, аң вә үткенлекләрен вә шул сәядә тәрәккый итүләрен күреп, бик мәмнүн булдык. Финнәр мәдәният, мәгариф вә сәнагатьтә бик тәрәккый иткәннәр. Алар һәммә нәрсәнең хисабын, акчаның процентын, сәүдәнең хәл вә истикъбален бик яхшы беләләр. Шундый мәдәниятле бер милләт арасында сәүдә кылу һәм байлык хасил итү өчен зур үткенлек кирәк. Финляндиядә торучы мөселманнарда шул бар икән»[3].

Кайбер татарлар Европага барып, кирәкле һөнәрләр өйрәнеп кайта. Әхмәтгәрәй Хәсәни 1910 елда китап, басмаханә эшләрен өйрәнеп, Европада йөри, Швейцария, Польша, Германия, Франциядә була, күп мәгълүмат туплый. Соңыннан «Аң» журналы редакторы булып китә, «Гасыр» нәшрияте оешмасы хуҗаларыннан берсе була.

Мәхмүт Алмаев Германиядә, Лейпциг шәһәрендә типография эшенә өйрәнеп кайта. Күп еллар Казанда Кәримовлар, Оренбургта Кәримов-Хөсәеновлар ширкәте типографияләрендә техник җитәкче булып эшли. Билгеле инде, чит илләрдә укулар арзанга төшмәгән. Хәзерге тел белән әйткәндә, спонсорлар да табылып торган. Шулардан берсе турында Тимерша Соловьев язып калдырган.

1901 елда, май ахырларында Фатих Кәрими белән Тимерша Соловьев Оренбургта Гани бай Хөсәеновның йортына баралар. Бервакыт контордан бер малай менеп:

— Мәхмүт Алмаев дигән кеше килгән. Казанныкы, ди. Сезне күрмәкче була. Ни әйтик? — дип сорады.

Гани бай:

— Алып менегез! — диде һәм Кәрими белән Соловьевка карап: — Кем ул? Сез беләсезме ул кешене? — дип сорау бирде.

Фатих әфәнде Мәхмүт Алмаевның мөселманча яхшы гына мәгълүматлы булуы өстенә Истанбулда һәм Германиядә фән укып кайткан егет икәнен, яшь мөхәррирләрдән булып, киләчәктә зур өметле бер зат булачагын аңлатты.

Мәхмүт Алмаев керде. Гани бай гыйлем ияләрен хөрмәт итүче кеше булганга, Мәхмүт Алмаевны якты чырай күрсәтеп каршы алды. Күрештеләр. Хәл-әхвәл сорашып, бер-берсе белән таныштылар. Мәхмүт әфәнде Германиядәге мәктәпләрне, андагы укыту эшләренең тәртип һәм ысулларын сөйләгәндә, бигрәк тә ибтидаи (башлангыч) мәктәпләр хакында сүз чыкканда, Гани бай зур дикъкать һәм ләззәт белән тыңлап торды[4].

Кагыйдә буларак, алдынгы, киң карашлы татарлар Европага тартыла, андагы фәннәрне, культураны үзләштерергә тели. Әле 1903 елда ук «Казанский телеграф» газетасы шундый хәбәр бирә:

«Күптән генә түгел «Journal de Debat» игълан иткәнчә, Юсуф әфәнде Парижда Ecole Libre de Siences politiques уку йортында чыгарылыш имтиханында өченче бүләк һәм отличиелы диплом алган. Башка Казан татары, С. Максудов әфәнде, ишеткәнебезчә, Париж университетында уңышлы укый. Максудов әфәнде Казанская учительская школаны тәмамлап, белемен Россиядә ахырына җиткерергә өмет иткән иде, ләкин яше буенча һәм хәзерлеге чамалы булу аркасында гимназиягә дә, университетка да алына алмады. Максудов әфәнде, пәйгамбәр васыятенә ияреп, фән артыннан еракка китте, акчасыз, тәэмин ителүдән мәхрүм булып юлга чыккан. Ләкин миһербанлы кешеләр аңа, мөселман җәмгыятенең булачак мәгърифәтле әгъзасына ярдәм иттеләр һәм итәчәкләр»[5].

Данлыклы «Галия» мәдрәсәсен торгызган һәм җитәкләгән Зыя әл-Камали әл-Әзһар мәдрәсәсендә белем алу белән генә канәгатьләнмичә, Парижда тукталып, бер ел философия фәнен өйрәнә.

XX нче гасыр башында Европада белем алган кайбер татарларны атап үтик. 1910 нчы елларда Бельгиядә Льеж университетының инженерлык бүлегендә Мидхәт Рәмиев укыган. Сара Шакулова Парижда Сорбонна университетында математика факультетында укыган. Казанга кайтып, Ләбибә Хөсәенова мәктәбендә геометрия мөгаллимәсе булып эшләгән. Скрипкачы Барый Кәримов Берлинда Югары мәктәптә белем алган. Мирсәяф Кәримбаев 1908 елда Франциягә китеп, Парижда укый. «Вакыт» газетасында ул «Париж мәктүбләре» дигән очерк урнаштыра (1911 ел, 24 июнь). Очеркның беренче юлларыннан ук күренә: автор Франция җирендә үзен иркен, бәхетле сизә. Авторны сокландырган нәрсә — андагы тәртип: «Мәдәниятнең бишеге булган Франциянең тимер юллары да бездәге кебек булмаенча, безнең төшкә дә кермәгән бөек дәрәҗәдә эшләнгәннәр. Поезд килергә алты сәгать, яраб! Сигез сәгать калган икән», — дип вокзалда аяк терәп, чәй эчеп ятучылар монда булмадыгы кеби, сәфәрченең танавы алдында: «Билет юк!» — дип бирәү дә касса тәрәзәсен шап итеп ябып куймый. Менә мәдәният. Менә теләсә ничаклы юлчы булсын — барсына да билет та җитә, көтеп утырырга да туры килми. Биш минутта бер поезд килә, станцияләрдә поезд фәкать бер минут тора».

Россиядә күренмәгән тагын бер могҗиза күзгә чалына: бае, ярлысы, ире, хатыны, хәтта ун-ундүрт яшьлек балалар да бертөрле фараз нәрсәне, яки закон кушкан бер эш эшләнгән төсле, һәммәсе иртәнге газеталарны сатып алып укырга тотыналар, тәүлек эчендә дөньяда ниләр булганны белеп, француз вә башка милләтләрнең мөхәррирләре язган мәкаләләрне

укып, рухани ләззәт белән ләззәтләнәләр. Барысы да укуда булганга, вокзал да гүя бер мәктәпкә кереп торган төсле тоела иде.

Халыкның укырга гадәтләнүе эзсез калмый, кешеләрнең үз-үзләрен тотышларына да йогынты ясый: «Күч кебек халык һичбер низагсыз, һич бер кычкырышсыз вагоннарга менә. Барсы да әдәпле, берәү дә кеше урынына утырмый, станциядә бер генә булсын жандарм яки бүтән шундый зат юк».

Ирексездән сораулар туа: «Бу нигә болай икән? Әлеге кешеләрнең җирләре дә, эшләргә куллары да дистәләп түгел, үзләре дә башка кешеләрдән аермалы түгел. Нигә соң монда бар нәрсә дә уңа, бар орлык та тишелми калмый, өйләр түбәсез түгел, тәрәзәләрдән җил өрми, берәү дә ач түгел!»

Һәм Мирсәяф байтак кына «материалист» тарихчылар, социологлар өнәмәгән җавап таба: «Бу — гыйлемлек җире. Монда белем көчсез кешене табигатькә баш итә. Бу — бәшәрият, мәдәният җире».

Мирсәяф — шагыйрь, журналист. Самара каласыннан. 1908 елны Самарада кулга алынып, күпмедер вакыт төрмәдә утыра. Аннан соң Франциягә китә, Парижда Сорбонна университетына укырга керә. 1908—1910 елларда Парижда рус телендә чыккан «Мусульманин» журналында секретарь булып эшли, Л. Н. Толстой белән хат алыша.

Күренекле татар эшлеклесе Йосыф Акчура да Парижда укый, Садри Максуди белән дуслашып, аралашып китә. Әмма чит илдә уку, мәдәниятнең җимешләрен тату Акчураны туган якларыннан биздерми. Ул да, башка акыллы, намуслы татар зыялылары кебек, татар культурасы белән элемтә тотуны туктатмый. Татар культурасы үзәгендә торучыларның берсе — Гаяз Исхакый. «Гаяз илә иң әүвәл Парижда таныштым,— дип яза Акчура.— Мәктәп аркадашым Садрида аның портреты һәм «Кәләпүшче кыз»ы бар иде. Татар әдәбиятыннан иң күп тәэсир белән укыган китабым «Кәләпүшче кыз» булды. Мәмләкәттән ерак идем, ул заман зиһенемне Казанның карлы, тавышсыз, җансыз көннәре, кыска буйлы татарларның йомшак киез итекләре илә Пләтән урамында сак кына йөрүләре, мәчет манараларыннан бер дә еракларга сузыла алмаенча, эре-эре яуган кар кисәкләре арасында югалган азан тавышлары — хөласа татарлар Казаны тутыра иде. «Кәләпүшче кыз»ны укыр көн шул Казанда гомер иттем һәм милләтемә чыккан иң тәһлекәле (куркынычлы), иң агулы бер чуанның сызлавын үз рухымда хис кыларак гомер иттем. Хикәянең икенче басылуында гыйлавә ителгән хатны укыганда чыдый алмадым, Картье Латэн мөсафирханәләреннән берсенең караңгы, фәкыйрь бер бүлмәсендә япа-ялгыз, мескен татар кызының секуты (түбәнгә төшүе), фәлакәте (бәхетсезлеге), атасының тәэсире шәфкате итеп озак-озак еладым[6]».

Татарлардан Европа илләрендә һәм башка илләрдә хезмәт итеп йөрүчеләр дә булган. Шулардан берсе татар диңгез капитаны Каюм Саттаров иде. Ул җир шарының диңгезләрендә йөзеп, 25 еллар үзенең милләтеннән аерылып торырга мәҗбүр булган. Ләкин күпме вакыт узмасын, үз илен, үз милләттәшләрен сагынып яшәгән. Иленә кайткач, 1914 елның 24 гыйнварында Казанда, «Шәрекъ клубы»нда «Мөгаллим» пьесасы буенча куелган спектакльне тамаша кылган. Күргәннәрен, тәэсирләрен учитель Фатих Сәйфи белән уртаклашкан, аңарга мондый сүзләр сөйләгән:

— Мин үз гомеремдә күп җирләрдә, күп милләтләр арасында булдым. Миңа Аурупа вә Америка театрларының иң шәпләрендә, иң мәшһүрләрендә булгаларга туры килде. Күп уеннар, күп җырлар, концертлар, мәшһүр артисткаларга очрадым. Ләкин боларның һәрберсендә мин шушы тәбәнәк, кечкенә заллы «Шәрекъ клубы»нда алган тәэсирне ала алмадым. Мәдәниятле халыкларның сәнаигы нәфисәнең иң соңгы ысулында эшләнгән зур, биек, матур сарайларында гали тәрбия алган, чын мәгърифәтле халык алдында буласың, телләрен аңлыйсың. Танышларың,

хәтта дусларың була. Шунда да ничектер син ялгыз, чит тоеласың. Әмма «Шәрекъ клубы»нда бар да сөйкемле, дөрес, якын танышларым булмау сәбәпле, бераз гына уңайсызлык сиздем. Ләкин ул миндә тиз бетте. Мин монда туган телемне, туган тавышымны тыңладым. Хәтта сәхнәдә сөекле әнкәмнең исемен ишеттем. Чын татар телендә, эшләнгән татар телендә шигырьләр, декламацияләрне ишеттем. Янымда- тирәмдә чын мәгърифәтле, гали тәрбияле туганнарымны, туташлар-сеңелләремне күрдем[7].

Европага сәяхәт иткән кайбер татар кешеләрен дә телгә алыйк. Габдерәшит Ибраһимов 1897—1900 елларда дөньяны гизеп йөргәндә Франция, Италия, Австриядә була. Фатих Кәрими 1899 елда Шакир Рәмиевнең юл иптәше һәм тылмачы сыйфатында Европаны күреп кайта. Иленә кайтып, күргән-белгәннәрен «Аурупа сәяхәтнамәсе» дигән юл язмаларында язып калдыра. Бу китап җәмәгатьчелек игътибарыннан читтә калмый. Бу вакыйгаларны хуплап, беренче татар туристларының Европага йөреп, культура аралашуларына үз вакытында «Тәрҗеман» газетасы да югары бәя бирә.

Татар сәяхәтчеләре Парижда «L'Athénée de France» исемле фәнни-әдәби җәмгыятенең гомуми җыелышына кунак итеп чакырылалар. Француз журналистлары һәм әдәбиятчылары татар кунакларына аерым игътибар бирәләр, ә мәҗлеснең дәвамында Шакир әфәнде татар телендә кыска гына нотык сөйли. Аның сүзләрен Фатих әфәнде шунда ук француз теленә тәрҗемә итә. Француз газеталары хәбәр итүенчә, татар сәяхәтчеләре французларда яхшы тәэсир калдырдылар.

Рус матбугаты да читтә калмады, әлеге китапка бәя бирде: «Автор үзенә хас аңлаешлы һәм әдәби телдә үзенең Европа буйлап сәяхәт иткәнен образлы итеп тасвирлый. Автор Германия, Голландия, Бельгия, Франция, Швейцария, Австро-Венгрия, Румыния, Болгария һәм Төркиядә булган. Китап кызык һәм күз алдына китерерлек итеп язылган. Ул азмы-күпме интеллигент яки һәрхәлдә күп китап укыган кешегә бүгенге Көнбатыш һәм Якын Көнчыгыш хакында кызыклы материал бирә[8]».

Ф. Кәрими язган китап чыннан да кызык һәм мәгълүматлы. Автор вак-төяк нәрсәләргә артык тукталмыйча, иң элек Европа илләрендәге мәдәни күренешләргә күз ата (музейлар, китапханәләр, театрлар, архитектура, һәйкәлләр, матбага һ. б.). Иң кызыклысы шунда ки, Ф. Кәрими гареп вә шәрекъ культураларын нindидер бер синтез рәвешендә күзалларга омтыла. Бу очракта немец философы Иоганн Гердерның бөтендөнья культурасы турындагы тәгълиматы Ф. Кәримигә йогынты ясамый калмагандыр.

Тагын бер татар сәяхәтчесе — Искәндәр Курамшин. Ул үз ирке белән, үз көченә генә таянып, бары 75 сум акча белән Россиядән чыгып киткән, бөтен Европаны йөреп бетерергә өстенә алган. Ул Грециядә, Палестинада, Гарәпстанда, Мисырда, Суданда, Алжирда, Туниста булган; Италиягә, Швейцариягә, Голландиягә киткән. Англиядә, бер хәреф инглизчә белмәгән кеше, алты ай торган вакытта ул яхшы гына инглизчә белә башлаган[9].

Бер төркем Дума депутатлары Англиядәге «Россия әхвален өйрәнү» җәмгыяте исеменнән Англиягә дустанә чакырылган иде. Чакырылганнар арасында Садри Максуди дә бар иде. Европага беренче баруы түгел, Франциядә, Парижда берничә ел яшәгән, Сорбонна университетында укыган. Шуңа күрәдер, юл язмаларында тирә-якка айнык карашта була, тышкы, тантаналы якларны гына күреп калмыйча, Европа илләренең иҗтимагый төзелеше, икътисади хәле, тәрәккыять юллары, тарихи хәтер, милләтара мөнәсәбәтләр хакында, кайбервакыт Россия белән чагыштырып, җитди уйлана. Англиядә йөргәндә Садри Максуди төрле җыелышларда чыгышлар ясый, кешеләр белән аралаша. Тылмач ярдәменә мохтаҗ булмый.

Кунаклар парламент мәҗлесенә дә чакырыла. С. Максуди тирә-якны күзәтеп, төрле уй-фикерләр кичерә: Великая хартия вольностей 1215 елда бирелгән Англиядә бу беренче хөррият вәгъдәсе, моннан җиде гасыр әүвәл бирелгән иде. Хөррият манифесты Русиядә 1905 елда, 17 октябрьдә чыкты. Шуннан чамалап, Англиягә нисбәтән ничә гасыр артта икәнебезне аңлап булыр... Әлбәттә, сайлау хокукының киңәйтелүе, тигезлекнең җәелүе, конституциянең камилләшүе үзеннән-үзе булмады. Хокуктан мәхрүм кешеләр авызны күтәреп: «Алма, пеш, авызыма төш», дип тормады. Киресенчә, хокуктан мәхрүм инглизләрнең бик күп тырышулары, бер туктамый тырышлык итүләре, мөмкин булган саен һәр җирдә үзләренең хокуксызлыкларын халыкка аңлатулары, мөнәсәбәте килгән саен кычкыру, сөйләүләре аркасында гына бу хокук тигезлеге вөҗүдкә чыкты. Бу хокук тигезлеге һәр милләттә, һәр мәмләкәттә шулай озак заманнар тырышу аркасында алына. Татарда бер мәкаль бар: «Еламаган балага имилек бирмиләр». Бу мәкаль сәясәттә дә кулланыла. Еламаган балага сөт бирмәгән кебек, сорамаган кешегә дә хокук бирмиләр. Сорагач та тиз генә бирмиләр. Фикердә, эштә нык тору, гайрәт вә үзеңнең хокукыңның мөкатдәслегенә, газизлегенә тирән бер иман лазим. Үзенең теләгәненә үзе ышанмаган кеше инсан түгел кебек, үзенең теләкләренә ышанмаган милләтләр дә милләт түгел. Французлар: «Инсан үз язмышының тимерчесе булырга кирәк»,— диләр. Инсан гына түгел, милләтләр дә шулай ук. Хәрәкәтсез, гамәлсез, кулын баглаган ялкау зарланучылардан да сөйкемсез кеше юк...

Менә тиҗари Англиянең тоткыларыннан берсе булган Ливерпуль шәһәре. Бу исем Садри әфәндегә Даниэль Дефоның «Робинзон Крузо» исемле романын тәрҗемә иткән чагыннан ук таныш. Хәзер үз күзе белән күрә. Мәҗлес «Аделфи отель» залында хәзерләнгән иде. Зал белән янәшә бүлмәдә хатын-кызлар оркестры уйный. Кем кайда утырасы махсус карточкалар ярдәмендә алдан билгеләп куелган. Садри әфәнде мәҗлеснең ахырында нотык сөйләячәк.

«Гладиаторларның керүе» маршы уйнала. Бу җиңел, күңелле, шатлыклы бер көй. С. Максуди сөйләячәк фикерләрен уйлый. Мөселманнарның хокукта тигезлеге хакында да берәр сүз әйтми булмый. Ләкин бу хакта бик күп сөйләп, хуҗаларның кәефен җибәрүдән сакланырга кирәк. Кунак итәләр дип кенә хакыйкатьне әйтми калырга да разый түгел. Рус иптәшләре аның мөселман мәсьәләләреннән хокуктан бәхәс итәчәген белгәнгә, бераз куркып торалар. Садри әфәнденең вазифасы читен иде: бүре дә тук булсын, сарыклар да исән калсын. Бу — сәясәт. Беркатлы, аңгыра кешеләр өчен түгел.

Садри әфәнденең алдан язып куелган кәгазе юк. Ул кәгазьгә карап сөйли белми. Һәрвакыт сөйләгәндә, кирәк Думада булсын, кирәк башка җирдә, электән бер план хәзерли дә шул план буенча бер кат алдан сөйләп карый.

Мәҗлеснең рәисе торып:

— Нәүбәт мистер Махзудов, Думаның мөселман партиясе әгъзасына,— дип игълан итте.

Садри әфәнде аякка басты. Алдында ап-ак дәстәрхан белән капланган өстәл, өстәл өстендә стаканнар вә бокаллар рәт-рәт тезелгән. Ике өстәлнең ике тарафында йөз илледән артык кара фраклы, ак күлмәкле инглизләр күзләрен Садри әфәндегә текәделәр.

— Мөхтәрәм әфәнделәр! — дип сүзен башлады Садри әфәнде.— Сездән сүземне үз лисаныгызда сөйли алмаганымны гафу кылуыгызны үтенәм. Мин французча сөйләячәкмен. Лисаныгызны лазим микъдарда белмәвемә тәәссеф итәм.

Думачыларны кунак иткән илгә һәм кешеләренә тиешле мактау

сүзләрен әйткәч, Садри әфәнде төп мәсьәләгә — Россия мөселманнары хәленә күчте.

— Мин мөселман бер депутатмын. Русиянең Шәрекъ татарында садә татар кавеменнән бер депутат. Татар дигәч, европалыларның күңеленә килешсез киемле, җирәнгеч чырайлы, кысык күзле, озын сөңгеле, уклыҗәяле, атка атланган бер монгол килә. Сәяхәтчеләр юл истәлекләрендә татарларның рәсемен теләсәләр ничек итеп күрсәтсеннәр. Тарихта һәр кавемнең ата-бабалары төрле хәл вә кыяфәтләрне кичергәннәр.

Мәгълүмегез булсын ки, Русиядәге төрек вә татар кавеме хәзер дә андый бер халык түгел. Гади, мәдәниятне күптән кабул иткән вә мәдәният галиянең юлына кергән 20 миллионлы кабилиятле бер милләт.

«Бүреләрне тукландыру» максатыннан Садри әфәнде татарларга Россиядә киң хокуклар бирелгәне турында әйтте. Аннары «Эзоп теленә» күчеп, шундый сүзләр өстәде:

— Әһле исламга милияләрендә булышу никадәр артык күрсәтелсә, аларның ватанга мәхәббәтләре шулкадәр арта. Дәүләт эшләренә никадәр катыштырылсалар, дуслыклары да шул дәрәҗә арта.

Оста төзелгән нотык залда утыручыларга хуш килде. Нотыкның башыннан ахырына кадәр кул чабулар туктамады. Ләкин Государственный Совет әгъзасы булган бер урысның бөтенләй кәефе китте. Күзәтүчән буларак, Садри әфәнде моны абайлап алды: «Бу кеше үз фикерен миңа әйтеп бирмәсә дә, аның кем икәнен белгәч, уйлап белүе читен түгел иде. Бу кешенең Англия халкына Руссиядә егерме миллион кадәр мөселман булганын һәм мөселманнарның аерым бер милләт булганын белдергәнгә эче поша иде. Бу кеше шул һаман мөселманнарны күндәм лакей, честный дворник итеп кенә күрсәтәсе килә. Хәтта үзенең барин табигате белән, кайда булганын онытып: «Татар баласы, синең боларны сөйләргә ни хакың бар?» — дип кычкырырга кыҗыраганга охшый иде. Ләкин татар баласы моны аңардан сораячак түгел. Дөньялар үзгәргән, хәлләр башка!»

ФАТИХ КӘРИМИ ҺӘМ ВАМБЕРИ

Фатих Кәриминең бай тормышы сәхифәләреннән берсе — мәшһүр венгр ориенталисты-галиме Арминий Вамбери белән танышлыгы. Ничек башланды соң бу тарихи танышлык?

1894 ел. Ф. Кәрими Истанбулда укый. Бер җомга көн иртә белән мәктәптән чыккач та ул туп-туры «Лондра» (Лондон) отеленә юнәлде. Берничә көн элек Истанбулга килгән Вамбери шул отельгә урнашкан иде. Ф. Кәрими аның белән күрешергә тели. Шул вакытка кадәр Вамберине тануы тик аның бер генә әсәре арадашлыгы белән иде. Китап «Бер дәрвишнең Урта Азиядә сәяхәте» дип исемләнгән иде. Бу мәшһүр әсәр Европа телләренең күбесенә тәрҗемә ителгән, хәтта төрекчәсе дә бар икән, ләкин солтан Хәмид идарәсе боларның барсын да тыйган. Төрекчәсен һич табып булмый. Фатих Кәрими аның француз китапчысыннан бик курка-курка, качып кына алды, чөнки яшерен полиция агентлары күрсәләр, эш харап буласы иде.

Мәктәптә укыган вакытта Ф. Кәримигә ул китапны яшереп кесәдә йөртергә туры килде. Ник дисәң, мәктәптә укучыларның өстеннән күзәтүчеләр ике-өч көнгә бер мәртәбә йокы бүлмәләрендәге сандыкларны һәм урыннарны тентеп чыгалар иде. Укыганда да качып, яшереп, китапның битләрен берәм-берәм ертып, дәрес китабы арасына салып кына укырга туры килә иде, югыйсә тапсалар, каты җәза бирелә. Тагын бер кыенлык — Ф. Кәрими французчаны да әле тәмам аңлап бетерә алмый, лөгать ярдәменә мөрәҗәгать итә.

Ничек кенә булмасын, Ф. Кәрими китапны укып, аңлап чыкты. Вамберине читтән торып яхшы гына таныды.

Бервакыт Вамбериның Истанбулга килүе хәбәре ишетелде һәм Кәримидә аның белән күрешү теләге туды. Әмма ничек итеп күрешергә? Урамда мәктәп киеменнән башка йөрергә ярамый, ә инде шул киемдә отельгә керсәң, полиция агентлары якадагы номерны язып алалар да мәктәпкә хәбәр бирәләр. Теләгән — елан итен ашаган, диләр. Ф. Кәрими шул отельгә кереп, Вамбери урнашкан номерны сорап, янына керде.

Вамбери, Ф. Кәрими тасвирлаганча, «кыскарак буйлы, чәч-сакалына чал керә башлаган, башына пәрәмәч кебек бер нәрсә кигән бер кеше» булып чыкты. Болар төрек телендә сөйләштеләр. Ф. Кәримине кызыктырган мәсьәләләр Ислам дөньясына мөнәсәбәтле иде, чөнки Вамбери күп газета-журналларда мәкаләләр бастыра, европалыларны Шәрекъ илләре хәлләре белән таныштыра. Европа илләрендә һәм Төркия даирәләрендә дә ихтирам казанган шәхес, белгеч, галим.

Ф. Кәрими дикъкать белән тыңлады һәм соңыннан Вамбериның кайбер сүзләрен хатирә дәфтәренә теркәп куйды: «Урта гасырларда христианнарның хәле хәзерге мөселманнардан күп түбән иде. Европа мәдәнияте христианлыкның авторитетын какшатып, мәйданга чыкты. Ислам дөньясында исә артта калу Ислам динендә булуга бәйләнмәгән. Азиянең үзенә махсус бер карашы, бер мәдәнияте бар, ул меңәр еллар дәвам итеп килгән; хәзер аны бердән сындырып ташлап, аңа бөтенләй башка булган Европа мәдәниятен кабул итү бик читен. Ләкин төрекләрне идарәсезлек харап итә, алар Европа ярдәме белән мәдәнияткә керә алалар. Европаны бу хәлгә китергән нәрсә аларның фикердә һәм гамәлдә ныклы булуларында, аларның сәясәтендә дә».

— Сез, Россия мөселманнары, гыйлем вә мәгарифтән мәхрүм, икътисади, иҗтимагый яклардан бик түбән. Сез әллә кайчан славян дәрьясы тарафыннан юылган булыр идегез. Сезне аннан бер генә нәрсә саклап калды: туплар белән тишелмәслек дәрәҗәдә каты динлелек,— дип йомгаклады әңгәмәне Вамбери.

Шул очрашудан башлап, Вамбери Ф. Кәримине күздән югалтмый, аның иҗатын күзәтеп бара, европалыларны аның әсәрләре һәм карашлары белән таныштыра. 1905 елда Вамбериның «Татарларның уянуы» дигән мәкаләсе Лондонда «The Nineteenth Century» («Унтугызынчы гасыр») исемле журналда басылып чыга. Мәкалә тирән эчтәлекле, мәгълүматлы һәм татарларның сәяси-мәдәни уянуында, алга китүендә дөнья җәмәгатьчелегенең дә катнашын фараз итәргә мөмкинлек бирә. А. Вамбери Ф. Кәрими фигурасына аерым туктала, аны киң карашлы, тирән белемле, ялкынлы тәрәккыйпәрвәр итеп яктырта. Менә ничек яза, мәсәлән, Вамбери Ф. Кәриминең «Кырымга сәяхәт» дигән әсәренең төп юнәлеше хакында:

«Бүгенге цивилизацияне төпле рәвештә үзләштергән, Көнбатыш тормышына тирән караштa булган Мөхәммәт Фатих Аурупа белән Америка тарихын һәм географиясен яхшы белә, дөньяга хәзерге чор күзлегеннән карый. Аның китабында (мин аны төгәл тәрҗемә итәргә тырыштым) без бу шәрекъ кешесенең дини, иҗтимагый, сәяси карашларына карата чиктән тыш йогынты ясаган үзгәрешләр турында ышандырырлык дәлилләр табабыз. Юлда күргән шәһәрләрне, илне сурәтләвендәге (Русия мөселманнары тормышын өйрәнүче көнбатыш кешесенә бу сурәтләү яңалык һәм бик кызыклы) күп кенә мөһим детальләргә дә игътибар бирә, без бигрәк тә аның Ислам белән хәзерге заман цивилизациясенең үзара мөнәсәбәтләре, диндәшләр һәм ватандашларының артта калганлыгы, Көнбатыш культурасын котылгысыз рәвештә үзләштерү зарурлыгы мәсьәләләрен колачлаган күзәтүләре һәм фикерләре белән кызыксындык».

Ф. Кәримигә язган бер хатында (1905 ел, 10 июль) Вамбери «Кырымга сәяхәт»не тәрҗемә итүен белдерә (хатларын ул татар телендә яза).

«Тәрҗеман» газетасының мөхәррире вә өстен булган сахибының, ягъни Исмәгыйль бәк хәзрәтләренең хакы бардыр. Бәндәгез төрле-төрле хакыйкатьләр вә яхшы эшләр белән туп-туры булган сәяхәтнамәгезне тәрҗемә итәргә телим, ләкин лисан уңышына әле карар бирмәдем: я инглизчә, я алманча галиягезгә камил шатлык белән җибәрергә ихтыяр итәчәкмен. Китабыгыз фикерләр вә белдерү ягыннан гадәттән тыш әсәрләрдән лаеклы вә госман әдәбиятында әсәрегезгә охшаган бер китап чыкмады. Инде аның өчен дикъкатемне җәлеп итеп, бер газета, ягъни «Nineteenth Century and after» дә бастырып, балкыган мәзмүнен белдерермен».

Киләсе хатында (1905 ел, 9 декабрь) Вамбери болай дип яза:

«Бу көннәрдә гаҗизанәмгә багып җиткән мәктүбегезне камил шатлык белән алдым. Соңгы вакытларда зат разыйләт галиягез илә артыграк мәшгуль булдым: чын каләмегез әсәре булган сәяхәтнамәгезнең тәрҗемәсе тәмам булып, иншалла, якыннарда китап басучы вә нәшир эшне башлап җибәрер.

Әсәрләрегез кадерле вә әһәмиятле фикерләр вә яктылык бирүче вөҗдан белән тулы. Сез, әфәндебез, ачык сөйләп, тыелмыйча, милләтегезнең косурларын вә хаталыкларын мәйданга куеп, тәрәккыйне бурыч итеп куеп, мөкатдәс ватанга бөек хезмәт итеп, кыз кардәшләрегез вә чит ил кешеләре күзендә хөрмәткә вә тәшәккергә лаек булдыгыз. Төрек милләте сезнең кебек гайрәтле вә зиһенле, ваемсызлык йокысыннан уяныр, диясез, әфәндем.

Шөкер итик, золмәт төнендә берничә йолдыз ялтырый башлады. Һич шөбһәм юк, милләтегезнең киләчәге нурланган офык дәрәҗәсенә ирешәчәк. «Әссабыр мифтах әлфәреҗ» (Сабырлык — ярыкка ачкыч.— Э. Н.) дигән сүзләрне күз угында тотып, төн вә көн эш артыннан йөрү вә гайрәтле булу төрек милләтенең башлыкларына дәрәҗә китерер».

Тәрҗемә өстендә эшләү вакыт ала, күрәсең, чөнки берничә ай үтүгә Вамбери Ф. Кәримигә багышланган чираттагы хатта (1906 ел, 17 февраль) бу мәсьәләгә кабат кайта:

«Могътәбәр «Вакыт» газетагыз чыгуына чын күңелдән тәбрик итәм. Чыннан да, тәрбияле милләтегез тәрәккыенә күп тырышлык бирәсез. Әгәр татарлар гайрәтле, ватанпәрвәрле галиягездән гыйбрәт алып бу юлда дәвам итсәләр, милләтегезгә бөек хезмәт иткән булырсыз, әфәндем. Хаким булырсыз.

«Кырымга сәяхәт» исемле гали әсәрегезнең тәрҗемәсен күптән бетердем. Ләкин моңа кадәр бастыру вә нәшер белән шөгыльләнә алмадым. Һәрникадәр хезмәтем өчен яхшылыкка каршы таләбе булмыйча, эчкерсез мәнфәгать уртаклашам. Ләкин катгый өмет итмим. Әгәр галиегез һәр яктан тиешенчә дәрәҗәдә игътибар итсәгез, әлбәттә, нәшер булыначак, әфәндем.

Бакый ихтирам вә сәлам, мәхәббәт гыйбадәт кылучыларга тәкъдим итәр Вамбери бәндәләре».

1906 елның 10 апрелендә язган хатында Вамбери «Таймс» газетасында Ф. Кәрими хатына (нинди хат икәнен әле киләчәктә ачыклыйсы бар) җавап китерелгәне турында хәбәр бирә.

Ф. Кәрими җитәкләгән «Вакыт» газетасы Вамберинең эшчәнлегенә уңай бәя бирә, татарлар тормышы белән кызыксынуын хуп күрә. «Аурупа газеталарында татар рәсемнәре» дигән мәкаләдә[10] болай дип языла: «Венгриянең пайтәхете улан Будапешт шәһәрендә торучы фазыл мөстәшрик (ориенталист) профессор мусье Вамбери җәнаплары безнең «Вакыт» газетасында дәрҗ ителмеш улан (кертелгән) Петербургта кичен январьдагы Җәмгыять исламия әгъзаларының рәсемнәрен Маҗарстанның мәшһүр рәсемле газеталарыннан «Вазанапи узаж» исемле бер җәридәгә табигъ вә нәшер иттермеш һәм бу хосуста үз тарафыннан бер мәкалә язмыштыр.

Шул рәсемнәр дәрҗ ителмеш газета мума иләйһи (исеме телгә алынган) профессор әфәнде җәнапларыннан әхсән боерыгы идарәханәбезгә килде.

Моннан ул «Вакыт» газетасының таралуы башламасы хакында тагы Англиянең мәшһүр «Таймс» газетасына күп гүзәл шәйләр язмыш иде. Шуның үзеренә Ауропадан «Вакыт» идарәсенә берничә тәбрик мәктүбләре (хатлары) килде.

Моннан башка бу зат мөхәрриребез Фатих әфәнденең «Кырымга сәяхәтнамә» әсәрен тәмам инглизчәгә тәрҗемә итмеш улып, якында табгы вә нәшер улыначак.

Мусье Вамбери җәнаплары Ауропаның иң фазыл голямасыннан вә исламият галәменә иң вакыйф (аңлаучы) затлардан һәм дә төрек вә татар миллиятенең иң күп хәер хаһларыннан улып, Ауропа матбугатында һәрвакыт болар хакында гүзәл шәйләр язмактадыр.

Фазыл мусье Вамбери җәнапларына татар милләте намыннан самими тәшәккерләр җиткерү «Вакыт» һәйәт идарәсе үзенең бурыч йөкләмәсе дип белер».

Хат язышу дәвам итә. Вамберинең 1906 елның 18 июлендә язган хаты да игътибарга лаек:

«Гыйлемнәр вә фәннәрне максат итеп куючы, фикердәшләр булучы чинлы, рус, татар, я маҗар, я алман булсын, һәммәсенә — алга киткән фикерләренә, рухи бердәмлеккә тәнкыйди анализ гайрәтен сарыф итегез. Әгәр бу мәсьәләдә бер нәтиҗә хасил булса, наданлык, караңгылык белән бергә золым вә деспотизм юкка чыгачак. Халык киң тереклеккә, муллыкка ирешер вә гомуми сәгадәт казаначак. Сез, татарлар, бу бабта тырышлык вә сәләтлелек күрсәтәсез, бер-ике ел эчендә галәмне хәйран итәчәк дәрәҗәдә тәрәккый иттегез. Әгәр бу юлда дәвам итсәгез, аз вакыт эчендә башкалардан өстен булып, борынгы заманнардагы кебек, муллыкны, куәтне казанырсыз. Шул вакытта туры юлга гыйлемнәр күндерүче, гомумны тәрбияче исеменә ирешәчәксез».

Бу хат агымдагы эшләрне, вакыйгаларны гына түгел, бәлки татар җәмгыяте хәрәкәтенең тарихи перспективасын күздә тота. Хатта татарларның иҗтимагый-икътисади һәм мәдәни тормышларының тизләтелгән үсешенә өмет баглана, чөнки, Вамбери карашынча, татарлар ата-бабаларының куәтен яңа тарихи этапта яңадан торгыза алачаклар. Сүз җаенда бу хатның мөндәриҗәсе «Будапешттан» дигән мәкалә башы белән «Вакыт» газетасына урнаштырыла[11]. Редакция исеменнән түбәндәге искәрмә кителә: «Профессор Вамбери җәнаплары дидекенчә, безнең милләтебездә истигъдад вә моннан өстен тагы аңлый белү куәте бар, ләкин тәэссеф (үкенече) шунсыдыр ки, эшләребездә дәвам вә сабыр юктыр. Иштә бу көнгә кадәр ушбу косурлыгыбыз сәбәбеннән, һәртөрле файдалы шәйләрдән мәхрүм тордык. Җәнабе Алла бу гадәтебезне тәбдил итәргә (үзгәртергә) муафыйк боерсын».

ИСКӘРМӘЛӘР

[1] Вакыт.— 1911.— 23 июнь.
[2] Казанский телеграф.— 1897.— 9 октября.
[3] Россия сәүдәсе.— 1917.— № 10.— Б. 70—71.
[4] Гани бай: Истәлекләр.— Б. 254—255.
[5] Казанский телеграф.— 1903.— 28 августа.
[6] Казан мохбире.— 1906.— 5 ноябрь.
[7] Йолдыз.—1914.—11 февраль.
[8] Казанский телеграф.— 1903.— 29 января.
[9] Ил.— 1914.— 2 январь.
[10] Вакыт.— 1906.— 11 май.
[11] Вакыт.— 1906.— 23 июль.

ЭНГЕЛЬ НИГЪМӘТУЛЛИН,
филология фәннәре кандидаты, доцент.

(Тәмам.)

Алтын Урда тарихы

ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТЧЕЛЕК ТАРИХЫНЫҢ ТӨП ЭТАПЛАРЫ ҺӘМ РӘВЕШЛӘРЕ

XX гасыр башында татарлар арасында милли азатлык хәрәкәтенең әйдәп баручыларыннан берсе — күренекле сәяхәтче һәм татар әдәбияты классигы Гаяз Исхакый татар халкының эчке сәяси-дәүләти егәрен болай дип бәяләгән иде: «Көрәштә чыныккан һәм үз мөстәкыйльлеге өчен ил эчендә генә түгел, аннан читтә дә,— эмиграциядә дә, көрәшүен дәвам итүче халыкка килгәндә исә, психологик яктан җитәрлек дәрәҗәдә дәүләти ул...». Халкыбызның сәяси-дәүләти тарихы гасырларны эченә ала. Татар дәүләтчелегенең этаплары һәм рәвешләре аның төрле тарихи чорларда үсүе һәм камилләшүе белән генә аңлатылмый, ә биниһая зур һәм уртак территориянең төрле төбәкләрендә халык булып өлгереп җиткән берничә этнографик төркемнәрнең булуы белән дә аңлатыла.

Евразиянең башка халыкларыннан шактый аермалы буларак, татар халкының гасырларга сузылган милли дәүләтчелек тарихы бар, ул бик борынгыдан, әле Төрки каханлыгы чорыннан (552—745 еллар) ук килә.

Татарларның сәяси һәм этник тарихы, аларның дәүләтчелеге һәм дәүләт мәдәнияте, уртача 1100 елны үз эченә алып, Көнчыгыш һәм Көнбатыш урта гасыр Евразиясенең башлангыч (Төрки, Кимәк һәм Хәзәр каханлыклары, Бөек Болгар һәм Идел Болгары) һәм көчәйгән (Алтын Урда) чорлары аша соңгы (Казан ханлыгы һәм башка татар ханлыклары) чорларын үтте. Югарыда күрсәтелгән сәяси төзелмәләрнең, урта гасыр чорыннан ук башлап, идарә органнарының һәм учреждениеләрнең системасы кебек, нормаларның тиешле системасын беркетүче хокукы, әлеге дәүләт карамагында булган территориясе кебек дәүләтчелек өчен кирәкле барлык институтлары бар иде. Бу берләшмәләрнең тарихы зур вакыйгаларга, атаклы дәүләт әһелләренә, сәясәтчеләргә, хәрби эшлеклеләргә гаять бай; ул дәүләт тарихы, халыкларның бай матди вә рухи мәдәниятенең үсеше белән, этногенезның һәм халыкның этник тарихының катлаулы, әмма шактый кызык этаплары белән табигый бәйләнгән. Шулар арасында Алтын Урда яисә Җуҗи Олысы (1240—1430 еллар), бөтен татар халкының гомуми һәм урта гасыр уртак мәмләкәте буларак, ул вакыттагы бөтендөнья инсанияте үзәкләренең берсе буларак, аерым урын алып тора. Аның тарихы дистә еллар гына түгел, ә гасырлар буе берьяклы гына яктыртылып килде һәм сәясәтләштерелгән тарихи фәндә дә тискәре бәя алды. Шуның өстенә Алтын Урда тарихын вә мәдәниятен өйрәнү һәм пропагандалау БКП(б) ҮКның 1944 елның 9 августындагы мәгълүм карары нигезендә Татарстанда бөтенләй диярлек тыелып килде. Бүген — җәмгыятьне үзгәртеп кору, демонстрацияләштерү, яңача фикер йөртү, халыкның рухи үсеше көч алган һәм тарихи хәтере яңара барган чорда, ә бездә, Татарстанда исә суверен дәүләт тә төзелә башлаган дәвердә Алтын Урданың онытыла язган, дөресрәге онытырга мәҗбүр ителгән тарихына, аның халкының бай мәдәниятенә яңадан әйләнеп кайту зарурлыгы һәм мөмкинлеге туды, әлеге дәүләтнең урта гасыр дәүләтләре һәм барлык Иске Җиһан инсаниятләре системасында тоткан урынның мөһимлеген аңлауга юл ачылды.

Соңгы елларда Татарстанда Алтын Урда тарихын өйрәнү һәм пропагандалау башланды. Ул әлеге мәмләкәт төзелүнең 750 еллыгын билгеләп үтүгә әзерлек эшләре алып барудан башланды һәм, беренче адымның нәтиҗәсе итеп, быел 9—10 августта «Алтын Урда: тарихы һәм мәдәнияте» дигән темага халыкара фәнни конференция уздырылды. Мондый форумны нәкъ менә Казанда үткәрү үзенә күрә тирән мәгънәгә ия: хәзерге заман татар дөньясының гомум танылган үзәге фәнни һәм киң җәмгыятьчелекнең игътибарын халкыбыз дәүләтчелегенең һәм дәүләт мәдәниятенең гаять зур күләмле этабына юнәлтте. Алтын Урда җимерелгәннән соң аның территориясендә, сәяси һәм этно-мәдәни нигездә барлыкка килгән татар дәүләтләренең (Казан, Кырым, Себер, Әстерхан,

Касыйм ханлыклары, шулай ук Нугай һәм Олугъ урдалар) тарихын да тирәннән өйрәнү һәм аңа объектив бәя бирү зарурлыгы туа. 1552 елдан 1783 елга кадәрге чорда урыс дәүләте тарафыннан яулап алу нәтиҗәсендә яшәешләрен дә юнәлткән урта гасыр татар дәүләтләре, татарларның милли дәүләтчелек нигезе генә булып калмыйча, халыкның изге истәлеге һәм бу дәүләтчелекнең якты киләчәге өчен тарихи нигез дә булып тора, ә дәүләтчелек төзүгә юл Татарстанның суверенлыгын игълан иткәннән (1990 елның августы), аның беренче президентын сайлаганнан (1991 елның июне), бәйсезлек өчен бөтенхалык референдумы уздырылганнан соң (1992 елның марты) һәм Татарстан Республикасы Конституциясен кабул иткәннән соң (шул ук елның ноябре) ачылды.

Татар дәүләтчелегенең башлангыч этабы — әлеге халыкның турыдан-туры борынгы бабалары булган кабиләләрнең һәм башлангыч мәмләкәтләрнең борынгы тарихы ул, шулай ук Евразиядәге зур төрки халыкларның берсе булган татарларның — сәяси-дәүләти төзелешен булдыруга һәм алга таба үстерүгә, гомумән, этносәяси тарихка турыдан-туры яисә читләтеп йогынты ясаучы этник төзелмәләрнең дә тарихы ул. Хронологик эзлеклелектә бу тарихи Төрки каханлыгы барлыкка килгән чордан: Көнчыгыш Байкал аръягының эпиграфик истәлекләре буенча, ягъни төрки руникасының орхон-енисей язмалары, шулай ук кытай, монгол, фарсы һәм төрки тарихи чыганаклар буенча билгеле булган төрки-татар кабиләләренең күпсанлы һәм көчле берлекләре тарих мәйданына чыккан мизгелдән башлана.

Каханлык җимерелгәннән соң әлеге кабиләләрнең шактые көнбатышка китә. Алар Көнбатыш Себернең, Урта Азиянең һәм Көнчыгыш Европаның аерым дәүләтләрен, Кимәк каханлыгын (XIII—X гасыр), Караханилар (X—XIII гасыр башы), өлешчә Идел Болгары мәмләкәтләрен төзүдә һәм аларны алга таба үстерүдә катнашалар. Борынгы татарларның Урта Евразиягә күченүләренең куәтле дулкыны XIII гасырның 20—40 елларында Чыңгыз хан һәм Батый хан гаскәрләре составында була. Татарлар Алтын Урда дәүләтен төзүдә катнашалар һәм, күпсанлы, аларга кардәш төрки кабиләләр булган кыпчаклар белән берлектә, Алтын Урданың иң көчәйгән чорында, ягъни XIV гасырда бөтен татар халкы формалашуның берләштерелгән нигезе булып саналган татар-кыпчак суперэтносын төзиләр.

Татар халкы дәүләтчелегенең беренче рәвешләре Урта Евразиянең башлангыч урта гасыр кабиләләре берлекләреннән һәм дәүләтләреннән гыйбарәт, шулар арасында Казан татарларының этносын һәм мәдәниятен формалаштыруда катнашучы, Идел буе болгарларының дәүләтчелек бишеге вә этносәяси тарихының башлангычы булган Азов буе Бөек Болгар мәмләкәте дә (632—660 еллар) бар.

Татар халкының сәяси-дәүләти төзелеше һәм этник тарихының башлангычы Көнчыгыш Европаның беренче феодаль дәүләтеннән — Хәзәр каханлыгыннан (XII—X гасыр) башлана. Казан татарларының этносәяси тарихында, Татарстанның урта гасыр тарихында һәм тулаем Урта Идел тарихында Идел буе Болгар дәүләте (X гасыр башы — 1236 ел) мөһим роль уйный. XIII гасырның 30—40 елларында Болгар үзенең дәүләти мөстәкыйльлеген югалта һәм ул, аның төньяк-көнбатыш олысы сыйфатында, Алтын Урда составына керә. Әлеге тарихи фактны һәм тулаем Алтын Урда составында Болгар җирләренең булуын кире кагу бернинди тарихи чыганакларда да расланмый. Алтын Урданың татарларга катнашы юк, дигән сүзләр бернинди тәнкыйть кысаларына да сыймый һәм асылда алга киткән урта гасыр татар халкының этносәяси тарих проблемалары фактларга нигезләнмичә хәл ителүгә кайтып кала.

Алтын Урданы озак еллар дәвамында империя дип атап һәм шулай атарга омтылып килделәр. Моның белән килешүе читен, чөнки ул үзе, мөстәкыйль дәүләт статусы алып, Монгол империясеннән аерылып чыга, ә халыкның төп составын төрки дәүләт мәдәниятен булдырган төрки халыклар тәшкил итә. Алтын Урда беренче нәүбәттә милли дәүләт, төгәлрәк итеп әйтсәк, татар мәмләкәте булып санала. Составында башка кабиләләр һәм халыклар (фин-угыр, татар булмаган төркиләр) булуга да карамастан, аның төп милләте дәүләт тотучы татарлар[1] булган. Алтын Урданың Көнбатыш Себердән алып бөтен Идел аша Кырымгача, төньякта Казаннан алып көньякта Хаҗитарханга (Әстерханга) кадәр җәелгән зур җирләре, ягъни аның Ак Урда дигән төп өлеше — татар җирләре[2].

Элеккеге Казан ханлыгы территориясе генә түгел, нәкъ менә шушы зур җир татар халкының тарихи ватаны булып санала, һәм шушы җирдә XV—XVI йөзләрдә тел, территория, икътисад һәм мәдәният уртаклыгы булган татар халкы барлыкка килә. Хәзерге вакытта шушы җирдә татар халкының төп өлеше — бөтен татар халкының дүрттән өче диярлек яши, һәм татарлар Россиянең боль-

шевик җитәкчеләре тарафыннан 1920 елда ясалма рәвештә төзелгән элеккеге Татарстан АССР территориясенең генә түгел, ә менә шушы җирләрнең төп халкы булып исәпләнә. «Татар диаспорасы» дигән төшенчә әлеге җирләрдән читтә, ягъни элеккеге Ак Урда, Алтын Урда, соңга таба — Казан, Кырым, Себер һәм башка татар ханлыклары җирләрендә яшәүче татар халкына гына туры килә.

Татар халкының урта гасыр милли дәүләтләренә карата «федерация» төшенчәсе бик үк туры килми, чөнки бу дәүләтләр составында булган башка кабиләләрдә һәм халыкларда үзләренең закон чыгару, башкарма һәм хөкем органнары белән идарә итүнең федератив рәвешләре күзәтелми әле ул чакта. Ә менә Алтын Урда һәм урыс дәүләтләренең ике арадагы мөнәсәбәтләрен конфедератив бәйләнешләр дип атап булыр иде. Әлеге ике дәүләт арасындагы мондый бәйләнешләр хакында килешүләр төзү буенча нииндидер мәгълүм белешмәләр юк-югын, әмма шулай да урыс кенәзләренең үзләрендәге дәүләт идарәсенә ярлык алу өчен Урдага килеп йөрүләре мәгълүм һәм бу асылда шундыйрак килешүләрдән санала[3].

Бу конференция урысның дәүләт идарәсе, салым салу, идеология һ. б. мәсьәләләрен Алтын Урда тарафыннан тикшереп торуның йомшак рәвешләре белән аңлатыла. Ә соңга таба Россиянең татарлар һәм ул яулап алган башка халыклар өстеннән хакимияте моның киресе белән аңлатыла (бу тарихи фактлар күпләргә билгеле һәм вакыт җитмәү сәбәпле, моңа карата күп санда мисаллар китереп тора алмыйбыз).

Татар халкының милли дәүләтчелеге торгызылу, аның үсеше һәм җимерелүенең озын тарихи юлы кыскача гына тасфир кылынды. Нәкъ менә шушы дәүләтчелек 1552 елда һәм аннан соңгы елларда урыс дәүләте тарафыннан явызларча тар-мар ителде. Шушы яулардан, иң әүвәл Казан ханлыгын яулап алудан Россия империясен төзү башлана, һәм ул империя көтмәгәнчә элеккегеләренә караганда шактый озын гомерле булып чыкты. Бу яулап алулардан соң татар җирләрен урыс колониясенә әйләндерү башлана. Ул төп халыкны милли изү, көчләп чукындыру һәм үз мөстәкыйльлеге өчен көрәшкә баш күтәрүчеләргә каршы вәхшиләрчә гамәлләр кылу белән аңлатыла, бу ахыр чиктә Россиянең өч революциясе арасында (1905-1907 еллар, 1917 елның февраль һәм октябрь революцияләре) татарларның милли азатлык хәрәкәте этабы башлануга китерә. Әмма соңгы революциядән соң хакимияткә килгән большевиклар әлеге хәрәкәтне 1918 елда, аның нәкъ югары ноктасына җиткән чорда туктаталар: Милли мәҗлесне һәм аның тарафыннан төзелгән чорда «Идел-Урал штатын» — булачак мөстәкыйль татар-башкорт дәүләтен куып тараталар. Әлеге хәрәкәтнең юлбашчыларын чит ил эмиграциясенә җибәрү, шулай ук аларның көрәштәшләрен һәм шәкертләрен Сталин лагерьларында юкка чыгару нәтиҗәсендә дистә еллар буена — совет тоталитаризмы чорында — татар милли азатлык көрәше җитәкчесез кала. Әмма тагын бер Россия революциясе чорында, ягъни СССРның җимерелүе, элеккеге союздаш һәм автономияле республикаларның суверенлык алулары башланган чорда бу көрәш, бик үк кискен булмыйча, мәдәниятле, парламент юлы белән башланды.

Элеккеге СССР халыкларының күбесеннән аермалы буларак, татарларның 1552 елдан ук башланган милли азатлык хәрәкәтенең нигезен татар халкының меңнәрчә елларны үз эченә алган милли дәүләтчелеге тәшкил итә.

ИСКӘРМӘЛӘР

[1] «Милләт» төшенчәсе хәзерге гыйбарәсендә кулланыла. Алтын Урда чоры өчен — бу билгеле, халык мәгънәсендә булган. (Алтын Урда татар милләте булуы турында соңгы вакытта төрле билгеләмәләр барлыкка килде.)

[2] Алтын Урданың көньяк-көнчыгыштагы Күк Урда дип аталган, элеккеге угыз халыкларыннан һәм кайбер Урта Азия халыкларыннан торган кечерәк өлеше федерациянең кечерәк формасы санала.

[3] Ярлык — дуслык һәм һөҗүм итмәү турындагы пакт ул, дип, Л. Н. Гумилев бик хаклы билгеләп үтә, аныңча, ярлык хакыйкый бәйлелекнең чагылышы булмаган.

РАВИЛ ФӘХРЕТДИНОВ,
тарих фәннәре докторы,
Татарстан Дәүләт премиясе лауреаты,
«Татар археологиясе» журналының
баш мөхәррире.

TÜRK KÜLTÜR VE SANATLARI ORTAK YÖNETIMI

1993

TÜRKSOY

ТӨРЕКСОЙ

Төрки халыклар дөньясы





ЧУВАШ ИСЕМЕ КАЯН КИЛГӘН?

Чуваш исеменең килеп чыгышы турында 1991 елда язып чыккан идем. Әмма ул язма этногенез, этноним мәсьәләсе белән кызыксынучыларның игътибарын җәлеп итмәгән, күрәсең. Шуңа бу мәсьәләгә яңадан кайтуны кирәк дип санйым. Ник дисәң М. З. Зәкиев, Я. Ф. Кузьмин-Юманадиның 1993 елны Казанда басылып чыккан «Волжские булгары и их потомки» дигән китабында бу мәсьәлә бер яклы гына карала...

Бервакыт без Казагыстан далаларында яшәүче туганнарга кунакка барган идек. Целиноград өлкәсенең Аккүл тукталышында поездан төшеп, Амангильде авылына киттек. Туганнар бу авылга әле сугышка чаклы ук күчеп килгән булганнар, хәзер инде оныкларын үстереп, үзләре дә казакълашып беткәннәр. Алар «бәрәңге» не дә безнеңчә бәрәңге, яисә җир алмасы дип тә, русча картофель дип тә әйтмиләр, ә үзләренчә, «картоция», диләр.

Биредә яшәүчеләр татар милләтеннән булса да, яшәү рәвешләре, гореф-гадәтләре, «бишбармаклары», терлек суеп аны пешерүләре, кунак итүләре гел казакъча. Соңгы юлга озату-күмү йолалары һәм каберләре генә татарча.

Бер көнне апа белән терлек куалап барганда аның: «Быел безнең терлекләргә чүп җитәрлек»,— дигән сүзе мине гаҗәпләндерде. «Чүп» татар телендә, үзегез беләсез, «мусор» мәгънәсендә йөри. Баксаң, ул казакъ телендә печәнне аңлата икән. Хәер, бездә дә «чүп үлән» дигән гыйбарә бар. Чүп үләне татарларда — терлек азыгы. Культуралы «чүп» — арыш, бодай, шалкан, кишер, кәбестә, суган кебек нәрсәләрне табигать үзе чәчкән чүп үләннәр — алабута, эт эчәгесе һәм башкалардан аеру өчен «чүп үләне» сүз тезмәсе килеп чыгуы ихтимал. Чүп үләнен утап ыргыткач, кем дә булса, бу нәрсә, дип сораса, «чүп» дип кенә җибәрәләр. Ташланган нәрсә, кирәкмәгән әйбер шуннан «чүп» дип атала башлаган күрәсең.

Менә шунда — Казагыстанда мин «чүп» сүзенә беренче мәртәбә игътибар иттем. Чүп сүзе башка халыкларда да бар икән. Ул мариларда һәм чувашларда да «мусор» мәгънәсендә йөри. Әлбәттә, сүзнең мәгънәсе гасырлар үтү белән үзгәрергә, яки кулланыштан бөтенләй төшеп калырга да мөмкин.

Татарларда «чүп» сүзе күп төрле мәгънәгә ия: чүп-чар, чүп үләне. Көчерелмә мәгънәсендә хәтта, чүп кеше, дип тә әйтелә.

Хәзер исә тарихка күз салыйк. Монда «чүп» сүзенең ясалыш тарихына түгел (анысы галимнәр эше), чувашларга кагылышлы тарихка тукталасым килә.

Урта Идел буенда Болгар дәүләте чәчәк аткан чорда да, Алтын Урда заманында да бу тирәдә яшәгән күп төрле халыклар арасында «чуваш» дигән исемне шул заманга кагылышлы чыганакларда очратып булмый. Урынлы бер сорау туа: бу тирәдә башта «чуваш» сүзе барлыкка килгәнме, әллә шундый исемле халык күчеп утырганмы?

«Чуваш» сүзе халык атамасы буларак бары 1508 еллар тирәсендәге чыганакларда гына искә алына. Бу сүз Казан елъязмаларында, Казан патшалыгы тарихында да бар икән[1]. Рус актларында «чуваш» исеме 1521 елларда гына искә алына[2]. Әлеге атама Мәскәү кенәзе Василий III нең Слободск шәһәренең наместнигы Гавриил Мансуровка 1552 елның 29 июнендә язылган грамотасында да бар. Соңыннан «чуваш» сүзе ешрак очрый һәм чит ил язмаларында, Сигизмунд Герберштейнныкында да ул сүз бар. Бу сәяхәтче 1517 һәм 1526 елларда Россиядә булган.

Тагын сигез елдан, ягъни 2008 елда, чуваш этнонимы һәм шуның нигезендә чуваш дип йөртелгән халыкка исем бирелүгә 500 ел тулуны билгеләп үтү кирәк булып чыга.

...1500 нче еллар. Бу нинди чор соң? Билгеле булганча, хәзерге Чувашстанның (шулай ук Куйбышев, Ульяновск өлкәләре, Татарстанның көньягы һәм көньяк-көнбатышы) көньяк-көнчыгыш һәм көньяктагы төбәкләре XIV гасыр азагында һәм XV—XVI гасырларның беренче яртысында «кыргый җирләр» саналган. Әлеге җирләрдән халык качып киткән, чөнки болар тынгысыз җирләр булалар — монда еш кына казанлыларның күршеләре — нугайлар, урыслар белән әледән-әле сугышып торганнар. Шуңа күрә сугыш мәйданына әверелгән бу җирләр бушап калган. Баш өстендә ике яктан да кылыч, чукмар, ук уйнап торганда ничек түзеп яшисең. Нугайларның казакъ һәм татар белән кушылып, башкортлар белән туганлашулары тарихта яхшы билгеле. Татар халкының легендаларына кергән Сөембикә дә шул нугай нәселеннән бит. Кем белә, бәлки «чүп» сүзе төрки сүзедер ул? Ә аңа халыклар үзләренчәрәк мәгънә биргәннәрдер: ул йә нугайлардан, йә казакълардан, йә булмаса үзебезнең татардан килеп чыккандыр?

Чувашлар яшәгән җирләр урманга бай булган. Әйтик, Бола елгасы буенда, ягъни көньяк-көнчыгыш Чувашия җирләрендә — хәзерге Батыр районының Тигәш дигән чуваш авылы янында «Тигән шәһәрчеге» дигән тарихи урын бар. Ул Идел буе Болгар дәүләтенең төньяк-көнбатыш форпосты булып санала. Хәзер бу җирләрдә чувашлар, татар-мишәрләр үзара аралашып яши. Шул Тигәш шәһәрчеге калын имән бүрәнәләр белән әйләндереп алынган булган. Аннан соң Кыр-Бикшик авылы кешеләре үзләренең болыннарында торф казыганда, торф эченнән бик таза сакланган имән агачлары табалар. Кыр-Бикшик авылы Тигәш шәһәрчегеннән 2-3 чакрымда гына. Моннан 3-4 чакрымда Имән кисәге авылы. Бирегә халык 1608—1609 елга кадәр күчеп килгән. Чабаксар өязеннән, шундый ук исемле авылдан, башта чувашлар килеп урнашкан. Бу авылда хәзер чувашлар һәм мишәр-татарлар яши. Ишәк авылы тирәсендә куе имән урманнары хәзер дә шаулап утыра.

Әйтергә кирәк, әлеге «кыргый җирләрдә» (Чувашстанның хәзерге Батыр районында һәм Ульяновск өлкәсендә) кешеләр XVI гасырның беренче яртысында гына кабат яши башлаганнар. Алар бирегә Чабаксар, Зөя һәм башка җирләрдән күченгәннәр... Чувашлар әле хәзер дә урман җимешләрен, үләннәрне, ягъни чүп үләннәрен яратып файдаланалар. Татар кешесенең, мәсәлән, гөмбәгә бик исе китми, хәтта кайсы берсе җыеп бирсәң дә пешерми. Ул заманнарда бу урманлы җирдә яшәгән халыкларның урман байлыкларыннан — чүп үләннәрдән, гөзнич, гөмбә һәм башкалардан даими файдаланулары табигый.

Татарлар, нугайлар, үзара алыш-биреш итешеп яшәп, яисә ат уйнатып уктан атып йөргәндә шунда яшәгән халыкның «чүп» — гөмбә ашавын күреп хәйран калулары, гаҗәпләнүләре табигый. Ник дисәң, аларның төп азыгы сөт, ит кебек ризыклар була. Халыкта «чүп ашаучылар», шуннан чувашлар килеп чыккан дигән гөман бар. Минемчә, болай расларга нигез юк түгел. Төрки чыганаклардан күренгәнчә, «чуваш» исемен аласы халык Сура Идел белән кушылган (почмак-куеныңдагы) җирләрдә яшәгән. Аларны мордвалар да белгәннәр һәм үзләренчә ветьке, веда, веде дип атаганнар. Ведь — елга (мордвача), ягъни, мәсәлән, елга буенда яшәүчеләр мәгънәсендә. Марилар чувашларны суасламари дип йөрткәннәр. Шунысын да искәртеп китү урынлы булыр: чувашларның теле мари (чирмешләр) теленнән һәм казанлылар теленнән ул вакытта ук аерылып торган. Бу уңайдан кенәз А. М. Курбский урысларның Казанга сәяхәтен тасвирлаганда болай дип яза (1552): «Сура елгасын кичкәч тә, шунда тау черимисләре, аларча чуваш дип аталучылары, телләре — үзенә бер төрле; русларны бишәр йөз, меңәрләп шатлык белән каршы алдылар». Һәм алардан астарак Зөядә «град» куела. (Монда аларның дине, мәдәнияте турында сүз әйтелми.)

Шунысы да игътибарга лаек: бер яктан, урыслар Идел буе болгарларын, казанлыларны электән үк белгәннәр, ә чувашлар белән беренче мәртәбә очрашкандай, телләрен дә аерып язалар; икенче яктан, казанлылар «суас» этнонимын ни өчен үзгәртеп чуваш сүзенә әйләндергәннәр соң? Минемчә, монда «чүп аш»тан (гөмбә ашаучылардан) «чуваш» сүзе, елга буенда яшәүчеләрдән «ветке» килеп чыккан кебек, урман кешеләреннән — «агацир» килеп чыгуы табигый хәл кебек.

Монда шундый бер кызык исемне әйтеп үтәсе килә. Биредә татар авылы — «Озын Куак» бар, ул авылны русча «Долгий остров» диләр, күрше Ишәк авылы чувашлары (аларның авылын урысчага күчереп әйткәндә, «Чесночный овраг» дип яңгырый), «Ыхра-Сырме» дип йөртәләр.

Шундый заманнарда кушамат-исемне бер үк халыкка, шул халыкның үзенчәлекле яшәешен күздә тотып, төрле халык төрлечә кушарга мөмкин. Ә инде чуваш халкының этногенезы исә башка мәсьәлә.

Монда искәртеп шуны да әйтәсе килә: чуваш һәм татар халыкларын антропологик яктан өйрәнгәндә локаль-җирле группаларны аерып өйрәнү кызыклы булыр иде. Ник дисәң, төрле төбәкләрдә яшәүчеләр сөйләм белән генә түгел, ә кыяфәт төрлелеге белән дә аерыла. Бу нәрсә халыкның «кәүсәсен» нинди тамырлар күбрәк сугарганын күрсәтер иде.

ИСКӘРМӘЛӘР

[1] Димитриев В. Д. Чувашия в эпоху феодализма (XVI — начало XIX вв.) — Чувашское книжное издательство. Чебоксары, 1986.— С. 7.

[2] История Чувашской АССР. Том первый. (С древнейших времен до Великой октябрьской социалистической революции).— Чувашское книжное издательство. Чебоксары, 1966.— С. 232.

НӘКЫЙП КАШТАНОВ,
Казан.

Рухи мирас



Насреддин бине Борһанеддин Рабгузи

Пәйгамбәрләр тарихы*

ЙОСЫФ ГАЛӘЙҺИССӘЛАМ КЫЙССАСЫ

БИСМИЛЛӘӘҺИР-РАХМӘӘНИР-РАХИИМ

Борынгы Кинган сахрасында яшәүче Ягъкуб пәйгамбәрнең ике хатыны вә унике углы була. Аларның өлкәннәре инде буй җиткән, өйләнгән. Әмма алар, һаман бергә яшиләр иде, уртак хуҗалык алып баралар. Ун өлкән углы далада шушы кавемнең көтүен көтәләр. Ягъкуб г-мнең сөекле хатыны Рахилә иртә үлеп киткәч яшьли ятим калган Йосыф илә Бинйәмин әтиләре янында тора. Ягъкуб г-м иң кече углы Йосыфны барчасыннан артык сөяр иде. Йосыф бик гүзәл, сөйкемле, зирәк, нечкә күңелле бала була.

Ягъкуб углы Йосыф исеме илән Коръән Кәримнең 12 сүрәсе тулысы белән дип әйтерлек аңа багышланган. Моннан башка 6:84 вә 40:34 аятьләрдә дә аның исеме телгә алына.

Йосыф бер көнне хикмәтле төш күрә, уянгач, моңа гаҗәпләнеп, әтисеннән әлеге төшенә тәгъбир кылуын, ягъни юрауын сорый. Бу хакта Коръән Кәримнең «Йосыф» сүрәсе 4 аятендә әйтелә:

إِذْ قَالَ يُوسُفُ لِأَبِيهِ يَٰٓأَبَتِ إِنِّى رَأَيْتُ أَحَدَ عَشَرَ كَوْكَبًا وَٱلشَّمْسَ وَٱلْقَمَرَ رَأَيْتُهُمْ لِى سَٰجِدِينَ ٤

«Из каалә Йүүсүфү ли әбииһи йәә әбәти инннии раәйтү әхәдә гәшәра кәүкәбәү үәшшәмсә үәл камәра раәйтүһүм лии сәәҗидиин».

Мәгънәсе: «Йосыф атасына әйтте: «Ий атам, мин төшемдә күрдем: унбер йолдыз һәм ай белән кояш көлеп миңа сәҗдә кылдылар».

Атасы әйтте: «Ий углым, син төшеңне агаларыңа сөйләмә! Әгәр аларга сөйләсәң, хөсетләнеп сине һәлак итәр өчен хәйлә корырлар, чөнки шайтан адәмнәргә ачык дошман, агаларыңны хәйләгә котыртыр. Хак Тәгалә сиңа яхшы төш күрсәткән, сине Үзенең пәйгамбәре итеп сайлыйдыр вә сиңа тәгъбирне, ягъни төш юрауны өйрәтәдер, сиңа вә минем башка балаларыма нигъмәтне мул итеп бирер, моннан элек яшәгән бабаларың Исхак илән Ибраһимга биргән кеби. Әлбәттә, Җәнабел Хак кемгә нәрсә, күпме бирергә икәнлеген тик Үзе генә белүче вә кирәгенчә эш кылучы».

Ата илән угылның бу сөйләшүен олы угылларының берсе тыңлап тора вә башка туганнарына ирештерә. Күңелләренә көнчелек уты кабынган агалары, шайтан вәсвәсәсе илән, Йосыфтан үч алу ниятенә керешәләр. Өстәвенә алар Йосыфның төшендә хәйләмәкер галәмәте дә күрәләр. Алар җыелышып сөйләштеләр, бәгъзеләре әйтте: «Йосыфны берәр хәйлә илән сахрага алып чыгып үтерик яки билгесез, моннан бик ерак җиргә илтеп ташлыйк»,— диделәр. Араларыннан берсе әйтте: «Йосыфны үтереп гөнаһка батарбыз, аны кое төбенә салыйк, бәгъзе мосафирлар аны табып алырлар да моннан ерак җирләргә алып китәрләр, ә без тәүбә итеп Хак Тәгалә каршында яхшы бәндәләрдән булырбыз, атабыз безгә дә кадер-хөрмәт кылыр». Бу киңәшкә бар да риза булып, Йосыфны сорарга аталары янына килеп: «Әй атабыз, иртәгә син Йосыфны безнең белән сахрага җибәрсәң иде, ул безнең илән уйнар, рәхәтләнеп сахра һавасын сулар, хозурланып кайтыр иде, борчылма, без аны үзебездән бер адым да читкә җибәрмәбез»,— дип кайнар вәгъдәләр бирделәр. Ниһаять, ата күңеле түзмәде, сөекле углын сәйранга җибәрергә риза була. Иртән ул үз кулы илән Йосыфның чәчен тарап үрә, ашата-эчертә, яхшы киемнәр кидереп, сөекле баласын агалары кулына тапшыра. Агалары Йосыфны бик кадерләп, иңнәренә күтәреп алып китәләр. Ягъкуб г-м юл өстендә елап озатып кала. Сахрага чыгу илән Йосыфны төрлечә җәберли башлыйлар, хәлдән тайганчы җәберләгәч аны кое яны-

---

* Дәвамы. Башы журналның 1999 елгы 1, 2, 3, 4, 6, 7, 8, 9, 10, 11, 12, 2000 елгы 1 саннарында.

на сөйрәп китерәләр, күлмәген салдырып коега ташлыйлар. Кое төбендәге ташларга бәрелеп имгәнмәсен өчен Җәбраил фәрештә канатын җәеп аны акрын гына таш өстенә төшереп куя вә кое төбен елан чаяннардан арындыра. Шулвакыт Аллаһы Тәгаләдән Җәбраил г-м аркылы Йосыф г-мгә вәхий кылә:

وَأَوْحَيْنَا إِلَيْهِ لَتُنَبِّئَنَّهُم بِأَمْرِهِمْ هَٰذَا وَهُمْ لَا يَشْعُرُونَ ١٥

«Үә әухәйнәә иләйһи ләтүнәбби-әннәһүм биәмриһим һәәзәә үә һүм ләә йәшгүрүүн». (Йосыф сүрәсе, 15 нче аять)

Мәгънәсе: «Без Йосыфка вәхий кылдык: «Бу җәфалардан, әлбәттә, бер көнне котылырсың вә сиңа кылган явызлыкларын үзләренә сөйләрсең»,— дип, ләкин агалары Йосыфка вәхий кылганыбызны сизмәделәр вә белмәделәр».

Йосыфның агалары кич җитү илән, чырайларына елаган кыяфәт ясап аталары янына кайттылар. Әтиләренә әйттеләр: «Әй атабыз, без үзара узыша идек, шул вакытта Йосыфны әйберләребез янында калдырдык. Кире әйләнеп килсәк Йосыфны бүре ашаган. Безнең сүзебезгә ышанмасагыз, менә аның канлы күлмәге»,— дип ялган канга буялган күлмәкне китереп каршына куйдылар. Канлы күлмәкне күргәч, мескен ата һуштан язып егыла.

Йосыф г-м өч көн коеда торганнан соң, юлда туктаган кәрванчыларның су алырга дип төшергән чиләккә ябышып чыга. Әмма ерак түгел генә көтү көткән туганнары килеп: «Ул безнең качкан колыбыз»,— дип аны кәрван хуҗасы Мәлик Дәгыйргә, арзан гына бәягә сатып җибәрәләр. Ошбу кәрван илән Йосыф Мисырга барып җитә. Мисырда аны патшаның хәзинәчесе Газизгә бик зур бәһагә сатып җибәрәләр. Сарайга кайткач, Газиз үзенең хатыны Зөләйхага әйтте: «Йә Зөләйха, бу егетне үзебезгә сатып алдым, син аңар яхшы урын әзерлә, ул безнең углыбыз булыр»,— диде.

Мәгъриб иле хөкемдары Тәймуснең бердәнбер сөекле кызы, чибәр Зөләйха, әле үсмер кыз чагында ук, Йосыфны төшендә күреп, аңар гашыйк иде. Зур бәһагә Газиз сатып алып кайткан гүзәл егет аның төшенә кергән, үзенә гашыйк иткән кол егет икәнен танып Зөләйха һушын җуя.

Зөләйха бик сөенә, Хак Тәгаләгә шөкрана кыла, бу кол егетне үз тәрбиясенә ала, аның әүвәлге мәхәббәт хисләре яңадан уяна, ягъни гашыйк уты тагын да көчлерәк дөрләп яна башлый. Бу көчле хистән Зөләйха саташу дәрәҗәсенә җитә. Йосыф исә Зөләйхага бары ихтирам гына саклый, шуңа күрә аның нәфесе теләгәнне үтәүдән баш тарта. Зөләйха әйтә: «Әгәр мин әмер кылганны эшләмәсәң, ягъни якынлык кылмасаң, мин сине зинданга салдырырмын, хурлыкка төшкән бәндәләрдән булырсың».

Коръән Кәрим аятьләреннән күренгәнчә, Йосыф г-м Зөләйханың теләген үтәмәгәнгә зинданга ябыла. Зинданда чакта ул шундый дога кылган:

قَالَ رَبِّ السِّجْنُ أَحَبُّ إِلَيَّ مِمَّا يَدْعُونَنِي إِلَيْهِ وَإِلَّا تَصْرِفْ
عَنِّي كَيْدَهُنَّ أَصْبُ إِلَيْهِنَّ وَأَكُن مِّنَ الْجَاهِلِينَ ٣٣ فَاسْتَجَابَ لَهُ رَبُّهُ
فَصَرَفَ عَنْهُ كَيْدَهُنَّ إِنَّهُ هُوَ السَّمِيعُ الْعَلِيمُ ٣٤

«Каалә Раббис-сиҗнү әхәббү иләййә миммәә йәдегүүнәнии иләйһи үә илләә тәсъриф гәнниии кәйдә һүннә әсбү иләйһиннә үәкүм-минәл җәәһиилин. Фәстәҗәәбә ләһү раббүһүү фәсарафә гәнһү кәйдә һүннә, иннәһү һүәс-сәмиигүл-гәлиим».

Мәгънәсе: «Ий Раббым! Мине чакырган зинага караганда зиндан яхшырак, әгәр бу хатыннарның хәйләләреннән мине коткармасаң, мин аларга иярүче җаһилләрдән булырмын». Йосыфның догасын Раббысы кабул әйләде вә Йосыфтан ул хатыннарның хәйләләреннән имин кылды, дөреслектә Ул сүзләрне ишетүче вә хәлләрне белүче». (Йосыф сүрәсе. 33—34 аятьләр)

Зинданга аның белән бергә ике егет тә керде. Берсе — хәмер ясаучы, икенчесе — икмәкче иде. Алар төш күрделәр. Аларның берсе әйтте: «Мин төшемдә хәмер сыкканымны күрдем». Икенчесе әйтте: «Мин төшемдә икмәк күтәреп йөргәнемне күрдем, ул күтәргән икмәгемне кошлар ашый, имеш. Ий Йосыф ул төшнең тәгъбире ничек, безгә сөйләп бирче? Без сине яхшы кеше дип беләбез».

Йосыф әйтте: «Төшегезне юраганчы мин сезгә иман кәлимәләрен өйрәтергә тиешмен: «Әшһәдү әлләә иләәһә илләллааһ», ягъни чын күңелемнән гуаһлык бирәмен ки, тәхкыйк, бер Аллаһы Тәгаләдән башка һич тәңре юктыр, дип. Алар иман кәлимәләрен кабатладылар, ягъни иман китерделәр. Шуннан соң Йосыф әйтте: «Ий зиндандагы ике

иптәшем, инде төшегезгә тәгъбир кылам: берегез моннан чыгып әүвәлге урынында хәмер ясаучы булыр, ә икенчегезне асып куярлар вә аның башын кошлар ашарлар, эш мин тәгъбир кылганча булыр, чөнки төш юрауны миңа Раббым Хак Тәгалә өйрәтте»,— диде.

Йосыф әйткәнчә, икмәкчене — асалар, хәмерче исә үз урынында эшли башлый. Хәмерчегә Йосыф әйтә: «Зинданнан чыккач, патшага минем нахакка утыруымны сөйлә, мине чыгарсын». Ләкин шайтан мәлгунь егеткә оныттыра, янә Йосыф г-м ничә еллар буе зинданда кала.

Мисыр падишаһы төннәрнең берендә серле төш күрде: имеш ул елга ярында утыра, ә аннан җиде симез сыер вә алар артыннан җиде арык сыер чыга. Аннары җиде симез сыерны җиде арык сыер ашый. Падишаһ бик куркып уяна. Бераз тынычлангач, ул янә йокыга китә вә төшендә җиде яшел башак, җиде корыган башак күрә. Корыган башаклар яшел башакларны ашап бетерә. Бик каты куркып, падишаһ икенче тапкыр уяна.

Иртә белән падишаһ барча сарай әһелләрен җыя вә төшендә күргәннәрен сөйли. Әмма берәү дә аның бу хикмәтле төшен юрый алмый. Шулчак шәрабчы төшләрне бик дөрес юраучы Йосыф турында искә төшерә. Падишаһ аны зинданга Йосыф г-м янына җибәрә. Төшне сөйләгәч, Йосыф әйтә: «Җиде ел тоташтан иген чәчегез, җиде елда уңыш яхшы булыр, алган уңышны сукмыйча башагы вә саламы илән кибәндә саклагыз, үзегез ашар кадәр генә сугарсыз. Моннан соң җиде ел ачлык килер, җиде елда җыйган игеннәрегез җиде ачлык елларында ашалып бетәр, мәгәр орлык өчен саклаган игеннәрегез калыр. Ачлык еллардан соң бер ел килер, ул елда яңгырлар явар, игеннәр вә җимешләр үсәр, һәр җәһәттән иркенлек булыр.

Падишаһ бу сүзләрне ишеткәч гаҗәпкә калды вә Аллаһының рәхмәте илән әйтте: «Китерегез миңа ул Йосыфны, мин аны игенчелек эшләренә хуҗа итеп куям»,— диде.

Йосыф г-м Хак Тәгаләнең аңа өйрәткән төш юрау белеме ярдәме илән зинданнан котылды. Шул вакыт ул болай дип дога кылды:

رَبِّ قَدْ ءَاتَيْتَنِى مِنَ الْمُلْكِ وَعَلَّمْتَنِى مِن تَأْوِيلِ الْأَحَادِيثِ ۚ
فَاطِرَ السَّمٰوٰتِ وَالْأَرْضِ أَنتَ وَلِىِّۦ فِى الدُّنْيَا وَالْءَاخِرَةِ ۖ
تَوَفَّنِى مُسْلِمًا وَأَلْحِقْنِى بِالصّٰلِحِينَ ١٠١

«Рабби каде әтәйтәнии минәл-мүлки үәгалләмтәнии мин тәәуиилил-әхәдис. Фәәтыйрас-сәмәмүәәти үәл әрдый әнтә үәлиййи фид-дүнйәә үәл әәхыйрати, тәүәффәнии мүслимәү-үә әлхикъниии биссаалихиин».

Мәгънәсе: «Ий Раббым! Син миңа Үзеңнең мөлкәтеңнән Мисыр байлыгын бирдең вә дәхи төшләр юрау могҗизасын өйрәттең. Ий Раббым, син күкләрне вә җирне Яратучы, дөнья вә ахирәттә Син миңа ярдәмчесең, йә Рабби, мөселман хәлемдә җанымны ал, вә мине изге бәндәләр илә бергә кыл!». (Йосыф сүрәсе, 101 аять)

Муллык яшәү еллары узып, ачлык еллары башлангач, Йосыфның агалары Кинган шәһәреннән Мисырга ашлык алырга килделәр, ашлык сорар өчен Йосыф г-м янына керделәр. Йосыф г-м аларны таныды, агалары исә аны танымадылар. Йосыф алардан сорашты: сез ничә кардәш, кем балалары, атагыз ни хәлдә? Алар җавап бирде: без Ибраһим г-м нәселеннән Ягъкуб пәйгамбәр балаларыбыз, барчабыз унике идек. Йосыф исемле кече кардәшебезне бүре ашады, Биниәмин исемле кече кардәшебез атабыз янында калды, без монда унау килдек.

Йосыф г-м аларның һәрберсенә берәр дөя йөге ашлык биргәч әйтте: «Атагыз янында калган кече кардәшегезне алып килерсез, әгәр дә ул кардәшегезне алып килмәсәгез, миндә сезнең өчен ашлык булмас».

Аталарына кайткач әйттеләр: «Ий атабыз, ашлык хуҗасы кече кардәшегез Биниәминне алып килмәсәгез, сезгә ашлык бирмим диде. Биниәминне безнең белән җибәр, аны сакларбыз, ашлык та алып кайтырбыз».

Аталары әйтте: «Безнең сөйләшкәнне Аллаһы Тәгалә ишетүче вә белүчедер, Аның исеме илән ант итеп вәгъдә бирми торып, Биниәминне сезнең илән җибәрмим». Угыллары ант иттеләр.

Туганнар исән-имин Мисырга барып җиттеләр. Бар да җыелып Йосыф г-м янына керделәр. Йосыф г-м агаларын сыйларга алты савыт аш китертте. Һәр савыттан икешәр-икешәр ашыйсыз диде, һәм агалары һәр савыттан икешәрләп ашый башладылар, Биниәмин исә бер савытка бер үзе калды. Йосыф г-м: «Без синең белән кардәш булырбыз, әйдә бергә ашыйк»,— дип, пәрдә артына алып керде һәм икесе бер савыттан ашадылар. Биниәмингә үзен танытты: «Мин синең кардәшең Йосыфмын, Аллаһы Тәгалә мине ташламады»,— диде, янә әйтте: «Ий кардәшем Биниәмин, сине алып калыр өчен бер хәйлә уйладым, бер бәһале савытны синең йөгеңә яшереп куярбыз да, аннары «савыт югалды» дип, игълан итәрбез, тентегәндә савыт синең йөгеңнән чыгар, сине карак исеме

илән кол итеп алып калырбыз». Бу хәйләгә Биниәмин дә риза булды. Шулай эшләделәр дә, Биниәмин карак исемен күтәреп, Йосыф г-м кулында калды.

Аталары янына кайткач әйттеләр: «Ий атабыз, углың Биниәмин бер зур бәһале савыт урлады, без фәкать белгәнебез вә күргәнебез илән шәһадәт бирәбез, ягъни аның йөгеннән бер алтын савыт чыкты, шуның өчен аны кол итеп алып калдылар». Аталары бу сүзләргә ышанмады: «Юк, сез дөрес сөйләмисез, нәфсегез бер яман эшне яхшы итеп күрсәткәндер, ә сез ул эшне Биниәмингә япкансыз. Моннан элек Йосыф хакында ышандым, ә сез нәрсә эшләдегез? Инде миңа Раббым Аллаһ сабырлык бир, бу ике углымны да Хак Сөбханә вә Тәгалә кире кайтарыр дип өмет итеп калам. Һичшиксез, Аллаһы Тәгалә аларның кайда икәнен белә вә гадел хөкем итә, Мисырга барып Йосыф вә Биниәмин турында белегез, өметегезне өзмәгез»,— диде.

يَـٰبَنِىَّ ٱذْهَبُوا۟ فَتَحَسَّسُوا۟ مِن يُوسُفَ وَأَخِيهِ وَلَا تَا۟يْـَٔسُوا۟ مِن
رَّوْحِ ٱللَّهِ ۖ لَا يَا۟يْـَٔسُ مِن رَّوْحِ ٱللَّهِ إِلَّا ٱلْقَوْمُ ٱلْكَـٰفِرُونَ ٨٧

«Йәәбәниййәз һәбүү фәтәхәссәсүү мий-йүүсүфә үә әхыйһи үәләә тәйәсүү миррау-хил-лаәһ. Ләә йәәәсү мир-раухил-ләәһи илләәл каумүл кәәфируун».

Мәгънәсе: Ий угылларым, Мисыр шәһәренә барып Йосыф турында вә кардәше турында сораштырып карагыз, алар хакында берәр хәбәр булмасмы, Аллаһы рәхмәтеннән өметегезне өзмәгез! Дөреслектә, мөэминнәр Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтеннән өметләрен өзмиләр, мәгәр кяферләр генә өметсез булалар». (Йосыф сүрәсе, 87 аять)

Ягъкуб угыллары Мисырга барып, Йосыфка кереп әйттеләр: «Ий, игенчелек эшләренә хуҗа! Безгә вә өй җәмәгатьләребезгә бик каты ачлык иреште, менә сезгә төрле акчалар китердек, акчабызга карата безгә ашлык үлчәп бир һәм мөмкин булса сәдака итеп тә бир, шулай ук Биниәминне дә биреп җибәр, атабыз аның өчен бик хәсрәтләнеп елый-елый ике күзе сукыр булды».

Агаларының бу сүзләреннән Йосыф г-мнең күңеле нечкәрде вә ул үзен танытырга теләп әйтте: «Хәтерегездәме, Йосыфка вә аның кардәше Биниәмингә җаһиллек иләнниләр кылдыгыз?» Кардәшләре гаҗәпләнеп вә куркып сорадылар: «Син әллә безнең кардәшебез Йосыфмы? Йосыф г-м аларның туры күзләренә карап әйтте: «Әйе, мин сезнең кардәшегез Йосыфмын, дөреслектә Аллаһы Тәгалә тәкъвалыгым өчен олуг нигъмәт вә дәрәҗәләр бирде». Агалары куркып вә калтырап аның аягына егылдылар вә әйттеләр: «Ий кардәшебез Йосыф, һичшиксез Хак Тәгалә сине безгә ихтыярлы вә баш кылды, син күргән төш, ягъни унбер йолдыз вә ай белән кояш көлеп миңа сәҗдә кылдылар, дигәнең Ходай рәхмәте илән хак булып чыкты. Безнең хаталануыбыз өчен безгә нинди җәза кыласың?» — диделәр.

Йосыф г-м әйтте: «Бүген минем шатлыклы көнем, сезне гаепләп җәза кылырга һич ниятем юк. Кылган гөнаһларыгызны Аллаһы Тәгалә үзе ярлыкасын, Ул бик шәфкатьле вә мәрхәмәтле!» — диде.

«Кардәшләрем! Хәзер инде сез хакыйкатьне белдегез, Кинганга кайтып атабыз Ягъкуб пәйгамбәрнең йөзенә ошбу күлмәгемне ябыгыз, иншә Аллаһ атабызның күзләре ачылыр, күрә башлар. Атамны вә барча җәмәгатьләрегезне җыеп Мисырга минем хозурыма килегез!»

Угылларының кәрваны Мисырдан чыгып киткәч, аталары Ягъкуб Кинганда әйтте: «Картлыгы илән саташып сөйли дип уйламагыз, мин сезгә бер хәбәр әйтәм, Йосыф углымның исен сизәм, ул исән икән, тиздән сез дә минем сүзләремә ышанырсыз».

فَلَمَّآ أَن جَآءَ ٱلْبَشِيرُ أَلْقَىٰهُ عَلَىٰ وَجْهِهِۦ فَٱرْتَدَّ بَصِيرًا ۖ قَالَ
أَلَمْ أَقُل لَّكُمْ إِنِّىٓ أَعْلَمُ مِنَ ٱللَّهِ مَا لَا تَعْلَمُونَ ٩٦

«Фәләммәә әң җәә-әл бәшиирул кааһү гәләә үәҗһиһии фәртәддә бәссыйр. Каалә әләм әкул ләкүм инниии әгләмү миналлааһи мәә ләә тәгләмүүн». (К. 12:96)

Мәгънәсе: «Кәрван Кинган шәһәренә кайтып җиткәч, күлмәкне кулына тотып, шатлыклы Йосыф хәбәрен китерүче бер углы атасы янына кереп, күлмәкне атасының йөзенә куйды вә дәрхаль атасының күзләре ачылды, ягъни күрә башлады. Шул вакыт Ягъкуб г-м әйтте: «Мин сезгә әйтмәдемме Аллаһы Тәгаләнең белдерүе илән сез белмәгән нәрсәләрне беләмен дип?»

Угыллары әйттеләр: «Ий атабыз! Тәхкыйк без хаталык кылдык, вә гөнаһлы булдык, инде безне зинһар гафу ит! Һәм безнең өчен Хак Тәгаләдән ярлыкау эстә!» Аталары әйтте: «Әлбәттә, мин сезнең өчен Аллаһы Тәгаләдән ярлыкау сорармын вә дәхи истигъфар кылырмын. Тәхкыйк, Ул Аллаһы Тәгалә ярлыкаучы вә рәхмәт кылучы».

Шуннан соң барчасы җыелып, җитмеш ике җан Мисыр шәһәренә күчеп киттеләр. Барып җитеп Мисыр шәһәренә кергәндә аларны Йосыф каршы алды, ата-анасын вә кардәшләрен кочаклады һәм әйтте: «Һәр бәла-казадан имин хәлдә, Мисыр шәһәренә керегез!» Йосыф г-м үзенең ата-анасын хөрмәтләп тәхеткә утыртты, аннары Йосыфны хөрмәтләп, шөкер йөзеннән барчасы да сәҗдәгә егылдылар, вә Йосыф әйтте: «Ий атам, күп еллар элек күргән төшемнең тәэвиле ошбудыр, тәхкыйк Раббым миңа ихсан кылды, мине зинданнан чыгару илән вә сезне сахрадан Мисырга китерү белән кардәшләрем арасына шайтан вәсвәсә илән дошманлыкны салганы соңында, тәхкыйк, Раббым теләгән нәрсәсен шәфкать илән кылучы, әлбәттә, Ул белүче вә тиешенчә эш кылучы».

Хак Сөбханә вә Тәгаләдән кодрәтле вә гүзәл Йосыфка Зөләйхага өйләнү хакында әмер килә, вә Зөләйха илаһи көч илә яңадан элекке яшьлегенә, матурлыгына вә дәхи гыйффәтенә кире кайтарыла. Аларның никахыннан Ифраһим вә Мөсаллим атлы ике угыл туа.

Ягъкуб пәйгамбәр углы Йосыф г-м вә башка балалары илән Мисырда бик бәхетле 17 ел гомер кичереп вафат була. Васыяте буенча аны Кинганга атасы Исхак г-м янына дәфен кылалар.

Әтисе Ягъкуб пәйгамбәр вафат булгач Йосыф г-м Мисырда янә 54 ел игенчелек илән идарә итә. Ул идарә иткәндә Аллаһы Тәгаләнең ярдәме илән илдә гел муллык вә иркенчелек була. Инде тиздән әҗәле якынлашуын белеп Йосыф пәйгамбәр ошбу доганы укый: «Йә Раббым! Мөселман хәлемдә җанымны ал вә мине изге бәндәләр илән урнаштыр!» (Йосыф сүрәсе, 101 аять)

Йосыф г-м 125 яшендә вафат була. Аның гәүдәсе салынган мәрмәрдән ясалган табутны Нил елгасының Нәһр әл-Гуйун (чишмәләр елгасы) дигән җиренә төшерәләр. Муса пәйгамбәр заманында бу табут Кинганга кайтарылып әтисе Ягъкуб г-м янына җирләнә.

Газиз мөселман кардәшләрем! Коръән Кәримдә «Йосыф кыйссасы» инде ничә гасырлардан бирле мөселман халкы күңелендә, аңында, теле вә язуында, әдәби мирасында яшәп килә. Җәнабел Хакның ошбу сүрәсе һаман да Ислам диненең рухи дөньясында әзлекле рәвештә тәэсир ясый торган, ягъни аңар ямь вә төс бирә торган иң асыл җәүһәрләренең берсе булып кала бирә. Халкыбызның рухи тормышына, аның көндәлек дөньясына бу кыйссаның никадәр тирән үтеп керүен, җомга көннәрендә хәзрәтләребезнең үзләренең вәгазьләрендә «Йосыф» сүрәсенә мөрәҗәгать итүләреннән, сөйләгәндә нинди рухи ләззәт алуларыннан күрергә мөмкин.

Коръән Кәримнең ошбу кабатланмас сүрәсе, гасырлар буена мөселман халкының әхлагын, зәвыгын тәрбияләүгә вә дәхи сафлык-пакьлек, гаделлек-тугърылык, кешелеклелек сыйфатларын үстерүгә зур йогынты ясаган. Сүрә барча мөселман халкына якын, гади, ягымлы, шул ук вакытта бик табигый да, укыганда аһәңле һәм дә Раббыбыз Раббүль Газзә вә Җәлләнең без бәндәләренә биргән кабатланмас могҗизасы булып кала. Укыганда сүрәнең тирән мәгънәле, гыйбрәтле сүзләре, тәгъбирләре өр-яңадан ачыла, үзгәчә яктыртыла. Шул чордагы пәйгамбәрләрнең катлаулы язмышлары, кайгы-хәсрәтләре, шатлыклары, борчулары әле бүген дә безне тетрәндерә, уйландыра.

Әйтәсе килгән сүзем шул, Коръән Кәримнең кыйммәтле җәүһәрләреннән берсе булган бу сүрә мөселман дөньясы яшьләренең зәвыгын, гыйффәтен тәрбияләүгә зур өлеш керткән олуг сүрә булып тора.

Газиз кардәшләрем! Киләчәк язмабызда без Әюб пәйгамбәр турында булган кыйссаны дәвам итәрбез, иншә Аллаһ.

Ошбу юллар илән «Йосыф г-м кыйссасы»н тәмамлап, бәхет-сәгадәт вә иман ныклыгы теләп калам.

Үәссәламугаләйкүм үә рахмәтуллаһи үә бәракәтүһ!

Текстны журналга
ҖӘГЪФӘР ХӘЗРӘТ МӨБАРӘК әзерләде.

Кыямәт көне

(Вәгазь-нәсыйхәт)

БИСМИЛЛӘҺИР-РАХМӘНИР-РАХИИМ

Әссаләмүгаләйкүм үә рахмәтуллаһи үә бәракәтүһ, мөхтәрәм газиз кардәшләр!

«Кыямәт көне» дигән сүз мәчетләрдә, әби-бабайлар авызында гына сөйләнеп калмасын, ә бәлки, әти-әниләр, абый-апалар, энекәшләр вә сеңелләр дә аның нәрсә икәнен белергә тиешләр. Кыямәт көнендә ниләр булачагы турында Аллаһы Тәгаләнең Коръән Кәримендә вә дәхи Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәламнең хәдис-шәрифләрендә хәбәрләр вә дәлилләр бармы? Әйе, Коръән Кәримдә вә хәдис-шәрифләрдә бу хакта бик күп мисал-дәлилләр китерелгән, без аларны вәгазебездә иншә Аллаһ күрсәтербез.

Кыямәт көне җиткәч Исрафил фәрештә үзенең кулына тапшырылган «Сур» исемле мөгезне өрәчәк, бәс, шуннан соң җир йөзендәге һәрбер җан иясе: адәмиләр һәм хайваннар, вә җирдә вә күкләрдә булган фәрештәләр үлеп бетәчәкләр. Ягъни, шул заманда дөнья мәхлукатның һәркайсы һәлак вә фани булып бетәчәкләр. Бәс, шул заманда Хак Тәгаләнең Үзеннән башка һичбер терек нәрсә калмаячак.

Дөнья мәхлукаты тәмам һәлак булып беткәннән соң Аллаһы Тәгалә галәмне янадан тергезәчәк. Шул рәвешчә ки: каберләрдә вә башка җирләрдә черегән вә таралган тәннәр вә гәүдәләр Аның кодрәте илә җыелып вә оешып, һәркайсы әүвәлге терек вакытындагы кеби рәвешләренә керәчәкләр. Аллаһы Тәгалә Исрафил г-мне тергезеп, аңа «Сур»ны икенче мәртәбә өрергә боерачак. Шуннан соң җаннарның һәркайсы үз гәүдәләренә керәчәк. Бәс, аннан соң каберләрнең өсте ачылып, һәрбер кеше, гүя йокыдан уянган рәвештә терелеп, каберләреннән җир өстенә чыгарлар. Бу турыда Коръән Кәримнең 6:73; 18:99; 20:102; 23:101; 27:87; 50:20; 41—42; 79:6—7,13 аятьләрендә әйтелә.

Коръән Кәримдә, хәдис-шәрифләрдә вә риваятьләрдә бу Мәхшәр көне хакында болай языла: «Менә Мәхшәр көне, әйе бу кешелек дөньясының җирдә яшәүдән туктау, ягъни Җәнабел Хак каршында хисап көне. Йә, Рабби, бу төсләре бозылган һавалар, зынҗырдан ычкынган төсле, бер-берсенә һөҗүм иткән җилләр, дөньяда булмаган куе караңгылык, куркыныч тавышлар илә тулган. Бу гаять тә караңгылык илән капланган очсыз-төпсез сахра шикелле урынның тирә-ягы адәм балалары белмәгән, ишетмәгән вә дәхи адәмнәрнең җанын бик күп өлешләргә яргалый торган куркыныч тавышлар илә тулган. Бу куркыныч тавышларның куркынычлыгын каләм илә язып вә тел илә сөйләп күрсәтү һич тә мөмкин түгел. Җир калтырый, җирдә булган вак ташлар агулы тузанга әйләнеп бөтен һаваны тутыралар. Бу кадәр агулы тузан вә куәтле җилдә гаять тә каты улау тавышларына әверелә. Бөтендөнья ничә вә ничә миллион төрле авазлар илә: «Йә Аллаһ!», «Йә, Рахмән!», «Йә, Рахим!», «Әстәгъфируллаһ!» дип акыралар-бакыралар. Тирә-якка әйләнеп

баксаң бөтен фикри дөнья юкка чыккан, тирә-юньдә коточкыч монзара.

Кинәт, барча бәндәләр йөрәкләре ярылырга җитеп җиргә аудылар, бар да шашып елый иде. Кайдандыр каты аваз ишетелде: «Торыгыз, уяныгыз, тетрәнегез бәндәләр! Бу көн хакимнәр хакиме, хөкемдарлар патшасы үзенең камил гаделлеген күрсәтә. Ошбу җирдә хакыйкать иясе сезнең явызлыкларыгызны эченә алган гамәл дәфтәрләрегезне Раббыгыз әшкяра итәр-күрсәтер. Гомерегез буе шәфкатьле, газиз анагыздан да йомшак булган Ислам дине бу көн Ходай рәхмәте илә көферанә нигъмәт итүчеләргә тимердәй нык ихтыярлы булып үзенең кодрәтен күрсәтә. Һәммәгез бер урынга җыелыгыз! Әүвәлге тәннәрегез вә кыяфәтләрегез илә гарасат мәйданына килегез! Сезне бу көн Раббел Галәмин хисап алырга Үзе чакыра!»

Төсләре бозылган, йөз нурлары качкан, өсләреннән кабер туфрагының ягылып калганнары коела-коела, бик куркынган чырайлар илә, рәтсез-тәртипсез бер сурәттә Аллаһы Тәгалә хозурына, хөкем урынына киләләр. Ий Җир, синдә — синең газиз куеныңда ничәмәничә төрле кавемнәр бар? Яһүди, насари, Мөхәммәди, дәһри, гыйсави, мусави, шигый ваһһаби, баһави, әһмәди һ. б. бик күпләр бер Аллаһ хозурына җыелалар. Ни хәсрәтле хәлләр, ни ялкынлы аһваһлар! Йә Раббымыз, бу көн җәза мәйданына чыгарылган гөнаһларның исәбен-хисабын кем белер? Монда ялганчылар, гамәл сатып ашаучылар, Ислам дине дошманнары, һиммәтләрен, юмартлыкларын һәммә гайрәтләрен мәйханәләрдә зина кылып үткәрүчеләр, өшкерүче-төкерүче ялганчы карчыклар вә дәхи үзләренә вәхи килә дип йөрүчеләр... Һичберенең үз башын коткарырга чарасы булмас. Борынгы олугълыкларыгыз, дәрел-дөнья горурлыгыгыз бетте — хәзер һәр җирдә һәркем һәр яктан тигез.

Йөрәкләрне тетрәтә торган аваз ишетелә: «И явызлар! Монда килегез! Ничә йөз, ничә мең еллардан бирле көтелгән җәза таңы атты. Динне хурладыгыз, мөселманлыктан көлдегез! Галимнәрне танымадыгыз, тугъры сөйләгәннәрне кыстыгыз, издегез. Аллаһы Тәгалә гафилмени?! Җавап бирегез! Монда сезне кызганучы юк!»

Аллаһыны сөйгән бәндәләр, ягъни дөньяда вакытта тел берләме, язу берләме дин Исламны, Мөхәммәд г-м өммәтенең һәр эше алга баруы өчен тырышучылар, Аллаһы Тәгалә биргән байлык илән мәктәп-мәдрәсәләр вә мәчетләр салучылар, кое вә чишмәләр казып, чистартып халыкны шатландыручылар йөзләрендә шатлык нуры балкыган хәлдә җәннәткә юл алырлар. Бу турыда Коръән Кәримнең 2:82, 111, 214, 3:142, 185, 4:124 аять кәримәләрдә бик ачык әйтелгән.

Мөхтәрәм газиз кардәшләрем! Җәнабел Хакның фани дөнья вә кыямәт көннең хуҗасы булуы хакында тышлыкның 4 битендә рәссам Ләйсән Сәмигуллинаның шәмаилен күрәсез. Бу шәмаилдә түбәндәге сүзләр язылган: «Иннәллааһә гәлә күлли шәэиң кадиир».

Мәгънәсе: «Дөреслектә Аның кулында ике дөньяның патшалыгы — Аллаһы Тәгалә мөбарәк вә олугъ».

Үәссәламүгаләйкүм үә рахмәтуллаһи үә бәракәтүһ!

ҖӘГЪФӘР ХӘЗРӘТ МӨБАРӘК.

Язмышың сатышлы булгач...

Фердинанд Галәм —— 2000 ел —— Дания Галәми
музыкасы ———————— сүзләре



Сары чәчәк өзмә дидем,
Син гел өздең сарысын.
Чәчәкләргә өләш дидең,
Хәсрәтеңнең барысын.

Кушымта:
Сары чәчәк алмадым мин,
Сары язмыш алдым мин.
Сарыларын белә торып,
Сагышларда калдым мин.

Сары чәчәк җыйма дидем,
Син гел җыйдың сарысын.
Сары чәчәкләрең биреп
Сагышларда калдырдың.

Кушымта.

Сары чәчәк бирмә дидем,
Син бирдең гел сарысын.
Язмышың сагышлы булгач
Җитсен дидең сабырың.

Кушымта.

Сары чәчәк бирмәдең син,
Сары сагыш бирдең син.
Шуннан бирле сагышларга
Йөрәгемне төрдең син.

Кушымта.
Соң аңладым: син ятларга*
Чәчәкләрнең алсуларын,
Өзәргә йөри идең.

---

*Соңгы өчъюллык дүртенче куплетның кушымтасыннан соң керешкә кушылып укыла.

MIRAS FUNDЬ

TATARSTAN COMЬYRIOTE

REPUBLIC OF TATARSTAN

ميراث فوندى

МИРАС

Китап ханәсе

Гаяз Исхакый

Зиндан

(ПОВЕСТЬ)

Подвалда мин өч көн тордым. Ләкин гомеремдә бу кадәр кешеләрнең җәберләнүен күреп, бу кадәр ачуым килгәнен белә алмыйм. Бу өч көндә һәр минутта мине чакырып, камчылар, мылтыклар берлән кыйнауны көтә идем. Бөтен куәтем берлән, ничек кыйнасалар да, тавыш та чыгармаска хәзерләнә идем. Ләкин ни өчендер мине кыйнамадылар.

Чистай танышларым миңа ашарга-эчәргә китерделәр. Күңел җәрәхәтен исәпләмәгәндә, мин монда бик яхшы тордым. Мондагы тормышта артык яңа эш булмады. Ята торган кешеләр һәммәсе дә шул элгәрегеләр иде. Тыштан да артык җәбер килми иде. Городовойлар килгән бер кешене кыйнийлар иде, алар чыккач, без җыелышып сүгә идек, аларнын кабахәтлекләрен тикшерә идек. Алай булса да, актык көнне кич берлән безгә тагы бер яңа кеше керттеләр. Бу кеше этап берлән килде. Үзе ап-ак сакаллы, киң маңгайлы, Толстой кыяфәтле җитмеш биш яшьлек бер карт иде. Бу карт бик туңып килгәнгә, мин аны хәзер чәй эчәргә чакырдым. Карт чәй эчәргә утырды. Мин алдына куйган нәрсәләрне ашарга тотынды. Ашамак-эчмәк әйберләрен бик тиз җийүе монын күптән бирле тамагы туйганы юк идекен белдерә иде. Ашап-эчеп туйгач, бабайдан сораша башладым. Бабайны Мамадыш өязендә рөхсәтсез китаплар тараткан өчен тотканнар икән. Мамадыш төрмәсендә бераз яткырганнан соң, үзен Чистайга китергәннәр икән. Бабай безнең кем идекемезне белмәгәнгә, ул сакланыбрак сөйләде. «Ни өчен соң Мамадыш уездына бардың?» — дигәч: «Атым югалган иде, шуны эзләп йөрдем»,— диде. Бераздан миңа аш китерделәр, мин тагы теге иптәшләрне һәм бабайны ашаттым. Аштан соң тагы чәй эчтек. Бабайны югарыга алып менделәр. Анда

* Ахыры. Башы журналның 2000 елгы 1 санында.

иртәгә чыгарачакларын әйткәннәр. Бабай хәзер, бер яктан безгә ышануы артудан, икенче яктан үзенең чыгуына шатланудан, безгә ап-ачык сөйләргә тотынды. Аның аты әллә кайчан югалса да, максуды һичбер ат эзләү түгел икән. Ат эзләү дигән сүзе бертөрле полиция күзеннән генә югалу икән. Ул ат эзләү хәйләсе берлән авылдан авылга йөреп сөйли, халыкны аңлата, әллә кайдан алган китаплар, гәзитәләр тарата икән! Ул Чистай өязендә, Бөгелмә өязендә әллә кайчаннан бирле йөри, шул тирәдә әллә кайчаннан бирле «җир һәм ирек» фикерен таратучы мәгълүм карт икән. Бабай үзе николаевский солдат булганга һәм дә флотта хезмәт иткәнгә, шактый гына мәгълүматы бар һәм дә күп мәмләкәтләрдә йөргәнгә, Европа падишаһлыкларының идарәсе хакында, андагы халыкның тормышы хакында бик күп нәрсә белә иде, аның өстенә тагы, сүзгә дә шактый гына оста иде. Шуның өчен ул шул үзе алган юлда халыкка бик күп файда итүендә шөбһә юк иде. Минем янымдагы рус аңарга: «Син, бабай, төрмәгә керсәң дә кайгырырга ярамый, анда чиркәү бар, көн дә гыйбадәт кылып торырсың!» — диде. Карт: «Юк, дустым, минем урыным чиркәү түгел, теләгән кеше барсын. Минем урыным хәзер авыл җыеннары, минем динем чиркәүгә барып гыйбадәт түгел, авыл халкына «җир һәм ирек» фикерен аңлату»,— диде.

Мин картның шулкадәр гакыллы сүзенә исем китте. Ул үзе дә миңа карап: «Минем хәзер угылларым өйләнгән, кызларым киткән, халыкка мин хезмәт итмәенчә кем итсен; менә синең балаң калган, хатының калган, ата-анаң калган, аларны тәрбиягә кешең юк! Мине төрмәгә япсалар, минем кемем кала! Юк инде, мин актык гомеремне шул юлда үткәрәм»,— диде. Мин: «Хәзер чыккач нишлисең?» — дидем. «Менә хәзер чыккач ук фәлән авылга барам. Анда танышларым бар, аларны җыям. Менә мине ничек йөртүләрен сөйлим, шунда халыкка файда итә торган кешеләрнең ничек ябылуларын аңлатам. Халыкка «җир һәм ирек»не ничек алып булуның юлларын күрсәтәм, анда кунам, икенче көн фәлән авылга барам, өченче көнне фәлән авылга», дип, ун-унбиш авылның исемнәрен әйтте.

Иртәгесен бабай миннән элек чыгып китте. Бәлки, ул тагы хәзер бер-бер җирдә тотылгандыр да тагы бер-бер җирдә ята торгандыр, ләкин кая булса да үзенең «динен», үзенең хезмәтен ташламагандыр. Мин бу бабайны күреп, руслардан шундый тырыш, аңлы кешеләр чыгуына исем китте. Үзем таныган татар картларының моның кебек яшьләрендә йә мич башында ятып киленен тиргәп торуын, яисә угълының бердәнбер атын өшәндереп, лырт-лырт күрше авыл ишанына хәтемгә йөрүен хәтеремә китереп, боларны чагыштырып карадым. Вакыйган, бу ике төрле халык арасында никадәр аерма: берсе үзенең карт гомерен халыкка хезмәт итеп үткәрмәкче булып, бала-чагасыннан аерылып, төрмәдән, полициядән курыкмаенча, халык арасында фикер таратырга чыга! Икенчесе дөньядагы һәрбер яңа эшкә каршы тора, үзенең файдасы кайда, зарары кайдалыгын белмәенчә, үзенең җәмәгатенең маңлай тиресе берлән табылган малын әллә нинди әрәмтамак ишаннарга сарыф кыла! Минем, әлбәттә, боларның кайсысын артык күргәнемне беләсез, гакылыңыз булса, сезнең дә минем берлән бу фикердә мөштәрәк булуыңызда шөбһәм юк!

Һәр нә исә фәлсәфә җитәр! Вакыйгага кайтыйк. Егерме җиденче декабрьдә сәгать унберләрдә мине тагы исправникка алып менделәр. Бу юлы миннән бер допрос та, фәлән дә булмады. Фәкать үзләренең мине ничек гаепләүләрен генә бәян кылдылар. Мин үзебезнең авылның теге Шәйхи куштанга һәм дә дөньяга да килмәгән бер Мөхәммәдиев исемле Чистай татарына: «Мин революционерлар партиясе кешесе»,— дигән имешмен! (Шуны да онытмагыз, дөньяда «революционерлар партиясе» дигән бер партия дә юк.) Шуның өчен мин бу сүзне әйткән булсам да, бу партия булмаганга, бу сүз бер кешенең: «Мин Казан ханының кызын урладым»,— дигән кабилдән генә булачак иде дә, минем гакылсызлыгымны яисә ялганчылыгымны күрсәтә торган бер эш кенә булачак иде.

Ләкин полиция алай карамады. Алар мине шуның өчен 129 нчы статья берлән гаепләп төрмәгә яптылар. Боларны укыганда мин, әлбәттә, көлеп тора идем. Чөнки монда аз гына да колакка ятарлык сүз юк иде. Актның гыйбарәләре хата булган кебек, мине ябарга күрсәткән дәлилләре үрмәкүч оялары гына иде. Әгәр бу язу кисәген, башка мәмләкәтләрдәге кебек, хакимнәргә бирелсә иде, бу язуга карап, түгел мине төрмәгә ябу, гакылдан язган дип исправникны сумасшедший домга җибәрерләр иде. Монда гаепләү дә, хөкем итү дә полициянең үз ихтыярында булганга, әлбәттә, мине төрмәгә җибәрделәр. Сәгать 12 ләрдә мине бер городовой Чистай төрмәсенә китерде. Капканы шалтыратып ачкач, мине конторага алып кереп тентеделәр. Янымдагы акчамны алып калдылар. Аның соңында исемнәремне, яшьләремне язып алып, мине төрмәгә керттеләр.

Төрмә йорты бик биек койма берлән әйләндереп алынган шәһәр читендә бер йорттыр. Капкасының өстендә төрмәнең чиркәве булганга, чиркәү астының ике ягында ике капкадыр. Урамга чыга торган капка агачтыр, төрмә йортына керә торганы — тимердер. Ике капка арасында, чиркәү астында, ике контор һәм старшийның фатиры бардыр. Төрмәнең бинасы соңгы капкадан 10—15 сажин ераклыгында өч катлы, акка буялган таш өйдер. Өч катының да тәрәзәләре тышкы каттан тимер рәшәткәләр берлән беркетелмештер.

Мин килгәндә сәяси кешеләр тышка йөрергә чыкканнар иде. Гариф абзый берлән дамелла дә йөреп торалар иде. Мине бер надзиратель алып кереп китте. Тар гына, караңгы гына, боргаланып беткән таш баскычлардан менә башладык. Өченче катка менгәч, караңгы гына коридорга кердек. Мине озатучы мондагы, кулына бик күп ачкычлар тоткан надзирательгә: «Бадамшиннарга керт!» — диде. Теге надзиратель ачкычларын алып, шалтыр-шолтыр китереп, бер бүлмәне ачып кертте.

Бүлмә бер дә искиткеч түгел иде. Бу, өстеннән генә караганда, Казанның Бәди карчык номерларының берсе иде. Шундагы кебек сәкесе бар иде, шундагы кебек мебеле юк иде, шундагы кебек буяулары искергән иде. Бәди карчык номерыннан аермасы булса, ул да моның тәрәзәсенең бик ямьсез киң булуы, пыялаларының кырык корама, йөз ялгаудан булуы һәм дә тәрәзәсенә тимер рәшәткә куелуы иде. Идәндәге таз, комган, сәкедәге юрганнар, мендәрләр моны тагы Бәди карчык номерына охшата иде.

Минем полициядә дүрт көндә бер мәртәбә дә рәтләп юынганым булмаганга (чөнки анда юына торган җир юк), мин комганда су күрү берлән юынырга тотындым. Бераздан соң әллә нинди кыңгырау тавышы чыкты. Аның артыннан ук тышта: «Бер вакыты үтте!» — дип кычкырдылар. Шуның артыннан ук гөрләшеп-кычкырышып сәясиләр югары менделәр. Алар берлән бергә Гариф абзый, дамелла да менде. Мин яңа кеше булганга, «ирек»тән хәбәрләр сораша башладылар. Һәм, кунакны сыйлыйк әле дип, чәйнек берлән кайнаган су алырга төшерделәр. Бер ике-өч минуттан соң без тәмам Бәди карчык номерына товар алырга килгән кешеләр кебек, яисә угылларын мәдрәсәгә китерергә килгән муллалар кебек сөйли-сөйли чәй эчә башладык. Миндә сүз күп булганга, күбрәк мин сөйли идем. Озак үтмәде, тагы звонок булды. Надзиратель: «Ашка төшеңез!» — дип кычкырды. Үзе чаңгырдатып авыр ишекләрне ачып йөри башлады. Коридорга халык анда да, монда да чаба башладылар. Бераздан безгә дә аш китерделәр. Аштан соң берәр сәгать вакыт үткәч, тагы йөрергә чыгарга кычкырдылар. Бу юлы мин дә йөрергә чыктым. Төрмәнең йортында җир эшләре берлән кергән авыл кешеләре, политическийлар, төрмә киемен кигән жуликлар (монда аларны шпана дип атыйлар) йөриләр иде. Кайсылары бер-берсе берлә көрәшә-сугышалар, кайсылары сөйләшәләр иде. Мин, дүрт көн полициянең сасы һавасында торганга, әлбәттә, бу саф һаваны рәхәтләнеп сулый идем. Мин шул көнне үк шундагы политическийларның күбесе берлән таныштым. Монда Государственный думаның члены Герасимов та бар иде. Һәммәсе дә ачыклар, уйныйлар, сөйлиләр, көләләр иде. Сәгать тулгач, тагы безне керттеләр. Бераздан соң та-

гы звонок булды. Тагы: «Ашка төшеңез! Суга барыгыз!» — дип кычкырдылар. Без дә яңадан чәй эчәргә тотындык. Чәй вакытында безгә әлеге парашаны керттеләр. Аның сасы исе керү белән бөтен бүлмәне тутырды. Монын исе монда да шул полициянеке төсле, Казанныкы төсле иде.

1 нче февраль, кич сәгать 10 нар.

Бераздан соң утлар керттеләр. Аннан да бераз үткәч, сәгать 6 ларда, бик озак звонок булды. Камераларның ишекләрен бик каты итеп яба башладылар, зур йозаклар куркынычлы тавышлар чыгара башладылар. Берәр минуттан соң бөтен төрмә тып-тын булды. Бераз вакыт үткәч, камераларның ишекләре берәм-берәм ачыла башлады. Поверка (тикшерү) башланды. Кәгазь карандаш тотып, юньсез генә бер солдат безгә кереп, кәгазенә өчле цифр куеп чыкты. Озакламады, поверка да бетте. Төрмә тагы кайный башлады. Анда да, монда да тавышлар ишетелә башлады. Сәясиләр волчок (ишектәге тишек) аша сөйләшә башладылар. Бер шпана (жулик) сызгырырга тотынды. Ераграк камералардан сүзләре аңлашылмаган тавышлар ишетелә башлады. Ерактагы татарлар җырларга тотындылар. Төрмә әллә нинди төрле тавышлар берлән гөрләргә тотынды. Безгә кичке ашны китерделәр. Без ашап-эчеп, сөйләшеп, кичке сәгать уннарга кадәр утырып, йокларга яттык. Төрмә бик озак йокламады. Ул бер тынга калган кебек була иде, бер зур машина кебек төрле тавыш берлә гөрләргә тотына иде. Полициядә йокы рәтләп булмаганга, мин, әллә нинди зур кайгысыннан котылган кеше кебек, тирән йокыга киттем.

Иртә берлән күземне ачып җибәргәндә, төрмә тагы уянган иде. Аның төрле тарафыннан төрле тавышлар чыга иде. Төрле почмагында татарча, русча сүзләр ишетелә иде. Мин уянгач ук үземнең кайдалыгымны белә алмадым. Мин школада, пансионда кебек тә булдым, мәдрәсәдә кебек тә булдым. Шалтырап ачылган авыр ишек тавышы мине бөтенләй уяндырды. Мин үземнең төрмәдә идекемне хәтеремә төшердем. Бераздан соң өчемез дә торып беттек. Озак үтмәде, юынып, киенеп чәй эчәргә утырдык. Без чәй эчә башлагач, кичәге кебек тагы бик озын звонок булды. Тагы бик кызу-кызу ишекләр бикләнде. Тагы төрмә тып-тын калды. Тагы поверка башланды. Тагы безгә кичәге юньсез урыс кереп кәгазенә өчле цифр куеп чыкты. Озак үтмәде, поверка бетте. Тагы авыр ишекләр бик ямьсез чыгырдап ачыла башладылар. Шул арада тагы звонок булды. Звоноктан соң, надзиратель: «Хөкем ителгәннәр, йөрергә!» — дип кычкырды. Безнең коридорның берничә кешесе чыгып киттеләр. Бер сәгать вакыт үткәч, тагы звонок булды. «Сәясиләр, йөрергә!» — дип кычкырдылар. Без барымыз да киенеп йөрергә чыктык. Бер сәгатьтән соң звонок булды. Камераларымызга кердек. Тагы кичәге кебек аш килде, чәй булды, поверка бетте, параша керде. Төрмә гөрли башлады. Шулай итеп, безнең бу көнге көнемез иртәгәгә, үткәне берсекөнгә охшап гомеремез үтә башлады.

Төрмәгә мин унынчы сәяси булып кердем. Миңа кадәр чын сәясиләр тугыз гына иде. Аларга башка җир эшләре берлә кергән авыл халыклары һәм дә, попларын, дьяконнарын стражниклар үтергәч, крәстиәннәрне бунтовать итте дип күрсәтер өчен китерелгән 17 Мамыйк руслары бар иде. Боларның арестовать ителүләре барыбер безнеке кебек үк низамсыз-нисез булса да, боларны, төрмәдәге укыган сәясиләргә катыштырмас өчен, нáчальство жуликлар берлән бергә утырткан иде. Укыган сәясиләр арасында өчесе авыл учительләре иде, икесе типография хезмәтчеләре, берсе авыл писаре, икесе дума члены, берсе Чистай мулласы — дамелла иде. Болар арасында унбиш яшьлек малай булган кебек, кырык берлә илле арасындагы йортлы-җирле, балачагалы кешеләр дә бар иде. Боларның күбесе фәкыйрьләр булганга, төрмә ашларын ашап торалар иде. Төрмә ашының начарлыгын төрмәгә кереп чыкмаган кешегә аңлату мөмкин булмаганга, аның начарлыгын язар өчен диңгезләр кара булса, күкләр кәгазь булса да язып бетерерлек булмаганга, болар тугърыдан-тугъры ач торалар иде. Төрмәнен эчә торган суы төрмәнен

коесыннан гына алына иде. Бу су шулкадәр каты, шулкадәр куе иде, моның стаканына чиреге балчык дисәң дә ялган булачак түгел иде. Мамыйкларның озак торудан (алар биш айдан бирле утыралар) һәм буйлы ачлы-туклы торудан төсләре ямьсезләнгән, кыяфәтләренә ачлык төсе чыккан иде. Һәммәсе дә һәр көнне фельдшерга эч авырта, баш авырта дип зарланалар иде. Тагы, шуның өстенә, алар безнеке кадәр ике зурлыгы бүлмәдә 18 кеше торалар иде. Шуның өчен аларның бүлмәләрендә кич берлән параша исе берлән Алла ризасы өчен дә һаваның заты калмый иде. Тагы, шуның өстенә, бик күбесенең эче киткәнгә, камералар кеше тора торган бүлмәдән битәр әбрәкәйгә охшый иде. Аларның камераларының тугърысында коридорда да әллә нинди сасы дуңгыз азбарыннан чыккан исләр чыга иде. Төрмәдә буш камералар булса да, боларны, мичкәгә төягән тозлы кыяр кебек, берсе өстенә берсен төяп, сасыда эштән чыгаралар иде. Кечкенә генә золымга чыдый алмый торган, кешене мыскыл итүнең һәр кайсы өчен эчтән хурлана торган минем күңелем моны күреп бик кайгырды. Ләкин боларга бертөрле дә ярдәм итәргә юлның юклыгы тагы кәефемне җибәрде. Мин боларның хәлләрен сорашып, фәкыйрьлекләрен белеп, кайсына 20, 30, 50 тиен акчалар бирдем, ләкин минем үземнең дә акчам бик аз булганга, ул акчалар, аларның ихтыяҗына караганда ком сахрасына бер тамчы ягъмур кебек кенә булганга, күзгә күренмәенчә бетә дә китә иде. Мин, уйлап-уйлап, Казанга, Оренбургка, Мәскәүгә телеграм бирергә үземнең акчам булмаганга, ул фикерне беразга кадәр кичектердем.

Мин, төрмәгә килгәч, үземнең якыннарыма күрешергә килергә рөхсәт сорап жандармскийга телеграм биргән идем. Аңарга бик тиз җавап килде. Аны мин әйтеп өйгә хат та яздым. Ләкин өйдән шактый гына килмәенчә тордылар. Мин кергәннең икенче атнасында дүшәнбе көн әби берлән хатыным күрешергә килделәр. Мине алар янына керттеләр. Аларның икесенең дә күзләреннән яшьләр ага иде. Мин көлеп чыккач, алар да бераз ачылдылар. Мине бик каты кыйнаганнар дигән хәбәрдән бик куркуларын сөйләделәр. Иртәгесен тагы килергә булып киттеләр. Иртәгесен мин Казанга җибәрергә хат һәм телеграм язып бирдем. Һәм дә хатынымны берәр атнага калырга куштым. Аларның сөйләүләренә караганда, мине волостной сходка уполномоченный итеп сайларга хәзерләнәләр иде. Шулай итеп, көннәр үтеп китте. Хатыным Казанга ике телеграм бирде! Ләкин берсеннән дә ашыгып акча килмәде. Чөнки андагы кешеләр иректә булганга һәм дә тамаклары бик тук булганга, мондагы ач кешеләрнең хәлләрен аңлау ихтималлары бик ерак иде. Шулай итеп, көннәр үтте, атналар үтте. Корбан гаете житә башлады. Мин, төрмәгә тәмам өйрәнеп, укырга тотындым. Бүлмәбез бик тыгыз булганга, язарга-фәләнгә мөмкин түгел иде. Корбан гаете җитәр алдыннан без начальниктан гает өчен мәчеткә чыгарырга сорадык. Начальник, мин чыгара алмыйм, жандармскийдан сораңыз, диде. Без телеграм берлән жандармскийдан сорадык. Бөтен Чистай безнең гаеткә чыгуымызга ышанып көтәргә тотындылар. Гаеттән бер-ике генә көн элек безгә отказ килде. Иректәге кешеләр безне министрга телеграм бирик дип йөдәттеләр. Без аннан да шул җавап киләсен белгәнгә, акча әрәм итүгә риза булмадык. Чистай халкына гаеткә чыгармау бигрәк авыр булды. Үзләренең унбиш еллык муллаларын исерек учитель Зәңгәр Сәлах сүзе берлән гаепсез-нисез ябып куеп та, гаеттән мәхрүм калулары бик ачуларын китерде. Тагы, аңарга башка, шул көннәрдә генә губернский сәбәпсез-нисез дамелланың указы алынуын да халыкка белдерткән иде. Шуның өчен чистайларның ачулары килүнең иге-чиге юк иде.

Гает житте. Мөселман арестаннарын мәчеткә алып киттеләр. Алар кайсы ат урлаган гына булганга, кайсысы кеше генә үтергәнгә, кайсысы биш-алты кибет кенә басканга, безнең кебек үк куркынычлы түгелләр иде.

Шуның өчен төрмә начальствосы вә бөтен хәзерге Россияне идарә кылып килә торган кешеләр каршысында алар унбиш еллык мөдәрристән, Дума членыннан артыграк иде. Аларга бюрократларның ышанычлары боларга караган-

да күбрәк иде. Без, бер дә булмагач, ике көн күрешергә килергә рөхсәт сорадык. Начальник рөхсәт бирде. Гает көнне безнең өчен күңелсезрәк булды. Гариф абзый бу көнне көн буе үзенең моң тавышы берлән коддуси укып үткәрде. Дамелла берсе артыннан берсе өзелми торган намазларын, догалыкларын укып гомерен үткәрде. Мин камерадан камерага йөреп вакытны уздырдым. Төрмәдәге бөтен сәяси безне бәйрәм берлән тәбрик кылдылар. Чистайдан да тәбрикләр килде. Мин дә үземчә, шактый гына хезмәтем бар, дусларым бар, иптәшләрем бар дип, күңелемнән генә тәбрик көттем. Ләкин дустлар, танышлар, иптәшләр мондый вакытта үзләренең шатлыклы бәйрәмнәрен үткәрү берлән мәшгуль булгангамы, үзләренең мәсгуд минутларын минем тугърымда уйлап сәгадәтен киметмәс өчен, бер вакытны үзләренең дуслары, үзләренең иптәшләре булган төрмәдәге бер кешене уйламадылар да күңелләренә кертмәделәр. Аның да күңеле барлыгы, аның да алар кебек үк бәйрәмнәр итәсе дә, бюрократиянең золымы саясендә шул вакытларын зинданда үткәрергә мәҗбүр булуы хәтерләренә дә килмәде. Чөнки ул хәзер алар арасында юк иде, чөнки хәзер алар аңарга мохтаҗ түгелләр иде. Чөнки аның берлән алар арасында бик калын төрмә стеналары бар иде.

Сәгать 12 ләрдә безгә Чистай кешеләре килә башладылар. Чистай төрмәсе бүген төрмәлектән чыкты. Бүген бу, бер зур әүлия зияраты кебек, кешелеген югалтмаган һәр татарның килә торган урыны булды. Монда Чистайның күзгә күренерлек кешеләре һәммәсе килделәр. Туксан яшьлек картлар, ун яшьлек малайларга кадәр, халыкның рәхәтләре, халыкның ирекләре өчен җәза күрә торган үзләренең корбаннарын күрергә, аларны күреп шатланырга, аларны шатландырырга килделәр. Һәммәсе дә күңелләреннән әллә никадәр дустлык, әллә никадәр хөер хаһлык, әллә никадәр туганлык алып килделәр. Һәммәсе дә күзләреннән яшьләр агызып, үзләренең безнең өчен никадәр кайгыртканнарын күрсәттеләр. Без елаган, яшьле карт бабайларны, еларга күзләре яшь берлән тулган яшьләрне үземезнең кәефемез берлән, үземезнең сүземез берлә юатып җибәрә идек. Һәммәсенә төрмәнең алар уйлаган кадәр үк начар түгеллеген, безнең тормышның бигрәк яхшылыгын исбат итә идек. Боларның берсе дә безнең сүземезгә ышанмасалар да, безнең кәефемезне күреп шатланыбрак китәләр иде. Бу ике көндә безнең берлә күрешергә килгән кешеләрнең күплеге Чистай төрмәсенең тарихында беренче эштер. Мондагы хезмәтчеләр капка ача-ача йөдәп беткән кебек, килгәннәрдән бәйрәм котлавы ала-ала да кесәләре тулып бетте. Ашарга-эчәргә китергән нәрсә берлән безнең дә камера бөтенләй тулды.

Бәйрәм үтеп китте. Без хәзер 15 нче гыйнвардагы волость сайлауларын көтә башладык.

2 нче февраль, сәгать 10 нар, кич.

16 нчы гыйнварда иртә берлән сәгать уннарда тәрәзәдән безнең кияү берлән безнең авылның бер кешене күрдек. Мин чыгып, бик сорап күрешергә алдым. Алар мине сайлау хәбәрен китерделәр. Мине волостьта беравыздан сайлаганнар. Ләкин земский начальник бик кәефсезләнгән һәм дә, боздырмаенча калмыйм дип, Шәйхидән прошение бирдерде, диделәр. Мин төрмәдә булганга, әлбәттә, хәзер земский начальник, предводитель дворянства берлән тартышырга куәтем юк иде. Тагы, шуның өстенә, земский сүзе берлә, протоколларында да хата бар иде. Шуның өчен мине төшерүләре бик ихтимал иде.

Шулай булса да, бүген бөтен сәясиләргә зур бәйрәм булды. Һәммәсе мине тәбрик иттеләр. Без үземез дә бүген чәйне бер мәртәбә артык эчтек. Тагы берәр көннән Фуадның сайлануы да ишетелде. Берәр көннән бөтен Чистай өязендә яхшы татарлар сайлануы ишетелде. Озакламады, бөтен Чистай өязенең сайланган кешеләрен белдек. Сайлауларда русларның татарларга караганда наданраклыклары яисә куркаклыклары беленде. Руслар арасында карагруһлар да бар иде. Һәр нә исә, күбесе яңа фикерле халык яклы кешеләр иде. Элгәреге Дума члены Герасимовны сайлатмас өчен земский начальник,

стражниклар берлән становой барганлыгы, шуның өчен аны сайлый алмаулары мәгълүм булды. Бу вакытта бөтен төрмәнең авызында сайлау сүзләре иде. «Кем сайланган? Нинди партия кешесе?» сөальләре, шуларга җаваплар берлән бөтен прогулка вакыты үтә иде. Хәзер һәммәмез, үземезнең төрмәдә идекемезне онытып, сайлау эшләренә бөтен тәнемез, җанымыз берлән кереп киткән идек. Тагы 21 нче гыйнварда Чистайда шәһәр халкыннан сайлаулар булачак иде. Шәһәрдән сайланырга дип тәгаен кылынган кешеләрнең өчесе дә — ягъни Гариф Бадамшин, Иван Кунучев, доктор Дерагин төрмәдә булганга, боларның бүген-иртәгә әллә нинди хәйләләр берлән сайлау правалары алыну ихтималы булганга, төрлечә планнар корып куя идек. Һәм шул планнарны ирекка язып чыгара идек. Шәһәр сайлауларында мөселманнар бик зур роль уйнаганга, Гариф абзый мөселманнан ике кеше, рустан бер сул кеше кертергә уйлый иде. Бу фикергә русларның социалист революционерлары риза булсалар да, социал-демократлары разый түгелләр иде. Һәм дә мин дә бу вакытта, тавышлар бүленеп, карагруһлар җиңәр дип курка идем. Икенче мөселманны — дамелланы кую фарыз булганга, аның ризалыгы кирәк иде. Ул бу эшне бик үк мәслихәт күреп бетерми иде. Доктор Дерагин (кадет) безнең барымыздан да соң ябылганнан, без анда эшне бетердек. Дерагин, Димрат, Бадамшинга карар бирдек. Социал-демократлар да, безнең берлән дип, безнең һәр эшемезгә каршы килә иде. Без Чистайда татарлар тавышы берлән үзләренең членнары унбиш кеше дә булмаган ике кадетны җибәрергә риза булмый идек. Без иреккә шулай кирәк, болай кирәк дип хатлар яза идек. Сайлау алынлардан Чистай исправнигы тагы дүрт-биш мөселманны ябарга хәзерләнгәнгә, эш башында йөри торган кешеләр бары да шәһәрдән шуып торалар иде. Русларның да сулларының кайсылары качкан, кайсылары коты очкан булганга, тышта, ирекга кадетлар гына калганнар иде. Шуның өчен алар мөмкин кадәр мөселман тавышы берлән үзләренең ике кадетларын җибәрер өчен татарлар янында төлкеләнеп йөриләр иде. Һәм дә, аерылсаңыз — карагруһлар җиңә, дип, Иван Кунучевның правасы бетсә, ике кадет ясарга сүз дә алганнар иде. Сайлаудан берничә көн генә элек Кунучевның сайлану правасы алынды. Без тышка аның урынына тагы сул кешене күрсәтеп хат яздык. Ләкин кадетлар алдап-йолдап аның урынына үзләренең Димратларын тыкканнар. Фуад килгәч, без аңарга берьюлы ике эш куштык. Берсе минем эшемне белешү, берсе ике кадет сайлатмау иде. Ул тиз генә минем эшемне белешә алмады, ике кадет сайлатмау өчен бик тырышса да, татарлар арасында бу фикер бик таралган булганга һәм дә хәзер, язуны алыштырсалар, күп халык бүленеп чуалу ихтималы булганга, аңарга каршы килә алмады. Тагы Фуадның үзенең дә эше бик шәп түгел иде. Чөнки Фуадның авылында бик зур сакаллы, бик кечкенә башлы бер татар Фуадны сайлатмаенча, үзе сайланасы килгәнгә, халык аны сайламый Фуадны сайлаганга, теге мужик куштаны бик хурланып Фуад өстеннән жалоба биргән. Һәм дә, һәр татар куштаны кебек, әллә ниләр алдап, аның өстеннән донос та ясаган иде. Шуның өчен Фуад үзе дә кыл өстендә генә тора иде. Һәм дә бик сакланып йөри иде. Сайланган-фәлән иткән дигән сүз Чистай полициясе өчен бер тиен дә тормаганга, ул награда алыр өчен яисә исправникның дәрәҗәсен үстерер өчен Думага сайлангач та ябудан чирканачак түгел иде. Шулар өчен минем эшем артыннан йөрүче һәм дә аны боздырмаска теләүче, бозылса, сәбәпләрен белешеп төзәтергә керешүче юк кабиленнән иде. Безнең ирекгәге кешемез бер Фуад булганга, без аңарга үзен төшертмәскә, мине төшертмәскә, ике кадет җибәртмәскә куша идек. Шуның өчен аның эше бик күп иде. Һәм дә бик авыр иде.

20 нче гыйнварда ул минем төшерелгәнемне язды. Шулай булса да өметләр бетмәгәнгә, минем өчен бик тырышырга тотындылар. Комиссиядәге кешеләрнең бик күбесе карагруһ тарафдары булганга һәм дә аның башы карагруһ генералы Якубович мине яптырыр өчен дә шактый хезмәтләр иткән кеше булганга, мине төшерүдән саклый алмадылар. Без инде, минем төшүемә

разый булып, Фуадка үзе өчен һәм дә Чистайдан бер мөселман, бер кадет, бер сул китсен өчен тырышырга куштык.

Егерме берендә шәһәрдә сайлау башланды. Ләкин безнең теләгәнчә булмаенча, ике кадет куелганга, безнең бик кәефемез киткән иде. Шул хосуста төрмәдәге социал-демократлар берлән социалист-революционер арасында шактый гына тавыш та булган иде. Без сайлауларның нәтиҗәсен көтә башладык. Чөнки Чистай шәһәрендә староверлар бик күп булганга, алар һәммәсе октябристлар булганга һәм дә кадетларның Димратлары бер дә мәгълүм түгел кеше булганга, без боларның өчесенең дә чигүенә ышанып бетми идек. Кичкә таба безнекеләр чигә дигән хәбәр килде, ләкин катгый хәбәр түгел иде. Шул көнне, ничек булса да төнлә берлән беленер дип, без төн буе хәбәр көттек. Ләкин бер нәрсә дә беленмәде. Иртәгесен сәгать берләрдә октябристлар чигелгәне мәгълүм булды. Һәм дә сәгать дүртләрдә кемнең күпме тавыш алуы да беленде. Безнең күңелемезнең йөздән бере генә октябристлар чигелгәнгә шатланса да, үз тавышымыз берлән ике кадет җибәрүемез өчен күңелемезнең туксан тугыз өлеше кайгырта иде. Төрмәнең кешеләре барысы да социалистлар булганга, һәммәсе дә безнең кебек бер яктан кайгырып йөриләр иде. Социал-демократлар да үзләренең гаепләрен белгән кебек халыктан читтә йөриләр иде. Төрмәдәге кадет Дерагинга бүген бик зур бәйрәм булды. Ул үзләренең җиңүләренә чын күңеленнән шатлана иде. Вакыйган, шатланмаслык та түгел. Унбиш тавышлары берлән ике кеше үткәргәч ник шатланмасыннар?!

22 гыйнварда тагы бер хат алдык. Минем эшем бөтенләй бетмәгән икән. Хәзер әллә нинди юллардан төзәтергә телиләр, бәлки төзәтә алырлар, дигәннәр. Мин боларга, әлбәттә, ышанмадым. Алай да өмет дигән нәрсә тагы уяна башлады. Шулай итеп, бу көнне үткәрдек. Хәзер без Гариф абзый Бадамшинны калдырыр өчен нишләрләр икән дип көтеп тора идек. Вакыйган, комиссия аны калдырыр өчен бик тырышачак иде. Чөнки ул төшерелгәндә, аның урынына октябрист городской глава китәчәк иде. Бу кабахәт старовер Бадамшинны калдырып, үзе керер өчен әллә нинди усаллыклар кылырга да разый иде. Тагы Бадамшинны донос ясап яптыручы да шул кеше иде. Вакыйган, иртәгесен үк комиссиядә бик зур тавыш чыккан. Гариф абзыйны төшерер өчен карагруһлар бик тартыша башлаганнар.

22 нче гыйнвар шулай үтте. Кич берлән без яттык. Бу көн сәгать 12 дән волостьтан сайлаган кешеләр арасында Казанга унөч кешене сайлау башланганга, без шул сайланудан хәбәр көтә идек. Минем дә правам кайтарылса, сайлануымда шөбһә юк иде. Тагы Фуадның өстеннән бирелгән прошениеләр мәгънәсезгә чыкканлыгы белдертелгәнгә, аның да сайлануында сүз юк иде. Шуның өчен бу көн без бик озак хәбәр көттек. Ләкин хәбәр булмагач, йокларга яттык.

Сәгать беренчеләрдә безнең ишекне кактылар. Без уяндык. Ишек ярыгыннан хат бирделәр. Без өчемез дә торып укырга тотындык. Хат Фуадтан иде. Әүвәлге хәбәре: мин тәмам төшерелгән идем. Икенчесе — Фуад сайланган иде. Без, Фуадның сайлануына шатланып, минем төшерелүемне кайгыртырга да онытгык. Хатның теге ягын карадык. Тагы язу. Ләкин монысы соңрак язылган. «Мин сайланып беткәч һәм дә миннән соң биш кешене сайлагач, губернатордан: Фуад Туктаров авылында тормый икән, шуның өчен аны төшерегез, дип телеграм килде дә, мине төшерделәр»,— дип язган. Без, бу хәбәрне укыгач, яшен суккан кебек булып киттек. Чөнки бу эш сайлауларда законның аз гына да ригайә кылынмавын белдерә иде. Һәм дә Гариф абзыйны төшерү ихтималыны да бик якынлата иде.

Без урыннарымыздан торып, нишләргә белмәенчә, сөйләшергә тотындык. Безнең кайгымызның хәзер иге-чиге юк иде. Без хәзер беремез артлы беремез бюрократияне сүгә идек. Бу хәбәр безнең бөтен өметләремезне бозды. Бу хәбәр безнең Дума яхшы була дигән казыямезне җимерде. Чөнки губернатор телеграм берлән һәр яхшы кешене чыгара барганда, әлбәттә, Думаның яхшы

булу ихтималы юк иде. Гариф абзый кызып-кызып сүгә иде. Мин, сайлау эшләре шулкадәр бюрократларның үз кулларында булгач, бу сайлауларга да бойкот ясамау фикере хата түгел микән дип уйлый идем. Дамелла стенага сөялеп бер сүз дәшмәенчә уйлый иде. Аның йөзенә чиксез ачу килү, иксез хәсрәт, бик зур хурлану әсәре чыккан иде. Ул безнең Чистай өязеннән минем дә Фуадның китмәве өчен кайгырта. Безне төшерү правасы шундый карт бюрократлар кулында булуына хурлана иде.

Без бер-ике сәгать шулай нишләргә белми утырганнан соң, яттык. Беремез дә йокыга китә алмадык. Мин әйләнә-әйләнә йөдәп бетеп, сәгать бишләрдә генә йокыга киттем.

4 нче февраль, сәгать 10 нар, кич.

Иртә торганда баш авырый, күңел кайгырта иде. Без өчемез дә бик кәефсез идек. Өчемез дә бик зур өметләремезне югалткан идек. Торгач ук руслар берлән үземезнең хәсрәтемезне бүлештек. Гариф абзыйның хәзер үзен утвердить итүгә тәмам ышанычы беткән иде. Безнең дә өметемез бик аз иде. Бөтен төрмәдә: «Монда болай булгач, бөтен Россиядә шулай инде. Алай булгач, Думаның начар булуында, Думаның карагруһ тарафлы булуында, Думаның халыкка зарарлы булуында шөбһә юк инде»,— диләр иде. Шуның өчен барысы да кайгырышалар, барсы да бу эшләргә исләре китә иде.

Бүген безнең төрмәдәге көнемезнең иң кәефсезе булды. Без алай-болай итеп сәгать 12 ләргә кадәр гомер үткәрдек. 12 дә безгә күрешергә килә башладылар. Фуад минем берлән күрешергә килде. Ул үзенең эшенең бөтенләй үк өметсез түгеллеген һәм дә губернаторның ул телеграммасы берлә сайлану правасын алу Дума хакындагы низамга хилаф булганга, мондагы карагруһ комиссиясенең, бигрәк тә предводитель дворянстваның усаллыгыннан гына төшерелүен сөйләде. Һәм дә, авылына барып, үзенең анда йорты-җире барлыгына приговор алып килеп, губернский комиссиягә прошение бирәчәген белдерде. Безнең тагы бераз өметемез артты. Бүген тагы без Чистай комиссиясенең Гариф абзыйны төшерер өчен бик тырышуын белдек.

Бүгенге көндә төрмәдә бер ят эш булды. Ул да төрмәдән доктор Дерагинны чыгарулары иде. Чистай полициясе ноябрь башыннан бирле өязнең төрле тарафыннан Думага сайлауда тәэсире булырлык кешеләрне тотып япса да, моңынчага кадәр берсе дә чыгарылганы юк иде. Дерагин чыгарылуы халыкка тагы бераз өмет бирде. Күп кеше тиздән чыгарылуын көтә башлады. Ләкин, Дерагинны чыгарып, Гариф абзыйны калдыру тагы безнең күңелемезгә шөбһә төшерде. Без Гариф абзыйны ничек булса да бер юл берлә төшермәделәр микән дип уйлый башладык. Бу көннәрдә Гариф абзыйга бик авыр булды. Күңеленә әллә нинди шөбһәләр килә иде. Тагы, шуның өстенә, аның бу арада тешләре бик сызлаганга, һәм дә тегеләй дә бер дә кәефе юк иде. Дерагинның чыгарылуы төрмәнең тормышына бер төрле дә тәэсир итмәде. Чөнки, бердән, ул соң гына кергәнгә, тәмам төрмә иптәше булып бетмәгән иде. Икенчедән, аның кадетлыгы һәрвакыт үзен башка сәясиләрдән аерып тора иде.

Сәясәт галәмендә ике атна бербуйдан әле буйга, әле аркылыга йөзгәннән соң, сәясәт сугышында бик күп өметләремез бетеп, үземезнең югалткан праваларымызны кайгыртып арып беткәннән соң, безнең күңелләр дә дулкыннан соңгы диңгез кебек тагы тынычлый башлады. Без тагы Гариф абзыйны, Фуадны Думага җибәрү өметләре берлән ләззәтләнә башладык. Думага баргач, аларга нинди партияләр берлә бергә хәрәкәт итүләре, нинди эшләр эшләргә кирәклеге тугърысында сөйләшә башладык. Шулай итеп, өч-дүрт көн вакыт үтеп китте.

Бер көнне өйләдән соң, сәгать 3 ләрдә, яңа гына алынган гәзитәне укып (гәзитә төрмәгә кертелми, ләкин без итәк астыннан алып, һәр көнне гәзитә укып тора идек) торганда, бик кызуланып старший килеп керде. Мин бик тиз гәзитәмне сәке астына ташладым. Керү берлән: «Бадамшин, сөенче, сине

чыгаралар!» — диде. Безнең исемез китте. Гариф абзый: «Мин чәемне эчеп бетерим әле»,— дип, безнең берлә актык мәртәбә тышта нишләргәлеген сөйләшмәкче булды. Ләкин старший һич ирек бирмәде: «Анда, конторда, хәзер начальник көтеп тора, алай булса, конторга төшеп кул гына куеп мен»,— диде. Гариф абзый чыгып китте. Бер биш минуттан соң Гариф абзый, аның артыннан начальник килеп керде. Гариф абзыйга ясаган чынаягын да эчәргә ирек бирмәенчә, киендереп алып чыгып киттеләр. Мин коридорга чыгып сәясиләрнең һәммәсенә дә Бадамшин чыгарыла дип әйтеп чыктым. Барысы да чыгып күрешеп калырга теләгәнгә, ишекләрне дөбердәтергә тотындылар, ләкин берсен дә чыгармадылар. Без дамелла берлән боларның ут капкан кебек кыланып йөрүләренә исемез китте. Без хәзер тәрәзәгә мендек. Гариф абзый акыртын гына төрмә юлы берлән китеп бара иде. Бер атлаган саен бер артына карый иде. Безне тәрәзәдән күргәч, яулык селкә башлады. Без дә яулык селектек. Бөтен тәрәзәләрдән сәясиләр яулыклар бутый башлады. Гариф абзый бер-ике мәртәбә тукталып торганнан соң, безнең күздән югалды. Моннан ун минут кына зур тимер йозак берлән бикләнгән Гариф абзый иреккә чыгып китте. Аның шулай тиз чыгып китүе, аның төрмәнең теге тарафында иректә күренүе безнең гакылга сыймый иде. Төрмә янындагы стражниклар аны тотып китерерләр кебек тоела иде. Ләкин аны яңадан тотып китермәделәр. Чистайда әллә никадәр стражник булса да, никтер аны тагы полициягә илтеп ябып куймадылар. Гаебе беткәндер диер идек, аның элгәре дә гаебе юк иде. Шуның өчен, гаепсез кешене ябып, кырык көннән соң гаепсез дип чыгарып җибәрүне безнең гакыл аңламый, безнең мантыйк сыйдырмый иде.

Ни булса булды, Гариф абзый иреккә чыкты. Ул хәзер үзе теләгәнчә йөри, үзе теләгәнчә тора, үзе теләгәнчә йоклый ала торган, звоноксыз-нисез чәй эчә ала торган, көненә ике мәртәбә поверкасыз гомер кичерә торган кеше булды. Ул качырмаенча гәзитә укый ала торган, өстеннән ун кадаклы йозак берлә бикләмәгән өйдә тора ала торган, надзирательләрнең әмерләреннән башка да теләсә кая бара ала торган, көннең теләсә кайвакытында саф һавада чыгып йөри ала торган кеше булды. Ул хәзер бу тар бүлмәнең сасы һавасыннан, бу сасы парашаның һәр көнне исен иснәүдән котылды. Ул бу сасы коридорның исеннән, бу былчырак бәдрәфнең кабахәтеннән котылды. Аның хәзер урамда йөрүе, үзе теләгән вакытында капканы ачып чыгып, теләгән вакытында ябып керүе безгә гаҗәеп төсле күренә иде. Чөнки безгә хәзер урамнарда кешеләр йөремиләр, капкаларда стражниклар саклап бикләп торалар кебек күренә иде.

Шулай итеп, без дамелла берлән икәү калдык. Дамелланың иртәдән үк бүген кәефе юк иде. Шуның өчен аның үзе берлән бергә кергән иптәшенең чыгып китеп, аның калуы тагы, әлбәттә, кәефе килергә сәбәп булмады. Аның кайгырганы үзенең өй җәмәгате өчен иде. Ул Гариф абзыйның чыгып, монын калуы аларга бик авыр булыр дип уйлый иде. Аларны тагы бик зур өметләрен җимерер дип хәсрәтләнә иде. Ләкин никадәр хәсрәтләнсәк тә, монда әллә нишләр хәл юк. Бу төрмә! Монда синең хәсрәтең, синең кәефең берлә эш йөрми. Монда үзләре куйган кагыйдәләр берлә эш йөри. Син үлсәң дә, яисә синең күңелеңдә җәһәннәм утыннан кызу кайгылар булса да, болар вакытлары җитсә — поверка ясыйлар, вакытлары җитсә — ишекне бикләп куялар, вакытлары җитсә — парашаны кертеп куялар, бу — төрмә!

Миңа Гариф абзыйның чыгуы бер дә артык тәэсир итмәде. Чөнки үземнең бик тиз чыкмауны бик яхшы белгәнгә, төрмәдә тору ниятен бик еракка куйган идем. Гариф абзыйның чыгуы миңа бер яктан файда да итте. Мин шул көнне кич берлән үземнең төрмәдәге тормышымны язарга тотынырга муаффәкъ булдым. Чөнки ул юкка хәзер камерамыз шактый иркен иде. Кара, кәгазь куярга урын бар иде. Мин көндезен каралар, кәгазьләр табып эшкә керештем. Монда кара, кәгазь алыр өчен хосуси рөхсәт алырга, язганыңны бер начальникка күрсәтә барырга, язганың русча булырга кирәк булганга,

мин, әлбәттә, рәсми суръттә йөртмәенчә, аннан-моннан кәгазь, кара алып, урланып язарга тотындым. Урланып язуыңны белсәләр, хәзер язган нәрсәңне алып жандармскийга җибәреләчәк булганга, язу шактый авыр иде. Көннең һәр вакытында язарга мөмкин түгел иде. Көндезләрен начальниклары, старшийлары бик күп йөргәнгә, мин аяк асты шил булгач кына, поверкалар беткәч кенә яза идем. Бу вакытта да ишектән бер кеше керүе, коридорда аяк тавышы ишетелүе минем фикеремне бүлдерә, каләмемне ташларга мәҗбүр итә иде. Тагы, шуның өстенә, язганнарны саклау да бик авыр иде. Монда төрмәдә сакласаң, тентү булса-нитсә, бөтен язганнарың харап булачак, бөтен хезмәт әрәм китәчәк иде. Шуның өчен боларны иреккә чыгарырга кирәк иде. Анда чыгару да итәк астында хезмәтчеләр аша һәм дә эшкә чыгучы арестантлар аша гына булганга, аларны да кайвакытларда тентеп чыгарганга, бу кәгазьләр иреккә чыгып җиткәндә җиде сугыш сафыннан котылган гаскәр кебек булалар иде. Шуның өстенә тагы, иреккә чыккач та югалмасын дип бик курка идем. Чөнки Чистай халкы һәммәсе безнең ничек торганны бик беләсе килгәнгә, һәммәсе дә укырга тырышачаклар иде. Укый-укый кулдан-кулга йөреп, башы югалуы да бик якын иде. Мин шуларның берсенә дә карамаенча яза башладым. Һәм дә тышка чыгарта башладым. Моңынча әле андый-мондый каза ирешкәне юк.

5 нче февраль, сәгать 10 нар, кич.

Язганымны күреп алганнары юк иде. Иреккә чыгарылганнары югалды дип хәбәр бирелгәне юк иде. Гариф абзый чыккач, февральнең башларында миңа эшемнең жандармскийдан чыгып, бер яктан губернаторга, икенче яктан прокурорга бирелгәне белдертелде. Мин 23 нче декабрьдә арестовать ителсәм дә, бу көнгә кадәр минем эшемнең жандармскийда торуы миңа жандармнарның бик әһәмият бирүләрен, минем эшемне бик җентекләп тикшерүләрен белдерә иде. Мин Казанда вакытта минем фатирымнан бик күп кәгазьләрем, бик күп язган әсәрләрем алынган булганга, шуларны да карап, шуларның да барын бергә бутап, җыенысыннан әллә нинди жандармский боткасы ясауларында шөбһәм юк иде. Минем шикләнгәнем андагы кешеләрдән минем хакымда алган мәгълүматлары мине әллә нинди эшләргә бутап, мине Казанга алдырмасыннар фикере иде. Эш каялыгын миңа мәгълүм итүләре минем Чистай төрмәсендә калуымны белдерү булганга, мин бу яктан шатлана идем. Тагы, шуның өстенә, минем эшемне икегә бүлеп, бер яктан губернаторның ихтыярына калдырылуы миңа сылтый торган гаепләрнең бик аз идекен, мәхкәмә алдында минем гаебемне исбат итү мөмкин түгеллеген белдерә иде. Шуның өчен мәхкәмә мине гаепсез тапса, алар губернаторның үз куәте берлән мине ссылкага җибәрергә юл хәзерлиләр иде. Мин моны бик яхшы аңласам да, аңарга бик исем китми иде. Чөнки шул арада җыела торган Думаның халык яклы булуы шул арада алына торган телеграмнардан бик ачык мәгълүм иде. Шуның өчен Думаны куганча бюрократия бераз йомшап торачак иде, реакция кимиячәк иде дә, безне шул вакытларда чыгарачаклар иде. Әгәр Думаны тиз куып, безне чыгарырга өлгерә дә алмый башласалар, Дума өчен халык арасында тагы чуалулар башланачак иде. Табигый, бик зур арестлар башланачак, төрмәләрдә яңа сәясиләргә урын кирәк булачак иде дә, безне тагы кайсымызны чыгарачаклар, кайсымызны читкә җибәрәчәкләр иде. Шуның өчен хәзер миңа булачак җәзаның иң зурысы — мине читкә җибәрү иде. Россиядә хөрриятләр игълан кылынганнан бирле шул хөрриятләрдән файдаланырга теләгән кешеләрдән илле мең кеше Себерләргә җибәрелгәнен бик яхшы белгәнгә, әлбәттә, мин мине Себергә җибәрәләр дип елап торачак түгел идем. Җибәрсәләр, китәчәк идем. Чыгарсалар, чыгачак идем. Себергә җибәрү тагы кеше арасына җибәрү булганга, мин, әлбәттә, анда да үз эшемдә булачак идем. Минем авызымны пичәтләп кую, каләмемне сындырып ыргыту мине үтермәенчә мөмкин булмаганга, әлбәттә, мин анда да язачак идем. Анда да үземнең фикеремне таратырга тырышачак идем. Шуның өчен читкә

җибәрү мине үземнең хезмәтемнән аера алмаганга, аның өчен бик үк кайгыртып торырга тугъры килми иде. Һәм мин бер дә кайгыртмый идем. Этап берлән бару шактый авыр эш булса да, этапта йөрегәндә бик күп мәшәкатьләр күрергә тугъры килсә дә, бу мәшәкатьләр, бу авырлыклар һәммәсе дә минем киләчәк язуларым өчен бик кыйммәтле материал булачак булганга, монда да минем күргән зарарымнан иткән файдам артык булачак иде. Шуның өчен бюрократлар нишләсәләр дә, мин җиңгән булып калачак идем. Мин үз фикерем берлә мине җибәрүне уйлап куйганга, аңарга хәзерләнергә тиеш идем. Шуның өчен мин Казанга хат язып, мөмкин кадәр шул «Зиндан»ымны бастырып сатып, акча хәзерләтергә тырышырга үтендем. Үземнең хатыныма юлга чыгарга хәзерләнеп торырга кусштым. Әниләрне дә: «Җибәрсәләр дә, минем өчен бер дә авыр булмаячак»,— дип, күңелләрене юата башладым.

Шулай иттереп көннәр үтте, атналар үтте, безнең тормышта бер үзгәрү дә булганы юк. Без һаман дамелла берлән бер бүлмәдә, һаман элгәреге кебек көннәрне, кичләрне үткәрәмез. Элгәреге кебек күрешү көннәрдә Чистайдан килгән утызар-кырыгар кеше берлән күрешәмез. Элгәреге кебек поверкалар ясала. Элгәреге кебек парашалар кертелә, әлгәреге кебек зур йозаклар берлән бүлмәләремез бикләнә. Тыш яктан караганда һичбер үзгәрү юк. Ләкин рухымызда бераз ару сизелә башлады. Дамелла бу көннәрдә бик начар йоклый башлады. Аның йокысы качты. Мин дә элгәреге кебек татлы йоклый алмый башладым. Ятканнан башлап торганчыга кадәр әллә нинди төшләр күреп, эштән чыга башладым. Төрмәнең һавасы, аның табигате акыртын гына безне җиңә башлады, без бер туктамаенча томау берлән авырый башладык. Бер туктамаенча борынымыз мыкырдап йөри башлады. Менә шулай итеп бүгенгә кадәр (7 нче февраль) тордык. Бу көн Гариф абзыйның Казанда Думага сайлануын ишетеп шатландык. Фуадның төшерелеп калдырылуы өчен бик кәефемез китте. Моннан соң тагы нинди кәефсез хәбәрләр ишетеләчәген киләчәккә багышлап, без һаман бер көйгә төрмәдә ятамыз.

* * *

Төрмәдә торганда Гариф абзыйның гомеренең иң күбесе авыру берлән үтте. Аның нервалары бик изелде. Ул бик тиз ачуы килә торган, бик кызулана торган булды. Кечкенә генә дә суык тию аны бөтенләй авыруга сантыра торган булды. Тагы, шуның өстенә, теш сызлавы аны өчәр көн бербуйдан ятып торырга мәҗбүр итә иде. Елның начарлыгы, сәүдә эшләренең бик авырлыгы аның тагы кәефен китәрә иде. Чөнки аның кибетендә караучысы булмаганга, төрмәдә яткан һәр көн аңарга материальный да зарар китерә иде. Чыгуның очы күренмәве, әлбәттә, аның кәефе китүен тагы арттыра иде. Шуның өчен төрмәдә яту безнең барыбыздан битәр Гариф абзыйга авыр булды.

Дамелланың эше башкача иде. Аның сәламәтлеге яхшы булганга, табигате сабыр булганга, ул һәр авырлыкларны бер дә авырсынмаенча күтәрә иде. Ул үзенең ябылуына, үзенең указы алынуга исе китми иде. Үзенең ябылуының халыкка тәэсире бик зур булуына, халыкның бюрократиягә ышануының кимүенә сәбәп булганга, ул ябылудан бер дә зарар күрми иде. Аның кайгырткан нәрсәсе үзенең өй җәмәгатьләре иде. Вакыйган, аның өй җәмәгатьләре кайгыртмаслык та түгел иде. Аның өендә берсеннән-берсе кечкенә алты бала аның хатынының кулына калган иде. Хатыныннан башка аларны караучы өйдә беркем дә юк иде. Тагы, шуның өстенә, алар һәммәсе дә һәр көнне бүген чыга, бүген чыга дип көтеп, чыкмый калгач, яңадан кайгыртырга тотыналар иде. Үзенең якыннарының кайгысын күрү, аларның шул хәсрәтләрен бетерергә йә киметергә ярдәм итә алмау, әлбәттә, дамелланың кәефен җибәрә иде. Тагы, шуның өстенә, күрешергә килгән чит кешеләр аның кәефен бик җибәрәләр. Бу кешеләрнең иң күбесе хәкыйкатән дамелланы кызганучылар булганга, алар кызганган кеше өчен елауны гадәт итеп ал-

ганга, дамелланы күрү берлән, дамелланың кайгыларын сөйләп-сөйләп еларга тотыналар иде. Әлбәттә, үзләренең бу эшләре берлән дамелланың йөрәгендә яшеренеп яткан кайгыларын уяталар иде. Кайсылары тагы, бик гакыллы булган булып, дамелланы бик юаткан булып: «Юк, хәзергә кайгырырга ярамый! Чыгаралар, шул көндә чыгаралар, менә күреп тор, чыгаралар!» — дип, дамелланы тиз көндә чыгарырга өметләндерәләр иде. Әлбәттә, алар вәгъдә кылган көннәр җитә иде. Үтә иде. Алар берлән бергә дамелланың тиз чыгарга өмете дә бетә иде. Килгән кешеләр тагы яңа күз яшьләре алып киләләр, тагы яңа вәгъдәләр берлән юатмакчы булалар иде. Шуның өчен дамелла күп көнне күрешүләрдән соң бик кәефсез була иде. Аңа иректән килгән шул кешеләрдән аерылып калу авыр тоела иде. Аларның каны гакылсыз бала кебек итеп, юк сүзләр берлән юаткан булып маташулары аңарга мыскыл иткән кебек тоела иде. Төрмә тормышының аның өчен авыр ягы булса, ул да — аның русча рәтләп сөйли белмәве һәм дә сөйләгәнне аңлый алмавы иде. Шуның өчен ул без сөйләшеп көлешкәндә, кычкырышканда аңламаенча тик тора иде. Шуның өчен ул төрмәдә үзенең хиссиятен, үзенең уйларын бездән башка кешеләр берлән бүлешә алмый, үзенең шатлыгын, хәсрәтен башкалар берлә уртаклаша алмый иде. Минем үземнән соң иректә кешесез-нисез магазиным калмаганга, төрмәгә кергәннән соң указым алынмаганга, әлбәттә, минем төрмәдә югалткан нәрсәм бөтенләй башка иде. Иткән зарарым бөтенләй икенче төрле иде. Өйдәге җәмәгатем, этиләр, әниләр, туганнарым, хатыным минем өчен кайгыртсалар, алар минем ябылуымны ике елдан бирле көтеп килгәнгә, әлбәттә, бу кайгы аларга дамелла җәмәгатьләре кебек ук авыр тоелмаган иде. Тагы, шуның өстенә, минем үземнең алар берлән күрешкәндә һәрвакыт ачык булуым аларның күзләренә тулган яшьләрен, күңелләренә җыелган хәсрәтләрен бөтенләй туздырып җибәрә иде. Шуның өчен алар миңа күз яшьләре түяп килеп, минем күңелемә үзләренең хәсрәтләрен аударып китмиләр иде. Алай булса да, мин алар өчен бераз кайгырта идем. Килгән вакытта мөмкин кадәр аларны үз янымнан шат иттереп чыгарырга тырыша идем. Минем күбрәк кызганганым хатыным иде. Чөнки аның миңа килгәненә өч ел булса да, ул шул өч ел эчендә бер дә рәтләп минем берлә тора алганы юк иде. Бу гомернең күбесендә мин качып йөргәнгә, ул ялгыз торырга мәҗбүр булган иде. Тагы быел бер ай тормас борын да мине төрмәгә япкач, тагы ялгыз калган иде. Шуның өстенә, киләчәктә аңарга тагы әллә нинди этапларда баруларны, төрмәдән төрмәгә күчеп йөрүләрне хәзерләп торганга, вакыйган, аның хәле кызганыч иде. Бу эшләргә барсына да мин сәбәп идекемне белгәнгә, әлбәттә, мин аның алдында үземнең бик зур бурычлы идекемне белә идем. Шуның өчен аны кызгана идем.

7 нче февраль, сәгать 10 нар, кич берлә.

Минем икенче кайгым — шундый әһәмиятле вакытта Россиянең идарә мөстәкыйлләсенең актык мәнзарәләре бөтен галәмнең күз алдыннан үткәндә үземнең төрмәдә ятып, бер эш эшли алмавым өчен иде. Тагы төрмәдә үземнең теләгән китапны укып булмау, үзең теләгәнчә язып булмау минем төрмәдәге гомеремне әрәм гомергә хисап итәргә мәҗбүр итә иде. Шуның өчен мин үземнең төрмәдә торуым өчен кайгырмасам да, төрмәдә вакыттагы гомеремнең әрәм булуы өчен кайгыра идем. Моңарга башка, төрмә минем исәнлегемә дә шактый гына зарар итәчәген, минем элгәредән йомшак нерваларымны изәчәген белгәнгә, бу тарафтан да бераз кайгырта идем. Бу хәсрәтләрнең һәммәсе кайгыртырга яраткан кешегә кайгыртырлык нәрсәләр булсалар да, мин кайгыртып кына кайгы кимемәгәнне бик яхшы белгәнгә, кайгыртмаска уйлап куйган идем. Һәм кайгыртмый да идем.

Төрмәдә бездән башка егермегә якын рус сәясиләре һәм дә җир эшләре берлә кергән 25 ләп авыл кешеләре бар иде. Бу соңгыларының ябылулары сәясиләр кебек жандармнар кулына бирелсә дә, безнең аларга сирайәт

итүемездән куркып, аларны мөмкин кадәр безнең берлә бергә булудан тыярга тырышалар иде. Аларны безнең берлә йөрергә чыгармыйлар, аларны үзләрен генә бер камерада аерым тоталар иде. Башка сәясиләр күбесе учительләр иде. Калганнары төрлесе төрле ак эштәге кешеләр иде. Болар үзләренең фикерләре берлә социалист революционерлар һәм дә социал-демократларга бүленәләр иде. Кайсылары бер партиянең да программасын рәтләп белеп бетермәгән партиясез социалистлар иде. Болар арасында бәгъзе мәсьәләләр мондагы социалист революционерлар да, социал-демократлар да, үзләренең төрмәдә идекләрен онытмаенча, төрмә эшләренең һәммәсендә дә бергә хәрәкәт итәләр иде. Без кергән вакытта сәясиләрнең бик күбесе фәкыйрьләр булса да, хәзер Чистайдан ярдәм килә башлаганга... хәзер начар булса да, барысының да ашарларына бар, барысының да чәй-шикәрләре вә башка кирәкләре җитеп тора иде. Ләкин крәстиәннәрнең хәлләре көннән-көн начарлана бара иде. Читтән килгән ярдәм барысын да тәрбия кылырга җитәрлек булмаганга, үзләренең бер тиен акчалары юкка, алар ачлы-туклы гомерләрен үткәрәләр иде.

Шуның өчен аларның хәлләре, алар арасында төрле авырулар күбәя бара иде. Безнең аларга иткән ярдәмемез бик аз булганга, аларга җитәрлек ярдәм итәргә акча булмаганга, без теләр-теләмәс аларның ачлы-туклы торуларына шаһид булып тора идек. Моңарга каршы бер юл берлә дә ярдәм итәргә чара таба алмаганга, мин бик кайгыра идем. Үземнең тук булып, аларның ач торуларына вөҗданым газаплана иде. Шуның өчен мөмкин кадәр аларга ярдәм итәргә тырыша идем вә башкаларны да шул ярдәмгә димли идем.

Төрмәнең хезмәтчеләренең, надзирательләренең безгә караулары элгәрегә караганда бөтенләй үзгәрде. Без кергәндә иртәдән алып кичкә кадәр бертуктамаенча сүгенеп тора торган надзирательләр чәй эчәргә, аш ашарга, сәгатьләп сөйләшеп утырырга кертә башладылар. Без хәзер, номердагы кебек, бер-беремезгә чәй эчәргә, аш ашарга, ләскит сатарга кунакка йөри башладык. Без хәзер төннең шактый соң вакытларында бәдрәфкә ачтырып чыга башладык, сәясиләрнең күплеге бөтен төрмәгә дә тәэсир итте. Безнең югарыгы этажда хәзер элгәреге кебек бертуктамаенча шпаналар сүгешеп тормыйлар. Безнең коридорда хәзер сүгенү тавышлары бөтенләй ишетелми башлады. Шпаналар, тоз күленә төшкән ишәк кебек, үзләре дә яртылай сәясигә әйләнделәр. Хәзер элгәреге мәгънәсез җырлар урынына башка җырларын җырлый башладылар. Элгәреге ботка өчен, лампа өчен тартышулар урынына, җир мәсьәләсе хакындагы низагълар, партияләр хакындагы моназәрәләр ишетелә башлады. Кыскасы гына, төрмә хәзер элгәреге бертуктамаенча кабахәт сүзләр ишетелеп тора торган төрле каракларның кеше үтерүчеләрнең җыелган җирләреннән битәр бер мәктәпнең пансионына яисә студентларның тора торган ярлы номерларына охшый башлады. Номерыннан, пансионнан аермасы булса шул ишекләрнең йозаклар берлә бикләнүендә, тәрәзәләрдәге тимер рәшәткәләрнең бер дә кирәкмәгән урында торуында һәм дә көне-төне револьвер таккан кешеләрнең, ни диптер, безне саклап торуларында иде. Без хәзер боларның барсына да өйрәнгәнгә, боларның берсе дә безгә искиткеч куркынычлы нәрсә кебек тоелмый иде. Төрмәнең начальствосы бик йомшак булганга, башка төрмәләрдә төшкә дә керми торган правалар берлән без монда билфигыль файдаланып торганга, безнең берлә төрмә начальствосы арасында низагълар бер дә булмый иде. Башка төрмәдәге кебек монда тентүләр-фәләннәр булмаганга, без үземезгә кирәк һәрнәрсәне камераларымызда саклый ала идек. Һәркөнне кебек без иректән хәбәр алып тора идек. Һәр көнне гәзитә укый идек. Тагы монда күрешергә кертүләр дә бик простой иде. Күрешергә рөхсәт бирелгән кешегә күрешү көнендә никадәр кеше килсә дә, мин карендәш дисә, кертәләр иде. Шуның өчен безнең хәлемез башка төрмәләрдә ята торган иптәшләремезнең хәленә караганда бик күп артык иде. Тагы, шуның өстенә, шул көннәрдә җыела торган Дума да безгә төрмә начальствосы-

ның йомшак мөгамәләсенә бик зур ярдәм итә иде. Думаның якынлашканы саен алар йомшара баралар иде. Сайлауларда суллар җиңү беленгән саен аларның безгә карашлары үзгәрә бара иде... Тагы шуны да онытырга ярамый, шул көннәрдә төрле сәяси вакыйгалар безнең хәлне тиздән яхшыртып җибәрде. Без әйтү берлә безгә ерактан йомшак су китерә башладылар. Старший, йомшак тотасың дип, надзирательләрне йөдәтми башлады. Ул безнең берлә үзе яхшы мөгамәлә кылырга тырышып, йөри башлады. Кечкенә генә бер эштә дә үзенең дибераллыгын күрсәтергә тырыша башлады (бугай).

Менә без, шулай итеп, һаман әле төрмәдә торамыз. Тагы кайчанга кадәр торуымыз, тагыниләр күрүемезне күрмәстән борын язарга мөмкин булмаганга, мин шуның берлә әлегә язуны тәмам итәм.

8 нче февраль, сәгать 9, кич берлә.

Әллә кичә «Зиндан»ны тәмам итеп куйгангамы, бүген, язарга тагы яңа эш чыкты. Бу эш ирекгәге кешеләргә бер дә әһәмиятсез вакыйга булса да, төрмәдә нервалары ватылган кешеләргә шактый тәэсир итә торган эш булганга вә безнең шактый ук кәефемезне китәргәнгә, язмакчы булам. Без Гариф абзыйны сайлануын ишеткәч, үк күтәргә тотынган идек. Кичә Гариф абзыйның кич берлән кайтачагын белдерделәр. Шуның өчен бүген көн буе без Гариф абзыйны көттек. Ул аннан яңа хәбәрләр алып кайтыр дип, ул безгә хәзер ирекнең хәлен белдерер дип, ул безнең Думага нинди кешеләр сайланганны сөйләр дип ике күземез берлә көтә идек. Көн буе көтеп, килмәгәч, төрле шөбһәләргә дә төштек. Ахырдан без прогулкада вакытта, сәгать дүртләрдә, Гариф абзый килә диделәр.

Озак үтмәде, ул килеп җитте. Бөтен сәясиләр үзләренең ун көн элек кенә чыккан иптәшләрене Дума члены итеп күрергә дип капка янына җыелдылар. Капка ашасыннан барымыз да исәнләштек. Старший чыгып, начальниктан кертергә рөхсәт сорарга китте. Без менә хәзер кертәләр дип көтә башладык. Бераздан старший килеп, начальник рөхсәт бирми, диде. Без Гариф абзыйга, үзең барып сора, дидек. Гариф абзый үзе китте. Бераздан соң килеп, начальник йоклый дип мине кертмәделәр, диде. Безнең барымызның да бик ачуымыз килде. Гариф абзыйның да ачуы килүе билгеле иде. Ул капка ашасыннан гына сайлауларның яхшы булуын, Думада сулларның бик куәтле булачагы күренүен сөйләп, иртәгә килергә вәгъдә кылып китте.

Гариф абзыйны кертмәү бөтен сәясиләрнең ачуын китерде, бигрәк минем кәефемне җибәрде. Мин үземнең төрмәдә идекемне, шуның өчен үзем күрергә теләгән кешене күрә алмавымны, ирекгәге кешеләрдә һич әһәмияте булмаган бер кеше берлә сөйләшү правам да төрмә начальникларының кулында булуы мине бик хурландырды. Бу эш минем күңелемдә ябылып яткан һавалылыгыма тукынды. Мин нишләргә белмәенчә, ачуымнан кая бәрелергә урын таба алмаенча бик озак йөрдем. Эчемнән әллә ниләр уйлап бетердем.

11 нче февраль, сәгать 10 лар, кич.

Тагы әле бетмәгән икән, кичә тагы яңа эшләр булды. Берсе — 10 нчы февраль булганга, 10 нчы февральдә, миңа егерме тугыз тулганга, минем туган бәйрәмем булды. Иптәшләр барсы да мине тәбрик иттеләр. Сәгать уннарда мин аларның иң якыннарын чакырып чәй эчердем. Өйләдән соң, сәгать 3 ләрдә, мине кунакка чакырдылар. Мин аларга барып чәй эчтем. Бүләк бирүфәлән итү, әлбәттә, төрмә булганга, булмады. Алай булса да, бүген минем өчен бәйрәм төсле үтте. Мин моңынча да үземнең туган көнемне бәйрәм итәргә теләп йөрсәм дә, моңынча төрле сәбәпләр берлә бу теләгемне булдыра алганым юк иде. Быел беренче мәртәбә уларак, төрмәдә утызга чыгуымны бәйрәм иттем.

Икенче вакыйга — кичкә йөрергә чыкканда иптәшләрдән берсе конторга кереп үзенең эше тугърысында прошение язарга сорады. Капка ачучы: «Хәзер начальник та юк, старший да юк»,— дип, кертмәде. Ул иптәшнең ачуы ки-

леп, бик каты звонок бирә башлады. Шул арада контордан мылтыгын күтәреп стражник чыкты. Һәм дә әллә ниләр әйтеп, ул иптәшне сүгә башлады. Ул каршы сүгешкәч, бик гайрәтләнеп: «Ә, әле синең ялгыз бүлмәдә утырасың килә икән. Без сине өйрәтермез!» — дип, старшийны эзләргә чыгып китте. (Ул иптәш әллә кайчаннан бирле ялгыз бүлмәдә утыручы иде.) Озак үтмәде, стражник старшийны алып керде. Һәм дә бик гайрәтләнеп-гайрәтләнеп сөйләргә тотынды, бөтен сәясиләр хәзер капка янына җыелып җиттек. Һәммәмез бер кеше кебек стражникка бәйләндек. Стражникның төрмә эшенә катышырга хакы юклыгын сөйләп, аның иптәшне сүгүе өчен протокол язарга требовать иттек. Стражникның безнең иптәшне һәм безне бераз өйрәтә ала алмавы өчен, әлбәттә, бик кәефе китте. Үзенең кыйнау правасының бөтен җирдә тигез, бөтен халык өчен гомуми, бөтен Россиянең гражданнарына тугърыдан-тугъры, бөтен мәхкәмәләрдә яшерен дип игътикад кылган стражник, әлбәттә, үзенең бүген кыйный алмавы өчен кәефе китте.

Ул, старшийга да карамаенча үзенең мөкаддәс вазыйфасын үтәмәкче булса да, безнең ялтыраган күзләремездән, йомарлаган йомрыкларымыздан куркып, кереп китте. Ул кергәч, без барымыз да шул мәсьәлә хакында сөйләшергә тотындык. Стражникның бу эше барымызның йөрәгенә тукынган иде. Барымызның да төрмәдәлекемезне хәтеремезгә төшергән иде. Стражникның бу эше кырмыска оясына таяк тыккан кебек булып, безнең йоклаган ачуларымызны уятты. Безгә әллә никадәр гайрәт бирде. Без кызуланып-кызуланып шуның хакында вә полиция хакында сөйләргә тотындык.

Бу кечкенә генә вакыйгага безнең бик ачуымыз килүе безнең нервалрымызның да шактый гына йомшарганлыгын белдерә иде. Без, начальник килеп, протокол язачагына вәгъдә алып, прогулканы бетереп, үз бүлмәләремезгә кердек.Тагы үз бүлмәләремездә көндәге кебек тора башладык. Хәзер без, Гариф абзый чыкканнан бирле, чәй йокыга зарар иткәнгә, көненә икедән артык чәй эчмәскә тырышамыз. Бүген, шулай итеп, кич берлән чәй эчмәдек. Мин үземезнең Казан төрмәсендәге ятучы иптәшләргә багышлап «Корбан гаете» дигән бер нәрсә яздым («Тавыш» гәзитәсенең беренче номерында басылды). Дамелла аны укып чыкты. Аның хакында сөйләштек тә, сәгать 12 ләрдә йокыга яттык.

Сәгать ничә икәнен белмим, безнең ишек шалтырап ачыла башлады. Мин сикереп тордым, дамелла да уянды. Ишектән старший берлә хәзер начальник урынына калган околоточный, дамеллага карап: «Сезгә өйгә кайтырга!» — диде. Без сикерешеп тордык. Тагы кемне чыгаралар икән дип, боларның аяк эзләре кая киткәнне көтә башладык. Аяк тавышы Кунучевлар камерасы тугърысына туктады. Алар камерасында кеше күп булганга, кайсысын чыгаралар икән дип көтә башладык. Аларның камералары гөрләргә тотынды. «Кунучев!» «Кунучев!» дигән тавыш ишетелә башлады. Бер минутта бөтен төрмә уянды — төрмә гөрләргә тотынды. Дамелла бик тиз киенде. Мин аңарга 11 нче февральдә язган «Зиндан»ның ахырын һәм «Корбан гаете» дип язган нәрсәләрне биреп чыгардым. Дамеллага «Зиндан» хакында Казан берлә белешергә һәм дә «Корбан гаете»не «Казан мөхбире»нә басарга җибәрергә куштым. (Бу вакытта үземезнең гәзитәмез юк иде.) Алар чыгып киттеләр. Мин сәгатьне карадым, сәгать дүртенче ярты иде. Мин тәрәзәгә мендем. Дамелла берлә Кунучев акрын гына китеп баралар иде. Алар артларына карый-карый гына күздән югалдылар. Мин бик озак йоклый алмаенча яттым. Часть сәгате бишне суккач кына мин йокыга киттем.

Иртә торгач та мин руслар бүлмәсенә Кунучев урынына күчтем. Өйләдән соң минем берлә күрешергә бик күп кешеләр килделәр. Чистайларның, дамелланың чыгуына бәйрәм ясап, кибетләр ябуларын сөйләделәр. Шул шатлык хөрмәтенә төрмәдәге фәкыйрьләр өчен акча җыюларын да сөйләделәр һәм миңа да акча китерделәр. Кунучев та күрешергә килде. Ул да руслардан җыеп акча китерде, безнең бердән йөз тәнкәләп акчамыз булды. Шуннан соң

акчадан яхшырак файдаланыр өчен без «коммуна» (бергә, бүлешмәенчә ашауэчү) ясарга карар бирдек. Һәм дә төрмәнең начальнигыннан үземезнең һәм дә җир өчен кергән авыл халкын ашатырга тотыла торган акчаны сорый башладык. Начальник безгә — сәясиләргә көненә бишәр тиен (төрмә ашын ашамаган кешенең простоена 5 тиен, мирзасына 10 тиен биреләдер) бирергә вәгъдә кылса да, авыл халкына бирмәвен катгый сурәттә белдерде. Без авыл кешеләренә, үзләре чынлап сорасалар, без аларны требовать итеп алыр өчен голодовкага кадәр барачагымызны белдердек. Ләкин алар үзләре алай каты иттереп сорый алмадылар. Шуның өчен ул мәсьәлә шулай тавышсыз-тынсыз гына бетте.

Без үзара «коммуна» ясадык. Эш бетерә башладык. Шул вакытларда начальник Казаннан барып кайтканга, безнең төрмәне тагы кыса башладылар. Безнең берлә төрмәнең начальствосы арасында тагы кычкырышлар китә башлады. Мин хәзер «Отпавший» исемле бер пьеса язарга хәзерләнә башладым. Бер көнне пьесаның пәрдәләрен бүлеп, планын бетереп, язарга гына тора идем, старший кереп безнең бүлмәдә тентү ясый башлады. Бездә әллә никадәр әйберләр булганга, китаплар, гәзитәләр, кәгазьләр алып чыкты. Һәм дә минем «Отпавший»ымның да планын алып чыкты. Безнең тагы төрмә начальствосы берлә арамыз бозылды.

Шулай итеп, дүрт-биш көн үтте. 17 нче февральдә минем берлә күрешергә дип әни берлә хатыным килде. Алар иртәгә дә күрешергә килергә вәгъдә кылып киттеләр. Бу көн тагы шулай үтте. Тагы кич булды. Кич сәгать сигезләрдә ике иптәшемезне конторга чакырып, Пермь губернасының ерак өязләренә — берсен ике елга, берсен бер елга себергә җибәрелүләрен белдерделәр. Боларның берсе 17 яшьлек, берсе 16 яшьлек малайлар гына булганга, кылган эшләре дә бер дә булмаганга, болар өчен бу җәза бик авыр иде. Шуның өчен бөтен төрмә бүген шул эш берлә, шул уй берлә мәшгуль булды. Без бөтен камерамыз берлә ссылкага җибәрәләр дип хөкем итеп куйдык. Әгәр үз ихтыярымыз берлә булса, кайларга китәргәлекләрен уйлаштык. Этапның юлын тикшерештек. Шулай итеп биз озак утырганның соңында, сәгать 12 ләрдә яттык.

Мин бер дә рәтләп йоклый алмадым. Шулай иттереп йоклар-йокламас яткан вакытта безнең ишек шалтырый башлады. Без барымыз уяндык. Ул арада булмады, начальник кереп: «Исхаков, өйгә!» — диде. Мин сикереп тордым, иптәшләр сикерешеп тордылар. Тегеләр тагы икенче бүлмәләргә дә кереп әйттеләр. Без хәзер минем берлә өч кеше чыгарылганны белдек. Бөтен төрмә уянды. Төрмә тагы гөрләргә тотынды. Мин барсы берлән дә күрешеп, иртәгә килергә вәгъдә кылып киттем.

Чыккач ук минем әүвәлге уем очраган городовойлардан качу иде. Чөнки алар, күрсәләр, тагы мине частька илтеп ябарлар кебек тоела иде. Мин извозчикка барып җиткәч үк әниләрнең торган фатирына яллап киттем. Озакламаенча кайтып та кердем. Әниләрнең исләре китте. Алар үз күзләренә үзләре ышанмый иде. Аларның шатлыкларының исәбе-хисабы юк иде. Без барымыз, йоклый алмавымызны белгәнгә, чәй эчәргә тотындык. Бик озак чәй эчеп, сәгать 5 ләрдә генә бер сәгать йоклап алдык. Иртә торгач, бөтен Чистай күрешергә килә башлады. Мине харчевняга чакырдылар. Анда мине 150 ләп кеше көтеп тора икән! Алар берлә, барсы берлән дә күрештем, барсына да рәхмәтләр укыдым. Тагы әллә ничә төшләргә барып, кичкә таба төрмәгә иптәшләргә бүләкләр алып күрешеп килдем. Әниләр өйгә кайтып киттеләр, мин хатыным берлә ат яллап кайтырга калдым. Шулай булса да, күрешүченең күплеге аркасында без кичке сәгать унсыз Чистайдан чыгып китә алмадык.

Сәгать 12 ләрдә Яуширмәгә кайтып җиттек. Иртәгесен минем берлә күрешер өчен тагы бөтен Яуширмә килде. Тагы әллә никадәр күз яшьләре түгел-

де, тагы әллә никадәр шатланылды. Мин тагы иреккә чыгып тора башладым. Тагы мин бүген ябалар, бүген ябалар дип көтә башладым.

ХАТИМӘ

Шул язганнарым берлә бу әсәремне бетермәкче булам. Чөнки бу язылганнардан төрмәнең ничек идеке, төрмәдәге тормышның ни төрле булдыгы беленә дип уйлыйм. Шулай булса да, төрмә хакындагы үземнең фикеремне кыска гына иттереп тагы әйтмәкче булам.

«Ирек»тәге кешеләр төрмәгә керү түгел, төрмә дигән сүзне ишеткәч үк котлары оча, тәннәре калтырый башлый, йөрәкләре еш-еш суга башлый. Иректәге кешеләр төрмәдә рәтләп ашап-эчеп, яхшылап йоклап булмый дип уйлыйлар. Иректәге кешеләр төрмәдә ятарга, утырырга урын юк, бер-берең берлә сөйләргә рөхсәт юк, күрешергә ирек юк дип беләләр. Иректәге кешеләр төрмәдәге кешеләрнең аякларын, кулларын богаулыйлар, теләгән саен кереп-кереп кыйныйлар дип фараз кылалар. Шуның өчен безнең халык төрмәдән бик куркалар. Төрмә дигән сүз ишеткәч үк: «Хакыннан, нахакыннан сакла!» — дип дога кылырга тотыналар. Вакыйган, төрмә шулкадәр куркынычлы урынмы? Вакыйган, төрмәнең начарлыгы кешене куркытып, үзе ышанган эшне эшләүдән тыярлыкмы? Һич юк! Төрмә, әлбәттә, куркаграк кешеләрне куркытыр өчен, йомшаграк кешеләрне кылган эшләреннән тәүбә кылдырыр өчен ясалган. Ләкин төрмә яратылганнан бирле хисаплаганда, төрмәдә ятудан туеп бер кергән кеше, икенче ятудан куркып, үзенең эшли торган эшләреннән тәүбә кылганы, үзенең сөекле хезмәтеннән баш тартканы бер дә юктыр, булса да, бик аздыр. Төрмәгә ябылган вак-төяк караклар, төрмәдәге зур караклардан өйрәнеп, аларның әллә никадәр дәресләрен тыңлап, чын карак булып чыгалар. Болар төрмәдән чыкканның икенче көнендә үк тагы урларга тотыналар. Төрмәдән курку боларны бер эштән дә тыя алмый. Сәясиләрнең йомшаграклары иптәшләрен күреп үзләрен тотарга өйрәнәләр, төрмәнең начальствосы берлән тартыша-тартыша табигатьләре ныгый, куркулары кими, аларның наданраклары әллә никадәр нәрсә укыйлар. Әллә никадәр сүз ишетәләр. Моңынчыга кадәр кеше әйтмештән генә с. р. яисә с. д. булып йөргән кешеләр, чынлап партия кешесе булып чыгалар. Төрмәдә вакытның йокыдан калганы бар да буш булганга, төрлесе төрле фән берлә мәшгуль булып, әллә никадәр мәгълүматларын арттыралар, төрмә боларга бертөрле мәктәп була! Шуның өстенә, үзеңне үзең саклап тотканда, ашарга-эчәргә җитәрлек булганда төрмәдә сәламәтлекне дә югалтмаска мөмкин. Шулай булгач, бу эшне эшләргә бик яратмасам да, төрмәгә ябарлар дип куркам дип, эшләми калырга ярыймы? Әлбәттә, юк!

Яшь шәкертләргә, үзенең мәгълүматын арттырырга теләгән кешеләргә төрмә бик зур файда бирәчәк, аларның русча рәтләп белмәгәннәренә русча өйрәнергә бер дәресханә булачак.

ГАЯЗ. 1907

(Тәмам.)

Барлас Камалов

Дулкынлана хәят

(Повесть)

Сәкинә мәктәп юлында булды, Гөлнур инде кул арасына керә, колхозда эшли башлаган иде. Ятимәләр икесе дә бик матур җырлыйлар иде. «Сөбханалла! Күзсендермик кенә инде бу балаларны!» — диләр иде авылда. Ә тавышларына сокланып, көрсенеп куярлар иде: «Ятим балалар моңлы була, диләр шул!»

Гөлнур әнисеннән отып башкарган бер җыр сүзләрен авылда төрле көйгә җырлый торган булып киттеләр:

> **Очрадым таң җилләренә,**
> **Бәрелде җиңнәремә;**
> **Миһербанлы ак язмышым,**
> **Тотсана иңнәремнән...**

Гөлнур җырлаганда һәрчак аңардан ике класс алда укучы Камил баян уйнап торыр иде. Нинди күрәзәлек беләндер, олысы-кечесе аларны килер көннәрдә мәхәббәт пары итеп юрыйлар иде. Хикмәти хода, юраулары юш килде бит. Инде кавышуларын көтәләр иде. Сәкинә дә җизнәле булырга өметләнеп йөри башлаган иде, тик...

Үсә-үсә Гөлнурның холык-фигыле бик үзенчәлекле булып калыпланды. Серлегә әйләнде диярлек. Ул үзенең эчке кануннары буенча көн итә, күпләргә ул табышмак, чөнки җан түренә читләрне кертергә ашыкмый иде. Ул гүя «Минем җаныма берәү дә хаким була алмас!» дигән сүзләрне яшәү догасы иткән. Безнең заманда, якыннарыбызга да, ятларга карата да түзем-чыдам җитмәгән бер заманда, җиләктәй пешеп җиткән кыз баланың үзен шулай тотуын аңларга кирәктер.

Байназар аның холкындагы үзгәрешләрне күңеленә киртли тора һәм балдызы тамырларындагы канның кушылу даулап ага башлавын тоя иде. Гөлнурның буй җитүе җизнәсен яшерен бер кымырҗу белән ярсындырды.

Гөлнур, колхозда төрле эшләрдә йөреп, бераз матавыклангач, колхозда сыер сава башлады. Аның авылда ныгытып төпләнергә карар кылуына Камилнең туган туфракка ябышып яшәве дә тәэсир итми калмагандыр. Егет ветеринария техникумын бетерде, армиягә барып, ир-ат иңенә төшкән бурычны үтәп кайтты да үз хуҗалыкларында ук зоотехник булып эшли башлады. Читтән торып институтта

---

* Дәвамы. Башы журналның 1999 елгы 12, 2000 елның 1 саннарында.

укый. Һәр тумыш көнне яшьләр гел бергә. Сөю тулы күңелләргә, йә, әйтегез, тагын ни кирәк? Вәгъдәләре бар көенә янәшә эшләүгә ни җитә?..

Тик... Язмыш үзе дә гел генә ак булмый һәм иңнән сыйпап кына да тормый икән...

Көннәрнең берсендә Гафура каты авырып китте. Әүвәле дә еш кына сиздергәли иде, декабрь башында йөрәге екты да салды. Бермәл өйдә дәваланып бакты, шулай да барыбер район сырхауханәсенә салмый булдыра алмадылар.

Гөлнурга өйдә дә мәшәкать җитәрлек, фермада да тел-теш тидермәслек эшлисе бар. Җизнәсе белән алмаш-тилмәш апасы янына да барып йөрми булмый. Шундый матавыклы иртәләрнең берсендә (Гөлнурны кулалмашы алыштырган көн иде) Байназар ике еллык үгезен суярга җыенды.

— Көннәр, шөкер, суыкка утырды бугай. Тагын ни гомер көтәргә була инде? Аллага тапшырып, балдыз, чалырбыз ул малны. Мунча суынырга да өлгермәгәндер әле, тагын да бераз чыралап кына ал да мул итеп су җылыт,— диде ул һәм барча шартын китереп терлек суя торган зур пычагын кайрарга утырды. Егерме елдан артык тракторчы-комбайнчы булып эшләгән бу азамат ир, гадәттә, нидер кайрарга, үткенләргә, төзәтергә, сипләргә дисәң, кинәнеп китүчән иде. Бу юлы озак маташуның хаҗәте дә юк иде шикелле, аннары ул үзалдына кызып-кыбырсып, ялманып-нәфесләнеп тора иде, пычакны, йөзен тастымал белән сөртеп, бер читкә куйды да мунчага юнәлде. Анда ул көткәннән дә артык манзарага юлыкты. Ишек ачып керсә, анадан тума Гөлнур, ишеккә йөз белән баскан килеш, өстенә тастан су агызып коена иде. Җизнәсен күрүгә, ул таш сын хәлендә калды, кулындагы тас идәнгә тәгәрәде. Кызның авызы ачык иде, әмма аннан сыңар аваз да чыкмады. Күзләре тонган иде. Ничә мизгел үткәндер, Гөлнур кинәт чырайлап җибәрде һәм җизнәсенә аркасы белән борылып, мич алдына чүгәләде, бөрешеп-бетәшеп калды. Озын куе чәчләре кара ефәк шәл булып иңнәренә таралган иде.

— Җизни, чык! Алла хакы өчен дим, чык! Кычкырам, чык! Каравыл салам!..

Зур гәүдәле, озын буйлы Байназарга җиңеллек каян килгәндер, ул селәүсен җитезлеге белән балдызына килеп ябышты, аны күтәреп торгызды, йөзе белән үзенә борды һәм шашынып үбәргә тотынды. Гөлнур телдән калды, тавышы каядыр бәгырь эчкәресенә китеп югалды, ул бизгәк тоткан төсле калтыранды, ниһаять, хәлдән тайды һәм идәнгә сыгылып төште.

Байназарга шул гына кирәк иде. Ул еш-еш сулый, ярсынудан тынына капкан иде. Өзми дә куймый сөйләнде.

— Балдыз, җаным, хәзер, хәзер... Син курыкма да, шикләнмә дә... Мин сине җәннәттә тотармын, җәннәттә...

Инде карышыр хәле калмаган балдызын Байназар сап-сары итеп юылган идәнгә сузып салды да тезләнде. Кызның ак мәрмәрдәй гәүдәсенә, буй-сынының зифалыгына шак катты. Бөдрәләнеп торган кара өчпочмакка күзләре оясыннан кубардай булып томырылып карады...

— Тор, балдыз, тор... Госел коен да өйгә кайтыйк. Асылларның асылы икәнсең. Бәяңне белермен мин моннан ары, бик белермен... Әйдә өйгә!.. Борчылма да, кайгырма да. Бу хәл икебез арасында кабергәчә сер булып калыр...

Байназар мунчадан чыгып киткәч, Гөлнур өстерәлеп кенә күтәрелде һәм ләүкә басмасына утырып, куллары белән башын учлады. Бөтен гәүдәсе ут булып яна, кыйнап ташлаганнан да битәр сызлый иде. Тагын моңача кичермәгән бер әрнүавырту бар...

«Нишләтте ул мине? Ниләр кылыйм хәзер? Бу килеш кемгә кирәгем бар минем?» — Гөлнурның күңеле болганды, косасы килә иде, ләкин ул укшудан узмады. Миендә бөтерелгән уйлар өере янгын булып ургылды. Алар арасында бер генә якты фикер дә юк.

Бик аз гына тын утыргач, ниндидер кискен карарга килеп, кыз сикереп торды. Иреннәрен кан чәчрәп чыгарлык итеп тешләгән иде. Мунчаның буеннан-буена сузылган баудан халатын алып киде дә өйгә ашыкты. Җил-җил кайтканда сөрлекте, абынды, төкәнде, кантарлы туң җиргә егылып тез күмәчен күгәртте, ләкин авырту тоймады.

Чоландагы өстәлдә мал чала торган пычак ята иде. Гөлнур шуны кулына алып, баш өстенә күтәрде. Электр уты яктысында пычак зәһәр ялтырады...

Кыз өй ишеген тибеп ачты. Җизнәсе түр өстәле буенда кырынып утыра. Ишеккә арты белән. Ул башлап бер сүз дә әйтмәде, балдызының сөйләшә башлавына өметләнә иде бугай. Гөлнур исә күзенә ак-кара күренерлек хәлдә түгел иде.

Ерткычка ташланган кыяфәттә кизәнеп, ул үткен озын пычакны Байназарның сул калак сөяге астына кадады. Җизнәсе кыргый тавыш белән үкереп идәнгә ауды. Аның күкрәгеннән чаптырып кан ага иде. Гөлнур ике куллап башына ябышты да, чайкала-чайкала тышка атлады. Бу минутта аның ике кулында ике камчыдай чәч иде.

Кылган гамәле кызны утлы кадакка бастырды. Беренче эше шул булды: күршеләренә кереп, тотлыга-терәлә хәбәр салды:

— Байназар җизнине кадап үтердем... Терлек суя торган пычак белән... Ул... минем... минем намусымны пычратты, яшьлегемне талады, кызлыгымны...

Иртәнге табында утырган күршеләре сикерешеп тордылар.

Гөлнур, кая барасына хисап бирмәстән, уңга-сулга карамыйча, басу капкасына таба йөгерде. Кемдер аны куа китте.

Байназар әле үлмәгән иде, шифаханә юлында җан бирде.

Гөлнур Нурдәүләтова зинданга эләкте.

Ире һәм сеңелесе хәлләрен ишеткәч, Гафура да үлемнән чак калды. Хәле шулкадәр начарайган иде, куна-төнә сакладылар. Мәгълүм инде, Байназарны аңардан башка гына җирләделәр.

Болай да сүзен санап кына сөйли иде, дәваланып чыккач, Гафура бөтенләй телсез калды диярлек. Йортка килгән афәт турында берәү белән дә сыңар сүз дә сөйләшмәде.

Азгын иренә нәфрәте ташкан идеме, Гөлнурны гаепләп һични әйтмәде. Сәкинәгә булган мәрхәмәтле карашы тамчы да үзгәрмәде. Урта мәктәпне тәмамлагач, кызның институтка китүенә риза иде, «Хәзинәдә барыннан өзмәм, укы!» — диде. Алай да Сәкинә бер ел эшләп алырга, азрак үз-үзен карарга булды.

Инеш авылында Гөлнурның кара язмышын уртаклашырга әзер тагын бер кеше бар иде. Ул — Камил. Төрмәгә, Гөлнурга дип язган хатларын ул Сәкинә аша җибәртте. Почтага Сәкинә сала иде аларны.

— Хатларымда ни язганыма син шаһит бул, сеңелем,— дия иде Камил.— Укып чык, аннары конвертларсың. Синнән бер яшерен сүзем дә юк минем...

Шуңа күрә аның хатларындагы сүзләрне Сәкинә яттан белә:

«Язмыш шулай явыз шаярган икән, ни хәлләр итик? Мин сине көтәм, Гөлнур. Үткән фаҗигане булмады дип бел. Кемнәр генә ниләр димәсен, син — минеке. Мин дә аңламасам, сине бүтәннәр аңламастыр да. Гөнаһсызлыгыңны беләм. Туры үзебезгә кайтырсың дип өметләнәм. Ишектән килен булып керерсең. Кайда ничек яшәү турында бергәләп уйлашырбыз. Сау-сәламәт кайта гына күр. Дөньяда синең өчен җаны фида Камил барын бер генә минутка да онытма. Безнең мәхәббәткә киртә юк...»

10

Гыйззәт институт тормышына бик тиз ияләште һәм яшьләрнең уртасында кайный башлады. Беренче курсның башында ук аны факультет комсомол бюросының әгъзасы итеп сайладылар. Сентябрьдән үк стипендия алуы хәлен җиңеләйтте. Авылдан да беркадәр булыштылар. Егетләр белән Ерак Устьега — баржалар, тимер юл станциясенә вагоннар бушатырга да йөрде. Анда акчасын көнендә санап бирәләр иде. Илленче елның көзе иде бит инде, сугыштан соң тормыш акрынлап эзенә төшеп бара иде.

Беренче семестрда нибары ике имтихан тапшырдылар. Гыйззәт Зарипов икесен дә «отлично»га бирә алды. Мондыйлар группада икәү генә булды. Икенчесе — Казан егете Заһир Яфизов.

Гыйззәтне тинтерәткәне бер фән иде — немец теле. Юк инде, юк, авыл мәктәпләрендә чит телне тиешенчә укытмыйлар. Хәер, Иж-Бубыйдан килгән кызлар әйбәт кенә беләләр иде немец телен. Тик аларны русчалары чамалы булу интектерә иде. Мәктәпләрдә немецчәдән татарчага тәрҗемәләп укытканнар.

Туп-турысын әйткәндә, керү имтиханында немец теленнән «дүртле»не Гыйззәткә, солдат егеткә, укытучы кызганып кына куйган иде. «Өчле» куйсам, бу солдат стипендиясез кала. Миннән булсын яхшылык! — дигәндер. Яшь, чибәр, пөхтә, нечкә зәвыклы шәһәр туташы иде имтихан алучы. Зөлфия Сәяровна Баһаветдинова. Бик яхшы укыган булган. Институтның чит ил телләре факультетын тәмамлауга, кафедрага алып калганнар. Гыйззәт боларны бераз соңрак белде. Ә имтихан алганда Зөлфия Сәяровна өлкән сержант Зариповка: «Сез инде, Зарипов, мине җайсыз хәлдә калдырмаска тырышыгыз. Чит телне ныклап өйрәнегез.

«Дүртле»не мин сезгә аванс итеп куям»,— дигән иде.

Гыйззәт, үзеннән кала ундүрт кеше белән бергә, нәкъ менә Зөлфия Бәһаветдинова группасына эләкте. Бүтәннәр кайсы — инглиз, кайсы француз теле өйрәнүчеләр булып чыкты.

Шунысы кызык, РТО бүлегендәге беренче курсның да яртысы Зөлфия Сәяровнада укый башлады. Сәкинә дә аңа эләкте. Гыйззәт белән Сәкинә еш кына үзләреннән өч-дүрт кенә яшькә өлкән укытучыларының таләпчәнлегенә, хәтта кырыслыгына хәйран калып сөйләшәләр иде.

Беренче курста чит телдән зачетлар гына. Икенче курс азагында — имтихан. Гыйззәт икенче курста исемле стипендия ала башлады. Аңа Горький исемендәге стипендия бирделәр. Укуын, җәмәгать эшләрен шулай дәвам итсә, студентларның фәнни җәмгыяте эшендә дә катнашса, өченче курста аны Сталин стипендиясенә тәкъдим итәчәкләре дә мәгълүм булды. Мәгәр моның өчен зачеткага бер генә «яхшы»ның да кермәве катгый шарт иде.

Язмышның ачу катыш елмаюыдыр, гел «бишле»гә бару юлында Гыйззәткә аяк чалган предмет ни булды димсез? Бөтен курсы кырык дүрт сәгатьлек «Мәктәп гигиенасы». Өченче семестр азагында Газраильгә тиң Рашат Сүнәков дигән бәндә, медицина институтыннан килеп укытучы, япон самураена охшаган, әмма буйга колга доцент студент Зариповның котын алды. Бу кеше хакында өлкән курста укучылар рас әйтә килгәннәр икән. «Егетләрне һәм гел «отличнo»га укучыларны өнәми»,— диләр иде. Моны Гыйззәт үз җилкәсендә татыды.

Имтихан тапшырганда студент Зарипов парта капкачы тактасының калынлыгын ике миллиметрга ким әйткән булып чыкты.

— Мин сезгә «отлично» куя алмыйм,— диде Сүнәков, калын пыялалы күзлеге аша карап һәм авызын бүлтәйтте.

— Тагын бер билет биреп карагыз алайса,— дип үтенде студент.

— Алыгыз...

Монысында төп сорау кеше күзенең төзелеше иде. Өлкән курстагылар тарафыннан кисәтелгән Гыйззәт кеше әгъзалары төзелешен күңелдән ятлаган иде. Кыл сыярга да җай калдырмаслык итеп җавап бирде. Сүнәков әллә янә сарказм катыш елмайды, әллә чырай сытты — анык кына әйтүе читен — һәм сорап куйды:

— Тагын бер билет аласызмы?

— Алам.

Гыйззәт Зарипов өченче билетка да авыз тутырып җавап бирде.

— Материалны намуслы өйрәнгәнсез...

Ниһаять, Сүнәковтан шундый сүз чыкты. Югыйсә аны «Мин — бу фән буенча Казанда бердәнбер белгеч. Кабат тапшырырга уйласагыз да имтиханны фәкать миңа гына бирәчәксез»,— дип өркетә диләр иде.

Алда яңа дәһшәт — дүртенче семестрның «палачы» — немец теле имтиханы иде. Тик Гыйззәт ниндидер гайре табигый көчкә, тылсымга ышангандай, бөтенләй үк шүрләми иде. Ике ел буена баш күтәрми шөгыльләнүе дә бәхәссез. Иоһан Гете, Иоһан Шиллер, Иммануил Кант телен өйрәнүдә чирек карыш кына алга китсә дә сабыйларча куанды. Немецчә журналларны, газеталарны, хәтта шигъри әсәрләрне, сүзлекне култык таягы итеп булса да, укый алуына сөенде. Шуннан тәм, ләззәт таба башлады. Монысы — бер.

Икенчеләй килеп, Гыйззәт Зарипов күңел эчкәресеннән генә Зөлфия Сәяровнаның миһербанлыгына да исәп тота иде. Укытучысының аны ихтирам итүен группадашлары да тоймый калмагандыр. Хәер, ул ихтирамның үтә үзенчәлекле икәнен институтның төп бинасындагы актлар залында Беренче Майга багышлап уздырылган кичәдән соң Гыйззәт үзе тирәннән аңлады.

Шулай килеп чыкты, ул кичтә Гыйззәт белән Зөлфия Сәяровна парлап танцевать иттеләр (Сәкинә бәйрәмгә Инешкә кайтып китмәгән булса, бәлки алай килеп чыкмас иде). Аннары Зөлфия үзен озатып куюны үтенде. Укытучы ерак түгел, Нариман урамында гына тора икән. Озата барды Гыйззәт. Зөлфия Сәяровна аны квартирасына чакырды. Чәй өлгертте. Бу кичтә ул үзенең — укытучы, Зариповның студент икәнен онытып торды бугай.

Гыйззәт тә яшь укытучыны бөтенләй башка бер ноктадан күрде. Гаҗәп ашкын, ачык күңелле иде бу сәгатьләрдә Зөлфия. Дөньяга гашыйкларча карый, беренче күз салганда ул һич искитмәслек ваклыкларда да матурлык күрә иде. Ул, мөгаен, вазадагы чәчәкләрнең төсен генә түгел, шул төстәге төсмерләрнең дә һәммәсен тойгандыр. Әлеге минутларда кош сайраса, ул аны нотага салырлык

дәрәҗәдә нечкәләп тыңлар иде шикелле. Зөлфия шундый дәртләнеп сөйләде, Гыйззәт онытылып китеп, аның авызына гына карап торды, укытучысының хыялларына ияреп, ерак-еракларга сәяхәт кылгандай булды. Зөлфия Сәяровна гүя канатлы җан һәм җиргә генә ябышып яшәү аңа ят иде сыман.

Чәй янына шәраб та килгәч, аны татып, икесе дә беркадәр иләсләнгәч, Зөлфия Гыйззәтне өнсез калдырырлык итеп: «Яратам мин сине! Бул минеке! Өйләнешик!» — диде һәм ике куллап аның муеныннан кочып алды. Егет күңелендә нинди өермә купканны тасвирлавы читен. Куәтле магнитка эләккән иде ул. Укытучысын кочагына алды.

Шашынудан айныгач, наянлыклары өчен орышылган балалар кебек, икесе ике урындыкка барып утырдылар. Беренче булып Зөлфия сүз башлады.

— Йә, җавабың нинди булыр? — диде.

Гыйззәт мондый тәкъдимгә җавап бирерлек хәлдә түгел иде. Шулай да иреннәрен тегеп куйган кеше төсле утырырга ярамаганлыгын чамалап:

— Берни дә әйтә алмыйм әле мин, Зөлфия Сәяровна,— диде.

Зөлфия, урындыгын алып, Гыйззәтнең каршысына ук килеп утырды. Тезләр тезгә орынып калды. Гыйззәт читенсенү тойды, ләкин сер бирмәскә кирәген төшенә иде. Зөлфия Сәяровна очкынланган күзләре белән егетнең карашын тотты. Күзгә-күз төбәшеп калдылар.

— Сине нәрсә шикләндерә? — диде Зөлфия, мәсьәләне тәмам шәрәләндереп. — Минем синнән дүрт яшькә өлкән булуыммы? Укыйсым бар, гаиләгә башымны бәйләп интегермен, дип куркасыңмы? Апаңның каршы төшәрен күз алдына китердеңме? Йә булмаса минем әрсезләнүем, башлап тәкъдим ясавым нәфрәт уяттымы? Әллә боларның һәммәсе бергәме?

Гыйззәт һаман җавапсыз иде, тик югалып калу халәте узды. Сынын туры тотып, ир-егетләрчә җитди утыра башлады. Зөлфиянең нинди дә булса җавап ишетми торып тынычланмасын да яхшы аңлый иде. Шуңа күрә:

— Мондый чакта җавапны бер кизәнүдә генә биреп буламы икән? — диде. Шул сүз җитә калды, Зөлфия Сәяровна фикерен дәвам итте:

— Миңа шундый ышаныч каян киләдер, белмим, тик сине бәхетсез итмәсемне сизәм. Укуыңа комачау булмаячакмын. Монысын өзеп әйтә алам. Мин эшләрмен, диссертациягә дә керешермен. Син бик тырышып укырсың. Кечкенә булса да яшәр урын бар.— Ул кулы белән квартираны әйләнеп чыккандай итте. Көнкүрешне җайлауны үз өстемә алам...

Бу көнне Гыйззәт өзеп кенә һични димәде. Тел күтәреп әйтер сүзе юк иде. Аның каруы миен биләп алган уйлар байтак иде.

Изге тамыры бармы әллә Зөлфия Сәяровнаның? Гыйззәтнең үзенә яратып, сокланып каравын ничек сизгән? Ул бит аңа чибәр дә, акыллы да туганын яраткан шикелле, сөйләп аңлаткысыз мөнәсәбәттә иде. Табигать гүзәллеген яраткан төсле ярата иде, матурлык өлгесе итеп, җанга рәхәт бирүче итеп. Өйләнергә уйлап түгел. Хатыны итеп күз алдына китереп карамыйча. Ниндидер бер илаһи ярату иде бит ул.

Кайта-кайта фикер йөртте Гыйззәт. Әгәр Зөлфия Сәяровна тәкъдим иткән юлны сайласам, дип, бер вариантны ихтималлап карады хәтта. Иң беренче итеп апасы каршы төшәр идеме икән? Төшәр идедер. Ул болай да энесен җилдән дә көнләшеп үстерде шикелле. Гыйззәт бит — апасының бердәнбер юанычы. Тормышының мәгънәсе дип йөргән энесенең укытучысына, үзеннән өлкән шәһәр кызына өйләнүен өнәмәс иде. «Үзебезчәрәк берәр кыз булса, әйбәткә барып чыкмас идеме икән соң? Бу татар марҗасы минем ишеләрнең сукмагын бик тиз суытыр бит синең тарафыңа»,— дияр иде.

Дус-ишләре, яшьтәшләре дә аңламаслар иде. Начар уйларлар иде. «Өйрәнчеккә бәрәнчек булып авызланган да инде бу малай, шуннан башың аралый алмаган. Әтегесенә... кайнар канлы яшьрәк ир кирәк булган. Бүтәнчәли боргаланырга хуты калмагандыр...» диярләр иде.

Урта мәктәптәге укытучылары һәммәсе гаҗәпләнеп бот чабарлар иде микән? «Егет башлы,— дип мәсхәрәле елмаючылар да табылыр иде.— Стипендиягә яшәп изаланмаска уйлаган. Укытучы акчасына көн итәргә җыена...»

Имеш-мимешнең, гайбәтнең чиге булмас иде. Монысына шикләнмәскә мөмкин. Бу тиклесе — Гыйззәтнең Зөлфия Сәяровнага өйләнүгә читтән караш мәсьәләсе. Ә үзе? Үзе бәхетле була алырмы? Зөлфияне бәхетле итәрлек кодрәткә ияме соң ул?

Сәкинә белән ике арада бөреләнеп килә торган мөнәсәбәтләр дә сискәндерергә тиеш түгелме соң аны?

Болар һәммәсе — үзенчә фактор. Шулай да... еллар үтеп, кайдадыр авыз пешерә калса, Зөлфия тәкъдимен кире кагу аны тәпәләмәсме соң? Өйләнгәч, балалары булгач, Зөлфия дигән гүзәл зат уеннан китмәсә, хыялыннан югалмаса, үзенә чакырып, өндәп, ымсындырып торса? Шул сәбәпле, булачак хатынына хөрмәт-ихтирам кимесә, аңа битарафлык чигендәге мөнәсәбәттә яшәргә калса?

Көне-төне уйланды Гыйззәт. Зөлфия Сәяровна квартирасында булган төнге аулак анның җан тәрәзәсенә көмеш сылады түгелме? Масаюга тартым бер халәт, таянычка ошаган ниндидер бер терәк тудырмасмы? Чип-чиста пыяла чагында анның тәрәзәсеннән киң дөнья күренә иде. Көмеш сылагач, пыяла көзгегә әверелде түгелме һәм Гыйззәт анда фәкать үзен генә күрә башламадымы соң? Хәерле үк фал түгел иде бу. Сәкинәгә мөгамәләсе томанланыбрак калды шикелле. Әмма мондый вәзгыять озакка бармады.

Путевкасы (хәзер татарча юллама дибез шикелле) шулай туры килдеме, Зөлфия Сәяровна Җиңү бәйрәменең иртәгесен Кисловодскига санаторийга китте. Шуннан ике генә көн элек Гыйззәтләр группасыннан вакытыннан элек имтихан алды. Кәефе әйбәт, күңеле күтәренке иде, берәүне дә «өчле» куеп рәнҗетмәде, стипендиясез калдыруга юл куймады. Шактый сагаеп торган имтихан Гыйззәт өчен дә көткәннән дә хәерлерәк узды. Зөлфия Сәяровна аңа бер дә авырсынмыйча «отлично» куйды. Зачеткасын егетнең кулына биргәндә, Гыйззәт үзе генә ишетерлек итеп әйтте дә: «Тәкъдимемә җавабың мин кайтканчы әзер булыр дип өметләнәм»,— диде.

Зөлфия ялдан кайтканда чын мәгънәсендә имтиханнар вакыты җиткән иде. Ул ничектер бик ипле-килешле итеп кенә Гыйззәт белән очрашу җаен тапты һәм алар китапханәнең уку залында аулак почмак табып сөйләшеп утырдылар.

— Сез ничек бәяләсәгез дә хаклы булырсыз, Зөлфия Сәяровна, мин ныклы карар кабул итәргә өлгермәдем әле,— диде Гыйззәт бу сөйләшүнең азагында. Хатын-кыз мондый сөяк-санаксыз, умырткасыз фикерләүне үз теленә бик тиз тәрҗемә итәргә сәләтле: «Мин тәкъдимеңне кабул итә алмыйм».

Зөлфия Сәяровна бик тыныч булып калырга тырышса да, булдыра алмады. «Хуш!» — дип саубуллашуы юлларның бөтенләйгә аерылуын белдергән ату тавышы иде. Русча җырдагыча: «ты — налево, я — направо, так назначено судьбой...»

Татарча әйтем бар: ак эт бәласе кара эткә. Гыйззәтнең чит тел укытучысының язмышларын мәгълүм бер юлдан борып җибәрердәй тәкъдимен кире кагуы Сәкинәгә бәла булып ябырылды. Гыйззәтнең Инеш авылы кызына булган җылы мөнәсәбәтен төбенә тоз коеп белеп алган Зөлфия Сәяровна икенче курс студенткасы Сәкинә Нурдәүләтованы имтиханда «батырды», өстәмә сораулар бирә-бирә интектергәч, «канәгатьләнерлек түгел» билгесе куеп, зачет кенәгәсен буяп чыгарды. Кыз җәйге айларга һәм өченче курсның беренче яртысына стипендиясез генә түгел, «койрыклы» булып та кала дигән сүз иде бу. Имтиханнарны тапшыра алмаучыларны тиз арада институттан чыгару тәртибе дә яши иде ул елларда.

Гадәттә зар түгүне, шыңшуны, мескенләнүне өнәмәгән Сәкинә шушы хәлдән коелып иңде һәм күз яше аралаш сыкрап-сыктады.

— Әлифне таяк дип белмәгәннәргә дә «яхшы» куеп чыгарды бит! Аудиториядән тыш тәрҗемәләү нормасын ике ел буена үтәмәгәннәргә дә... Миңа гына кан үче бар төсле кыланды,— дип рәнҗеде.

Гыйззәт эшнең асылын аңа турыдан-туры аңлата алмый иде. Чынын сөйләсә, бердән, үз бәясен күтәргән сыман ахмак хәлдә калачак. Икенчедән, бар булганын Сәкинәгә тәфсилләп ирештерү егетләр эше түгел һәм бу «информация» Сәкинәнең җәрәхәтле җанына юшкын булып ятачак.

Егет Сәкинәгә болай дип киңәш бирде: имтиханны кабат, ләкин бүтән укытучыга тапшырырга рөхсәт сорап, факультет деканына гариза язарга. Үзем дә булышам рөхсәт алырга, диде.

Факультет деканы Сәкинә Нурдәүләтовага чит телдән имтиханны кабат тапшырырга рөхсәт итте, әмма бүтән укытучыга түгел, фәкать Зөлфия Сәяровнага тапшырасы. Сәкинәгә бу бер нәрсә дә бирмәячәк иде. Зөлфия туташ позициясеннән чигенүчеләрдәнмени?!

Шуннан соң Гыйззәт институт директоры Йосыф ага Туишев хозурына керергә кирәк дигән карарга килде. Сәкинә имәнеп калды. Институт башлыгын борчырга ничек җөрьәт итмәк кирәк? Ни дияр иде ул студентканың гаризасын укыгач?

Кыз директор янына керүгә аяк терәп каршы торды, бичаралыгыннан гаҗиз булып елады гына.

Үзең өчен үзең тырышмасаң, берәү дә синә стипендия китереп бирмәячәген анык төшенгән Гыйззәт Сәкинәнең гаризасы белән Йосыф Әхмәтҗан улы Туишев янына үзе керергә булды. Уку отличнигы, комсомолда җан атып йөргән бу егетне директор әйбәт белә, бик җылы каршылады. Мәгәр эшнең асылын аңлагач, сәерсенә калды. Төкселәнде дә кебек хәтта.

Зур симез гәүдәле Йосыф Туишев мондый кешеләргә хас булмаган җитезлек белән кәнәфиеннән күтәрелде дә үз өстәленә терәп куелган озын өстәл янәшәсеннән йөреп китте. Тамак кыргалады, симез учы белән пеләшен сыйпаштыргалады.

— Зарипов, син ни үтенергә кергәнеңне ахырынача уйлаган идеңме?

— Сезнең каршыгызга уйламыйча гына керер идемме соң, Йосыф абый?!

— Кире борып чыгарсам?

— Ни хәл итим, чыгармын.

— Әгәр мин мондый гаризаларның барысына да уңай җавап биреп утырсам, дөрес эшләр идемме соң?

— ???

— Студентларга нинди билге кую тулысы белән укытучының үз кулында, үз вөҗданында. Ул — бу очракта дәүләт вәкиле.

Гыйззәтнең көймәсе комга терәлде. Чынында алай ук терәлмәгән дә иде ул, тик ничекләр итеп кенә хагын сөйлисең, ди? Булмаганны!

Гыйззәт чыгарга борылган иде, Йосыф агасы тонык куе тавыш белән әйтеп куйды.

— Сабыр ит...— Ул кәнәфиенә килеп утырды һәм Сәкинә Нурдәүләтова гаризасы читенә берничә сүз язып, имзасын сырлады.— Чит ил телләре кафедрасы мөдиренә барсын. Кемгә тапшырасын ул хәл кылыр.

— Бик рәхмәт, Йосыф абый! Кичерә күрегез. Хушыгыз!

Сәкинә директорның кабул итү бүлмәсендә көтеп торырга тиеш кебек тоелган иде Гыйззәткә. Юк! Гыйззәт аскы кат коридорын айкап чыкты, табылмады. Йөгереп икенче катка менде, актлар залына күз салды, Сәкинә анда да күренмәде. Җене кузгала язды егетнең. «Ничек була соң инде бу? Берәү аның өчен олы кешедән гозерләп-үтенеп йөри, ә ул илченең әйләнеп чыкканын да көтә алмый, әллә кая китеп бара. Аңламассың бу кызларны, билләһи!»

Тулай торакта бирермен инде, гаризаны кесәсенә бөкләп тыкты да Гыйззәт Зарипов Зур Кызыл урамына кайтырга кузгалды. Болак күперенә җиткәндә ни күрсен, Сәкинә Болакның таш коймасына сөяләп тора. Гыйззәтне күргәч тә каршысына килмәде, каккан казыктай тора бирде.

— Нишләвең бу, Сәкинә? — диде егет, ачуланырга да, ачуланмаска да белмичә.— Ник шунда гына көтмәдең?

Кыз урталай теленгән чиядәй иреннәрен дымландырып, озын куе керфекләрен еш-еш йомгалап сүзсез торды. Аның тәмам тулышканлыгын чамалап алды Гыйззәт. Шуңа күрә кырыслыгын куып, бик җылы эндәште.

— Булды, Сәкинә, булды! Рөхсәт алынды!..

Бөялеп торган күз яше чишмәләре әнә кайчан ерылды! Сәкинә кулъяулыгын күзләренә каплап, тыелгысыз елап җибәрде. Рөхсәт алу шатлыгыннан идеме бу, шул хәлгә төшү гарьлегеннән идеме, Гыйззәтне бимазалап йөрергә мәҗбүрлегеннән кыенсыныпмы — белмәссең. Егет аны Кабан күле ягына арырак алып китте. Югыйсә бигрәк юл өсте, колхоз базарына баручы-кайтучының чуты-хисабы юк. Тоташ агым монда, кешеләр агымы.

— Рәхмәт сиңа, Гыйззәт, минем өчен дип күпме җәфаланасың, йөз суы түгәсең. Гафу итә күр бер үк. Болай интегүләрнең соңгысы гына булсын иде инде, ходаем. Рәхмәт! — Бераз бушангач, кыз шулай диде. Аның әлеге сүзләрен тыңлап тору Гыйззәткә әллә ничек кыен булып китте.

— Йә сәнә инде, ни дип кат-кат рәхмәтләр укыйсың? Әҗәл даруы табып кайтмадым ла! — дип сөйләнде ул.

— Әҗәл даруы шул... — Сәкинә борын тартып куйды да күзләрен мөлдерәтеп Гыйззәткә карады. Зур зәңгәр күзләрдә яхшылыкның кадерен белү галәмәте тулып ташкан иде.— Минем уку-укымау хәл ителәчәк бит шушы имтихан аркасында. Стипендия булмаса, мин нишлим? Атна буе йокламасам йокламам, «яхшы»га бирми калмам. Кара көнче Зөлфиядән аралаган өчен Йосыф абыйга мең рәхмәт!

— «Кара көнче»? — Шулай кабатлап соравын Гыйззәт искәрми дә калды.— Монысын ничегрәк аңларга инде, Сәкинә?

Кызны алыштырып куйдылар диярсең. Ул әле генә мәлҗерәп-мышкылдап торган Нурдәүләтовадан утлы бөҗра аша сикерергә тәвәккәллек иткән яшь арсланга әверелгән сыман иде.

— Белмәмешкә салынма, Гыйззәт, яме.— Сәкинә тавышына әллә нинди читят аһәң килеп керде, чишмә чылтыравы юкка чыкты.— Мине дә берни белми йөргән диванага санама. Бөтенесен сизәм. Синә гашыйк бит ул Зәнки Зөлфия. Сине үзенә аудармакчы. Ә син ике ут арасында газап чиктең-чиктең дә мине сайладың. Зөлфия шуңа үчләнде, гарьлегенә чыдаша алмаганнан минем канны эчә...

— Сә-ә-ки-нә-ә!

— Таң калган булып маташма, яме. Алай түгел дип расларга да әрсезләнмә, һәммәсе мин әйткәнчә...

Шул тикле катгыйлеге белән бер мизгелгә кыз Гыйззәткә аяусыз, мәрхәмәтсез булып күренеп алды. «Тормышыңны мондый юха белән бәйләсәң, башың бетәр!» — дигән уй миен көйдереп узды. Ул ирексездән бер-ике адым читкә тайпылды һәм Болакның уң ягындагы төссез-чырайсыз сөт заводы бинасына карап торды. Мондый холык иясе белән язмышын бәйли калса, киләчәктә аны да шундый соры көннәр көтеп алмасмы?

Хаксыз туган уйлар бик тиз таралды да. «Дөресен генә сөйли бит Сәкинә, тач дөресен генә әйтә. Күңеле һәммәсен тоеп торган аның». Шундый яктылык сызылып үтү белән, Гыйззәт җанының әллә кайсы почмагында укмаша башлаган бик бәләкәй таш кисәге эреп юкка чыкты.

— Әйдә, тулай торакка кайтабыз,— диде ул бик самими итеп.— Болак ярын сакларга куймаганнардыр ич безне...

— Әйдә! — диде Сәкинә дә.

Кояшның кинәнеп елмаюын шунда гына күргәндәй булдылар.

11

Икенче курсны Гыйззәт гел «отлично»га, Сәкинә стипендия алырлык итеп очлап чыккач, җәйге каникулда кемнең нишләячәген киңәштеләр.

Сәкинәнең һич кенә дә Инеш авылына кайтып, күз көеге буласы килми иде. Аның бу хакта Гыйззәткә телләнеп әйткәне булмады, әмма егет йөрәгенең сизгерлеге моны гына чамаламаслыкмы? Ул Сәкинәгә сак кына, ипләп кенә киңәш бирәсе итте.

— Җәйге пионер лагерьларына вожатый-тәрбиячеләр кирәк. Комсомол комитетында берничә завод-фабрика профкомыннан заявкалар бар. Ике айга... августның егерме бишенә кадәр. Барасыңмы бирәрсенә? — диде.

— Барам! Җибәрттер генә! — Сәкинә моны шундый кискен, тәвәккәл итеп әйтте, гүя, ходага тапшырып, язмышның хәлиткеч борылышына кереп китүе иде.— Саф һавада булырмын, балалар белән эшләп каравым да зыян итмәс...— Аннары әйтимме-әйтмимме дип торды бугай да, өстәп куйды.— Ике ай буена ашау-эчү дә шунда уза дигән сүз. Азрак акчасы да булыр бит инде. Җәй айлары стипендиясенә иш янына куш. Өскә берәр нәрсә юнәтермен...

— Кай тирәгә барыр идең? Аккош күленәме? Васильевогамы?

— Кайсына булса да ярый.

— Аккош күлендәге «Кояшлы» лагерына алайса...

— Бик әйбәт булыр! Каян башыңа килде әле, Гыйззәт?

— Һәрчак сине уйлап йөргәнгә.

Бер-берсенә карап елмаештылар. Аннары Гыйззәт әйтте:

— Рәтләп ял итә алмыйсың инде, шунысын ачык белеп тор,— диде.— Ул малайлар, кызлар тынгы бирмәячәкләр. Адашмасыннар, суга батмасыннар, ут-күз чыгармасыннар... Мең мәшәкать булачак.

— Укытучының эше мең дә бер мәшәкать буласын белә торып килдем ич мин бу институтка.

— Акыл белән чамалау — бер нәрсә, гамәлдә килеп терәлү — икенчерәк дип беләм.

— И-и, ил карты! — Сәкинә Гыйззәтнең иңенә кагылып алды.— Түзәрмен! Бүредән курыксаң, урманга барма, диләрме? Мин аралап чыккан утлар мондый гынамы соң? Беләсең ләбаса. Миңа җәен кайда булса да эшләргә кирәк, Гыйззәт.

Бар ул дөньяның бүтәнчәрәк яшәүчеләре. Тәскирә әнә әнисе белән Кырымга бара. Әтисе ике путевка алган...

— Әйе, кем ничек инде. Ярар, эшләгәннән үлмәбез. Мин авылга кайтам. Җәй буе шунда булачакмын,— диде егет.— Апа белән җизнигә җиң сызганып булышмый ярамый. Кышлык утын хәзерләшермен, мал-туарларына кышлык печән... Каралты-кураларын ныгытасы булыр. Мунчаларының рәте беткән. Җизнәң, син дә булышыр булсаң, яңа мунча күтәртмәкче, диебрәк язган иде апа. «Кайт!» — дип әмер бирмәсәләр дә аңлашыла бит инде...

— Бик дөрес әйтәсең, Гыйззәт. Гөлфирә апа синнән гайре кемгә таянсын инде,— дип хуплады Сәкинә. Шуннан соң бу юлы да әйтергәме-юкмы дип торды да әйтми булдыра алмады.— Җизнәң андый эшләргә ярамый бит инде...

— Шулай шул.

Сәкинәне Аккош күлендәге пионер лагерьларының берсенә озаткан көнне үк Гыйззәт туган авылына кайтып китте.

* * *

«Ярый әле аерылу бар, күрешүләр булмас иде» дигән бугай шагыйрь. Ике ай гомер яшьләргә ике ел сыман тоелган иде шикелле, егет белән кыз Сак-Сок хәленнән котылгандай күрештеләр.

Өченче курс башланды.

Һәммәсе дә үз чираты белән барганда, Гыйззәтне сискәндерерлек бер хәл булды.

Сентябрь иде. Якшәмбе. Көн уртасы якынлашкан чак. Гыйззәт үзләренең өченче каттагы бүлмәләрендә ялгызы. Бүлмәдәшләренең берсе — колхозда, курслары белән көзге эшләрдә булышуда, икенчесе — Зеленодол егете, кайта-китә йөри, бүген өендә.

Ишек шакыдылар.

— Керегез! — Семинар дәрескә хәстәрлек күрергә йөргән Гыйззәт рөхсәт сораучыга шулай дип җавап бирде.

Бусагада... Рәзинә иде. Өстендә төймәләре каптырмаган җиңел плащ, зәңгәр костюм-күлмәк, аягында зәңгәр туфлиләр, пәрәвездәй генә зәңгәр ефәк яулыгын муенына салган. Кулында сумка. Бизәнеп-төзәнеп алганы сизелә. Иреннәрендә иннек галәмәте, бит очларына да тидергән булса кирәк. Зәңгәр күзләренә сөрмә тарткан. Ул күзләрдә хәйләкәрлекме, тормыш мутлыгымы арткан сыман. Бәлки, тәнкыйтьле караш белән текәлгәнгә, Гыйззәткә генә шулай тоелгандыр. «Исәнмесаумы»дан да алда Гыйззәт миендә «Киенә-ясана белә, каһәр! — дигән уй йөгереп узды.— Күзләренең зәңгәр күл икәнен бер генә минутка да исеннән чыгармый...»

— Исәнме, Гыйззәт! — Рәзинә күрешергә кул сузды. Егет тә күрешми булдыра алмады.— Көтмәгән идеңме? Төшеңә дә кермәдемме?

— Көтмәгән идем, Рәзинә. Хуш киләсең, түрдән уз. Кунак булырсың. Менә монда утыр... Чишенеп куй. Бир плащыңны, кием шкафына элик. Хәзер чәй кайнатам...

— Борчылма, кабаланма...— Рәзинә плащын салып Гыйззәткә бирде.— Чәй кирәкми. Мине үз сые белән килгән кунак дип бел.— Ул учы белән йон күлмәгенең артын сак кына сыпырып, урындыкка утырды. Аннары күкрәгенә төшәргә азапланган алтын толымын аркасына салды.— Монда аулак булмаса, табигать куйнына чыгарбызмы диебрәк тә килгән идем...— Исән-сау укып ятасыңмы, авылдаш? Фән дигән кыяны кимерүләре бик алҗытмыймы? Хәлләрең әйбәт икәнен ишеттем болай. Беркөнне Казан радиосыннан студентлар тапшыруында исемеңне каткат телгә алдылар. Отличник, диделәр, актив җәмәгать эшлеклесе, диделәр.

— Хәл-әхвәл сорашуыңа рәхмәт, Рәзинә. Эшләрем начар түгел.

— Син гомереңә тыйнак булдың инде, Гыйззәт. Ярый, тагы да уңышлар телим. Өйләнергә өлгермәгәнсең бугай әле...

Гыйззәт чәнечкелерәк сүз эзләп карады, тиз генә табалмады. Шулай да:

— Ашыккан ашка пешә, диләр бит. Укып бетерми торып, башны гаиләгә бәйләмәскә исәп,— диде.— Өлгерермен...

— Сабыр шул син, Гыйззәт. Ашка пешү турында да бик дөрес әйттең. Татар акылы төштән соң дип тә әйтәләр бугай. Миңа шунысы кагыла торгандыр инде...

— Бөтен татарның да акылы соңлап йөрмидер, Рәзинә. Алай булса, ничә йөз еллар буена таш астында ятып та үзен-үзе саклап кала алмас иде ул татар.

Төштән соң гына уяна торган акыл белән телне, гореф-гадәтне, иң мөһиме — динне саклау мөмкин булыр иде микән? Кайберәүләргә бәлки, чыннан да, соңгарыбрак килә торгандыр акыл дигән хәзинә... Йә, ярар, үзең ни хәлләрдә йөрисең? Тормышларың ничек?

Рәзинә урыныннан торып, сумкасын алды.

— Ашап-эчә торган җирегез кайда? Шкаф артындамы?

— Әйе.

— Бушатыйк әле сумканы. Мин җәһәт кенә өстәл көйлим. Ашый-эчә сөйләшербез, ярыймы? Хәлләремне тыңлар булсаң, шунда сөйләрмен. Гыйззәт ни дисен?

— Ярый, ай алла, ярый. Тартынма, гап-гади студент торагы булмәсе бит бу.

Рәзинәнең кыюлыгын, моңарчы күреп өйрәнмәгән чатлы-чотлы кискен хәрәкәтләрен күзәтеп, Гыйззәт уйлап куйды: «Бу ханым йә бераз шәраб авыз иткән (моннан ничә ел элек белгән Рәзинә түгел ич инде), йә тарсынуыннан, егет алдында үзен җайсыз тоюдан котылырга теләп, аңлы рәвештә кыюланып бага. Икенең берсе, билләһи...»

Рәзинә өстәлгә өч йолдызлы бер шешә коньяк һәм җимеш суы чыгарып куйды. Тарелкага алмалар тутырды, аларны «Юып керсәнә!» дип Гыйззәткә тоттырды. Аннары колбаса турады, ак күмәч кисте. Иң азактан студентларның шикәр савытына учлап кыйммәтле конфетлар тутырды. Чөмәкәй итеп.

Алмаларны юып кергән Гыйззәтне үз өендәге хуҗабикә сыман базу итеп өстәл янына чакырды.

— Рюмкаларыгыз бармы? — дип тә сорап куйды.

— Менә анысы юк инде, Рәзинә.— Гыйззәт кечкенәдән генә уңайсызланып калды.— Студент халкы стаканнан гына...

Рәзинә шул ук тонда ялгап китте.

— Стаканның да төбеннән төшми ул... Кил, утыр. Очрашуны билгеләп үтик әле. Тамгасыз нәрсә файдасыз, ди. Тик шешә ачу кадәресен синнән үтенергә туры килә инде.

Бик тиз генә мәҗлес коруларына беркадәр сәерсенеп калган Гыйззәт коньяк шешәсен җәлт ачты да хуҗасына бирде.

— Рәхим ит!

Рәзинә үзенә дигән стаканга ике-өч тамчы гына тамызды да Гыйззәт багышланганына яртылаш диярлек коеп куйды. Аннары янә үз стаканына бик аз гына итеп агызды.

«Шартын китерә. Монысын өйрәнгән...» Егет ихтыярсыздан шулай уйлап куйды.

— Күрешү хакына!

Шартын китереп чәкештеләр, эчеп куйдылар. Аннары алма тешләделәр.

— Өчәү яшисезме?

— Әйе, өч кеше. Сезнең тору кайдарак, Рәзинә?

— Безнекеләр димме инде, әйе, безнекеләр була инде. Мәктәп тыкрыгында...

— Яшеллеккә бай төбәк.

— Начальство кисәкләренең байтагы шунда көн күрә.

— Синең кайнатаңны да министрмы дигәннәр иде.

— Бер баскыч менеп җитә алмаган министр. Финанс министрының урынбасары кайната дигән адәм.

— Ник бик энәләнеп кенә әйтәсең?

— Энәләнмим. Эшендә ничектер, әйтер хәлем юк, өендә — хатынының олтаны. Чүпрәк!

— Кайнананы киленнәр гомергә өнәмәгәннәр...

— Анысы да бар, ну безнеке кадәр кислотаны көндез чыра яндырып эзләп тә таба алмассың. Малаеннан көнләшә дип әйтимме? Ничә ел инде чыраен ача алмый интегә бичара... Ул семьяда һәркем үзен генә ярата. Бүтәннәргә өстән карыйлар. Мин дә алар өчен баштарак җанлы курчак идем, аннары сызлавыкка әйләндем, ахрысы. Йә, ярар сана, ансыз үтемә үткәнне сөйләп утырмыйм әле...— Рәзинә стаканнарга янә коньяк агызды.

Тыйнак кына авыз итеп куйдылар.

— Иреңне инженер дигәннәр иде шикелле.— Сүзне Гыйззәт ялгап китте.

— Инженер. КАИны бетерде. Мин килгәч әле. Егерме икенче заводта эшли, Горбуновта... Бердәнбер малайны читкә җибәрмәделәр инде, Казанда алып калдылар.

— Үзегез икәү генәме әле? — Урынсызрак кызыксыну килеп чыкты бугай дип, Гыйззәт читенсенеп алган иде, Рәзинә бер дә исе китмәгәндәй, җавап кайтарды.

— Һаман да икәү генә әле. Бәлки хәерлегәдер...

Гыйззәт соңгы җөмләне төшенеп җитмәде.

— Ничек хәерлегә?

Рәзинә урынында кузгалгалап куйды.

— И-их, белсәң иде, Гыйззәт! — Ул уң кул чугын хәрәкәтләндереп алды.— Аларын соңрак, беравыктан... Син бик ашыкмыйсыңдыр бит? Әллә мин тәҗел эшеңә комачау булдыммы?

Гыйззәт аны тынычландырды. Ничә еллардан соң очрашканнар икән инде, сөйләшергә кирәк иркенләп. Бала-чага төсле, сабагымны укыйсым бар дип тормас лабаса инде.

— Әйдәле! — Рәзинә тагын коньяк уртлап куйды. Гыйззәт тә аңа иярде. Үзе коньяк татыды, үзе уйлана калды. Хәмер-мазарның тәмен түгел, исен дә белмәгән Рәзинә ни гомердә шактый кыю эчәргә күнегеп киткән соң әле? Гаиләсендә мәҗлесләр бик еш микәнни? Әллә ире кунактан-кунакка ияртеп йөриме? Хәтере хаталанмаса, балалар бакчасында тәрбияче булып эшли дип ишеткән иде бит Гыйззәт. Шешәгә гыйшык тоткан хатын-кызның сабыйлар тирәсендә йөрүе ничегрәк була икән? — Уйлары шул җиргә җиткәч, егет, кире борылып чапкан кеше сыман, үз-үзенә каршы төшеп, бүтәнчә фикерли башлады.— Мин ни дип соң әле артык туры, артык дөрес кеше булып утырам? Йа, хода, барысын бер рюмкага салсаң, илле-алтмыш грамм коньяк капкандыр, алкоголичка ясадым да куйдым. Мәгънәсез дә соң мин!..

Ботаклы-чачаклы фикерләрен куып җибәрергә теләп, сорыйсы итте Гыйззәт.

— Үзең кайда эшлисең, Рәзинә?

— Казанга килгәннән бирле детсадта. Тәрбияче. Эшем ярыйсы минем. Туйганчы сөяргә сабыйлар бар. Эштә дөньямны онытып торам. Минем турыда байтакны белдең бугай, Гыйззәт. Инде бер сорау бирим: миңа бик рәнҗисеңме? Син мине беркайчан да гафу итә алмаячаксың, әйеме?

Гыйззәт чигәсендә бармак битләрен биетеп торды. Аннары гына бик салмаклап әйтте:

— Син, Рәзинә, минем гафу итүемә мохтаҗ түгелсең. Рәнҗеп нишлим? Рәнҗемим. Сүзеңдә тора алмаганың өчен бик нык үпкәләгәнем булды, турысын әйтим. Аннары уйлап-уйлап йөри торгач, кызлар чыдамсызрак яратылганнардыр, мөгаен, дигән фикергә килдем. Рәнҗемим, бәхет телим...

Рәзинә чырай сытып алды шикелле, аннары үтә томырылып Гыйззәткә текәлде.

— Үзем теләп килмәгән бәхет син теләп кенә килмәс инде ул, Гыйззәт,— дип кистереп куйды.— Килмәс. Акыллы кешеләр бәхет гөлен үз куллары белән йолкып ташламыйлар... Йә, кызганма мине, мескен буласым килми. Килми, шайтан алгыры!..

Яшь ханым өстәл янына торып басты, шешәдәге коньякны стаканнарга салып бетерде һәм ике сөйләшмәслек итеп, Гыйззәткә тәкъдим итте:

— Эчеп бетерик әле шуны! Шикләнмә, исереп аумам...

Ир-егеткә ни кала инде соң? Каршысында балкып та, ярсып та, үртәлеп тә, үкенеп тә утырган яшь хатынга аркылы сүз әйтсенме? Вәгазь тансыктыр дисеңме аңа? Үгет-нәсихәт тыңларга килгәнмени соң ул? Юк! Һич алай түгел. Сизә Гыйззәт: күңел дәрьясы ярларыннан ташып чыгарга тора аның. Эчен бушатырга килгән ул. Тулай торак адресын табу кыен булмагандыр аңа, әмма бүлмә ишеген шакуы бик ансат та булмагандыр. Коньяк шешәсен дә таяныч юлдаш итеп алган ул, батыраер өчен. Җанында мәхшәр бу кешенең. Ут, өермә, вулкан... Тик Гыйззәт бит аңа теләктәшлек итүдән уза алмый. Бу очракта ул бичарадан ни чара хәлдә.

Стаканнарны түнтәреп куйдылар. Рәзинә аягүрә генә эчте. Шуннан конфет капты. Аш-су ягын бүлеп куйган чаршауны күтәреп, түргә чыкты. Ишеккә барып, уентыгында торган ачкычны борды һәм кире әйләнеп килде дә, табуреткада утырган Гыйззәтнең артына басып, муеныннан кысып кочаклады. Шул рәвешле, егеткә табышмакның кәттәсен бирде. Теләсә нишләсен! Гыйззәт:

— Рәзинә! — дип нидер әйтмәкче иде, яшь хатын аның сүзен кисте.

— Тыныч кына утыр әле, зинһар дип әйтәм, Гыйззәт, кочканнан куршылмас-

сың ич?! Шул килеш басып кына мин сиңа җиде кат таш астында яткан серләремне сөйлим. Ниятләремне. Ни барын...

— Рәзинә! Әйдә, түр якка чыгып утырыйк!

Алар Гыйззәтнең караватына барып утырдылар. Рәзинә егетнең кулын үз учларына алды.

— Тыңла! Әллә тагын азрак өстибезме? Минем бар анда...

— Юк, Рәзинә, бик җитте. Рәхмәт сый-хөрмәтеңә... Җитте!

Хатын янә чырай бозып куйды.

Рәхмәткә сусап килмәдем лә мин... Уйладым-уйладым да, дөп-дөресен сөйләрлек бердәнбер кеше син дип килдем. Ни генә димик, син бит минем беренче мәхәббәтем, Гыйззәт. Өйләнешә калсак, ниләр булып бетәр иде, бер алла үзе белә, ә болай син минем өчен азаккача иң кадерле кеше булып калырсыңдыр. Моны мин язмышымны су баса башлагач кына аңладым...

— Тынычлан, Рәзинә. Җайлап кына сөйләшик.

— Мин тыныч. Чебен дулап тәрәзә вата алмаганны гына аңларлыгым бар. Шулай да мин Яртугайдагыча тыныч түгел инде, Гыйззәт, түгел. Нервылар дулаштыргалый. Тешне кысып түзүнең дә шаукымы бардыр инде...

— Бардыр...— Егет бүтәнчә һични әйтә алмады.

— Ничава дисәң чүп тә юк, диләрме әле безнең авылда? Миннән күпкә яман хәлдәгеләр дә яши әле дөньяда, чыдармын. Кыскасы шул, Гыйззәт, мин Илгиз Тәүгилдиев дигән адәмнән китәргә булдым. Бөтенләйгә. Бу сүзләремне сиңа сагызланырга исәп итә дип уйлый күрмә. Юк, юк! Үзем өчен синең күңел капкаң мәңгегә ябык икәнен бик әйбәт чамалыйм. Шу-ул... Әти дә, әни дә бу хакта беләләр. Күнделәр. Авылга кайтмыйм, ни за что! Казан пропискасын югалтасым килми. Әтинең җегәре, шөкер, май заводы эшләп торсын да, умарта кортлары үрчи бирсен. Миңа бит Һади Такташ урамындагы бик шәп йортның яртысын сатып алды. Торак дигәнең шулай хәл кылынды. Бер атнадан шунда күчәм. Алдан ук кунакка чакырып куям, үзенә күрә өй туена. Сөйгәнеңне алып килерсең. Урыныгыз түрдә булыр...

Гыйззәт ихластан көлеп куйды.

— Әй, киң күңелле дә соң үзең, Рәзинә! Бик рәхмәт инде. Бүләккә ни салырбыз соң? — Егет уенын-чынын бергә кушып сорады.

— Бер нәрсә дә кирәкми! Син — үзең иң дәү бүләк. Кич буе читтән-читтән генә сиңа карап торсам, моннан артык бүләкнең булуы мөмкинме? Менә шу-ул... Кичә Илгиз Тәүгилдиевкә әйттем: «Көенсәң дә, сөенсәң дә синең эш — мин балага уздым. Көенмә дә, сөенмә дә, синнән китәм. Гомереңбуе алимент түләрсең»,— дидем. Акылдан шаша язды. Бернинди балага да узмадым, юк. Ул кысырдан булмастыр, күпме көтсәң дә...— Рәзинә кинәт сүздән туктады да, идән тактасындагы бер ботак урынына карап тын калды. Исереп китүе дип уйлап Гыйззәт ялгышты. Тыныштан соң бик аек кешеләрчә өздереп әйтте, тәвәккәллек җыеп утыруы гына булган икән.— Синнән бер бала булуын телим, Гыйззәт. Үлепләр телим. Төсең итеп, юанычым итеп үстерер идем. Ризалаш әле шуңа, Гыйззәт. Тырнак очы кадәр дә дәгъвам булмаячак. Кояш белән, якты көн белән, гомерем белән ант итеп әйтәм. Тагын ничек карганыйм?

Гыйззәт кулын яшь хатынның учыннан алды, әмма утырган урыныннан кымшанмады.

— Берничек тә карганма, Рәзинә, кирәкми. Дөресен генә әйтимме? Мин сине танып җиткермим бит, матурым...

Рәзинә егетнең соңгы сүзен эләктереп алды.

— Матурым дия аласыңмыни әле? Менә шә-әп! Алайса назла мине...— Ул кинәт сикереп торып, чишенә башлады. Аның артыннан ук Гыйззәт тә ялт күтәрелде һәм Рәзинәнең иңнәреннән килеп кочты.

— Акылыңа кил, Рәзинә. Яртугайның бик тыйнак кызы булган чагыңны онытма, Рәзинә, үтенеп сорыйм...

Яшь хатын, җәһәт борылып, егет белән йөзгә-йөз калды һәм муенына сарылып, аны караватка таба тартты. Шундук егетнең ятагына барып чалкан ятты, Гыйззәт басып калды.

— Рәзинә дим, исермә!

— Кил, хода хакы өчен кил, сине генә зарыгып теләгән минутларым... бүген балага узмый калмаячакмын, килсәнә, кил!..

Гыйззәт әллә ачудан, әллә аптыраудан чырайдан төште.

— Үз башыңа бәла чакырасың бит, Рәзинә. Сүрел азрак, суын. Дилбегәне акылыңа бир.

Яшь ханым караватта үрсәләнә һәм яткан килеш чишенә иде инде.

— Кил дим, кил, Гыйззәт! У-уф, бөтен дөньям ташып чыкты, тиргә баттым...

— Юк, Рәзинә. Икебезне дә гомерлеккә пычрату булачак бу! — Шулай диде студент егет. Тик шул мизгелдә һәммә дәлилләрен бәреп егарлык бер фикер баш калкытты. «Мәми авыз дип китәчәк бит бу хатын. Мәлҗерәгән җан дип каһәрләячәк. Куркаклыкта, йөрәксезлектә гаепләячәк... Яшүсмер чагында яратканы өчен үз-үзен кинәләячәк. Әллә соң...»

Аның үзен дә җиңелчә дерелдәү тинтерәтә башлаган иде. Шул чак күз алдына Сәкинә килде. Әнә ул көлемсерәп карап тора. Ачуланмый да, үпкәләми дә, наянланып кына бармак яный. «Сез, егет-җилән халкы, кызлардан сафлык, гыйффәтлелек таләп итәсез, ә үзегез берәр нәфиснең шәрә тәнен күрсәгез, капланырга гына торасыз. Парлы тормыш юлына ике як та саф булып керергә тиеш түгелмени?» — ди. Шушы күзаллау барысына да нокта куйды.

— Киен, Рәзинә, тор, киен. Берәрсенең килеп шакуы бар. Җайсыз хәлдә калырбыз, сүз китәр...

Рәзинәнең дә ярсу минутлары узган, беркадәр бушанырга өлгергән иде бугай инде, ул күңелсезләнеп, боегып-нәүмизләнеп калган иде. Үзенең әле генә котырынуына да үкенгәнгә охшый иде. Кечерәйде генә булып чыкты бит инде Гыйззәт алдында, түбәнсетте генә үзен.

Ул торды, ашыкмый гына киенде-каптырынды һәм сүзсез килеп шкаф артына кереп китте. Аның тырыша-тырыша шешә ачканы, стаканнарга сыеклык койганы ишетелеп торды. Аннары ул бүлмә тынлыгын бозып, шактый кырыс, хәтта тупасрак та итеп Гыйззәтне чакырды.

— Бире кил әле, хур егете! Кил, пажалысты!

Гыйззәт аны тыңлады.

— Тот, Гыйззәт, соңгы тапкыр бер чәкешеп эчик тә, хуш, бәхил бул! Мәңгегә! Бүтәнчәли мин сине эзләп килмәм. Эч әйдә!

Үзе, Гыйззәтнең нишләгәнен дә карап тормастан, ярты стакан коньякны әйләндереп каплады да, плащын сорап алды. Аны тиз-тиз киеп, ишектәге ачкычны борды.

— Хәзер озата чыгам.

— Кирәкми, озатма! — Рәзинә җылысы, яме качкан тавыш белән җавап бирде.— Үзем генә озаермын. Исерек хатын белән күрсәләр, абруең төшүе бар...— Ул кырт борылып, Гыйззәткә үтергеч караш ташлады.— Соңлабрак тугансың, хан кәнизәкләрен сакларга җибәрерләр иде үзеңне. Шәп каравыл булыр идең. Селәгәй дә агызмый саклар идең гүзәлләрне. Яулык бөркән, Гыйззәт бүгеннән соң, яулык. Чалбарыңны үткенрәк берәр марҗага бир... Булдыксыз!..

Ул бүлмә ишеген киереп ачты да ирләрчә эре атлап коридорга чыкты һәм чайкалып китте, чак кына егылмый калды. «Ой!» — дип аваз салганын да сизмәде булса кирәк. Гыйззәт аның артыннан чыгып, беләгеннән килеп тотты.

Нәкъ шул чакта беренче каттагы кухнядан аш күтәреп егетнең үз дигәне Сәкинә менеп бара иде. Ул, берни күрмәгәндәй, «Исәнмесез!» — диде дә җил-җил үтеп китте.

Үзен утлы табада сизсә дә, Гыйззәт Рәзинәне тулай торакның таш капкасына кадәр озата чыкты. Рәзинә аны янәшәсендә итеп тоймады да. Урамга чыгып җиткәч, хушлашмый да китеп барды.

Егет, авызына сугып рәнҗеткән малай шикелле, тирән боегып та, чик-чамасыз гарьләнеп тә бүлмәсенә кереп утырды. Ике кулының да бармакларын куе чәчләренә батырып, башын аска иеп бик озак уйланды ул. «Хаталануын бик авыр кичерә Рәзинә. Башын ташка орырдай булып бәргәләнә. Иртәгесе көнгә карашы ябык. Бозыклыкка баруга да җиңел карый башлаган... Сафлык сагында торыйм дисә, кыя, ташкыя бит ул хатын-кыз. Үтерә алырсың, намусына кагыла алмассың. Ә Рәзинә? Хәер, ул гынамы соң?!

(Дәвамы бар.)

Вакыйф Нуруллин

Хыянәтчеләр
(Повесть)

8

Конверттагы «Иптәш Шәкүровка. Шәхсән үз кулына бирергә!» дигән сүзләргә күз төшереп кенә алды да, калтырана-калтырана ачып, укый башлады. «Хөрмәтле Шәриф Шәкүрович! Патшалык итү көннәрегез бетте. Сезгә «тәхет»тән китәргә туры киләчәк. Тартышып, көрәшеп азапланмаска киңәш итәбез. Чөнки моның файдасы булмаячак.

Сезгә яхшылык теләүче».

Моңарчы да аноним хатлар алганы булды Шәрифнең. Мондый ук усал язылганы юк иде әле. Әмма ул моңа бик алай аһ итмәде. Чөнки хәзер заманы шундый: кем ни тели, шуны кычкыра. Шәриф ишеләргә генә түгел, әнә ил күләмендәге дәү җитәкчеләргә, хәтта президентның үзенә дә ниләр генә әйтмиләр. Кыскасы, Шәриф өчен әллә ни зур яңалык юк иде бу хатта. Оешмада аны яратмаучылар бар икәнен ул инде күптән белә. Начальник кешегә үз кулы астында эшләүчеләрнең барысына да ошарлык итеп эш алып бару мөмкин түгел. Әнә, хәтта пәйгамбәрләрне анларга теләмәүчеләр дә күпме булган. Дөресен генә әйткәндә, аларның бөтен тормышы, бөтен эшчәнлеге яхшылыкны аңламаучы шул туң миләргә каршы көрәштән гыйбарәт тә инде. Һәм, гомумән, тормыш — көрәш. Яхшылык белән яманлык, искелек белән яңалык, картлык белән яшьлек, фәкыйрь белән бай, булдыклы белән булдык-

---

* Дәвамы. Башы журналның 1999 елгы 12 һәм 2000 елның 1 саннарында.

сыз, акыллы белән ахмак, ялкау белән эшлекле, мәхәббәт белән нәфрәт көрәше — кешелек дөньясының тарихы әнә шулардан гыйбарәт. Каршылык, көрәш һәм җиңү булмаса, бернинди үсеш тә, алга китеш тә булмас, тереклек дөньясы күптән инде примитив бер халәттә торып калган булыр яисә бөтенләй яшәүдән туктар иде. Шулай булгач, нигә дип бер Шәрифнең генә дошманнары булмаска тиеш ди?

Шәриф оешмасында да бар алар. Оешмада сайлау үткәрергә дип йөрүчеләр дә шулар, әлбәттә.

Сайлау үзе болай начар нәрсә түгел ул. Берничә әйбер арасыннан теләгәненңне сайлап алырга мөмкин дигән сүз. Ләкин бит өч йөз кешелек Оешмага җитәкче сайлау уен эш түгел. Монда ялгышып куюлары да бик мөмкин. Һәр хәлдә аларның барысы да Шәриф ягында булыр дип өметләнү — беркатлылык булыр иде. Шәрифне өнәмәгәннән генә дә түгел бу. Башында мие булган хезмәткәрләрнең берсе дә Шәрифне начар директор дип әйтергә тиеш түгел. Дөрес, бу Оешмада директор булып утырган чорда ул әллә ни зур үзгәрешләр ясады дип әйтеп булмый. Чөнки чоры шул — торгынлык заманы иде.

Шул ук вакытта артка да китмәде Оешманың эшләре, хәтта байтак мәсьәләләр буенча үсешкә дә иреште әле. Мәсәлән, Шәриф директор булып килгәндә, Оешмада ике йөздән илле җиде кеше эшләгән булса, хәзер — өч йөз дә бер хезмәткәр бар.

Ул килгәндә директор урынбасары нибары берәү булса, хәзер алар өчәү.

Ул килгәндә менә шушы директор кабинетында нибары бер телефон аппараты булган булса, хәзер алар дүртәү.

Шәриф килеп эшли башлаганда искереп беткән китап шкафы, бер өстәл, унбиш урындыктан башка нәрсәсе булмаган кабинетны хәзер венгр кабинет гарнитурасы бизәп тора. Аны Мәскәүгә үзе барып юллап алып кайткан иде Шәриф.

Элек кабинет ишеге бер катлы гына иде. Ә Шәриф аны ике катлы иттерде һәм яхшылап тышлаттырды.

Ул килеп эшли башлаганда директорның машинасы «Москвич» кына, ул бик иске булган булса, хәзер менә дигән «Волга»сы бар.

Оешма бинасына ремонт ясатты.

Бер яңа бүлек ачты. Саный китсәң тагын күп әле ул Шәриф килгәч башкарылган эшләр. Хәер, аңлый белгән кешегә болары да җитеп ашкан. Бер «Волга» алу өчен генә дә күпме йөрергә туры килде Шәрифкә. Фатирларны да үзләренеке ише башка Оешмалар белән чагыштырганда күбрәк алды. Дөрес, ул фатирларны Оешмада бүлеп бирү һәр очракта да гадел эшләнде дип әйтеп булмый. Ләкин кайда соң безнең илдә бер нәрсәне дә тик тәртибе, чираты белән генә бирәләр?! Кемгә бирелсә дә, шушы Оешма хезмәткәрләренә бирелгән ләбаса ул фатирлар. Ә бит дәүләт фатирларын акчага сатып ятучылар да җитәрлек хәзер. Алар да җитәкче булып утыра. Ничек кенә утыралар әле! Шәриф алар белән чагыштырганда гөнаһсыз сабый гына ул!..

Шулаен шулай да, әмма ваемсызланып, барысы да әйбәт булыр, мине алыштырырлык бүтән кешеләре юк аларның дип, тыныч кына көтеп торырга ярамас. Үз постында калу өчен тиешле чараларын күреп куярга кирәк аңа хәзер. Мине яклагыз, мине сайлагыз — мин әйбәт кеше дип, ачыктан-ачык агитация юлы белән түгел, билгеле. Иң элек, Шәриф тарафыннан һәрвакыт ярдәм тоеп яшәгән иптәшләр белән аерым-аерым сөйләшеп чыгасы булыр. Ләкин барысы белән дә ачылып бетәргә ярамый. Иң ышанычлы, иң тугрылыклылары белән генә эш итәргә туры килер. Хезмәт хакларын күтәрүне өмет итеп, фатир көтеп, разрядларын күтәрүне өметләнеп йөрүче хезмәткәрләрне

шулай ук чуттан чыгарырга ярамый, фатир дигәннән, ул мәсьәләдә вәгъдәне кызганмаска кирәк. Ул вәгъдәнең гамәлгә ашу-ашмавы бу очракта беренинди роль уйнамый. Иң мөһиме — халыкны үз ягына тарту. Югары Советларга сайлаулар вакытында депутатлыкка кандидатлар үзләренең платформаларында ниләр генә вәгъдә итмәделәр! Шул чакта биргән вәгъдәләреннең йөздән бишесен генә үтәсәләр дә, бүген җир шарында бездән дә бай, яхшы яшәүче ил булмас иде. Республикабыз авылларының һәр йортына газ үткәрелгән, һәр авылга асфальт юл сузылган, начальстволарның персональ машиналары алынган, алар өчен махсус кибетләр һәм шифаханәләр бетерелгән, ришвәт, спекуляция, кода-кодагыйлыкның исе дә калмаган, илдә чын-чынлап социаль гаделлек урнаштырылган булырга тиеш иде.

Әмма әлеге илнең һәм халыкның экономик хәле начарайганнан-начарая бара. Аңа карап бер генә депутатны да, вәгъдәңне үтәмисең дип, депутатлыктан төшергәннәре юк... Шулай булгач, Шәрифкә дә ярый торгандыр кайбер нәрсәләрне вәгъдә итәргә. Хезмәткәрләрнең эш хакын күтәрәчәкмен, бу нәрсә тиздән, яңа ел башыннан ук гамәлгә керергә тиеш, шуны юллап йөрим, дип тә хәбәр тарату кирәк булыр. Оешма хезмәткәрләре өчен, бик шәп урында — Идел буенда — дача җире алырга йөрим, теләгән кешеләрнең барысына да шунда участок бирергә мөмкин булачак, дип теләүчеләрдән гариза җыйната башлауның да файдасы булмый калмас. Уйлый башласаң, шундый «җимнәрне» тагын...

9

Кадрлар бүлеге башлыгы Хафизова керде. Дәү авызлы, юантык гәүдәле, салам сыйраклы бу хатынны Оешманың тере тарихы дип йөриләр. Җидене бетергәч, шушы Оешмага машинистка булып килгән булган. Кичен укып, шушында урта белем алган. Институтка да кергән булган, әмма анысына ук башы җитмәгән, икенче курстан ташлаган. Ә менә Оешманың үзешчәннәре арасында аннан да остасы, аннан да активы юк. Җырлый да, бии дә. Концертларны да ул алып бара. Кияүгә чыкмаган. Бала тапмаган. Пенсиягә чыкканына дүрт ел. Ләкин эштән китәргә исәбе юк.

«Көннәр буе өйдә ялгыз утырып, акылдан язарга мөмкин. Эштә, кеше арасында, рәхәтләнеп йөрим ичмаса»,— ди.

Унсигез ел машинистка булып эшләгәч, тырышлыгын, гаделлеге һәм Оешма эшенә, бигрәк тә җитәкчеләргә тугрылыгын искә алып, Шәрифкә кадәрге директор секретарь-машинистка итеп куйган аны. Шәриф килгәндә дә шунда эшли иде әле.

Тугрылыгы әйбәт, тырышлыгы, төгәллеге шәп. Ләкин директор секретаре булып утырган кеше өчен болар гына җитми, тышкы кыяфәт тә кирәк. Анысы, ихтимал, барыннан да кирәктер әле. Көненә ничә мәртәбә яныңа кереп, күзеңә күренеп йөри торган кеше бит ул.

Яхшы хәбәр генә түгел, күңелсез хәбәрләрне дә алып керә торган кеше. Кәефең яхшы чакта гына түгел, бөтен дөньясын сүгеп, ачуланып утырган чагында да килеп керә торган кеше. Юньле буй-сыны һәм бер елмаеп куюы белән бөтен мәшәкатьләреңне оныттырып, күңелеңне эретеп җибәрә алырлык чибәрлеге дә булмаса, ничек итеп аның белән еллар буе бергә эшләмәк кирәк?

Аннары килгән кешеләрне дә истән чыгарырга ярамый. Директор кабул иткәнне көтеп, приемныйда утырганда салам сыйраклы ирдәүкә хатынга карап утыру аларга да кызык түгел.

Әнә шуны истә тотып, килү белән, кадрлар бүлегенә күчергән иде аны Шәриф. Бик дөрес иткән булып чыкты. Шәрифнең күзенә генә карап тора.

Кушкан эшне вакытында үти, тиешле-тиешсез җиргә тыкшынмый, кирәкмәсне күрми. Янә бер бик әйбәт сыйфаты бар: Оешмада булган кечкенә генә яңалыкны да белеп-күреп, сәгате-минуты белән Шәрифкә җиткереп тора! Бүген дә берәр төрле яңа хәбәр алып кергәндер әле:

— Әйдә, Гөлшат, үт, утыр. Һәм сөйлә: нилә р бар дөньяда?

— Дөнья хәлләре белән кызыксынырга вакыт юк, Шәриф Шәкүрович. Үзебезнең хәлләр хөртиләнеп бара әле монда!

Тегенең нәрсә хакында әйтүен чамалаган иде Шәриф. Әмма аңламаганга сабышты:

— Нәрсә булды алай борчылырлык?

— Нүжәли, берни дә сизмисез: бөтен Оешма гөжли бит анда!

— Нигә гөжлиләр?

— Сайлау үткәрәбез дип мәш киләләр.

— Бик әйбәт! Битараф булсалар начар булыр иде.

— Алар бит яңа директор сайлап куябыз дип йөриләр!

— Кемне куймакчылар икән соң?

— Кичә шул мәсьәләне кузгатып, Галиевне тәкъдим итәргә карар кылганнар. Гайнуллин хакында да сүз булган. Ә Сабитов, Акбашов үз кандидатураларын үзләре тәкъдим итәргә җыеналар, ди. Моңа юл куярга ярамый, үзегезгә дә тиешле чараларын күрә башларга кирәктер.

— Кирәк икәнен беләм мин аны. Ләкин ничек итеп?

— Мәсәлән, нигә бүген, менә хәзер үк, бөтен бүлек мөдирләрен җыеп алып, халыкны сайлауга ничек әзерләү турында күрсәтмә биреп куймаска?

— Юк, Гөлшат, алай эшләргә һич ярамый: заманы ул түгел.

— Алайса башка юлларын уйларга кирәк.

— Дөрес әйттең. Мин дә уйлармын, син дә уйлана тор әле, яме. Ә иң мөһиме — кемнең нинди фикердә булуын ачыклый тор.

10

Күңелен тынычландырырлык сүз ишетмәде Шәриф үзенең төп «информаторы» Хафизовадан. Шулай да аның белән сөйләшеп алу ярады: мәсьәлә үзе уйлаганга караганда бик күпкә катлаулы булачак икәнен аңлады Шәриф. Кара син аларны, кичә ул балыкта йөргәндә ни кыланганнар! Аркага пычак кадау белән бер ләбаса бу...

Юк, яхшылыкның кадерен белми икән адәм балалары. Басып, куркытып кына тотарга кирәк икән аларны. Сталин бик дөрес эшләгән, илдә тимер тәртип урнаштырып. Шунсыз булмый икән бу халык белән эшләп...

Әллә бүлек мөдирләрен, профком членнарын җыеп, булачак сайлау мәсьәләсендә ачыктан-ачык сөйләшеп караргамы, дип тә уйлаган иде Шәриф. Шундый җитди мәсьәләләр каралачак җыелышлар алдыннан Оешманың активын җыеп сөйләшеп, тиешле юнәлеш биреп куюның файдасы зур була иде. Дөрес, Оешма халкы арасында моны бик үк өнәп бетермиләр. Кайберләре хәтта ачыктан-ачык: «Актив җыелышы түгел, куштаннар корылтае»,— дип саныйлар иде. Ләкин, ничек кенә булмасын, Шәриф моңарчы үз политикасын үткәреп, үз дигәнен эшләп килә иде әле. Әмма менә хәзер, тегеләр инде карар кабул иткәч, андый киңәшмә үткәрү шактый куркыныч: директор демократияне кысарга итә дип, отыры нык котырынып китүләре мөмкин иде.

Шәриф үзенең иң ышанычлы кешеләре белән аерым-аерым сөйләшеп куярга кирәк дигән нәтиҗәгә килде. Бу эшне Али Тазетдиновичтан башларга булып, аны чакыртты.

Юан гәүдәсе белән ишек авызын тутырып, Али Тазетдинович килеп тә керде.

— Әйдә, Али Тазетдинович, утыр якынрак. Сөйләшеп-киңәшеп алыйк бераз.

Шәриф дустанә эндәшкәч, урынбасарның йөзе яктырып китте:

— Сүләшергә була. Сүләшергә пажалысты. Тик менә киңәш мәсьәләсенә килгәндә, белмим: мине сезгә ярардай киңәш атя алырмынмы?

— Теләсәң — аласың.

— Теләк бездә һәрвакыт бар. Мөмкинлек кенә елдан-ел кими бара,— диде теге, сүзне шаяруга борып.

— Ярар, ярар, мескенләнмә: әле өченче көн генә янгын сүндерергә чапкандай чаптың бит завмаг абыстаең янына! Ну, ничек, ир-ат халкын оятка калдырмадыңмы ул көнне?

— Анысы берцәк булды инде. «Фирма»ның маркасын төшермәдек шикелле. Тагын цакырып калды.

— Молодец, эшкә алай атлыгып тормасаң да, ул яктан сынатмыйсың!

— Ә нигә алай атясез: моңарцы кайцан подводить иткәнем булды?

— Ярар, шаяруым гына. Дөрес әйтәсең, андый хәл булганы юк моңарчы. Ә менә киләчәктә ни эшләрсең икән соң? Мине шул мәсьәлә кызыксындыра, Али Тазетдинович?

— Ә нәрсә булацак киләцәктә?

«Хәйләкәр дә соң бу Таз эт: кичәге утырыш карарын да, Оешма халкының сайлау үткәрергә дип даулап йөргәнен дә белә бит инде! Ә ничек беркатлы булып кыланып маташа!»

— Әйдә, без инде алай качышлы уйнамыйк, Али Тазетдинович, ачыктан-ачык сөйләшик! Халык ниләр сөйли булачак сайлау хакында?

— Сүлиләр инде. Бер бөген генә түгел, күптән сүлиләр. Халыкның сүләми торган цагы юк аның. Ну вәт алар сүләгәнгә карап нәрсә үзгәргәне бар? Ана аптырарга түгел, минемчә.

— Син алай читләтеп-урап йөрмә, турысын әйт: минем хакта ни сөйлиләр?

— Нәрсә сүлиләр. Төрлечә сүлиләр. Бар сезне калдырмак келәүцеләр, бар алмаштырырга кирәк дип атүцеләр.

— Анысын үзем дә беләм. Кайсылары күбрәк аларның?

— Моны мин атя алмыйм. Улим, что моны беркем атя алмас. Кемнең нәрсә уляуын кем белә?

«Беләсең син аны, бик яхшы беләсең. Син белмәгән нәрсә юк бу Оешмада! Тик нигәдер ачыласың килми: мәтәштерәсең»,— дип уйлады Шәриф. Әмма тегенең үзенә әйтмәде.

— Ярар, аңлашылды. Ә кемне куймакчы соң алар минем урынга?

— Тоже конкрет кына атя алмыйм. Атялар, што, телиләр бүлек мөдире Фәрит Ринат Галиевне тәкъдим итәргә. Ә моңа Фәрит Сабирович үз кандидатурысын үзе тәкъдим итмәк кели, имеш.

— Кит аннан! Соң ул бит төрмәдә утырган кеше.

— Шылаен шылай да. Хәзер модада шындыйлар бит. Аня ул да, көрәшеп карыйм әле, дип атя, ди. Әгәр мине директор ясасалар, бер ел эчендә мировой масштабка алып чыгачакмын Оешманы дип атя, ди.

— Неужели шуның сүзен житди итеп кабул итүчеләр бар?

— Булырга да мөмкин. Хәзер вит шындый: кем күбрәк вәгъдә итә — халык шуңа ышана. Аня, үткән сайлауларны кара. Кемнәр депутат булды? Кем күбрәк партияне, житәкчеләрне сукте, шылар! Кем гомер булмастай әйберләрне булдырам дип вәгъдә бирде — шылар!

— Дөрес әйтәсең, Али Тазетдинович. Ләкин алар халык ышанычын югалтачак бит, болай барса.

— Ә аларга халык ышанычы цуртымамы кирәк? Власть — хакимият, ягъни хакимлек итү дигән сүз ул. Хөкүмәт дигәне шул бер тамырдан аның. Ә хакимлек итүцеләренең беркайцан халык мәнфәгатен кайгыртканы юк. Аның төп максаты — халыкны буйсындырып тоту, аның өстеннән хакимлек итү. Халык белән хакимият беркайчан да икесе бергә бер арбада утырып бара алмый. Арбаны халык тарта, ә хакимият арбада утырып, аңа команда биреп, аны куалап бара. Һәм, әлбәттә, иң элек үзенә муллык, иркенлек булдыру өцен тырыша. Бер бездә генә түгел, кешелек тарихының башыннан шылай килә. Хакимлекнең формалары гына алышына, ә асылы, эцтәлеге — үзгәрешсез калып килә. Формасы да алышынмас, хакимлек итүцеләр мәңге шылай хакимлек итеп утырыр иде, ләкин монысын халык эшли: үзен изүгә түзә-түзә дә, түземе беткәц, күтәрелеп цыгып, хакимиятне туздырып ташлый. Но ул барыбер үзенә ирек, хокук ала алмый. Цөнки иске хакимиятне төшерү вакытында хакимлеккә омтылуцыларның башка төре, ягъни икенце бер партиясе оешып ала да: «Без бөтенләй башкаца эшлибез: илдә тигезлек, гаделлек урнаштырабыз. Безнең максатыбыз халыкның тормышын яхшырту!» — дип алтын таулары вәгъдә итеп, хакимият арбасына менеп утыра. Менеп утыра да халыкның тормышын яхшырту өцен «җиң сызганып эшкә» тотына: «тарихи» программалар төзи, законнар кабул итә, указлар цыгара. Асылда болар барысы да хакимиятне ныгыту, анда утыруцыларның мәнфәгатен яклау өцен эшләнә. Ә халык, нәкъ элеккецә, арбаны тартып баруын дәвам итә.

— Син моның белән нәрсә әйтергә телисең, Али Тазетдинович?

— Мин моның белән сезнең хакимият заманы үтте, башкалар хакимияте заманы килде, дип әйтмә келим, Шәриф Шәкүрович.

— Нигә минем хакимият кенә соң әле ул? Нигә «безнең хакимият» дип сөйләмисең?

— Адә, каняштырма инде син, абзыкаем! Минем беркайцан сезнең белән бер арбада утырып барган булмады. Мин һәрвакыт зам булдым, беркайчан «сам» булмадым.

— Ләкин бит барысын да бергә эшләдек!

— Ә ничек эшләдек соң? Сез теләгәнне, сезгә кирәк булганны, сез кирәк дип санаганны эшләдек ләбаса!

— Син нәрсә, берни белмим, берни күрмәдем, дип җаваплылыктан качмакчы буласыңмыни?

— Мәсьәлә кацу-кацмауда түгел. Мин ницек булган — шыны атям. Заман үзгәргәнен, әллә нинди көтелмәгән халләр килеп цыгарга можыт икәнен атеп куюны үземнең гражданлык бурыцым дип саныйм. Вот и атям. Как ни как унбер ел сезнең тирәдә каняшам вит.

— Димәк, Сабитовның үз кандидатурасын куярга йөрүен, син нормаль хәл дип саныйсың?

— Нормаль-юкмы, эш анда түгел. Ну, атяләр, ул кандидатурасын куймак кели. Ә бит аны яклауцылар да булацак, мона карарсыз...

Юк, Шәриф ничек кенә әйтмәде. Ә бит күп кенә акыллы киңәшләрне Шәрифкә шушы адәм бирә, аның ярдәме белән Шәриф теләсә кайчан судан коры чыга торган иде. Юк, булмады бүген...

11

Сәлиханы дәшеп алды да бүлек мөдире Шакир Рәхимовны чакырырга кушты Шәриф. Шакир Җиһаншин — искиткеч һәм хәйләкәр кеше. Оешмада булган хәлләрне генә түгел, булачакларын да алдан белеп тора. Үзе беркайчан тиешсез җиргә тыкшынмый, нәтиҗәсе ни булып бетәре билгеле булмаган тарткалашканны тыңлап утыра. Соңыннан, җепнең инде очы күренә

башлагач кына, сүз ала һәм нәкъ вакытында, нәкъ кирәкле, бар кешене дә канәгатьләндерә торган фикерне әйтә.

Аның шулай сак кылануына башта гаҗәпләнеп йөргән иде Шәриф. Соңыннан белде: авызы пешкәне бар икән тегенең. Илленче елларда, бүгенге шикелле сүз иреге булуы хакында кешеләр хыялланырга да курыккан заманда, комсомол җыелышында бик зур хата ясаган ул. Алдын-артын уйлап тормыйча:

«Менә безгә, комсомолларга, партия җитәкчеләре, зурдан кубып, сез — партиянең ярдәмчеләре, сез — партиянең ышанычлы таянычы, диләр. Комсомолның ярдәме, чыннан, зур партиягә: кайда авыр — шунда комсомолларны җибәрәләр. Ә җитәкче урыннарда партиялеләр утыра. Безгә тик эш атлары, хезмәтчеләр итеп кенә карыйлар»,— дип ычкындырган.

Шуның өчен хөкем ителеп, сигез ел утырып чыккан. Шуңа күрә һәр сүзен уйлап-үлчәп, җилнең кай якка искәне билгеле булганнан соң гына сөйли. Начальствога ярарга да шунда өйрәнеп кайткан. Бик тугрылыклы, ышанычлы кешесе иде ул Шәрифнең: карап карыйк, ул ни әйтер икән булачак сайлау... Әһә, энә, үзе дә кереп килә. Күрәсең төрмә еллары нәтиҗәседер, начальство янына кергәндә каушап-куркып кала ул: йөзе агарына, елтыр кара күзләренең нуры сүнеп, тоныклана, болай да зур булмаган гәүдәсе тагын да чулыгып китә. Әнә, бүген дә шулай шөбһәләнеп килеп керде дә ишек төбендә туктап калды:

— Сәлам, Шакир Җиһаншин, сәлам! — диде Шәриф, дустанә әңгәмәгә чакырганын сиздерер өчен ягымлы итеп.— Әйдә, үт. Утыр да сөйлә: ниләр бар дөньяда?

Секунд эчендә ачылып, кыюланып китте тегесе:

— Дөньяда ниләр барын әйтә алмыйм. Ә менә үзебезнең Оешмада хәлләр катлауланып баруы — хак!

— Сайлау үткәрергә йөрүне әйтәсеңме?

— Әйе, Шәриф Шәкүрович, нәкъ шуны.

— Нәрсә соң анда?

— Хәлләр бик шәптән булырга ошамый, Шәриф Шәкүрович. Җитәр инде, күп утырды, алыштырырга кирәк директорны, дип ачыктан-ачык әйтүчеләр дә бар.

— Һаман шул Акбашевтыр инде?

— Ул гына булса бер хәл иде, баш бухгалтерыгызга тикле яңа директор куярга кирәк дип йөри икән анда. Ә Акбашев хәтта үз кандидатурасын үзе тәкъдим итмәкче, имеш. Әгәр директор булып калырга телисез икән, сез боларны белеп торырга һәм вакытында тиешле чараларны күреп куярга тиешсез. Мин сездән бары тик яхшылык кына күрдем. Ике бүлмәле фатирдан өч бүлмәлегә сез күчердегез. Сез килгәнче мине монда санга суккан кеше юк, нинди дер бер мокыт итеп кенә карыйлар иде. Бүлек мөдире итеп сез куйдыгыз. Алты ел профком председателе итеп утырттыгыз. Мин бу яхшылыкларыгызның берсен дә онытмыйм. Нинди генә хәлдә дә сезнең яклы булып калачакмын. Монысына һич шикләнмәгез. Моннан тыш тагын нинди ярдәм итә алам — анысын, әйдә, бергәләп уйлашыйк, Шәриф Шәкүрович? Ә сезгә, сизеп торам, ярдәм бик кирәк булачак бу юлы.

Рәхимовның бу сүзләре бары да дөрес: Шәриф үстерде аны. Шуның аркасында күп кенә сүзләр дә ишетергә туры килде. Бигрәк тә аны профком председателе итеп куйганны ошатмаган иде халык: «Үз фикере юк», «Коллектив өчен кайгырмый», «Директорның авызына карап, аның рупоры булып кына утыра!» дип хәтта җыелышларда да чыгып әйткәлиләр иде. Шулай да кимсетергә ирек бирмәде, алты ел утыртты аны Шәриф, профком председателе итеп.

Телсез-тешсез булганы өчен генә түгел. Профком председателенең вәкаләте зур: фатир булу, премияләр булу, санаторийларга, ял йортларына путевкалар булу, хезмәткәрләрнең балаларын яслеләргә, бакчаларга урнаштыру — барысы да аның катнашы, аның ризалыгы белән эшләнә. Шуңа профком председателенең син дигәнчә, сиңа кирәк булганча эш итүе бик мөһим. Ә Рәхимов бу яктан сүз тидерә торган түгел. Перестройка башлангач, жалоба арты жалоба яза башладылар Шәриф өстеннән. Ике ел эчендә Оешмада өч тапкыр комплекслы (ягъни җентекләп) тикшерү үткәрелде. Утсыз төтен чыкмый. Жалобачы да тоташ ялганны гына язмый. Аның да хаклы урыннары була. Һәм, гомумән, ныклап торып тикшерә башласаң, теләсә кайсы җитәкчедән гаеп табарга була. Чөнки безнең илдә эген-эккә, җеген-җеккә туры китереп, барысын да закон буенча гына алып бару мөмкин нәрсә түгел. Шәрифтән дә, төрмәгә утыртырлык ук булмаса да, эшеннән алып ташларга артыгы белән җитәрлек гаеп табып була иде. Ә аңа партия линиясе буенча каты шелтә бирделәр, бер айлык хезмәт хакын тотып калу белән генә чикләнделәр. Моның өчен Шәриф барыннан да элек менә шушы хәзер аның каршында утыра торган Рәхимовка бурычлы. Тикшерүчеләрнең башлыгы белән «дустанә» контакт урнаштырып, күп кенә нәрсәләрне «күрмичә» калдыруда аның роле бик зур булды...

Менә хәзер дә, әнә, ярдәм итәргә үзе сорап тора. Шунысына куанды Шәриф Шәкүрович.

— Әйе, дөрес әйтәсең, Шакир Җиһаншич,— диде ул, тегенең сүзен куәтләп.— Ярдәм бик кирәк булачак миңа. Хәзер бит элекке чак түгел, команда биреп кенә тыңлатып булмый халыкны. Шулай да бергәләп тырышканда дилбегәне кулда калдырып булырга тиеш. Инде конкрет сиңа килгәндә, ни эшли аласың? Иң элек сүзең үтә торган иптәшләр белән сөйләшеп, дүртбиш кешелек инициатив группа оештырырга кирәк. Сайлауга әзерлек барышында коллективта минем кандидатураны күрсәтү һәм үткәрү буенча бик актив эш алып барырга тиеш алар. Ә үзең турында инде әйтеп тә торасы юк: кулыңнан килгәннең бөтенесен дә эшләрсең, дип ышанам.

— Анысыннан эш тормас, Шәриф Шәкүрович. Бишне үк булмаса да, чыгыш ясарга бер-ике иптәшне әзерләрмен. Ләкин җиңеп чыгу өчен болар гына җитәрме икән соң? Җиләевалар, Рәсуловлар, Харисовлар бик каты әзерләнә бит анда сезгә каршы чыгарга.

Шәриф дерт итеп китте: Шакир атаган исемнәр барысы да Шәрифнең ышанычлы кешеләре: үзе үткәрергә теләгән политиканы ул нәкъ әнә шулар авызы белән гамәлгә ашырып килә һәм бу «система»ның моңарчы ышанычны акламыйча калганы юк иде.

— Неужели шулар да миңа каршы булырга йөри? — диде Шәриф, бик нык аптырап.

— Ничек кенә йөриләр әле!

— Минем өчен үлеп торалар иде бит алар. Нигә алай үзгәрделәр икән?

— Алар үзгәрмәде. Үзгәрә торган бәндәләр түгел алар: ялагай булып туган, ялагай булып үләчәкләр! Заман үзгәрде. П-ерес-т-р-о-й-ка! Татарча әйтсәк — үзгәртеп кору! Рас үзгәртергә икән, димәк, барысын да, шул исәптән начальствоны да, үзгәртергә кирәк дип саный халык. Моңа шаккатырга ярамый. Үзгәреш икән — сезгә дә үзгәрергә, халыкны үз ягыгызга тартырдай «җим» ыргытырга кирәк!

— Ярый, акыллы фикерләрең өчен рәхмәт. Ә нәрсә эшлисен мин уйлармын. Ә син үз җаең белән минем шушы идеяләрне халыкка җиткерә башла, ярыймы.

— Анысы өчен борчылмагыз — эшлим! Миңа сезнең фатихагыз гына кирәк иде.

(Дәвамы бар.)

Каим Шәйхетдин

Сөннәтчеләр

(Повесть)

БЕРЕНЧЕ БҮЛЕК

1

Авыл малайлары арасында иң көчлесе, иң абруйлысы Галинур иде. Бөтен ягы килгән: буе-сыны, акылы дисеңме. Аңа унҗиде яшь тулып килә. Соңгы елларда җиткән егетләр, ирләр белән беррәттән колхоз эшләренә йөри башлады. Печән чабу, җир сөрү, ашлык чәчү кебек эшләрдә дә — берсеннән дә калышмады. Әлбәттә инде, Галинур малайлардан һәрчак алдан йөрде.

Гаиләдә дә бердәнбер ул. Әнисе Хәмидә түти авыру булу сәбәпле, бүтән баласы булмады. Әтисе Әхәт агайны сугыш башлангач та фронтка алып киттеләр. Бөтен эш: мал-туарны карау егет җилкәсенә төште. Ярый әле йорт-каралтылары төзек, әтисе тырыш кеше иде, керешкән эшен һәрчак җиренә җиткереп эшләде. Әтисе кырык беренче елның көзендә үк Мәскәү тирәсендәге сугышларда һәлак була. Ошбу яман хәбәр ирешкәч, Галинур каушады, ни уйларга, ни эшләргә белмәде. Көннәр, төннәр белән буталып бетте, тамакка аш бармады, күзгә йокы кермәде. Ябыкты Галинур, коры сөяккә калды. Алар әнисе белән фәкать икесе инде. Ничек тә дөнья көтәргә кирәк иде.

Малай үз-үзенә йомылып шактый йөрде. Вакыт уза торды, ахырда әтидән башка хәбәр көтәсе юк дигән нәрсә белән килешергә туры килде. Язмыш шундыйдыр, ни эшлисең бит, сугыш үлемсез булмый.

Әнисе Хәмидә күз алдында сүнде. Хатын-кыз ир затына караганда йомшаграк, нечкәрәк күңелле шул: кайгысын җинә алмады. Электән дә сәламәтлеге шәптән түгел иде, бөтенләй чирләшкәгә әверелде. Әллә акыл ягы да кузгалды инде, янындагы кешене күрмәс, сөйләшмәс булды. Күзләре эчкә батты, йөзендәге җыерчыклар тирәнәйгәннән-тирәнәйде. Ябыкты, йөзе саргайды.

Авылдан ир-затларны себереп диярлек сугышка алдылар. Бөтен колхоз эшләре хатын-кыз, карт-коры һәм яшүсмер җилкәсенә калды. Җитмәсә колхоз рәисе итеп Миңҗиһан исемле бер усал хатынны куйдылар. Бригадир вазифалары да хатын-кыз кулына күчте. Нишләмәк кирәк, җитәкчелеккә куярлык ирләр беткән иде. Билгеле инде, хатын-кыз түрә булса, ирләр кебек кенә кыланмый...

Хәмидә түтине иртә таңнан колхоз эшенә куалар. Тәмам каныкты бригадир аңа, авыру хатын дип уйлау кая ул! Күпмедер вакыт эшкә йөрде Хәмидә. Булдыра алганча тырышып эшләде. Әмма җан торышы, сәламәтлеге көннәнкөн начарлана барды. Ә язга таба өйдән чыга алмас хәлгә төште. Галинур да көне-төне хуҗалык эшендә. Өйгә кайткан чакларда әнисенең түшәктә ятуын, чәй кайнатып эчәрлек тә хәле юклыгын күрер иде дә, йөрәкләре әрнер иде.

Ниһаять, көннәрнең бер көнендә учакта ут сүнгән булып чыкты. Шырпы кибеттә күптән юк иде инде. Галинур күршеләргә күмергә йөрде. Өйдәге һәммә эш Галинур кулында. Ярый әле күрше Өммекамал әби ешрак кереп йөри башлады. Күрше хакы — Тәңре хакы дип юкка гына әйтмәгәннәр. Хәмидәдән күргән игелекләрне дә онытмаган. Бер көнне Галинурны ишегалдында очраткач, әнисе ишетмәсен диптер инде, пышылдап кына киңәшләр дә биреп китте күрше әби: моны болай ит, тегесен тегеләй ит.

Бәрәңге шытып чыгып, яшел сабак җибәргәч, Хәмидә түтигә бераз хәл керде. Кеше ярдәме белән булса да өй каршына чыгып, кояш җылысында оеп утыра башлады. Андый көннәрдә Галинур сөенә иде — әнисенең терелүедер бу!

Сугышның икенче елы китте. Фронтта да, тылда да эшләр мөшкел. Авылдагылар үлем хәбәре килгән кешеләрнең инде санын югалттылар. Һәр кешенең үз кайгысы кайгы. Шуңа да карамастан, авыл халкы Хәмидә түтинең хәлен белешеп тора, булдыра алганча ярдәм итәргә тырыша иде. Күршеләр көтү кайтканда малны кертеп яба, су китереп куя, хәл белергә килгәндә күчтәнәчен дә кыстырып килә. Галинурга: «Әниеңнең сәламәтлеге начарлана бара, әллә ни озакка чыдамас, өегезгә килен китерергә кирәк, улым»,— дип, турыдан-туры киңәш бирүчеләр дә табылды. Әмма җәй башында әнисенең шактый аруланган чакларын истә тотып, Галинур мондый киңәшләргә җитди колак салмады.

Авылның икенче очында Галинурның Ислам исемле дәү әтисе яши иде. Узганда-барганда тәрәзә аша аны чакырып алып, килене турында сораша. Менә бүген дә, төшке аш вакытында әнисе янына ашыгып кайтып барганда, бабасының тавышы ишетелде.

— Кереп чык әле, улым. Вакытың да тар инде,— диде. Ислам карт, Галинур түргә узгач, тезләрен уа-уа, сүз башлады.

— Киленнең хәле ничегрәк соң, улым? Тазарамы инде? Киптергән үләннәр бирергә кушты әбиең, әниеңә кайнатып эчертеп кара. Файдасы тими калмас, тияр, иншалла.

— Һаман бер көйгә, бабай. Ныклап хәлләнгәне сизелми шул әле.

— Әйе, әйе. Юньләп карау тимәгәч, шулайдыр инде. Бер үзенә кыендыр шул. Бирмәде бит Ходай бер кыз бала үзегезгә.— Озак кына сүзсез утырды да бабасы, ахыр сүзен дәвам итте:— Сугыш бетәргә бер дә ошамаган шул әле, улым. Озакламый синңа да вакыт җитәр. Сугышка китәргә дим. Анаң нишләр, кем кулына калыр? Без дә инде кабер читендә басып торабыз. Өебез сезнең очтарак булса, ярдәмебез тияр иде. Юк бит, якынрак урынга башка чыкмады атаң,— диде бабасы һәм авызын каплап озак кына йөткерде.

— Салкын тидеме әллә, бабай?

— Шайтан алгыры. Үпкәсе дә череп бетмәде инде. Аллаһы Тәгалә дә дөньядан алмый. Яшьләр интегү генә җитмәгән. Ашыктырма, Газраил, ди торгандыр инде.

Үпкә чирен бабай Себердә — лагерьда эләктереп кайтты. Кайтуына өч ел чамасы вакыт үтүгә карамастан, чире чигенмәде. Яшьтән таза-сәламәт булса да, лагерь еллары эзсез калмаган, күрәсең. Бабасы йөткереп куйды һәм киңәш иткәндәй:

— Әллә соң, улым, өйләнеп куясыңмы? Әниеңне карарга да кеше булыр иде. Үзең көн-төн эштә.

Галинур ни әйтергә белми җавапсыз торды. Ахыр саубуллашты да чыгып китте.

Дәү әтисеннән чыккач, урам буйлап атлаганда башында бары тик бер уй бөтерелде. Өйләнү. Нигә өйләнергә? Аннары кемгә?.. Кеме бар аның? Ярый, кемгә булса күзе дә төште ди. Өйләнергә? Әйтүе генә җиңел. Сөннәтле булсам бер хәл иде... Галинурның өйләнү турында сүз чыкканда шул хакта уйлаганда, уй-фикере гел шуңа барып төртелә иде.

Эш шунда ки, авылда бердәнбер сөннәтсез малай иде ул. Тормыш шулай мәкерле шаярып алды аның белән. Бер аның белән генә түгел, әлбәттә, бабасы Ислам белән дә, әтисе Әхәт белән дә...

Утызынчы еллар башында, совет власте кызып-кызып колхозлар төзегәндә, шактый баеп киткән Ислам бабасы, байлар санына кертелеп, авылдан куылмый калды. Аңа бик нык бәйләнә башладылар. Кулак, имеш, җитешле яши: бер аты, ике сыеры бар.

Шуннан бабасы авылдан чыгып китәргә мәҗбүр булды. Авылны балкытып торган ике катлы йортын, кибет-амбарларын советларга ирекле рәвештә тапшырып, кирәкле кәгазьләр алып, иш-гаиләсе белән авылдан чыгып китте. Кая? Бик еракка — Донбасс якларына. Шахтерлыкка. Ләкин аңа монда да көн күрсәтмиләр, ни сәбәпледер Себергә сөрәләр. Бабасы Ислам шактый еллар тайгада урман кисә, тазалыгы да шунда какшый. Утыз тугызынчы елның азагында туган авылына кайтып егыла.

Бабасы ирекле рәвештә бар байлыгын советларга тапшырып киткәнгәме, Галинурның атасы Әхәткә кагылмадылар.

Тырыш, хезмәт сөючән кеше буларак Галинурның атасы өй-каралтыларын да төзек тотты, тиешле мал-туарын да асрады, бер сүз белән — җитешле яшәде. Көнләшәләр иде аңардан кайберәүләр, күрә алмыйлар иде. Бай Ислам малае икәнен дә онытмадылар. Атасына булмаган яла яктылар, бай малае дип үртәделәр. Әмма Әхәт тешен кысып булса да түзде, дәшмәде. Чөнки бер аны гына кыерсытмыйлар иде. Хакимияткә килгән большевиклар, дин тотучыларны да рәнҗеттеләр, мыскыл иттеләр, сүктеләр. Ахыр шул чиккә җиттеләр ки, мәчет манараларын кисә башладылар. Дин кирәкми, дин ул халык өчен агу, әфиун, дип җикеренделәр. Халыкның гореф-гадәтләре белән дә исәпләшмәделәр. Яңача укыйбыз, яңача эшлибез, имеш. Оланнарны сөннәткә утырту — кая ул?!

Менә шул чорда Галинур сөннәткә утыртылмый калды да инде. Әтисе кулак малае санала, ә ул, бахыр, яшерен рәвештә малаен сөннәткә бирергә кыймады, курыкты. Әнә шулай сөннәтсез калды Галинур. Әмма бер дә офтанып йөрисе түгел кебек иде. Ләкин бу хәл барыбер гомер буена баштан китмәслек кайгыдыр, мөгаен. Балачакта бер хәл, хәзер исә исәйгәч, сөннәт дигән нәрсә гел борчып тора башлады. Кызлар Галинурны үсмер чакта ук яраттылар. Эш ярата, таза, чибәр дә. Әмма кызларның чәчләрен тарта торган чаклар узгач, аңа ниндидер өмет белән карый башладылар. Күзләрендә соклану, егеткә тартылу, сагышлы-моңсу карашлар... Кемгә насыйп булыр икән бу егет дип уфтанулар да булгалады.

Җиткән кызлар арасында иң чибәре, Галинурга иң ошаганы — Гөлүсә. Ул — Өммекамал әбинең оныгы. Бер йорт аша гына торалар. Бергә үстеләр, бергә уйнадылар, бергә каз бәпкәләре сакладылар. Мәктәпкә йөри башлагач та Гөлүсә күршесе Галинурның өеннән чыкканын көтеп торыр иде. Икенче

сыйныфка күчкәч, Гөлүсәнең дәфтәренә кара түккән «Куян» кушаматлы Нәбиулла исемле малайны кыйнаган иде Галинур. Шуннан соң Гөлүсә аны абый кебек күрә башлады. Мәктәпне бетергәнче шулай абыйлы-сеңелле кебек җитәкләшеп йөрделәр. Укуны дәвам итәргә теләүчеләр район үзәгенә күчтеләр. Галинур белән Гөлүсә дә бишенче сыйныфка шунда йөрделәр.

Җиде классны тәмамлагач, икесе дә авылда калдылар. Җитдиләнделәр, сабырландылар яшьләр. Гөлүсә дә инде җитеп килгән чибәр, зифа-сылу гәүдәле кызга әверелде. Карашы да моңсуланды, җитдиләнде. Балачактагы кебек: «Күтәр ыштаныңны, куян койрыгына охшап йөрмә!» — диюләр дә бетте. Бер сүз белән әйткәндә, ике яшь арасына гүя мәхәббәт гөле үсте. Яшьләр күңелендә моңарчы күзгә күренмәгән, үзләре дә аңлап бетермәгән мәхәббәт хисе туды. Ни иде бу? Мәхәббәтме? Әллә соң күрше хакы гынамы? Ни Галинур, ни Гөлүсә белмәде. Иллә моны ата-аналары бик тиз сизделәр, ләкин күрмәмешкә салыштылар.

Шулай истәлекләргә, уйларына, хыялларына чумып кайта торгач, Галинур Гөлүсәләр өе янына якынайганын сизми дә калды. Ул катгый бер карарга килде: өйләнергә кирәктер.

Әле дә булса хәтерендә, бәрәңге чыгарып бетергән көн иде. Галинур соңгы ике капчыкны баз ишеге төбенә китереп куйды да, тәмәке көйрәтергә чүгәләде. Алҗыткан иде. Шырпысын сызарга өлгермәде, өйдән Өммекамал әбинең тавышы ишетелде. Ул аның әнисенә нәрсәдер сөйли. Сүз Галинур турында бара. Тәмәке кабызылмый калды.

— Хәмидәкәем, бөтен эш шунда. Әйем. Шуны аңла, улыңның сөннәте булмыйча торып, киленле була алмыйсың. Марҗа-фәләнне тапса гына инде... Әйем, син аны ничек тә күндерергә тырыш инде. Безнең якта, үзең беләсең, сөннәтсез егетләргә кызларның кияүгә чыкканы юк. Булмас та ул. Галинурыңа да чыкмаслар. Камал апа әйтте диярсең.

Шуннан соң күрше әби сөйләгәнне аңлап булмады: карчык пышылдауга күчтеме, әллә читкә борылып сөйли идеме — белмәссең. Тәнгә нәрсәдер йөгергәндәй булды да, Галинур тәмәкесен көйрәтеп җибәрде. Зиһене ачылып китте. Тавыш янә ишетелә башлады.— Син инде... уйлап торасы да юк, бер нинди куркынычы юк аның. Һич онытмыйм теге урысны. Минем кыз чагымда безнең авылыбызга бер тимерче килеп урнашты. Гомер буена татар авылларында тимерче булып йөргән бу. Үзе дә, балалары да татарча шартлатып сөйләшәләр иде. Бер малай, ике кыз үстерде. Бер вакытны малаен өйләндерергә кереште бу татар кызына. Теге егет бер кызны үлеплләр ярата икән. Ә теге кыз: «Сөннәтсез егеткә кияүгә чыкмыйм!» — дип әйтеп әйтә икән. Хәмидәкәем, теге егет сөннәтләнде бит. Улың сөннәтләнсә, ике дә уйламый үзебезнең Гөлүсәне бирер идек.

Әнисе Галинурга бу сөйләшү хакында ләм-мим бер сүз әйтмәде. Ә Галинур катгый карарга килде: өйләнергә! Ә аңарчы бабачыны табарга да Аллага тапшырырга...

Ул дәү әтисе янына китте, үзенең уй-ниятен сөйләп бирде. Ислам карт киң итеп елмайды. Хәтта таягын тотарга да онытып, ишекле-түрле йөрənә башлады. «Изге эш, улым, тәвәккәллә»,— диде. Киңәшләрен бирде.

Кичен Галинур колхоз рәисе өенә барды. Аңа да барысын да түкми-чәчми сөйләп бирергә туры килде.

— Гариза яз. Әниеңне карарга табиб алып килү өчен бер атнага дип яз. Матри, ипле йөр. Үзең беләсең, сугыш вакыты...

Иртәгесен Галинур бер сарык тәкәсен көтүгә чыгармады. Аны суйды, итен кар базына төшереп куйды, муен итеннән аш пешерде. Хәмидә апа, улының ниятен тыңлагач, шатланды. «Әниең өчен кайгыртып йөрисең икән, рәхмәт инде балакаем»,— диде.

Көн узды. Кояш чыгар-чыкмас борын ул аркасына ит тутырылган капчык асты да, район үзәгенә таба кузгалды. Базардагы тәртипкә китереп, бер урында урнашты да, өйдә үк кискәләп килгән ит калҗаларын таратып-тезеп куйды. Хакын-бәясен башка ит сатучылар белән сөйләшеп чамалады инде. Яшь ит тиз сатылып бетте. Дәү әтисенең киңәшен тотып, кычытканга төреп салган ит кисәкләрен сатмады. Акчаның эрерәкләрен эчке кесәсенә яшергәч базар читендәге чәйханәгә юнәлде. Ике стакан чәй эчеп, өйдән алган ипие белән тамак ялгады, күңеле күтәрелеп китте.

Ул кичкә таба гына Ислам бабасы биргән адрес белән Габидуллин фамилияле кешене эзләп тапты. Габидуллин нык бәдәнле, шактый дөнья күргән кешегә охшаган иде.

— Син Исламның оныгы икәнсең бит, танымый торам. Атаңа тартым. Аны яхшы беләм, тырыш кеше иде... Әйе, мин синең ни өчен килүеңне беләм, егет. Мин сине Рече Кыр авылы бабачысы Хәмидулла картка җибәрәм. Бабачыга әйт — Габидулла абзыкай җибәрде диген...

Кече кыр авылына барып кергәндә көтү кайта иде инде. Дәү әтисенең, кеше күзенә чагылып йөрмәскә тырыш, дигән киңәшен тотып, Галинур берара куаклыкта ял итеп алды. Итекләрен салып ташлады, чолгауларын җиргә җәеп салды, аягын ял иттерде. Башын капчыгына терәп, ятып торды. Җир салкынча иде, күз җитеп килә ич. Ара-тирә саргайган яфраклар очып төшкәли, очкан кош тавышлары ишетелеп куя.

Ниһаять, авылда хәрәкәт сүрелде, ара-тирә мал куып йөргән малайлар гына күренгәләде. Галинур Аллага тапшырды. Авылга килеп керүгә, беренче очраган малайдан Хәмидулла картның өен сорады.

— Бабачы Хәмидулла яшел капкалы өйдә тора. Әнә, уң яктан беренче тыкрыкны узгач та — аның өе,— дип, малай йөгереп китеп барды.

Хәмидулла карт ишегалдында беркем дә күренми. Шуңа карамастан, Галинур капка турында тукталып тормады, ишегалдына керде, өй ишегенә кагылды. Ишек ачык икән, әллә кайчангы таныш-белеш кебек килеп керде. Түр яктан:

— Кем йөри анда?— дигән шактый тупас тавыш ишетелде.

Ул түргә узды. Агач сәкедә тун ябынган карт ята икән. Ләкин ул олы кеше түгел икән әле.

— Саумысез, бабай? Мин сезгә бабам Исламнан күп сәлам алып килдем. Такталачыктан мин,— диде Галинур.

— Такталачык Ислам оныгы мени син! Ә-ә, алай булгач, түрдән уз. Утыр. Һәм йөгең әйт. Әйем... Бирәсен апкилденме соң?

— Апкилдем, Хәмидулла абзый. Ә йөгем... Теге, ни шул бер нәрсә инде...

— Алай икән... Аңлашылды. Йә, болай булгач, чыгар бабаң җибәргәннәрне.

Галинур, ишек төбендә калдырган капчыгын чишеп, алып килгән әйберләрен өстәлгә чыгарып тезде. Монда май да, бал да, әбисе пешергән күмәч, пәрәмәч тә, кичә суйган сарык ире, пешкән йомыркалар да бар иде. Иң азактан өстәлгә бер шешә аракы да менеп утырды.

Сөннәтче карт канәгать иде булса кирәк. Ул, сәкесеннән торып, өстәл янына килде.

Бабачы Хәмидулла шкафтан стакан, бер баш суган алып, өстәл янына утырды. Кулы калтырап тора. Ул, пычак яны белән каккалап, шешәнең сөргечле бөкесен ачты. Аракыны стаканга салганда, шешә борыны стакан читенә бәрелеп бии, ниндидер көй чыгарган кебек: тең-тең-тең, кичә күбрәк эчтең дигәндәй... Стакан тоткач та кулы калтырый иде, шулай да иплэп кенә эчеп куйды. Галинур бу «авыр эшне» авызын ачкан килеш күзәтеп торды. Шешәнең яртысы диярлек эчелеп бетеп, суган, йомырка, пәрәмәчләр ашалгач,

бабайның кәефе күтәрелде. Шуннан соң ул Галинурның үтенече турында сүз кузгатты.

— Син минем салганга карап күңелеңне төшермә. Эшне менә дигән итеп эшләрбез. Шуны аңла: бер духтыр да эспирт эчмичә, әпирәтсәгә тотынмый. Ә мин хирур! Тик миңа эспирте төшми шул. Аракы яки көмешкә инде. Әтү кул калдырый бит. Иртәгә иртән, Алла кушса, сиңа әпирәтсә ясарбыз. Мөселман затына сөннәтсез ярамый, ю-ук. Такталачыкта, әйе, сезнең авылда күптән булганым юк — чакырмыйлар. Ә син үзең килгәнсең — маладис! — дигәч, ул бераз башын кашып, уйланып утыргандай итте.— Тик монда бер кыенлык бар. Әбиең менә, теге... китте бит әле миннән. Кичә сеңелесе янына сыпырды, күрше авылда торганына. Беренче китүе түгел инде. Пыранлап чыга да китә. Ни җитмәгән аңа, ә? Акчасын табам, ашатам, эчертәм... Эчәм инде эчүен, анысы юк түгел. Кичә дә шуның өчен эләкте. Син, ни... самауыр куеп җибәр әле. Үзең дә эчәрсең. Без иртәгә болай итәрбез... Күпме акча алып килдең әле? Минем такса да куелган бит».

Галинур такса дигәннең нәрсә икәнен белми иде. Акча турында сүз барадыр дип, сарык акчасының бер өлешен — уң як кесәдәгесен чыгарып салды. Тегесе аны санап чыкты да иренен турсайтты, күзен кыскалады. Бераздан нәрсәнедер исенә төшергәндәй:

— Ярар, җитәр. Ислам ахирәт хакына,— диде ул.

Бабачы карт әллә кайдан — сәке астыннан, нииндидер әрҗә тартып чыгарды, эчендәге әйберләрне барлады булса кирәк. Чоланга чыгып, каплар күтәреп керде, кайберләрен бушатты, кайберләренә нәрсәдер койды. Пәке үткерләгән тавышлар чыкты. Галинур боларны йокы аралаш кына ишетте. Ул бабачы кушкан сәкегә иске толып җәеп ятып шунда ук йокыга киткән иде. Бик арыткан.

Иртәгесен сөннәтче карт, кичәдән калган аракысы белән башын төзәтте дә, «әпирәтсә»сен эшләде дә куйды. Галинур моңа күңеленнән күптән әзер иде, әллә нинди көтмәгән нәрсә килеп чыкмады. Кисеп җибәргән мизгелдә генә үзәк өздергеч авырту сизде, бербөтен әгъзасын өзеп алдылар мыни. Нәрсәдер сибеп, чүпрәк белән урап куйды бабай теге төшне.

— Тик кенә ят, кыймылдама. Мин хәзер әбиең янына чабам. Кичкә әйләнеп кайтырмын. Менә янында төш вакытында кабыштырырлык ашамлык калдырам. Суны бөтенләй эчмисең, түзәсең. Әбиеңне алып кайткач, үзеңне мунчага күчерермен, анда әйбәтрәк: җиләс тә, тынычрак та. Кеше дә күрмәс. Өч-дүрт көн ятарга туры килер.

Хәмидулла бабачының Галинур килеп кергәндә исереп ятуына һәм бүген генә сөннәткә утырткан кешене япа-ялгыз калдырып чыгып китүенә сәбәп тә, нигез дә бар иде. Эш шунда ки, өченче көн көтмәгәндә-нитмәгәндә Хәмидулланы кичкырын авыл советына чакырып алдылар. Йомышчы хатын капкадан да кереп тормады.

— Хәмидулла абзый, җәһәт кенә силсәвиткә бар, хәзер үк килергә куштылар,— диде.

Мондый чакыруны көтмәгән Хәмидулла капка төбенә чыгып өлгерде.

— Ни булды, сеңелем, белмисеңме?— дип сорады ягымлы тавыш белән.— Кем чакыра?

— Бөтенесе дә шунда: рәис тә, сиклитар да. Әллә нинди комиссия диләрме...

Башка сорамады, чөнки бу хатын барыбер рәтләп әйтә алмасына төшенде. Тиз-тиз киенеп, башына түбәтәен каплады да китте инде.

Авыл советы элеккеге бай Шәйдуллин йортында зур гына бер бүлмәдә урнашкан. Монда авыл советы рәисе — гражданнар сугышында яраланып кайткан чатан аяклы Миңнуллин, совет секретаре — сугыш башлангач кире

урынына кайтарылган Шәмсиев карт утыра. Алардан башка колхоз рәисе, партоешма һәм комсомол секретаре, тагын берничә кеше дивар буена тезелгән урындыкларда һәм калайга төрелгән сандыкка тезелеп утырганнар. Берничә авыл карты да күренә.

— Утыр, Хәмидулла. Бик җитди сөйләшү булыр! — дип, Хәмидулланы буш урындыкка әйдәделәр.

Миңнуллин тезгенне кыска тотты:

— Колхозчылардан хәттин жалу җыелды. Соңгы вакытта әледән-әле эчүең белән авыл халкының саруын кайната башладың. Күренмәгән хәл: илебез фашистларга каршы көрәштә кан коя, ә Хәмидулла авыл урамын айкап эчеп йөри. Теләсә кемгә бәйләнә, хәтта хатын-кызларга да. Моны ничек аңларга?

Хәмидулла сүзнең болай кискен башлануын көтмәгән иде, әлбәттә. Шуңа күрә ул башта бер сүз дә әйтә алмый торды, авызы кисәк корып китте, тел кыймылдарга теләмәде.

— Соң... соң... Әйткән чакта колхоз эшенә чыгам...

— Эчкән көннәреңдә чыкмаган чакларың да булды,— диде бригадир Маһирә.

— Чыгам мин колхоз эшенә, чыгам. Алсалар, фронтка да китәр идем...

— Алырлар. Вакыты җиткәч. Син хәзергә тәртибең өчен җавап тот. Яшең илледән узган, үзең түбәтәй киеп йөргән буласың. Нинди эчкечелек булырга мөмкин шушы авыр вакытта?

— Гаепле мин. Аннан соң... аракы саталар бит кибеттә.

— Сатсалар ни? Авызыңа егып салмыйлар ич! — Сүзгә инде яше буенча сиксәнне узган Гарифулла карт кушыла.— Авылда күренмәгән хәл: исереп урамда җырлап йөр инде, ә? Җитмәсә хатын-кызларга бәйләнеп. Оят түгелме сиңа? Авылда муллалар юк дигәч тә, миңа сүз әйтүче табылмас, дип уйлыйсыңмы?

Хәмидулланың каршы әйтерлек бер сүзе дә табылмады. Эттәй итеп тиргәделәр аны. Керергә тишек табылса, кереп качарга әзер иде.

Урамнан кайтканда бите-йөзе уттай янды. Кибет каршысында торган кешеләрне читләтебрәк узды ул. Һәммәсен белеп торалар иде кебек тоелды.

Эчкән килеш кеше күзенә күренеп йөрү турында башка кертәсе дә юк, бетте болай булгач күңел ачулар. Ни эшләргә соң? Бөтенләй эчми торып та булмас бит әле. Шулай баш вата-вата өенә кайтып җиткәнен сизми дә калды. «Менә хәзер үк бер йөз грамм саласы иде»,— дип уйлана-уйлана чоланда гадәттә шешәләр торган почмакка күз салды. Ах, нинди бәхет — буш шешәләр арасында яртылаш бушатылган бер чирек тора иде! (Аракыны кибеттә өч литр ярымлы «чирек» шешәләрдә саталар. Кирәк кешегә теләгәнчә бүлеп тә бирәләр.)

Бер стакан тутырып салып эчте. Башка төшкән кайгысын ничектер басарга кирәк бит. Бераздан тагын ярты стакан салды. Бер сүз әйтми күз кырые белән генә ирен күзәткән хатынына борылып та карамады. Шулай исереп йоклаган иде ул көнне Хәмидулла.

* * *

Галинур инде өченче көн бабачының мунчасында ята. Мунчага Галинур, хуҗа кайтмагач, икенче көнне үк караңгы төшкәч өстерәлеп чыгып ятты. Нәрсәдер булганын сизде.

Тән яна, яра авырта. Су эчәсе килә. Бәйләгән чүпрәк аша нәрсәдер саркып тора. Кан дисәң, кан түгел, күренер иде. Сидек тотмый иде. «Кая югалды бу бабай?»

Нәрсәдер булган иде шул. Бабай балдызы өенә барып кереп, зур тавыш

чыгарды. Тавыш кынамы әле, ике хатынны да тәпәләп үк ташлады. Балдызга күбрәк эләкте. Ул, җизнәсенең таягыннан ничектер ычкынып, урамга чыгып йөгерде һәм: «Үтерә, үтерә»,— дип кычкырып, ярдәмгә кешеләр чакырды. Ярдәм озак көттермәде. Авылда нәкъ шушы вакытта районнан килгән вәкил белән бер милиционер да бар икән. Хәмидулла картны кулга алып, колхоз идарәсендәге буш бүлмәгә ябып куйдылар...

2

Гөлүсә Галинурның авылда юк икәнен икенче көнне үк сизде. Әбисенә, әнисенә бу турыда бер сүз дә әйтмәде, әмма борчылу шәүләсе йөзенә кунган иде. Үз-үзен кая куярга белмичә ике-өч көн йөргәннән соң түземе калмады. Хәмидә апасы янына кереп, елап-ялварып серен ачтырды.

Менә нәрсәдә икән! Әнисенең хәле мөшкел булуга карамастан, Гөлүсә өчен киткән бит! Ник кайтмый соң ул? Ни булган? Моның сәбәбе турында баш ватып йөргәндә, бер хәбәр ишетте: «Хәмидулла сөннәтче кулга алынган, кемнедер кыйнап имгәткәнме шунда...»

Гөлүсә район үзәгенә юл тоткан атка утырып барды. Беренче адресы Габидуллин йорты иде. Аннан чыккач, Кече Кырга юнәлергә исәп итте. Ләкин ниятеннән кайтты: Габдуллин бабай аны икенчегә күндерде.

— Анда барып йөрүнең хаҗәте юк, кызым. Галинур монда ул, район үзәгендә. Кулга алганнар аны, каталажкага утыртканнар.

— Нәрсә эшләгән ул?

— Төгәл генә әйтә алмыйм, ничек килеп чыккандыр. Чакырган вакытка военкоматка килмәгән.

— Әйе, дүрт кешегә повестка килгән иде шул. Галинурга да.

— Менә, менә. Ә аны Кече Кырда Хәмидулла сөннәтче мунчасыннан табып алганнар. Тегенең өендә тентү ясаган вакытта. «Ә-ә, менә кайда качып ята ул призывтан!» — дип җилтерәткәннәр. Әйе, кулга алганнар. «Преднамеренное членовредительство» — дип баралар ди. Таныш-белеш белән сөйләшеп чыктым. Балакайның күңеле бик төшенке икән. Ничәмә көн мунчада чирләп яткан бит. Бик авыр кичергән теге нәрсәне. Исерек булган бит теге чукынган карт. Карап җиткермичә, өзлектерүе дә бар, каян беләсең хәзер. Яшьлеге бирештермәгәндер инде. Хәзер терелеп бара икән, куркыныч юк. Сорау ала башлаганнар. Тик Галинур нәрсәнедер сөйләп бетерми кебек. Сөннәтчегә гаеп такмасыннар, ди микән, белмим. Әллә дөресен сөйләгәнгә ышанмыйлармы...

* * *

Халык телендә каталажка дип йөртелгән урын милициянең төп бинасына терәп салынган бер сарай кебек нәрсә иде. Эчендә берничә камера. Галинур эләккәненең түрендә дивардан диварга хәтле киң сәке. Ишектән кергәч, сул якта параша. Каршы якта бүрек белән каплап куярлык тимер рәшәткәле тәрәзә. Галинурны камерага кертеп, ишекне шарт итеп бикләп куйгач, сәкедә сузылып яткан тоткыннар аңа күз текәделәр. Кем бу тагын? Кулына тоткан капчыгын кая куярга белмичә катып калган Галинур башта нишләргә белми торды: камерада караңгы иде. Почмактан аңкыган ис косасын китерде.

— Ник катып калдың? Әнә, почмакка ят, җайлан. Тиз генә чыгармаслар, өметләнмә, дигән тавыш иясен шәйләде Галинур.

Сорауга чакыруларны искә алмаганда, каталажкадагы тормыш иксез-чиксез минутлар-сәгатьләрдән үрелә: эчтәге караңгылык көндез дә, төнлә дә бер — түшәм астындагы тәрәзәдән якты төшми диярлек. Тәүлегенә ике тапкыр баланда китерәләр. Иртәнгесен кичкесе белән бутап җибәрсәң, көнне төн белән алмаштырдың дигән сүз.

Галинурның «хәрби хезмәттән читләшү максатында үз-үзенә зыян салу»

дип аталган җинаять эше озакка сузылды. Бер нәрсәне дә яшерми сөйләп бирүенә карамастан, тикшерүчеләр ышанырга теләмәде. Чөнки сүзләрен раслаучы кеше юк иде. Кече Кырда аны күрүче булмаган, ә күрше камерада тотылган Хәмидулла: «Белмим дә, күргәнем дә юк. Инде элекке кәсебем белән маташмаганыма йөз ел»,— дип бара ди. Аның өендә үткәрелгән тентү беркетмәсе буенча сөннәткә кую әсбапларыннан бер нәрсә дә табылмаган: бәрәңге әрчү өчен пычактан башка кисү әйберләренең заты да юк. Йөзгә-йөз сорау алу вакытында Хәмидулла Галинурга күз төшереп кенә алды да:

— Башымны ватмагыз, гомеремдә бу кешене күргәнем юк. Ничек җиткән егеткә сөннәт ясыйм ди мин? Җүләрме әллә,— дип кенә әйтте.

Галинур бу сүзләрдән соң бөтенләй югалып калды: шушы яшькә җитеп, күзгә карап алдаша бит. Кече Кырга килеп кергәндә очраган малай турында, сөннәтченең күршесе турында да сөйләп карады ул. Бу сүзләрне тикшерер өчен Кече Кырга тагын барып килделәр. Галинур сүзләрен раслаучы табылмады. Һәммәсе курка иде.

Октябрь азагы якынлашты. Камерада салкын. Галинурның бишмәтеннән башка бер җылы киеме дә юк. Тикшерүнең чиге күренми. Күңелдә тынычсызлык, килүче юк. Аны кем кайгыртсын? Бабасы, әбисе үлем көтеп ята. Әнисе дә шул ук хәлдә — түшәктә. «Әх, әни, әни! Болай буласын белсәм... Синең хакка чыгып киттем бит. Хәзер мин чын татар малае, синең янга килен китерә алам. Аннан соң армиягә дә китәргә булыр иде, берүзең калмас идең. Түз инде бераз, барыбер чыгарырлар. Нинди җинаять эшләгән мин? Һич кемгә начарлык кылганым юк, беркем алдында гаепле түгел. Сугышка китмәскә дигән уй башыма да кермәде. Бу «членовредительство» дигәннәре нахак ул».

Камерадан бер чакырып алган вакытта тикшерүче бүлмәсендә Габдуллин бабай утыра иде. Тикшерүче аңа нидер әйтте дә, чыгып китте. Пенсиягә чыкканчы үзе дә табиб булып эшләгән Габдуллин:

— Ну, улым, эләккәнсең,— диде башын чайкап.— Кече Кыр турында нигә миңа әйтмәдең соң? Ничек тә булса киңәш биргән булыр идем бит, ничек тә булса ярдәм итәргә тырышыр идем.

Галинур җавап кайтармады, башын иеп кенә утырды.

Озак кына сөйләштеләр. Бабай Такталачыкка барып, Ходай апаны карап кайтуы турында сөйләде. Сүзеннән аңлашылды — әнисе озак яшәмәс.

— Монда эләгүең дә хәлен начарайтты. Тән чире күңел чире белән бәйле ул. Ислам белән Закирәне Хәмидә янына — сезнең өйгә күчерергә булыштым. Хәзер бергә торалар. Алар дип бик бетеренмә. Терелер, Ходай боерса... Синең эшне хаклап военком янына кереп чыктым. Милиция начальнигы Кече Кырга үзе барып кайтырга сүз биреп калды, күп нәрсә ачыкланмады, тикшерербез, диде.

Габдуллин килеп киткәнгә инде байтак вакыт узды. Бернинди үзгәреш сизелми әле, һаман шул: «Призывтан качып йөргәнсең. Сөннәткә утырам, дип, үзеңне имгәткәнсең. Аннан соң хастаханәгә ятып, призывтан калырга уйлагансың. Хастаханәдә кем танышларыгыз? Кемнәр алар? Ник авылдан киткәнеңне военкоматка хәбәр итмәдең? «Колхоз рәисеннән сорап киттем»,— диюенә: «Син бер атнага гына район үзәгенә сорап киткәнсең, нигә Кече Кырга киттең? Ник вакытында кайтмадың?» Авызны шулай йомалар да куялар. Ышанмыйлар.

Гөлүсәгә Галинур белән очрашырга рөхсәт бирмәделәр.

— Кем син? Сеңлесеме? Туганымы? Түгел? Алай булгач, йөрмә монда буталып. Синнән башка да эшебез күп,— диделәр.

Озак уйланып тормады кыз, китте военкоматка. Ап-ак чәчле, кырык яшьләрдәге хәрби комиссар майор Халиков ачык йөз белән каршылады, өстәл

янына утыртып, кем икәнлеген, нинди эш белән килгәнен сорашты.

— Кызык, кызык. Бер кеме дә түгелсең, ә үзең призывник Исламов турында юллап йөрисең. Синең ни эшең бар анда?

Озак сөйләде Гөлүсә. Дулкынланудан сулуы капты, сүзенең башын-азагын бутап бетерде, мәктәптә укыган вакытларын искә төшерде. Ничек тә ышандырырга тырышты. Галинурның эчкерсез кеше икәнлеген, аның бер генә начар уе булмаганлыгын, армия сафына китәргә инде күптән әзер булуын, тик әнисенең чирле икәнен, өйгә килен китереп, әнисен карарга хатынын калдырып китәргә ниятләнүен, ә моның өчен сөннәте булмаганлыгын кабатлап-кабатлап сөйләде.

— Берәр кеше барып караса иде... Хәмидә апа үлем түшәгендә ята. Ул үлеп китсә, Галинур кеше күзенә күренә алырмы? Ничек акланыр? — дип тәмамлады ул сүзен һәм кычкырып-кычкырып елый башлады.

— Да-а! Хәлләр бар икән... Чү-чү, тынычлан, кызым. Мин сиңа ышанам. Әйдә, бергәләп сөйләшеп карыйк әле, тыңламаслар микән,— дип, комиссар телефоннан кемдер белән сөйләшә башлады:

— Карале, теге Такталачык малае утырамы әле? Утыра... Үзе белән сөйләшеп караганың булмадымы?.. Беләм тикшерүчеләрең барын... Нинди качып йөрү булсын инде? Армиягә китәр алдыннан сөннәткә утырырга теләгән. Уң кулының имән бармагын кисмәгән ич ул!.. Шулай булгач... Татарның йоласы инде ул... Карале, минем бер кешегә чакыру планы үтәлми бара... Ярый, мин сине аңладым, рәхмәт. Кече Кырдан кайткач шалтырат, яме? Хуш, күтәм.

Ул милиция башлыгы белән сөйләшкән икән. Гөлүсәнең күңеле үсеп китте. Ул, ак чәчле бу абыйның Галинурны коткаруына ышанып, авылга кайтып китте.

Язган нәрсә булмый калмый икән: Хәмидә түти беренче кар төшкән төнне дөньядан китеп барды. Галинурга бу турыдагы хәбәр өч көннән соң гына килеп ирешти. Башын сәкегә бәрә-бәрә үкереп елады егет. Әнисенең үлемен тик үзеннән генә күрде.

Тормыш вакыты белән искиткеч авыр газаплар да китерә. Ул, күп вакытта сайланып тормый, газапларны гөнаһлы кешеләргә генә өләшми. Бөтенләй гаепсез, үзенә мөкиббән китеп, аны чын күңеленнән яратып яшәгән адәмнәргә дә өлеш чыгара. Ислам картның нинди гөнаһы бар? Нинди? Әйе, баеды вакытында. Ләкин бит ул кануннарны бозмады, кешенекен урламады. Тик үзенең тырышлыгы, эшчәнлеге белән генә баеды. Авылдан китәргә мәҗбүр булды. Тормыш аны гөнаһсыз көйгә туган иленнән аерды. Себер урманнарында ул тазалыгын югалтты. Малае Әхәтне сугыш кара җиргә индерде. Ә япь-яшь Галинурның нинди гаебе бар? Әти-әнисез калды, гаепсезгә каталажкада утыра. Коры сөяк калды егеттән, эче аркасына беректе, күзе сүнгән күмергә әйләнде. Нишләтәсең син, тормыш, кешене?

Ноябрь аеның салкын бер көнендә, Октябрь бәйрәмнәре узгач, камера ишеге ачылып:

— Исламов, чык! Әйберләреңне ал! — дигән сүз яңгырады. Галинурны милиция башлыгы бүлмәсенә алып керделәр. Бүлмә хуҗасыннан башка монда хәрби комиссар майор Халиков та бар иде.

— Гаебегез расланмады, Исламов. Сез шушы минуттан азат,— диде начальник. Аннан тагын нәрсәдер сөйләде. Моны Галинур ишетмәде дә, ишетсә дә аңа кирәкле сүзләр түгел иде.

(Дәвамы бар.)

Фирдәвес Зариф

Агымсу

(хикәяләр)

КАЙТУ

Төне буе яуган яңгыр иртән дә туктамады. Инде өченче көн сибәли. Күк йөзен каплап алган соры болытлардан, тоташ боламыкка әйләнгән юллардан күңелгә авыр басынкылык иңә, кемнәндер генә түгел, хәтта үз-үзеңнән каядыр качып китәсе килә.

Рәсим эчпошыргыч авыр уйлар белән уянды. Кичә булган хәлләр берәм-берәм күз алдыннан уза башлады. Ул ыңгырашып куйды: «Юк, авыр төш кенә түгел икән! Инде хәзер нишләргә?!.»

* * *

Рәсим ашап утыра иде. Һәрвакыттагыча, ваемсыз йөз белән, нindидер көйгә сызгыра-сызгыра, Гани килеп керде.

— Сәлам. Син нәрсә боегып утырасың! Әйдә, бер җиргә алып барам үзеңне. Сразы күңелең күтәрелеп китәр.

Кичке тынлыкны бозып, трактор кабынды. Гани утыргыч астыннан чирекле банка тартып чыгарды.

— Менә, гәрүчи дә бар. Әйдә, тот берне, күңелең ачылыр. Безгә бүген җебеп торырга ярамый.

Авылны чыккач, Гани «Беларусь» тракторын шоссе юлга борды. Рәсим Ганигә сораулы караш ташлады.

— Бүген абзаң хатынлы булачак. Курыкма, ул кыз риза, алдан сөйләшеп куелган. Үзең беләсең, ата-бабадан калган йола. Вәт, Хатипның йөрәге янар инде. Да, Гөлгенәгә күз тотучылар күп булды.

— Тукта әле, Гани. Хатип белән Гөлгенә бер-берсен яратышып йөрде түгелме соң? Армиягә озатканда, Гөлгенә җылап та калды бит.

— Хы, кем кемне яратмаган да, кем кемне җылап озатмаган. Кызларны белмисең әле син. Әнә, Галия дә минем арттан җылап калган иде. Бер ел тулар-тулмас бер кызыл авызга кияүгә дә чыгып куйды.

Хатиптан күңеле суынды инде аның. Соң, нәрсәсенә кызыгасың. Күзлеге белән чыкмаган җаны гына эленеп тора.

Ну, кияү җегете итәм әле мин сине. Гөлгенә үзе синең белән килергә кушты, понимаешь? Элекке классташы булганга, якын күрә ул сине.

Сүз белән мавыгып, күрше авылга килеп керүләрен сизми дә калдылар. Гани тракторын клуб янындагы бакча артына туктатты.

— Хәзер чыгабыз. Син кабинада гына утырып тор.

Ун-унбиш минуттан клубтан Гани белән Гөлгенә килеп чыкты. Гөлгенә, нигәдер, каушап калганга охшаган.

— Менә, Гөлгенә, Рәсим сине кабинада көтеп утыра. Хатиптан хат алган. Бик ашыгыч әйтәсе сүзем бар дигәч, алып килдем инде, күрше бит. Мин сезгә комачауламыйм.

Рәсим авыз ачып сүз әйтергә өлгергәнче, Гани Гөлгенәне кабинага этеп кертте дә, ишекне шапылдатып япты һәм тизлекне күчереп, газга басты. Трактор үкереп караңгылыкка омтылды.

Гөлгенә ялварып Рәсимнең күзләренә карады.

— Рәсим, бу ни дигән сүз? Нигә син мине алдап чакырттың?

Хәлне әзрәк аңлап алган Рәсим рульгә ябышты.

— Бор тракторыңны. Үз акылыңдамы син, Гани.

— Тавышланма. Икебезгә дә җитәр. Әнә посадкага да җитеп киләбез.

Гөлгенә үксеп елап җибәрде.

— Гани абый, җаным, зинһар җибәр. Минем яраткан егетем бар бит! Нәрсә өчен үч аласың, кемгә начарлыгым тигәне бар?..

— Хы, бик масаеп йөри идең чибәрлегең белән. Миңа кияүгә чыкмый, имеш. Санга сукмый.

Рәсимнең ачудан күз аллары караңгыланып китте.

— Туктат хәзер үк, эт җан. Мондый уеңны белгән булсам...

— Шулаймы, этме?!

Гани ниндидер тимер тартып чыгарды.

— Мә, ал, үзеңә кирәген!

Рәсим аңына килеп күзләрен ачканда, кабинада Гөлгенә юк иде инде. Трактор үкереп алга бара. Гани тешләрен кысып рульгә ябышкан, күзләре алга текәлгән, карашында бушлык, битарафлык чагыла. Трактор фарасыннан төшкән яктылыкны караңгылык үзенә йота бара. Ара-тирә Гани тешләрен шыгырдатып куя.

Кайтып җиткәнче башка сөйләшмәделәр. Трактор туктауга, Рәсим ава-түнә капкага юнәлде. Әрнеп башы чатный, күңеле болгана иде.

Икенче көнне авылда хәбәр таралды: «Имеш, Габдулланың Гание белән Харис малае күрше авыл кызын мәсхәрә иткәннәр. Ул кыз хәзер баш күтәрми елый икән. Бүген районнан ике милиционер килеп, Габдулла малаен алып киткәннәр, ди. Харис малаен акыллы, юаш диләр иде, юаштан юан чыга ул...»

* * *

Поезд ыргылып алга чаба. Туган якның каеннары яшел яулык болгап йөгереп бардылар да артта калдылар. Тепловоз сузып кычкырткан саен, йөрәк сулкылдап куя.

Тукта, кемнән кача, кая ашыга соң ул? Булып узган вакыйгада аның ни гаебе бар? Нигә соң аның керсез исемен тапладылар? Кешеләргә ничек ышана, киләчәккә нинди матур өметләре бар иде.

Ичмаса, әнисенә бер бала дип, армиягә дә алмадылар. Инде менә бу хәл.

Уйлары инде тәмам чуалып бетеп, Рәсим йокыга талды...

* * *

...Көннәр бер-бер артлы уза тора. Инде аның Төмән якларына килеп, буровой-

да эшли башлавына да ярты ел була. Рәсимнең күңелендәге читләшү, рәнҗү дә басылып килә кебек.

Авылдашлары ни уйлый икән аның хакында: качып китте, гаебе булган, диләрме икән?! Инде хәзер кайтсаң да егетлек түгел, эшли алмаган, мәми авыз, диярләр. Юк, ничек тә берәр елга түзәргә кирәк. Аңларлар аны, беркемгә дә начарлык теләгәне булмады бит.

Әнисен генә түгел, авыл урамына кадәр сагына ул. Шәһәрдә исә бушбугазлар, эшлексезләр генә түгел, намуслы эшләп тә тулай тораклан башка сыену урыны таба алмаучылар күпме. Әмма авылда этләрнең дә баш өстендә түбәсе, ачыкса, ашар ризыгы бар. Этләр булып этләр дә ишек алдында үзен хуҗа итеп сизә авылда. Ә шәһәрдә сукбай этләр генә түгел, тормышы җимерелгән, бар бәхетне аракыга күчерүчеләр дә тулып ята. Аек вакытта алар да бит уйлана торгандыр... Туган җирдә кеше сукбай була алмый, җирдән, туган нигездән аерылу сукбайга әйләндерә кешене. «Чит җирдә солтан булганчы, үз илеңдә олтан бул»,— дип әйтә иде Шиһап бабай.

* * *

Кошлар язлар саен туган якка сагынып, ерак юллар узып кайта. Тик кешеләр генә табигатьтән аерылган: алар бәхет эзли, байлык эзли. Бәхет эзләп, язмышлар чуала, байлык эзләп, күңелләр ярлылана, бер-берсеннән ерагая бара. Бәхетсез «бәхетлеләр». Нигә соң олыгайгач кына төшенә моңа кеше, нигә вакытында кайтмыйча, бер уч туфрак сорап яза?!. Сагынуны басу түгел, баш куярга да җитми бит ул. Өзгәләнә, төшләрендә кайтыр юлга чыга, ә кайтыр юллар... урау!

Кайтыгыз, кошлар кебек язларда гына түгел, бөтенләйгә кайтыгыз! Шулай дип кычкырасы килә Рәсимнең. Бәлки, кем дә булса ишетер иде аны.

Рәсим дә бит кайтмаска дип китеп барды. Ә хәзер китмәскә дип кайтып бара.

Поездлан алда күңел чаба. Хәер, бер ел инде ул күңеле белән туган якка кайта, тик авыл башына җиткәч, керергә кыймый, кире борыла иде.

...Атна арасы булгангамы, станциядә алар ягына кайтучы машина күренмәде. Бер кулына чемоданын, икенчесенә сумкасын тотып, Рәсим кайтыр юлга чыкты. Авылга кадәр 5 чакрым ара бар, шуның ике чакрымын урман аша үтәсе. «Качкын урманы» дип йөртәләр аны. Нигә шулай атала: тау-чокырлы булгангамы, әллә чынлап та качкыннар яшеренеп ятканмы — анысын хәзер төгәл белүче кеше юк. Урман юлы тын, баш өстендә имән яфраклары шаулый. Алда урман ачыклыгы күренде. Шулчак ул аяк тавышы ишетте, ләкин артына борылып карарга өлгермәде: башында каты авырту һәм караңгы бушлыкка очуын тойды...

Рәсим аңына килгәндә, көн кичкә авышкан иде инде. Ул торырга теләде, ләкин, нишләптер, аяк-куллары аны тыңламый иде. Башыннан ниндидер җылы нәрсә агуын тоеп, кулын тидерде. Кан... Ул тирә-ягына күз салды. Яшел чирәм кызыл төскә кергән, әйберләре дә күренми. Шулай ук монда ятып калыр микәнни? Юк, ул яшәргә тиеш. Аннан башка әнисе нишләр?

— Син, кояш, зинһар, беразга сабыр ит, яктыда кайтып җитәсе бар бит! Сүндермә күңелдәге өмет чаткысын.

Офыкта кызарып кояш байый, кояшның соңгы нурлары шәфәкъ кызыллыгында эреп югала бара. Рәсимнең әле шыксыз караңгы һәм озын төнне уздырасы бар. Ә алда аны борчу һәм шатлыклар тулы якты көннәр, олы тормыш көтә иде.

АГЫМСУ

Агымсу... Кемнәр кушкан икән бу дәртле елгага шундый гүзәл исемне?!.

Кешеләр моны хәтерләмиләр инде. Дөрес, үзләренчә юраучылар бар: аны кайберәүләр Агымсуның тиз агышлы булуы белән бәйләсә, икенчеләр исә, бу — халкыбызның, сагыш-хәсрәтләреңне елга-сулар белән уртаклашсаң, агымсуларда агып китә, дигән борынгы ышану-йоласына барып тоташа, диләр.

Юк, ялгышалар адәм балалары!..

Кешеләрнең иманнары гына зәгыйфьләнмичә, буыннарны бәйләүче хәтер җебе дә нечкәреп, өзелер чиккә җитеп бара ахыры...

Ә елга, чын тарихны үзе дәвам итеп, туктаусыз ага да ага, әле ярсып, әле агышын акрынайтып, кешеләргә шанлы вә фаҗигале үткәнне сөйли... Тик ишетмиләр шул аны: җаннар — саңгыраулланган, горурлык — коллык белән томаланган...

...Моннан мең ярым ел чамасы элек аның чишмәдәй саф сулы ярына Ирбатыр атлы ир белән аның Агымсу исемле сылу хатыны килеп урнашты. Һәр иртәне Агымсу елганың йомшак суларында ефәктәй чәчләрен юды, ә җылы җилләр назлап тарады. Ирбатыр да, Ил-көнгә рәхмәт йөзеннән, яр буйларына җиләк-җимеш куаклары утыртты. Тиешенчә карап-тәрбияләп торганга, һәр язны шау чәчәккә күмелде аның ярлары. Яшь парның яңа туган, уймактай иренле, зәңгәр күзле, туп кебек теп-түгәрәк йөзле уллары, чәчәкләрнең хуш исеннән, кошларның өздереп сайрауларыннан, изрәп йокыга тала торган иде. Ә ул, аларга бәхет һәм тигезлек теләп, акты да акты, елларны санады...

Ире Илен яклап яуга киткәндә, мул сулы елга хатынга иптәш, таяныч булды. Сылу, сагыну-сагышларын моңга салып, ашкын суда агызды, елга ул моңны суын эчәргә килгән бердәнбере — Ирбатырга ирештерә торды. Ир дә, якын итеп, аңа хатыны исеме белән: «Агымсу»,— дип эндәшә иде. Гаҗәеп матур Ил-җир буйлап агып, Ил кайгысына хәсрәтләнеп, шатлыкларына куанып, зәңгәр сулы диңгезгә коя иде елга. Юл уңаенда бу илнең тырыш халкы иген иккән уңдырышлы басуларны, елкылар утлап йөргән хәтфә болыннарны сугарды ул. Туган Илен шушы гүзәл якларга күз аткан дошманнардан яклый белгән батыр халыкны үз итте елга.

Еллар үтә, сулар ага торды. Әлеге сихри гүзәллек ил халкына чиксез дәвам итәр кебек тоелды һәм... халык уяулыгын югалта башлады. Шуны гына көткән Иблис кешеләр арасына коткы салды һәм ыру-кабиләләр үзара ызгыша, хакимлекне бүлешә башладылар. Ә төньяктагы дошманнар моннан бик оста файдаландылар: ыруларның бер өлешен, хакимияткә килүдә ярдәм вәгъдә итеп, үз якларына аудардылар һәм зур яу белән илнең башкаласына юл тоттылар.

Бабайларның: «Аерылганны аю ашар, бүленгәнне бүре ашар», — дигән акыллы сүзләрен искә төшерүчеләр булса да, игътибар итеп, тыңлаучы булмады. Ил агалары сүзеннән, яшьләр генә түгел, урта буын да чыга башлаган иде шул — калебләрдән Ил кадере китеп бара иде... Җитмәсә, яу безне читләтеп үтәр, дип, кардәш ырулар да башкалага ярдәм җибәрмәделәр. Хәйләкәр һәм мәкерле иде дошман. Аның җәтмәсенә диңгез буйларында, чиксез киңлекләрдә хакимлек иткән кавем падишаһы да эләкте: Агымсу Ил-дәүләте көчәйсә, Сездәйләргә көндәш булачак, дип ышандырдылар аны. Юха, йомшак телгә кушып, затлы бүләкләр күндерергә дә онытмадылар. Ерак гасырларда далаларны, дәрья вә диңгез буйларын тетрәткән төрки кавем варислары шулай бүлгәләнде, һәлакәткә юл тотты...

Үзәк кала алынды, Ил таланды, исән калган ирләр һәм арба көпчәгеннән калкуырак ир балалар кылыч аша уздырылды, гүзәл хатын-кызлар, әсирлеккә алынып, ятларга коллыкка сатылды. Елга суы ай буе кан ташкыны белән кушылып акты, ә аннары мәсхәрәләүдән, рәнҗү һәм кайгыдан карасу төскә керде...

Шуннан соң, вакыты-вакыты белән кузгалса да, бу халык күтәрелә, Ил-җирен торгыза алмады. Юк, сәбәбе дошманнарның көчендә түгел, ә бердәмлек булмауда, кешеләрнең көнчелек белән бер-берсенең башын «ашавында» иде...

Менә, дүрт ярым гасыр диярлек вакыт узгач, бу халык яңадан уянып килә, тернәкләнергә тели. Әмма... ялгышлар кабатлана, башлар «ашала», яуланмаган дәрәҗә, хакимият бүленә. Агымсу да инде аларга тарихны, Ил-җирнең элекке гүзәллеген искә төшерә алмый, суы саега, көннән-көн агулана бара. Шулай да, соңгы көчен җыеп, аның бу халыкка аваз саласы килә: «Кешеләр, акылыгызга килегез! Бүлгәләнсәгез, кем коткарыр Ил-җирне? Кем? Кем?».

СОҢГЫ СӨТ ТАМЧЫСЫ

Искәндәр патша яуларын, башбирмәс, горур вайнах, дак ыруларын хәтерләгән мәгъруп таулар тезмәсе артыннан акрын гына кояш күтәрелде. Авылда гадәти тор-

мыш кайный башлады: аксакаллар көтүләрне тау утлавыкларына кудылар, хатыннар көндәлек мәшәкатьләргә чумдылар. Урамда бала-чага чыр-чу килде. Тик авыл тоткасы булган ирләр генә күренмәде — алар инде ничәнче мәртәбә Туган илне якларга күтәрелгән иде. Ирләрнең исәнлекләрен атнага бер килгәләп чыккан хәбәрчеләр генә җиткереп тора.

Каты, аяусыз сугышлар бара... Сугыш сызыгы әле авылга килеп җитмәсә дә, аның вәхши кырыслыгы аналарның чәчләренә ак бәс булып кунды, балалыкларын югалтып барган малайларның йөзләренә ирләрчә җитдилек булып сарылды.

Кемгә кирәк бу сугыш?! Ни өчен гел әйләнеп кайта? Чарасызлыкка төшкән кешеләр моны салкын акыл белән кабул итеп, аңлап бетерә алмый. Әмма бер нәрсәгә нык инанганнар: Ватан — бер генә, чигенер урын юк...

Көндәлек ыгы-зыгы белән кайдан пәйда булган штурмовикларны күрми, сизми калдылар. Хәер, күзәтү очышлары ясаучы самолетлар авыл өстендә күренгәләп китә, тик бер-ике әйләнеш ясагач, юкка чыгалар иде. Тик бу юлы тау ташларыннан өелгән йортларга бомба, ракеталар ява башлады. Берничә минуттан, артларында хәрабәләр, тузан өермәсе калдырып, алар гаип булды. Актарылган йорт нигезләрендә канлы гәүдәләр, утлы күмер кисәүләре генә торып калды.

Авылда җан әсәре калмаган кебек иде. Әмма хәрабә астыннан, җәрәхәтле арт санын сөйрәп, бер эт үрмәләп чыкты. Сызланудан, ялгызлыктан үзәк өзгеч тавыш белән шыңшып куйды. Тик ярдәмгә килүче күренмәде. Эт, ал аякларына башын куеп, тынып калды, йомык күзләреннән яшь бөртекләре кысылып чыкты.

Кинәт, дәһшәтле тынлыкны бүлеп, бала тавышы яңгырады. Өзгәләнеп... бала елый иде. Каядыр янәшәдә, бик якында ишетелә... Җимерек бер йорт янында шәүлә-карамчык селкенеп куйды. Ул каядыр үрмәли, нәрсәдер тарткалый иде. Миләрне өшетүче, йөрәкләрне телгәләүче манзара иде бу: хәрабәләргә әйләнгән йортның подвал ишеге төбендә бер хатын-кыз гәүдәсе ята. Аның күкрәгенә бер сабый үрмәли, нәни куллары белән нәрсәдер эзли. Һәр төртеп торган урынны уймактай иреннәре белән суыра. Тик теләгән нәрсәсе һаман табылмый.

Менә баланың куллары изүгә кереп китте, кадерле нәрсәсен табып, ул аңа йомшак иреннәрен тигезде. Тик эләктереп ала алмый, читкә тайчынды. Ананың күкрәге буйлап суырыла алмый калган соңгы сөт тамчысы агып төште...

Гүя кояш та, әрнүгә түзә алмый, йөзен болыт белән каплады. Бары Терек елгасы гына, тирә-якка яшәү көче, тереклек өстәп, шаулап-гөрләп ага бирде.

Октябрь, 1999 ел.

ЗӨЛФИЯ

Талгын агышлы Сакмар суы буйларында туып үсте ул. Коңгырт күзле, кыйгач кашлы, күперенке куе чәчле Зөлфия мәктәптә укыганда ук һәр эштә башлап йөрде. Шаян табигатьле булса да, җитди, үткен карашлы, һәр нәрсә хакында фикере булган бу кыз белән, классташлары гына түгел, укытучылар да исәпләшә иде.

Күңеле каядыр алгысына иде Зөлфиянең. Күрәсең, шуңадыр, сигезенче классны тәмамлауга, Казанга — педучилищега китәргә карар кылды. Әти-әнисе дә каршы килмәде: яшенә хас булмаганча мөстәкыйль һәм һәр адымын уйлап эш итә иде кыз. Казанда якын туганнарыбыз да яши — аларда торыр, күз-колак булырлар, дип, үз-үзләрен юаттылар. Ялгышмадылар да, баштагы елларда ук туганнарыннан Зөлфия хакында гел мактау сүзләре генә ишетеп тордылар: кызлары гел бишкә укый, апасына өй эшләрендә дә булыша икән.

Кулына кызыл диплом алуга, балалар бакчасына тәрбияче булып урнашты Зөлфия. Югыйсә, әти-әнисе укуны берәр югары уку йортының көндезге бүлегендә дәвам итү ягында иде.

— Укырга өлгерермен әле,— диде Зөлфия кистереп,— университетта читтән торып дәвам итәрмен.

Баштарак:

— Авыр булыр бит, Зөлфия,— дип каршы төшсәләр дә, соңрак:

— Ярар алайса,— дип ризалашудан башка чара калмады.

Ни генә әйтсәң дә, кызлар кош кебек бит алар. Кияүгә чыгар, тормышын җайлавы җиңелрәк булыр, дип фикер йөрттеләр.

Зөлфия сүзендә торды: шул ук елны Казан дәүләт университетына читтән торып укырга керде.

Төрле яшьтәге һәм төрле һөнәрле кешеләр иде ул укыган татар теле һәм әдәбияты бүлегендә. Дөрес, күпчелек аның кебек яшьләр, әмма арада инде гаилә корып балалар үстергәннәре дә бар. Гамир исемле бер егет, әле өйләнергә өлгермәсә дә, армиядә хезмәт итеп кайткан, Себердә эшләп йөри. Ничектер башкалардан читтәрәк тора, төркемдәшләре белән бик аралашмый иде ул егет. Бер караганда — үзен башкалардан өстенрәк куя, артык җитди, икенче караганда — романтиграк табигатьле кебек. Һәрхәлдә, аңлап бетереп булмый торган, кешелекле һәм ярдәмчел бу егеткә азрак көлемсерәп һәм ихтирам белән карадылар. Һәркемнең күзе төшәрлек чибәр дә иде Гамир. Бер кызга да игътибар итмәгән, үчекләбрәк сөйләшкән зәңгәр күзле, саргылт чәчле бу егетне Зөлфиянең этеп егардай чаклары да булмады түгел. Әмма, җитдилек саклап, тыелып калды. Игътибар итмәве бер нәрсә, төркемдә староста билгеләү мәсьәләсе кузгалгач, Зөлфияне тәкъдим итүгә каршы төшеп, инде гаиләле Саттарны яклады. Шуннан соң, җае чыккан саен, бер-берсен дусларча «чеметкәли» — төрткеле сүзләр әйткәли башладылар.

Зөлфиянең Гамирга битараф түгеллеген Саттар да сизеп алды.

— Икенче курска укырга килгәндә, өйләнешкән булсагыз да гаҗәпләнмәм,— диде ул киң итеп елмаеп.

Әйе, ярата иде Зөлфия Гамирны — җитдилеге, кешелеклелеге һәм горур булуы өчен яратты ул аны. Әмма егет, җитди теләк белдермичә, Зөлфиянең елмаюлы карашын кире кага килде.

* * *

Кызлар, чыкса, егерме яшькә кадәр кияүгә чыгып кала, диләр. Хак сүз. Зөлфия дә сазаган кыз булып утырып калудан курыкты. Шуңа да, үзеннән дүрт яшькә олы Хәйдәр тәкъдим ясагач, озак уйламый ризалашты. Дөрес, Хәйдәр, хөкем ителеп, ел ярым утырып чыккан. Әмма карап торышка яхшы күңелле, булдыклы кешегә охшаган. Һәрчак елмаеп: «Зөлфиям»,— диеп кенә тора.

— Утырып чыкканнар арасында да яхшы кешеләр бар бит,— дип акланды ул төркемдәшләре алдында,— әйбәт кенә торып та китәләр.

Хәер, аны гаепләүче дә табылмады, дөнья бит, төрлесе була, дип карадылар.

* * *

Кыз бала тапкач, Зөлфия академик ял алды. Тормышы да җайланып килә кебек. Зөлфия теләге буенча, Хәйдәрнең әнисе фатирыннан тулай торакка күчтеләр. Өнәп бетерми иде шул каенанасы Зөлфияне, ничектер якын итә алмады. Һәр нәрсәдә буйсыну, үзенчә яшәүне таләп итте. Әнисе янына барган саен, үзгәреп кайта иде Хәйдәр. Эчкән чакта кул да күтәргәли, Зөлфиянең яшьлегеннән, хәтта үткәненнән дә көнләшә башлады. Ярты еллап түзгәч, Зөлфия аерылышырга карар бирде, судка гариза язды.

Аерылышкач та тынычлана алмады Хәйдәр, һәр көнне килеп йөрде.

— Зөлфиям, яңадан бергә булыйк, башка кабатланмас,— дип ялынды. Бер килүендә елап ялварды да.

Юк, кичерә алмады аны Зөлфия.

— Бер кискән ипи кире ябышмый,— дип кырт кисте. Кызгану хисен горурлык җинде.

Баласы булса да, Зөлфия белән танышырга теләүчеләр гел табылып торды. Арада унҗиде яшьлек егет тә бар иде. Мәхәббәттән исергән Алмаз исемле бу егет, бер килүендә, өйләнергә нияте булуын да белдерде.

— Яратам мин сине, Зулечка, синсез тора алмыйм,— диде.

— Юләрем минем,— дип каршы төште Зөлфия.— Мин синең апаң яшендә бит.

— Шуннан нәрсә,— дип үҗәтләнде Алмаз.— Паспортыңны күрсәтеп йөрмәм әле.

— Азрак үс әле,— дип көлде Зөлфия.— Соңрак үзең ук рәхмәт әйтерсең.

Шулай аерылыштылар. Дөрес, Зөлфия дә аны якын күрә иде, ләкин гаилә тормышы хискә генә корыла алмый шул. «Тора-бара яшьрәкләргә күзе төшәр, бары бер китәр»,— дип шикләнде Зөлфия.

* * *

Еллар уза торды. Менә инде Зөлфия университетны тәмамлап килә. Тормышы да җайланыр төсле. Туган якларга бер кайтуында, әле һаман да өйләнмичә йөргән сабакташы Харис очрап, ун ел буе яшереп килгән хисләрен ачты:

— Мин сине мәктәптә укыган еллардан бирле яратам, әмма сүз кушарга тәвәккәллегем җитмәде. Чык миңа кияүгә, аяк астында туфрак булырмын.

— Беләм, син әйбәт егет, Харис,— диде Зөлфия азрак уйланып торгач.— Тик мин инде кияүдә булдым, балам да бар.

— Мин барысына да риза, Зөлфия. Күреп торасың, һәр түмгәккә абына торган яшьтә түгел инде хәзер. Ныклап уйладым мин. Әни дә каршы түгел. Синең дә әниең үзе генә калды, инде олыгаеп та бара. Бергә булыйк. Әниеңә терәк, балаңа әти булырмын.

Кистереп әйтә алмады Зөлфия.

— Уйлап карармын, азрак вакыт бир,— дию белән чикләнде.

— Ярый, бер айдан Казанга килермен. Каршы килмә, зинһар. Үкенмәссең.

Бер айдан, Зөлфиянең ризалыгын алып, канатланып кайтып китте Харис.

* * *

Университетны тәмамлаган көннәрдә Зөлфиянең яшьлек хисләрен яңарткан очрашу булды. Казан урамыннан барганда, Кекин йортына җитәрәк, каршына Гамир килеп чыкты.

— Исәнме, Зөлфия.

— Исәнме, Гамир. Тормышларың ничек?

— Әйбәт, Зөлфия. Үзең ни хәлдә, кияүгә чыкмадыңмы әле?

— Синнән яшермим, Гамир. Авылга кайткач, элекке классташым очрады. Кияүгә чыгарга тәкъдим ясады.

— Үзеңне аңлый торган әйбәт кеше булса, чык, Зөлфия. Син кемне дә бәхетле итәрлек.

— Рәхмәт, Гамир. Яхшы кеше икәнеңне беләм мин.

Берара тын тордылар. Сүзне Зөлфия ялгады:

— Беләсеңме, Гамир. Очравың яхшы булды әле. Үзем дә эшеңә шалтыратырга тора идем. Без — элек бергә укыган кызлар, сөйләштек тә, сине чыгарылыш кичәсенә чакырырга булдык. Ихлас күңелдән. Килерсеңме?

— Килермен, Зөлфия. Мин барыгызны да, элеккечә якын-үз күрәм. Чакыруың өчен рәхмәт.

Алар шулай аерылыштылар. Күз карашлары моңсу иде. Икесе дә, әлеге очрашуның соңгысы булачагын, аннан гомер юллары мәңгегә аерылачагын сизеп-тоеп торды. Бер-берсен күз карашларыннан ук аңлаган кешеләрнең соңгы очрашуы иде ул...

Радмир Фаяз-Уралы

Соңгы шаһит

(Тарихи хикәя)

Иртәнге куе томан талгын гына тарала бара. Ак ташлы текә таулар, калын урманнар, яшел болыннар буйлап ашыкмыйча гына боргалана-сыргалана Ирән елгасы ага. Аның сул ярына урнашкан, мәдрәсәсе белән тирәякта дан тоткан, өстәвенә зур Уфа-Көңгер юлы кисеп үткән Енапай авылы да татлы йокысыннан уянып килә.

Чияле тау каршыннан көзге кояш күтәрелеп чыкты да, җылы алтынкөмеш нурларын сибә башлады. Җаннарны нурландырып, зиһеннәрне яңартып, миһербанлык, шәфкать теләп, авыл өстендә мәчет манарасыннан азан авазы яңгырады. Атлар кешнәве, мал-туар мөгрәве, әтәчләр кычкыруы ишетелде... Ниһаять, кояш күтәрелде. Томан да таралып бетте.

Таш юлның ике ягында әби патша заманында утыртылган ак каеннар, юлчыларны озатып, көз аеның йомшак җилендә саргая барган яфракларын коя-сибә баш иеп калалар. Бу каеннар аякларына чылбырлы тимер богау салынган адәм балаларын ерак Себергә озатуларны да, әрҗәсенә патша туграсы — ике башлы кара кош төшерелгән беренче автомобильләрне дә күргән шаһитлар. Шунысы кызык, автомобильләр авылга килеп керүгә, бөтенесе: кош-корты, каралты тирәсендәге хайваннар, үзләренә урын таба алмыйча, арлы-бирле чабышырга тотынырлар иде. Ахырзаман килгән диярсең. Бигрәк тә атлар бик сизгер җан икән: авылдан бер чакрымда торган Вахип тавы башыннан бу дүрт көпчәкле әкәмәт күренүгә үк арбаны каертып калдырырлар иде дә, дулый-дулый басу ягына элдерерләр иде...

Икенче ел инде җир йөзе асты-өскә килә. Бер якта кызыллар, икенче якта аклар. Кайдадыр еракта-еракта, бугазга-бугаз килеп, каты сугышлар бара. Дөньяның бу дәһшәтле шаукымы моңа кадәрле Енапай авылын читләтеп узып килгән иде. Менә бүген авыл старшинасыннан иртә белән мәдрәсә каршындагы яшел мәйданчыкка җыелырга диган фәрман таралды. Башка елларда бу вакытта — елның көз диган фасылында — үзенә күрә авылга ямь өстәп, кара кәләпүшле, зәвык белән тегелгән камзуллар кигән, култык асларына китап-дәфтәр кыстырган шәкертләр мәдрәсә ягына агылырлар иде. Быел йөзәр чакрымнардан сабак алырга дип килгәннәрен дә өйләренә кире бордылар. Моңа әлеге дә баягы шомлы ел-

лар сөреме сәбәпче булды. Күп тә үтми авылның киртә белән әйләндереп алынган җыйнак мәйданчыгы ир-ат белән тулды.

«Нәрсә булды? Нинди яңалыклар?» — дигәндәй, алар үзара гәпләшә дә башладылар. Ул арада әтиләре, олы абыйларына ияреп килгән сәләмә киемле малай-шалай да шул тирәдә тулгана башлады. Старшина Миңнеәхмәт мәдрәсә болдырына чыгып басты, аның янына Фәйзерахман мулла белән мөгаллим Мирхәйдәр кунаклады. Старшина уң кулын күтәрде: тынычланыгыз, янәсе. Тыны кысылуга карамастан, ул да озак көттереп тормады, сүз башлады:

— Җәмәгать... җәмәгать, дим, тынычланыгыз әле. Үзегез күрәсез, дөньялар болгавырланды, юк-бар сөйләшеп, вакытны әрәм итмик, дим. Җыелуның асыл сәбәбе шунда, җәмәгать: сезнең белән мәслихәтләшеп аласы бар. Яңалыклар әйбәттән түгел. Дөресен әйтик, хәлебез мөшкел. Үзегез ишетәсез, сирәк-мирәк булса да туп тавышлары безгә дә килеп җитә. Хикмәт шунда: Көңгер — Пермьгә таба безнең юл буйлап кызыл чирү якынлаша, икенче өлеше Кызылъярга* борылган. Ак гаскәрләр үкчәләренә басып килә икән,— дип, дулкынлануын баса төшеп, тамагын кырып алды старшина. Аннары: — Кызыл чирүне ят кеше җитәкли икән,— дип өстәде һәм, шул гаскәр башлыгы ни атлы дигән сорау биргән сыман, Мирхәйдәргә таба борылды.

Төркемдәгеләрнең барысының да күзләре башына каракүл бүрек, якасы укалы бишмәт кигән мәһабәт гәүдәле Мирхәйдәргә текәлде. Аның Герман сугышыннан забит — офицер булып кайтканын авылдашлары беләләр иде инде. Ул алтын погонлы мундирын, биек түбәле фуражкасын озак киеп йөрмәде: тиз арада мөгаллимлек эшенә керeште — мәдрәсәдә җәгърафия фәнен, исәп-хисап белемен укыта башлады.

Мирхәйдәр үзенең сугыштагы гадәтен онытмаган икән — хәрбиләрчә төз басып торган җиреннән:

— Кызыл гаскәрне Блюхер атлы кеше җитәкли,— диюгә, төркемнең алгы сафында торучы, сугыштан контузияләнеп кайткан агач аяклы Габдулла атылып чыкты һәм бишмәтендәге ике башлы каракош сурәте төшерелгән медаленә** төртә-төртә:

— Каһәр суккыры, таныш исем: Бюхмер ул! Чыгышы белән немеч. Беләм мин аны! Менә шул мөртәт аркасында германда аягымны калдырып кайттым мин,— дип шапырынырга тотынды.

Герман сугышында бер аягын калдырып кайткан Габдулла сүзләреннән соң халык гөжләшеп, көлешеп алды.

Агач аяклы Габдулла бу медален урында йоклаганда да салмый икән, йә булмаса мендәр астына куеп йоклый икән, дип сөйлиләр иде.

— Җәмәгать, бүтән вакытны көлешербез, елашырбыз. Бүген сабантуе түгел — күңел ачарга җыелмадык,— диде, тавышын күтәрә төшеп старшина Миңнеәхмәт. — Вакытыбыз чамалы. Шунысын әйтеп үтү зарур булыр: кызыл чирүнең амбарлардагы ашлыкны атларына фуражга җыюлары, атларыбызны хәрби эшкә — туплар, обоз тарттырырга алулары турында хәбәр иттеләр. Ашлык, атлар өчен мөһерсез кәгазь тоттыралар икән дә, вәссәлам, ягъни Аллаһы әкбәр. Шулай булгач, безгә дә каныкмый калмаслар, безнең дә атларыбыздан, икмәгебездән колак кагуыбыз бар. Җәмәгать, авылдашларым! Уйлашыйк, киңәш йөртеп, уртак фикергә килик. Бу авыр, киеренке сәгатьләрдә безгә нәрсә эшләргә? Нинди эш кылырга безгә, халаек, ә?..

Җыен шаулаша башлады, бәхәс тагы да кыза төште. Кайсылары, авылда калырга, дигән уй-фикер әйттеләр. Беришләре исә: «Бу чирү узып киткәнче авылны ташлап китәргә кирәк»,— дип каршы төштеләр.

— Җәмәгать, күреп торасыз, вакыт тар,— дип, Фәйзерахман мулла сүз алды, халык та тынып калды.— Үзегез ишетәсез, туп тавышлары безгә якынлашканнан-якынлаша бара. Иртәгә төш вакытларында аларның

---

* Красноуфимск.

** Ике башлы каракош сурәте төшерелгән медаль — патша армиясендә татар-мөселман солдатларына, Георгий тәресе урынына, дәүләт туграсы куелган ике башлы каракош куеп эшләнгән медаль бирелгән.

бездә булачагы көн кебек ачык. Минем киңәшем шул булыр: атсыз, малсыз, кыш чыгарга — икмәксез, язгы чәчүгә — орлыксыз калсак, нәрсә эшләрбез? Җирне хатыннарыбызны җигеп сукаларбызмы? Мондый мөһим, хәлиткеч вакытта әүвәл киңәшергә, аннан соң гына эш кылу кирәк... Минем тәкъдимем шул: бу чирү узып киткәнче, Аделгә барып торырга кирәк. Алар безне аңларлар, безнең хәлебезгә керерләр, беравыкка безгә урын табып, безне сыйдырырлар, шәт.

Фәйзерахман мулланың сүзе үтемле булды, күрәсең. Җыендагыларның күбесе аның белән килеште, старшина Миңнеәхмәт тә бу фикерне дөрес дип тапты. Шулай итеп алар Енапай авылыннан егерме чакрымнар чамасы ераклыктагы, кайчандыр кан-кардәшләре булган, зур юлдан читтәге кара урман эчендә урнашкан авылга — Адел авылына күчеп торырга булдылар.

Старшина Миңнеәхмәт, баш киемен салып, тирләгән маңгаен кульяулыгы белән сөртеп алды, аннан кара постаудан тегелгән бишмәтенең кесәсеннән чылбырлы сәгатен чыгарды — вакытны чамалады, күрәсең. Ул — буйга зур түгел, әмма төптән юан гәүдәле, көр тавышлы, кылган гамәлләре белән хөрмәткә ия кеше иде.

Старшина үз вазифасын үтәргә керешге: әүвәлгечә дилбегәне үз кулына алды. Һәм шунда ук нык, кыю боерыкларын бирә башлады. Ул амбардагы, келәтләрдәге ашлыкны олауларга төяп, урманга илтергә, вакытлыча җиргә күмеп куярга, эре хайванны ат арбаларына тагарга да, мал-туарның берсен дә калдырмыйча — барысын да үзләре белән алырга дигән әмер бирде. Халык дәррәү старшина әмерен үтәргә таралды.

Барысы да әзер булгач, иртә белән таң ата башлауга ук, юлга чыктылар.

Мөгаллим Мирхәйдәр җитәкчелегендәге ир-егетләрне Атәр урманына — олы юл аркылы озын, юан чыршы агачларын аударырга җибәрергә булдылар. Бу чирү үзенең юлын тимер юл буйлап Кызылъярга борыр, авылны читләтеп узар, дип уйладылар, күрәсең.

Таң ата башлауга, берничә чакрымга сузылган олау Адел авылы ягына таба кузгалды. Мал-туарның нидер сизенгәндәй ямьсез тавыш белән мөгрәве, этләр өрүе, биләүдәге имчәк балаларының елаулары, адашкан кәҗә бәтиләренең нечкә тавыш белән кычкырулары, арбада утырган хатын-кызның тавыш-тынсыз гына яшь түгүе — барысы да йөрәкне телә, сызлата иде. Авылны чыгып бераз китүгә, яңгыр яварга тотынды. Ләкин олау туктамады, юлын дәвам итте.

Һичбер җан иясез диярлек авыл артта калды...

Атәр урманында таш юл аркылы салынган чыршы агачларын кызыллар бик тиз тазарттылар. Гаскәрнең билгеләнгән маршрутын үзгәртергә хокукы да, хәрби әмерне үтәмәскә хакы да юк иде. Кызыл чирү, олы юлдан тайпылмыйча, Енапай авылы аша узды...

Адел авылында атна-ун көн чамасы шомлы вә борчулы көннәрен үткәреп, енапайлылар яңадан, олау булып, үз авылларына таба юл тоттылар.

Арыган, йончыган атлар арбаларны үргә сөйри — алар өчен бу соңгы киртә иде. Олаулар бик авырлык белән Сарна калкулыгына менеп җитте.

Олуг, зур булган Енапай авылы, уч төбендәге кебек, тау итәгендә җәйрәп ята иде. Тик ул... кара күмергә әверелгән иде шул. Урманга качып котылган этләр генә әллә авылдашларына, әллә авылны яндырып киткән кызыл чирү башкисәрләренә ләң-ләң өрәләр иде.

...Кайчандыр кызыл чирү узган бу юл елдан-ел үз әһәмиятен, мөһимлеген югалта барды. Хәзерге вакытта Енапай авылының бер очыннан, иске трактны аркылыга кисеп, кояш нурларында ялтырап, күзгә сыман тигез асфальт юл уза. Иске олы, таш юл буена утыртылган, олыгайган, картайган каеннар, үзләренең тугрылыклы хезмәтләрен үтәп,— кышларын кар тотып, әле булса көз-кыш айларында юлчыларны зәһәр җилләрдән, ачы бураннардан саклыйлар. Ә күпләре тәмам картаеп, корып, җил-давылларда иске таш юлга авалар. Тарихның әби патша, революция михнәтләрен күргән тере шаһитлар да елдан-ел сирәгәя бара. Әйе, Енапай

Дания Гайнетдинова

Хәтер

(Нәсерләр)

ҖИР-АНА КИСӘТҮЕ

Гөлия йокысыннан елап уянды. Әле генә күргән төшен күңеленнән үткәреп урыныннан тормый берникадәр уйланып ятты ул. Җир шары күчәреннән ычкынган, имеш. Җирдәге тереклек ияләре юкка чыккан. Басу өстендә тибрәлеп җырлаучы соңгы тургай да Гөлиянең учларында җан бирде...

Ул урыныннан торды да, язу өстәле буена эленгән картага күз төшерде. Туган җире Татарстан чиген барлап чыкты. Йа Алла, гел коңгырт-соры төсләрдән генә тора икән бит аның яшәгән төбәге. Яшел билгеләр бөтенләй юк диярлек. Шунда кылт итеп аның исенә моннан берничә ел элек яңа йорт җиткергәндә капка төбендәге юкәләрне төбе-тамыры белән төпләп алулары төште. Бер мәлгә уйлары чуалып китте. Агачларны кызганып елаган иде ул теге чакта. Әтисе: «Елама, кызым, яңаларын, яшьрәкләрен утыртырбыз»,— дигән иде. Тик сүзендә генә тормады.

Аның уйлары кабат әбисе исән чакка барып тоташты. Әбисенә ияреп болында, инеш буйларында йөрергә ярата иде Гөлия. Ялгыш кына берәр чәчкәне өзгәнен күрсә, әбисе шундук,тереклек дөньясын бүләк итүче Җир-Анабыз ни дияр, дип кисәтә иде. Гөлия әбисенең, кызым, без кечкенә чакта Җир-Анага мәрхәмәт белән карыйлар, аңа табыналар иде, дигән сүзләрен исенә төшерде. Игеннәр буын сикерткәндә, печән өлгергәндә, болын чәчәкләре бөреләнеп, җиләк пешкәндә Җир-Ананы аяу көннәре була иде. Дөньяга тереклек туганда урманда агач кисмиләр,болынга кереп үлән таптамыйлар, елгада балык тотмыйлар иде, дия иде ул.

Әбием исән булса, ни дияр иде икән бүген?! Мөгаен, кичермәс иде ул безне. Әнә бит, басу-кырларны агулап кошлар җырыннан мәхрүм калдык, урманнарны кисеп Җир-Анага балта күтәрдек, чишмәләр кипте. Җир-Ана-

быз елый бүген. Җир-Анабыз елый... Шул хакта уйланыр вакыт җитте. Бүген күргән төшен Галия Җир-Ана кисәтүе итеп кабул итте.

Чишмәләрнең моңы, кошлар җыры, агачлар шавы тынмасын туган ягыбызда, Җир-Анабыз рәнҗемәсен безгә!..

ӘНИЕМНЕ КӨТӘМ

Ятимнәр йортының эче тулы сагыштыр, моңаен. Бу йорт, әгәр дә җаны булып, телгә килә алса, җир йөзендәге барлык аналарга ишетелерлек итеп: «Сине юксынудан сабыеңның күзләрен моң баскан, сине сагынудан өзгәләнә нәниең!» — дип аваз салыр иде. Әнә бит, биш яшьлек Гөлфия инде ничә көннәр тәрәзә янына басып әнисен көтә. Әнисенең йөз-кыяфәтен дә, хәтта исемен дә белми ул. Чөнки танып-белә башлаганнан бирле аның өчен әни кеше — әлеге йортның тәрбиячесе. Шулай да Гөлфиянең нәни генә йөрәге үз әнисенең дөньяда барлыгын белә. Балачак хыялында аның әнисе кебек матур да, ягымлы да әни әле беркемдә дә юк. Дөньяда иң гүзәл әни аныкы гына.

Моңарчы бер генә тапкыр да әнисен күрмәгән сабый үзен упкын төбенә ташлаган ананы шундый илаһи зат итеп йөрәк түрендә сакласын әле! Таш булып — таш эрерлек.

Иптәш малае Рамилне әни-әниләре алып киткәч, Гөлфиягә бигрәк тә ямансу булып калды. Юк, Рамилгә тигән бәхеттән көнләшми. Барлык балаларның да әти-әниләре булырга тиешлеген белә ул. Бүген булмаса, иртәгә килерләр дә: «Әйдә, кызым, сине алырга килдек»,— дип әйтерләр сыман аңа. Башка балалар йоклап беткәч, әкрен генә торып пәрдә читен аз гына ачып куя ул: килерләр дә, тапмый китәрләр дип курка. Рамилнең әнисе биргән күчтәнәч кәнфитен дә, әниемә бүләк итәрмен дип, мендәр астында яшереп саклый Гөлфия.

Тәрбияче апалары урамга уйнарга алып чыккач, койма буендарак йөрергә тырыша. «Нигә бу йортның коймалары шулай биек икән?» — дигән сорау еш килә аның күңеленә. Койманың теге ягында башка бертөрле серле-сихри дөнья бар сыман аңа. Бәлки мине әниемнән шушы биек койма гына аерып торадыр? Менә-менә койма ишелер дә, нәни Гөлфияне әнисе күреп алыр кебек.

Бераз үсә генә төшим, укый-яза башлагач, иң беренче булып әниемә хат язып салам: «Әнием, нигә шулай озак килмисең?Мин сине бик-бик сагындым. Синең йомшак кулларыңда иркәләнәсем, җылы куеныңа сыенып, әннәм, дип дәшәсем килә»,— диярмен. Әйтелмәгән, бары тик әнисенә генә әйтәсе тагын әллә никадәр матур сүзләре бар әле Гөлфиянең. Тик нигәдер һаман күренми аның әнисе.

Аныкы гына микән? Гөлфия кебек бик күпләрнең әниләре дә шулай нигәдер озаклады шул... Сабый күңеле барыбер көтә, өметләнә...

Газиз әнкәйләр, көттермәгез сез сабыйларыгызны! «Әнием» дип эндәшергә тилмермәсен алар. Гөнаһсыз сабыйлар елмаюыннан да матуррак ни бар соң бу дөньяда?! Рәнҗетмик әле аларның күңелен. Ятимнәр йортында «әнием» дип дәшәргә тилмермәсен әле йөрәк парәләребез, тилмермәсен!

САГЫШ

И-и, бу сагыш дигән нәрсә, адәм балаларын ничек кенә яндырмый, көйдерми икән?! Олыгая төшкәч бу хис аеруча көчәя бара. Күрше фатирда яшәүче Бибигайшә әби дә калага күчеп килгәннән бирле җанына тынычлык тапмый, авылын, ялгызы калган йортын сагына. Төннәрен дә йокы керми аның күзләренә. Һәркемне эшкә киткәндә озатып, кайтканда каршы алып, хәл-әхвәл сорашмый калмый ул. Аннан соң ул кырт кына

авыл тормышына күчә дә, күңеле түрендәге иң нечкә кыллар тибрәнүеннән булса кирәк, ихластан дулкынланып сөйләп китә:

— Ишеткәнсездер инде, сеңлем, быел авыл халкы игеннәрне вакытында җыеп ала алмады, яңгырлар комачаулады бугай, безнең район да артта калган дип ишеттем әле...

Аның төсе уңа төшкән коңгырт күзләрендә очкын кабына, киң маңгаендагы җыерчыклары язылып киткәндәй була. Матур булып картайган бу әбинең йөзендә карап туймаслык елмаю балкый.

— И-и-и, безнең Мишә буе бодайлары! Анда үскән шикәр чөгендере, сеңлем, мин сиңа әйтим!.. Сулышым белән тартып китердәй булам туган якларны шушы кала җирендә. Гомер иткән нигезеннән кубып-каерылып йөрмәсен икән ул адәм баласы...

Шулай ди дә тынып тора Бибигайшә әби. Аннары күңелен бушатып сөйләп китә:

— Без яшь чакта: «Сандугачның, мескенкәйнең, канаты каерылган, бер без генә түгел инде илләрдән аерылган»,— дип җырлыйлар иде. Риза булып, теләп аерылгач ни!..

Андый минутларда Бибигайшә әбинең йөзе үзгәреп китә. Күзләрендәге йолдыз җемен ниндидер ямансулык әлпәсе томалый. Маңгаендагы гомер буразналары тирәнәя төшә. Бөтен гәүдәсе бөрешеп, кечерәеп кала төсле. Гүя аның күңел учагын сүндерәләр.

Кеше тормышының җебе-җиге белән кызыксынудан түгел, бәлки тирән уфтануына теләктәшлек итеп, сак кына сораштырып куям:

— Киленегез белән арагыз бик үк җылы түгелме соң әллә, Бибигайшә әби?

Күршем сискәнеп үк китә.

— Юк, сеңлем, юк-юк, гөлкәем, авызыңнан җил алсын, киленем кызымнан да миһербанлырак, якты көн менә!

Үзем хаталандым, үзем, кубасы калмаган төп нигездән. Ялгыз калган йортым да, әкрен генә хуҗасын сагынып, сыкрана торгандыр бәгырь. «Ник мине ялгызымны ташлап киттең?»,— ди торгандыр, җаныкаем.

Сүз авылга кагылдымы, аның тыны кайнарлана, теле җорлана. Таң тынлыгын ярып кычкырган әтәчләр дә, язларын яңа гына тернәкләнгән яшел үлән өстендә сары йомгаклар булып тәгәрәшкән каз бәпкәләре дә, туклыктан ялык-йолык килеп торган яшь бозауның, арт аякларын атып, йөгереп китүе дә, сәрви куакларының чәчәкләрендә ширбәт ләззәтеннән оеп, безелдәгән бал кортларының гөжләве дә бик еракта калган хатирә сыман тоела аңа. Кое сиртмәсен чүктереп су алулар, болынга чыгып чалгы кайраулар, көзге мәлне каз өмәләренә җыелып гөр килүләр... тагын әллә ниләр күз алдына килә Бибигайшә әбинең... Аның теленә әледән-әле яшелле-сарылы дулкыннар йөгерешкән басулар, Мишә суының назлы кыз йөрешен хәтерләткән бормалары, талгын җил ындыр табагыннан китергән бөртек исе керә тора. Дөресрәге, болар аның теленнән төшеп тормый. Өнендә дә шулар истә, төшенә дә шулар керә. Бу кала җирендә аның, әйтерсең лә, шәүләсе генә, җаны белән ул үзенең туган-үскән җире, үзе белән картайган йортында.

...Һавада кыр казларының моңсу гына тонык тавышлары ишетелде. Бибигайшә әби, сискәнеп, утырган урыныннан ук торып, кулын маңгаена куя да:

— Әй, кайталар җанкисәккәйләрем, кыйгач сафларга тезелеп! Әй, аваз салган булалар бәгырькәйләрем, туган якларга тагын кайттык, диләр. Сагынганнар безнең якларны... Кош булып, кош туган күлләренә кайтуына сөенеп бетә алмый, адәм баласы ничек җирсенмәсен дә, ничек моңсуланмасын!.. — дип өзгәләнә.

Киек казлардан да биегрәк очар булып, сагыну-сагышларын куды ул. Җыерчыклар баскан битендә елмаю чаткылары күренде. Әйтерсең лә

күңеле белән сагышланып көткән иске йортының терәүле капкасын ачып керде Бибигайшә әби бу минутта.

Шулай гына була күрсен, насыйп булсын иде...

ИКМӘК КАДЕРЕ

Игенченең җан җылысы иңгән
Җир баласы — галиҗәнап икмәк!
Җир-Анага хөрмәтебез ничек?
Рәнҗетмибез микән?

Әйе, икмәк беркайчан да җиңел табыла торган байлык булмады. Ул һәркайда да игенчедән авыр хезмәт таләп итә. Шуңа күрә аның кадерен игенче генә белә.

Ә без яртышар күмәч икмәкне чүплеккә чыгарып ташлаган чакта ул икмәкне үстерүчеләр хакында уйлыйбызмы икән? Еш кына мин битен тирән сырлар баскан бер әбинең, чүплек савыты кырыена килеп, икмәк кисәкләре җыеп торганын күрәм. Басынкы гәүдәле әлеге әби нигәдер миңа инде күптән вафат булган әниемне хәтерләтә. Ирексездән, әниемнең, ачлык елларында ачка шешенеп, зур газаплар белән үлем тырнагыннан котылып калулары турында сөйләгән сүзләре искә төшә. Аның моңсу күзләре әле дә булса миңа сынаулы карыйлар кебек: «Син минем корычтай авыр кулларымны, яргаланып җир төсенә кергән бармакларымны хәтерлисеңме? — диләр сыман.— Менә шул куллар белән алтын бөртекләрне җиргә иңдереп, алар үсеп яңа икмәк булганчы күпме көч сарыф ителгәнен игенче генә белә шул». Әниемнең җилдә яргаланып беткән иреннәре шулай дип пышылдый сыман.

Сугыштан соң туган балалар без. Ачлык, сугыш газапларын күрмәдек, шулай да әле безнең буын икмәк кадерен белми димәс идем. Әле дә хәтеремдә, без кечкенә чакта авыл халкы ташлы тегермәндә он тартып, үзе икмәк пешерә иде. Әниемнең дә ап-ак яулык, ак алъяпкыч бәйләп ипи камырын басуын күзәткәнем бар минем. Бисмилласын әйтеп кулларын юар, куна тактасын алып он иләр, камыр басыласы кисмәккә җылымса су салып озаклап камыр басар иде. Камыр тыгызланып кабарып киткәнче, нәзек куллары тәмам талчыкканчы баса ул камырны. Аннары кисмәк өстенә җитеннән үзе тукып суккан ашъяулык каплап, төнгә мич башына куя.

Ипи пешерәсе көнгә каршы йокы керми иде аның күзләренә. Берничә тапкыр торып камыр кабаруын күзәтә. Таң атканчы мичкә ягып, инде өлгереп җиткән камырны кисәкләргә бүлеп, тәмам түгәрәкләнгәнче кулында әвәли, аннан соң он сибелгән тактасына тезә. Мичтәге кисәүләрне, тигезләп, мич төбенә тарата. Ипиләр тигез пешсен, йөзе килсен, ди ул. Аннан пумала белән калган күмерләрне җыя, мич төбе тәмам күмер-тузаннан арынгач, түгәрәк камырларны агач көрәк белән мич төбенә тезеп чыга да мич авызын калай капкач белән каплап куя. Менә бераздан өйгә хуш исле икмәк исе тарала...

Шунда икмәкләрне мичтән сак кына алып, почмак сәкедәге ястык өстенә ябылган ак җәймәгә тезеп чыга. Кетердәп торган хуш исле икмәкнең азрак суынуына түземлек җитмичә, әнинең безгә сындырып биргәнен көтәбез. Кулларны пешерерлек кайнар икмәкне тотып урамга йөгерүдән дә бәхетлерәк чак бармы икән?! Шулчак әнинең күзләрендә яшь тамчылары пәйда була. Куану-шатлык яшьләре иде алар. 32 нче елгы ачлыкта, алабута ипие ашап, шешенгән чаклары күз алдына килә булса кирәк аның. Әтисенә ияреп, үгез җигеп, чәчү чәчкән чакларын, шул төнне йокламыйча яңгыр теләп Ходайга ялваруларын, беренче шытып чыккан үсентеләрне, игеннәрнең башак кысуын, бөртекләрнең тугаеп, тулышканын күзәтүен, уракка төшкән беренче көн, беренче учманы күреп кабат сөенүләрен күз алдына китерә ул.

Елларның авыр килгән чаклары, тулышкан башакларны җыеп алырга насыйп булмаган, корылык яки бик явымлы еллар да булгалый. Андый вакытларда Җир-Ана белән бергә елый игенче. Шуңадыр да икмәкнең кадерен игенче генә белә шул. Элек-электән икмәк пешергән хатын-кызга арка белән тору гөнаһ саналган. Икмәк урлау — зур хурлык, икмәкне исраф итү зур җинаять булган.

Ә без, бүгенге балалар, беләбез микән икмәк кадерен? Игенченең хезмәтен олылыйбыз микән? Шул хакта уйланырга күптән вакыт!

ХӘТЕР

Бөек Ватан сугышы тәмамланугa ярты гасырдан артык вакыт узды. Ә яралар әле һаман да төзәлмәгән.

— Без — 37 миллион... Күбебез яу кырында батырларча сугышып, мәңгегә ятып калдык,— дип, һәрдаим искә төшереп торалар. Аларга, әйтерсең лә, кайтаваз булып, гитлерчылар тарафыннан җәзалап үтерелгән ил картлары, хатын-кызлар, сабыйлар авазы да кушыла. Бер йотым суга, бер валчык икмәккә тилмереп, ачлыктан җан биргәннәрнең дә бүгенге яшь буынга әйтелми калган сүзләре хәтеребезне чарлый сыман.

Җөмһүриятебездән генә дә Бөек Ватан сугышына 566 мең ир-егет киткән, шуларның 325 меңе әйләнеп кайтмаган.

Яу кырында башларын салган батырларның, гөнаһсызга һәлак булганнарның үлемгә кергәндә язылган хатларын актарам...

1944 елда Белоруссияне азат иткәндә Лиозно шәһәрендәге бер йорт җимерекләре арасыннан табылган, 15 яшьлек Катя Сусанина язган хат. Конвертка: кадерле апалар, абыйлар, немецлардан яшереп язылган бу хатымны кем генә тапса да, почта аша әтиемә җибәрегез, зинһар, дип язылган. Хатта мондый юллар бар: «Кадерле әтием, бу хатны алганда мин инде исән булмам. Әнине эзләмә, аны немецлар атып үтерде. Әтием, миңа бүген нәкъ 15 яшь. Мине күрсәң, таный алмас идең, мин бик ябыктым, чәч толымнарымны кисеп, пеләш итеп кырдылар. Мин Шарлэна исемле немецта кол хезмәтендә. Аның дуңгызларын карыйм. Көнгә 2 тапкыр дуңгызлар белән бер тагарактан ашыйм. Бер көнне ата дуңгыз кулымны тешләп өзә язды. Ике тапкыр качарга омтылып карадым, барып чыкмады. Аяклары белән тибә-тибә аңымны җуйганчы кыйнадылар. Бөерләрем бик авырта.

Әтием, минем өчен алардан үч алырсың, яме, мин үлемгә киттем.

Кызың КАТЯ».

Бу хат миллионнарның берсе генә. Катя язмышы кебек күпме солдатлар, хатын-кызлар, сабыйлар гомере немец аягы астында эзсез югалган. Дөньялар әле дә тыныч түгел. Җир өстендә туплар, бомба, снарядлар шартлый, авыллар, калалар җимерелә. Үлем ачысына түзә алмый Җир-Ана ыңгыраша. Ишетәсезме, кешеләр, яңа гасыр бусагасын атлаганда вәхшилеккә юл куймыйк! Тарих гафу итмәс. Бүгенге якты көн, Ватан, туачак сабыйлар хакына сугышта җаннарын биргән корбаннар рухы рәнҗер! Хәтер ни дияр?!

Дмитрий Стахеев

Кырым бакчаларында

(хикәя)

I

Җиләк-җимеш бакчасы. Аның кырыйларыннан үзләренең юан башакларын төрле якка тараткан зур чикләвек агачлары, өлгереп килүче җиләкләре белән капланган озын төче чияләре тигез рәт булып сузылган. Бакчаның бөтен калган мәйданын алма, груша, персик, абрикос һәм миндаль агачлары алып тора. Алар әллә ни озын түгел, нечкә башаклылар һәм һәркайсы очыннан төбенә кадәр кояш нурлары төшәрлек итеп утыртылган.

Көн уртасы. Күктә болыт әсәре юк. Кызган ут шары чиксез күк йөзе буйлап йөзә һәм аның нурларына эләккән һәр нәрсәне рәхимсез кыздыра. Бакчадагы чикләвек һәм төче чия агачларының куе күләгәсендә әле кояш нурлары эссесеннән котылып торырга һәм, мөгаен, үләнгә ятып, бакчаның бу урыныннан күренеп торган хәрәкәтсез зәңгәр диңгезгә карап череп итеп алырга да мөмкин. Чикләвекнең куе күләгәсендә беркем юк, җимеш агачлары бернинди күләгә бирми торган урыннарда гына кешеләр күренә. Бер агачтан икенчесенә күчә-күчә һәм аларның һәркайсының ботакларын төрле яклап карый-карый, алар үзара кыска-кыска фразалар белән алмашалар: «Ярыйсы!.. Ярый!.. Монысында бар!» — «Монысы инде азрак булыр, ләкин шулай да ярыйсы гына...» — «Ә менә монда, әйтергә кирәк, сыеграк инде...».

Һәр агачны җентекләп карап һәм аннары чикләвеклек күләгәсенә кереп, алар аны да ничектер үтеп барышлый гына күз йөртеп алдылар да, бакча капкасына таба киттеләр. Анда читән янында таштан балчык белән сылап эшләнгән, яссы җир түбәле кечкенә алачык бар иде. Күрәсең, каравылчы өе булып исәпләнгән бу алачык янында карап торырга кәкре-бөкре һәм зәгыйфь булып күренгән һәм үзенең хәлсез ботакларын кояшның көйдергеч нурлары астына игән кечкенә груша агачы үсә иде. Бакчаны карап йөргән кешеләр әлеге агач янында туктадылар һәм янә кыска гына сөйләшеп алдылар. Күбрәк бер кеше сөйләде, ә калган икесе ул әйткәннәрне генә кабатлады. Ул: «Ну,

монысы сыеграк»,— диде. «Әйе, шулайрак, чыннан да сыеграк»,— дип җавап кайтардылар тегеләре. Яки ул: «Менә монысы, егетләр, җимешле агач: монысыннан рәт чыгачак»,— дип әйтеп алды. «Әйе, әйе,— дип кабатладылар тегеләре,— анысыннан, димәк ки, чын уңыш булачак. Чынлап шулай булыр». Кыскасы, сөйләгәннәрне тыңлап та тормыйча һәм бер карау белән үк боларның берсе хуҗа, калган икесе аның приказчиклары икәнен икеләнмичә әйтергә мөмкин иде. Хуҗа — юан гәүдәле, аз гына бөкре, филне хәтерләткәнрәк бер кеше. Аның өстендә озын чабулы, постаудан тегелгән сюртук, башында кояш нурларын көзгедәй чагылдырган ялтыравык козыреклы картуз. Аның рәсәй кешесе булуы һәм кырым эсселәренә шаккатмыйчарак каравы әллә каян күренеп тора: «Миңа инде хәзерге яшемдә аларга яраклашырга соңрак, моңа вакыт та юк». Чәче аның тиешенчә каралган, сакалы шактый сирәкләнгән, агарган да, йөзе куе алсу төстә.

Приказчиклары да постау киемнән, ләкин кигәннәре хуҗа кебек үк озын түгел, итекләренең куныны исә хуҗаныкы шикелле. Чандыр гәүдәле, кечкенә сакаллы һәм кояшта каралган йөзле бу затлар хуҗаларына, аның иреннәренең һәр хәрәкәтенә сизгер булып карыйлар. Киемнәре һәм үз-үзләрен тотышлары буенча алар җирсез рус мещаннары катлавына карыйлар, ә бу катлау элек-электән сәүдәгәрләргә «бай бирергә кирәк тапкан» бәягә хезмәт итәргә мәҗбүр булган.

Кырымның көньяк ярында алар әле монда килүләренә тәүлек тә тулмаган кунаклар. Бирегә алар Рәсәйнең әчке шәһәрләренең берсеннән — әллә Курскидан, әллә Тамбовтан килгәннәр һәм алар туктаган җирле трактир хуҗасы яһүднең колачын җәеп каршылавына һәм дустанә кулларын кысуына караганда, бирегә беренче мәртәбә генә килүләре түгелдер. Сәүдәгәрнең сәламәтлеге белән кызыксынып тормыйча, чөнки моңа ихтыяҗ юк иде, аның көр гәүдәсенә карау белән үк физик халәтен чамаларга була иде,— ул очрашуның беренче минутында ук кулын иреннәренә куеп һәм трактир бүлмәләренә ишарә ясап: «Ике кеше бар һәм алар да сез йөргән эш артыннан килделәр»,— дип пышылдады. Җавап урынына симез сәүдәгәр уйланып җилкәсен кашып алды, аннары кинәт, һич көтмәгәндә, үзенең егетләрен гаҗәпкә калдырып кычкырды: «Сез нәрсә, юләрләр, нинди алебастра кебек басып торасыз!» Аннары ул бөтен кич буе, күрәсең, трактир хуҗасы җиткергән хәбәрләр тәэсирендә, кәефсез булды. Әле моннан бер көн элек кенә Лозово-Севастополь тимер юлы вагонында шулай ук диңгез буена баручы бер сәүдәгәр белән очрашып бакчаларны арендага алуда бер-берсенә комачауламау турында дусларча сүз куешуларын искә алгач, аның канәгатьсезлеге тагын да көчәйде: «Тагын кем килеп чыккан монда?» — дип күңелсезләнеп уйланды ул һәм бу халәт аның күңелен шулкадәр биләде ки, кичен йокыга китәр алдыннан гадәттәгечә догаларын укый башлагач, ул үзе дә сизмәстән чукына-чукына: «Күрәсең, теге Тула этләре чабып килеп җиткәннәрдер, башка беркем дә булмас!» — дип кычкырып җибәрде. Аның чандыр егетләре асларына юл келәмен җәеп идәндә яткан җирләреннән хуҗа соравына җавап бирергә теләп торып басмакчы булганнар иде, әмма хуҗаның кабат чукына башлавын күреп янә урыннарына яттылар. Иртән таң атар-атмас хуҗа егетләре белән бакчаларны карарга китмәкче булган иде, әмма «Тула этләре» аны беркадәр вакытка тоткарладылар. Алар белән ул нәрсә турында һәм нинди тон белән сөйләшкәндер, моны егетләр ишетмәделәр. Аннары, хуҗа аны тоткарлаган кунаклар белән саубуллашып, ниһаять, татар бакчаларын карарга киткәч, аның шат күңелле булуыннан егетләр аңарда булган кунакларның бакчаларны арендага алуда көндәш түгеллекләрен аңладылар.

Анда бакча түрендә нәрсә каралып күренә ул? Күрәсең, кемдер читән аша бакчага керә? Әйе. Менә берәү керде, аның артыннан икенчесе һәм икесе дә симез сәүдәгәр белән аның приказчиклары күләгәсендә утырган ала-

чык ягына юнәлделәр. Иртән трактирда сәүдәгәр белән сөйләшкән теге кунаклар булып чыктылар алар. Икесе дә сайлап алганда озын буйлылар һәм базиклар, йөзләре кояшта каралган, сакаллары тузгыган һәм шулай ук озын чабулы сюртуктан. Берсенең икенчесеннән өстенлеге бер нәрсәдә дә күренми — икесе дә җирәнрәк йөзле, зур борынлы һәм соры күзле. Аларны байлыгы белән татар бакчасы читәне аша сикереп чыгу ихтыяры булмаган кайсыдыр бер бай сәүдәгәр приказчиклары дип уйларга мөмкин иде. Тик мондый уйга аларның бакчага алданрак килгән юан сәүдәгәргә ялагай елмаеп караулары һәм хөрмәт белән баш июләре генә комачаулый иде. Аларның баш июләренә:

— Ә сез тагын минем арттан килдегезме! — дип төксе һәм теләмичә генә җавап бирде сәүдәгәр.

— Әйе, нәкъ шулай. Гафу итегез...— дип сүз башлады килүчеләрнең сакалы карарак һәм куерак булганы,— сезнең эшегез, әлбәттә, безнекенә тиң түгел һәм сез һәрвакыт үзегез теләгәнчә эш итә аласыз, тик шуны искә алыгыз — монда бәяләрне саклар өчен бөтенесе бергәләп эш итәләр. Ишеткәнсездер, бәлки, Мәскәү сәүдәгәрләре дә үзара килешкәннәр: яһүдләр шулай бергәләп арендага алалар.

— Беләм, беләм. Чыннан да шулай. Нәрсә әйтәсең! — дип уйчан төстә раслады сәүдәгәр.

— Гафу итә күрегез. Без сезнең файдага тырышачакбыз. Һәм сез безне үз ярдәмегездән ташламассыз. Безгә күп кирәк түгел ич. Әгәр бөтен сатып алганыгыздан безгә кечкенә өлеш чыгарсагыз, мәсәлән, мең сум — без шуңа канәгать: бик рәхмәтле булырбыз һәм алга таба да Сезгә хезмәт итәрбез.

— Елга артыннан бакча сатып алдыгызмы әллә? — дип сорады сәүдәгәр сүзенең тонын нык киметеп.

— Ахыргача булмады әле... Әйтергә кирәк, без мең ике йөзне биргән идек... Хәзер сез шунда барып бары тугыз йөз сум тәкъдим итсәгез икән. Шул чакта ул шактый йомшарыр иде.

— Бу төпле фикер. Ә монысы өчен күпме тәкъдим иттегез?

— Булмады әле.

— Һм!.. Шу-ла-й! Татар, ишетәсезме, бакчада юк, мәчеткә китте.

Сәүдәгәрнең егетләре хуҗадан читкәрәк киттеләр, ә килгән пар стена күләгәсендә аның янына утырды.

Сөйләшүнең тоны күренеп төште, нәрсә турында сөйләшкәннәре ишетелми. Юан сәүдәгәр авырлык белән бер терсәгеннән икенчесенә борылды, ә сакалбайларның берсе ике кулын болгап һәм кояшта каралган йөзе белән аның чәченә тияр дәрәҗәдә якынаеп кызып-кызып колагына нәрсәдер пышылдый. Аның күзләре әле тулысынча ачылалар, әле җептәй кысылалар, ә уң кулын ул минут саен күкрәгенә кыса, әмма җәенке ягы белән түгел, бәлки кабыргасы белән, юан бармагы исә ничектер башкаларыннан аерылып, читтәрәк калкып тора.

— Бакчаларны бирәчәкләрен Ходай үзе генә белә,— дип фаҗигале тон белән пышылдады ул,— бәлки югалтулар да булыр әле, чөнки җимешләрне күргән дә юк әле, ә акчаны инде чыгарып салырга кирәк.

— Син монысын дөрес әйтәсең, әйе! Көчле җил булып җимешләрне коярга мөмкин, корылык булуы да ихтимал... Төрлесе булырга мөмкин... Түзәргә кирәк, чөнки бөтенесе Ходай кулында,— диде сәүдәгәр уфтанып: — менә нәрсә, егетләр,— ул сүзенең тыныч һәм моңсу тонын кинәт кырыс һәм катгый тонга күчерде — мин сезне, ягъни мәсәлән, ихластан кисәтәм: сез сатып алган бакчаны да, минекен дә бәхәсләшеп тормыйча, Ходай кушканча бүләчәкбез.

— Я Хода, без чынлап та! Кичә сездә ничек ант иттек, шулай булыр,— барысы да бөек намуслылык нигезендә.

— Шулай булгач, хәзергә китеп торыгыз, мин монда татарны көтеп калам. Ул тиздән килер, чөнки аларның гыйбадәт кылулары озак булмый, өч-дүрт мәртәбә бөгелеп ала да, шуның белән вәссәлам.

Сакалбайлар күрәсең, православиенең исламнан өстенлеген аңлаудан канәгать булып, ә аннан да бигрәк сәүдә мәнфәгатьләрендә үзара килешүгә килүдән канәгать калып көлеп алдылар.

Татарның гыйбадәте чыннан да озак бармады. Сәүдәгәрнең яшерен компаньоннары бакча читәне артында юкка чыгуга ун минут та үтмәде, бакчаны тау итәгенә ябешкән татар авылыннан аерып торучы тузанлы шоссе юлында мәчеттән кайтып килүче татар гәүдәсе күренде. Аны ерактан күргәч, сәүдәгәр үзенең егетләре белән бакчага яңа гына килеп кергән кыяфәттә янә бер агачтан икенчесенә күчеп йөри башлады.

— Ә-ә! Исәнме, иске таныш,— дип каршылады ул бакчада күренгән татарны,— менә мин килдем дә. Киләм дип әйттем һәм — килдем.

— Яхшы. Аллага шөкер! — диде татар, сәүдәгәр әйткәннәрдән бары «здравствуй» сүзен генә аңлап.

— Ну, менә әйбәт булды. Яхшы икән, димәк, беренче сорт дигән сүз. Хәзер синең бакчаңны карап чыгабыз, анда кайда һәм нәрсә барлыгын, ягъни мәсәлән.

Сәүдәгәр агачларны каравын дәвам итте. Татар, уйчан кара күзле, чаларган, кояшта каралган һәм сөякчел карт, кинәт салкынайтып җибәргәндәй мехлы бүреген кашларына кадәр төшерде һәм, әле сәүдәгәрнең калын гәүдәсенә, әле егетләргә карый-карый, алар артыннан китте. Аның күкрәге ачылган, киндер күлмәгенең җиңнәре терсәккә кадәр бөкләнгән, авызында кечкенә трубка төтенли. Уйнаган роле ышандырырлык булсын өчен сәүдәгәр бакчадан алыначак табыш турында егетләре белән берничә сүз әйтешеп алды һәм, ниһаять, кашларын җимереп татарга мөрәҗәгать итте:

— Начар. Аңлыйсыңмы?.. Бик тә начар, ягъни мәсәлән...

Татар да кырысланды, әмма бер нәрсә дә әйтмәде, бары ризалашмыйча башын гына чайкады.

— Чайкама башыңны,— дип дәвам итте сәүдәгәр,— син мин әйткәнне тыңла. Бакчаңда эшләр шәптән түгел, табыш аз булачак. Аңлыйсыңмы?

Татарның каралган йөзеннән елмаю үтеп китте.

— Начар юк. Яхшы бар... Яхшы! — диде ул, трубкасын тарта-тарта.

— Ә бу нәрсә? Менә бу, мәсәлән, груша дип аталамы? — Кәкре-бөкре нәмәстә җимеш тә бирмәячәк ул. Әгәр санап карасаң, бакчада андыйлар күп җыела...

— Без санап чыктык,— дип алдан әзерләнгәндәй сүз кушты егетләрнең берсе.

— Ну, мисал өчен, ничегрәк?

— Шактый ук...

— Ике дистәләп булырмы?

— Шул тирә булыр, күрәсең...

— Менә шулай ул... Ишетәмсең? Бераз киметергә кирәк,— дип дәвам итте сәүдәгәр, тавышын күтәрә төшеп һәм татарга текәлебрәк карап.

Татар кинәт моңа кадәрге тыныч һәм ваемсыз халәтеннән чыкты һәм кулларын болгый-болгый кычкырып сөйли башлады:

— Киметергә? Ничек киметергә! — дип кычкырды ул,— минеке өч йөз сум сорыйм, синеке өч йөз бирергә теләмисең, минеке өч йөздән түбәнне теләми...

Ниндидер кирәкле сүзен таба алмыйча, ул кинәт үзенең туган телендә сөйли башлады.

Егетләрнең берсе аның янына килде һәм шулай ук татарча сөйләп китте. Сәүдәгәр стена күләгәсенә елышты һәм, картузын салып чәчәкле кульяулыгы белән маңгай тирен сөртте.

— Я!..— дип мөрәҗәгать итте ул, ниһаять, татар белән сөйләшкән егетенә,— нәрсә ди ул, ягъни мәсәлән.

— Ул әйтә,— диде приказчик ашыгып һәм сүзләрен йоткалап,— быел че-

решня электәге белән чагыштырганда бермә-бер күп булачак, чикләвек тә шулай ук күп көтелә, чөнки ул узган ел бөтенләй булмады, ди...

— Ахмак син! — дип бүлде аны сәүдәгәр.— Сүз бу хакта түгел.

— Киметерме дип сорыйм мин.

— Булмастыр. Нык тора.

— Я, ярый, маташсын. Менә теге егетләр аны әле йончытырлар, шуннан соң аның белән сөйләшү җиңелрәк булыр. Хуш, дус кеше? — диде ул татарга, бакчадан чыгу ягына юнәлеп.

— Хуш, әлбәттә! Өч йөз яхшы,— диде татар,— минеке өч йөздән кимне теләми. Әлбәттә!..

II

Бу вакытта ике сакалбай күрше бакчада читән күләгәсендә тәмәке пыскытып утыра иде. Читән үрмәләп үсүче үсемлекләр белән шулкадәр куе капланган иде ки, аның чыбыклары гына түгел, биек имән казыклары да күренми иде. Кыргый виноградның ачык яшел яфраклары чәнечкеле үсемлек ажинаның кечкенә карасу яфраклары белән аралашып беткәннәр һәм читән казыклары буенча югарыга үрмәләгәннәр: ябышучан һәркайда үзенең исәпсез тамырларын җибәргән, әкренләп, ләкин ныклап казыклар буенча үзенә юл яра; читәнне астан өскә кадәр йөрәк рәвешендәге калын һәм тыгыз ятьмә белән каплый; кыргый ясминнең ак чәчәкләре бу җанлы коймада таралганнар һәм тирә-якка хуш ис тараталар иде.

Сакалбайлар үсемлекләрнең күптөрле яшеллегенә дә, чәчәкләрнең матурлыгына һәм исенә дә берничек тә игътибар бирмәделәр. Алар юан сәүдәгәр белән булган сөйләшүләрнең нәтиҗәсе турындагы уйларга бирелгәннәр иде. Йөзләренең борчулы булуыннан һәм бер-берсенең сүзен еш кына һәм ачулы өзүләреннән аларның нәрсәдер усал һәм мәкерле үк булмаса да, һәрхәлдә әдәпсезрәк эшләргә җыенганнарын чамаларга була иде.

— Аңла син, сәер кеше, игътибар ит,— дип пышылдады берсе, иптәшен ике кулыннан тотып.

— Аңлыйм, нишләп аңламаска! — дип җавап кайтарды тегесе, тик кара, егет, оттырмаска иде. Ул да бик сизгер. Аның күзләре, күргәнсендер, ничек аталар...

— Ярый, җайларбыз...

— Шулай булсын иде, билгеле...

— Әгәр бу эш барып чыкса, ул буш кул белән калачак. Сизәсеңме? Тегендә, Гурзуфның аръягында нинди бәяләр буласы әле билгесез, монда исә мәсьәлә инде ачык һәм эш кызганда пешереп калырга кирәк. Форсатны безгә Ходай үзе бирә.

— Нигә безгә өч йөзгә бу бакчаны да эләктермәскә? — диде иптәше,— икесен бергә саклап торырга да, су сибәргә дә булыр иде. Менә монда канау да бик уңайлы казылган һәм аңардан ике бакчада да файдаланырга мөмкин.

— Я, я,— дип каршы төште икенчесе,— ике куян артыннан куудан файда юк. Тор әйдә, кузгалырга кирәк, безнең юан баебыз инде татардан китеп барды.

Алар торып бастылар һәм бакчадан чыгу ягына юнәлделәр, ә бераздан теге, сәүдәгәр белән килешә алмаган татар бакчасына барып керделәр.

Тагын бер агачтан икенчесенә күчеп йөрү башланды. Татар кычкырып һәм ачуланып үзенчә нәрсәдер сөйли, юан сәүдәгәр приказчиклары белән китеп барган якка төртеп күрсәтә. Әлбәттә, ул сәүдәгәр биргән бәя турында әйтә. Сакалбайларның берсе һавалы елмаю белән аның җилкәсеннән каккалый һәм, күрәсең, кызмаска үгетли; әмма татарның ачудан иреннәре дерелди, күзләре атылып чыгардай булып торалар. Мөгаен, алар җимешләр өчен юан сәүдәгәр

тәкъдим иткән бәядән шактый түбәнне бирәләр. Сакалбайлар бәядә килешә алмыйча китеп барганда татар аларны озатырга теләмәде. Ул кечкенә генә бер алма агачының кечерәк күләгәсенә чүгәләде дә трубкасын суыра башлады.

Аның кашлары җыерылган, бүреге маңгаена кадәр төшереп киелгән. Һәр нәрсәдән аның кәефе начар булды, сату-алу буенча сөйләшүләрнең барышы белән канәгать булмавы сизелә иде. Әмма күзләре еш кына әле генә сатып алучылар киткән якка текәлә; ул аларның коймакны хәтерләткән постау картузлары кабаттан менә-менә күренерләр дип көтә иде кебек.

Бер сәгатьләп вакыт үтте. Сатып алучыларның кире әйләнеп кайтуына өметен өзеп, татар инде кәтмәнгә тотынды һәм су өчен канау казый башлады. Нияте караңгы төшү белән күрше арыктан бакчага су агызу иде. Бераздан юан сәүдәгәр белән аның егетләре кабат бакчада пәйда булдылар. Татарның йөрәге дөп-дөп тибә башлады, ул китмәнен җиргә ташлады һәм килүчеләргә таба китте. Тегеләрнең килүенә канәгать булуы күренеп тора иде, әмма сер бирмәде һәм килүчеләргә маңгай астыннан карый иде. Сәүдәгәр дә аңа шактый текәлеп карады, күпмедер ачулы да иде, монысын инде арыганлык белән аңлатып була иде. Ул иртә таңнан бирле сәүдә мәнфәгатьләре белән кайнашып кояшның яндыргыч нурлары астында йөри, шунлыктан хәзер ял итеп алу мөмкинлеге аның өчен сәүдә табышы кебек үк кадерле иде. Аның егетләре исә үзләрен бик кәефле тоталар. Гәрчә йөзләре кызарган һәм тирдән дымланган булса да, күз карашлары шулай ук җитез, борчулы һәм минут саен хуҗаларына юнәлтелгән, аның әмерләрен шунда ук һәм берсүзсез үтәргә әзер булуларын белдерә иде.

— Исәнме, дус кеше! Тагын бер мәртәбә исәнме! — дип каршылады сәүдәгәр, күзләрен татардан алмыйча һәм аның бакча өчен сораган бәясеннән бераз гына булса да чигенмәсме дигән уйга бирелеп.

Татар исә аның каршылау сүзенә берничек тә җавап бирми һәм аның сүзен дәвам итүен көтә.

— Бераз төшерергә кирәк. Ишетәсеңме... дүрттән бер өлешен кимет. Егерме биш сумга, ягъни мәсәлән.

— Минеке теләми. Биш тиен дә кимeтергә теләми.

— Димәк, берничек тә киметмисең?

— Татар татарча сөйләшә белүче приказчикка сораулы караш ташлады һәм аның тәрҗемәсендә киметү турындагы үтенечне ишеткәч, аны кире кагып башын чайкады. Сәүдәгәр кинәт башыннан картузын тартып төшерде, чукынып алды һәм кызып әйтте:

— Бер кызылга киметмисеңме? Киметмисеңмени? Ә бер зәңгәргә?

Татар кире какты.

— Я, ярый, алай булса. Синеңчә булсын. Өч йөз, димәк, шулаймы? Кәгазь язарга китәбез.

Алар чикләвеклек күләгәсенә барып утырдылар. Егетләрнең берсе каядыр йөгерде һәм бераздан кәгазь белән кара савыты тотып килеп җитте. Чикләвек агачы төбендәге эскәмия яңа вазифа алды — язу өстәленә әверелде. Сәүдәгәр үләндә утыруны уңайсыз сизеп, бер янтыгына ауды һәм сүзенә әледән-әле итләч кулының хәрәкәтен өстәп егеткә нәрсәдер әйтеп яздыра башлады. Менә ул терсәгенә таянды һәм авырлык белән генә үләннән күтәрелеп кесәсеннән акча янчыгы тартып чыгарды. Татарның бүреге артка янтайды, үз-үзен тотышы җанланып һәм күңеллеләнеп китте.

— Өч йөз күпмени? — дип кычкыра ул,— өч йөз күп түгел... Узган ел син үзең дүрт йөз биргән идең.

— Нәфесең бар икән. Хи, хи,— диде сәүдәгәр, үткән җәй үтте инде, хәзер Ходай монысын башкарып чыгарга булышсын. Кәгазь янына утыр...

— Кәгазь! Э! Кәгазь нәрсә ул! Минем кәгазем менә кайда!

Татар кулы белән йөрәгенә күрсәтте, аннары күккә карады.

— Я, я, ярый! Күккә күрсәтеп торасы юк, барыбыз да шунда булачак.

Мишутка, кәгазьдә нәрсә һәм ничек булачагын аңлат син аңа.

— Мин инде әйттем, ул беләм,— диде приказчик.

— Яхшы, беләм,— дип кушылды татар — ике йөзне хәзер бирәсең, бер йөзне соңыннан өч ай үткәч бирәсең. Шулай!

— Дөрес. Кәгазьгә үз имзаңны куй.

Татар эскәмия янына килде, җайсыз гына иелде, тезенә таянды һәм ике кулын да сәүдәгәргә сузды:

— Ике йөзне бир...

— Ә-ә! Яратасың, димәк... Акча — яхшы,— дип көлеп җибәрде сәүдәгәр.

— Яхшы, әлбәттә, бакча яхшы: алма, груша, фундук — төрле җимешләр.

— Акчаны алгач ул кәгазьгә татарча нәрсәдер яза башлады. Кояшта янган һәм җыерчыклы маңгае тагын да ныграк җыерчыкланды, иреннәре кысылды һәм сулышы туктагандай булды.

— Уф, Алла! — дип авыр сулап алды ул, гадәти булмаган эшне, ниһаять, бөтереп һәм шунда ук җиргә утырды,— син, дус кеше, хәзер әйт инде, күрше бакчасы өчен күпме бирдең? Икенче бакчаны сатып алдыңмы?

— Алабыз, алабыз,— диде сәүдәгәр,— Ходайның ачуын китермик, әкренләп сатып алабыз. Мин әле, дус кеше, мисалга әйтсәк, Гурзуф ягына барып чыгарга телим. Ходай бирсә, бәлки анда да әле берәр бакчаны эләктереп булыр.

Татар, күрәсең, нәрсә турында сүз барганын аңламады һәм башы белән күрше бакчага ишарәләп үзенекен дәвам итте:

— Күпме бирдең? Ә? Сатып алдыңмы?

— Алдым,— диде сәүдәгәр, ләкин ярты сүздә тотлыкты.

III

Өч көннән соң шул ук бакчада һәм татар карты үз бакчасын арендага бирү турында симез сәүдәгәр белән килешү төзегән шул ук чикләвек агачлары күләгәсендә бу сәүдәгәр белән аның ике компаньоны утыра иде. Бу юлы бакчада татар юк иде, сәүдәгәрнең егетләре дә хуҗа янында бөтерелмиләр, читтәрәк, агачлар артына яшеренеп торалар иде. Аларның икесенең дә күңеле төшенке иде һәм хуҗаның ачулы тавышына борчылып колак салалар иде. Сак кына агачлар артыннан чыгып һәм хуҗалары ике сакалбай белән утырган якка карангалап, алар җилкәләрен селкетеп авыр сулап, «эшнең хөрти» булуы турында үзара сүз әйтешеп алалар.

Сәүдәгәрнең хәзер инде үзенең мөстәкыйль халәтен һәм башкаларга өстән карау хокукын аңлаган кеше кыяфәтендә элеккечә тыныч кына үлән өстендә ятмавыннан, бәлки бөгелеп утыруыннан, зур һәм авыр гәүдәсен тигез тотар өчен сул кулы терсәге белән җиргә таянуыннан да эшнең чыннан да шәптән түгел икәнен чамаларга мөмкин иде. Сәүдәгәр алдында яткан кәгазьгә уң кулы белән төртеп күрсәтә-күрсәтә сакалбайларга нәрсәдер сөйли, тауга йөк өстерәп меңгән кебек авыр сулый иде. Сакалбайлар да аның кебек үк кычкырып сөйлиләр, әмма алар алдында бернинди дә кәгазь юк иде. Вакыт белән алар өчесе берьюлы сөйлиләр. Сәүдәгәр әле ачуланып каш җыера, әле кинәт кенә үзенең картузына тотына һәм аны, үзенең рухи халәте бозылуда төп гаепле итеп санагандай, ачыргаланып үләнгә ташлый. Ике сакалбай, аңа игътибар итмичә үзара бәхәсләшә һәм сәүдәгәр белән үзара мөнәсәбәтләрендә аңлашылмаучылык килеп чыгуда бер-берсен гаепләп кычкырыша башлагач, сәүдәгәр хәлдән калган кешедәй, башын чайкады.

— Әгәр син булмасаң,— дип кычкырды сакалбайларның берсе,— мин мондый мәгънәсез эшкә катнашып торыр идеммени? Моның урынына мин бер үзем тыныч кына, беркем белән дә бәйләнмичә бер-ике бакчаны әмәлләгән булыр идем.

— Моны син әйтергә тиеш түгел,— диде тагын да кычкырыбрак икенчесе, юри сәүдәгәрнең сүзләренә игътибар итмичә.— Мин бары синең арка-

да гына бу эшкә кереп буталмадыммени?.. Син хет шартла, әмма мин бернинди ташламаны да белергә теләмим, киресенчә, әгәр бакча минем исемгә арендага алынса, ул минеке булачак дигән караштa торачакмын.

Сәүдәгәр картузына тотынды, аны маңгаена кадәр батырып киде һәм сакалбайлар бары аның белән аңлашудан качу өчен генә үзара кычкырышалар дип уйлап, күрәсең, аякка баса башлаган иде, әмма бәхәстә катнашмыйча кала алмады.

— Сез нәрсә минем башымны катырасыз,— дип карлыккан тавыш белән кычкырды ул.— Әллә мин сезнең хәзер нәрсәгә ниятләгәнегезне күрмимме? Бер сүз белән әйткәндә, намуслы эш итмисез. Бөтен сатып алынган бакчаларны бергәләп бүлү турында мин әйтмәдеммени? Моны хәзер ничек атарга? Нинди махинация булып чыга бу?

Сакалбайлар җавап урынына әлеге яшерен килешүнең бөтен көче сатып алганда бер-берeңне яклаудан гыйбарәт һәм кем нәрсә сатып алса, ул шуның белән канәгатьләнергә тиеш дип сөйли башладылар.

— Ә бит мин бик азга гына, барысы мең дә өч йөзгә генә сатып алдым,— дип дәвам итте сәүдәгәр,— ә сез тулы бер бит меңгә эләктергәнсез. Кайда гаделлек? Бит сез үзегез ятимнәр булып кыландыгыз, ә хәзер кулларыгызга шул кадәр байлыкны эләктергәнсез. Шулай намуслы буламы? Пычранасы гына килми, югыйсә суд ярдәмендә хәл итеп булыр иде...

— Монысы берничек тә мөмкин түгел...

— Ничек мөмкин түгел? Монда пристав бар...

— Ул безнең өчен беркем дә түгел. Әгәр кирәк булса, чакырыгыз приставны, без аның алдында да үз эшебездә акланабыз, чөнки без бакчаларны арендага намус кушканча алдык, акчасын да бирдек һәм бөтенесе закон буенча. Пристав безнең өчен мөһим нәрсә түгел.

— Э, нигә монда юкны бушка аударып торырга,— дип кул селтәде сәүдәгәр,— әллә сез чынлап та мин сезнең белән тарткалашыр дип уйлыйсызмы? Мин андый кеше түгел, аннан соң минем монда вакытым да юк. Юкка гына вакытымны әрәм итәм...

Бары ул кәгазьне кулга эләктереп һәм ашыгып сюртук кесәсенә тыгып аякка баскач кына аның егетләре хуҗаның дәһшәтле карашы каршына басарга вакыт дигән фикергә килделәр һәм агачлар артыннан чыктылар.

— Менә нинди халык, ә? — дип елмайды ул, үзенең соравын тегеләргә юнәлтеп.

— Әйе-е... шулай дөрес... без бит монда эш намуссыз хәл ителмәсен өчен килдек тә...

— Алдадылар... Я, ярый, Ходай үзе карасын. Эш әле алда — торна да күктә. Тик менә күрше бакча гына кызганыч, борын астыннан тартып алдылар... Ну, килде заманнар!

Ул бакча капкасына таба китте: анда пар ат җигелгән почта тарантайкасы тора иде. Анда юлда барганда селкетүне бераз киметү өчен сетка рәвешендә бау белән бәйләнгән пассажир урынына кызыл комач тышлы зур мендәр куелган иде. Сәүдәгәр егетләре ярдәмендә көчкә генә таратайкага менде һәм зур гәүдәсе белән баудан ясалган сетканың дүрттән өч өлешен алды, ә калган урынны егетләренең берсенә бирде һәм тегесе ул урынга сыяр-сыймас кына утырды.

— Ходай ярдәме белән кузгалыйк... Әй, юк, аз гына көт!

— Күпме көтәргә була, я Ходa! — дип сукранып алды ямщик,— көтәм дә көтәм... Моның өчен бездән түләтәләр бит.

— Я, ярар... Тиешлесен миннән алырсың әле. Мишутка ишетәсеңме? — дип борчылып мөрәҗәгать итте сәүдәгәр монда калучы егеткә: — син, ягъни мәсәлән, кара аны, йоклап йөрмә... Ходайның безгә күршелеккә кемнәрне җибәргәнен үзең күрәсең, уяу бул, ишетәсеңме?

— Туктагыз әле, ничек аңламаска, нәрсәгә омтылганнары әллә каян күренеп тора.

— Я, я, сөйләп әле, ахмак! — диде үпкәле тавыш белән сәүдәгәр,— нинди әллә каян ул! Мин, беләсең, синнән өлкәнрәк һәм синнән күбрәк беләм — шуңа күрә дәшмә! Ящикләргә килгәндә,— диде әле генә акылга утыртылган егеткә,— ящикләрне, димәк, җимешләр өчен дә, черешня өчен дә җибәрермен, эшләргә мужик та җибәрермен. Я, кузгалдык! — диде ул һәм картузын салып чукынып алды.

Таратайканың бер кырына сыенган егет тә чукынып алды һәм ике ябык та, артларыннан тузан болытлары калдырып, шоссе буенча китеп барды.

Сәүдәгәр таратайкага утырып егетенә хуҗа күрсәтмәләрен биргәндә, аның кечкенә компаньоннары — сакалбайлар бакчада иделәр һәм сакалларын тотып көлешәләр иде. Таратайка, ниһаять, күрше бакча почмагыннан күренмәс булгач һәм монда калган егет алар янына килгәч, тегеләре аны кычкырып көлеп каршыладылар.

— Бакча сездән очтымы, ә?

— Шулай булды ахры...

— Һа, һа! Ә бит югалту кечкенә түгел — без сезне мең ярымга утырттык.

— Күрербез әле: уңыш өлгергәч, күләме дә ачыкланыр...

— Әйе, табыш булачак; күрәсеңдер, сезнең мыегыгыздан акты, ә авызыгызга кермәде. Картыгыз инде эш барып чыкты дип исәпләп үләндә ата мәчедәй күзләрен кыскалап йокымсырап ята иде. Менә йокымсырап авызын ачып та калды, һа, һа, һа!

— Монысы миңа карамый,— дип читләтеп җавап бирде приказчик.

— Хәзер инде ничек кенә әйтмә, сиңа карыймы-карамыймы, ә сезнең барыгыз да йоклап калуыгыз ап-ачык...

Сакалбайлар кулларын баш артына куеп үләндә ауныйлар һәм мыскыллап сәүдәгәр приказчигына карыйлар, приказчик та үз чиратында аларга нәфрәтен көчкә яшереп күз сала иде.

— Сезгә көләрлек нәрсә күренми әле,— диде ул,— үз өстегездән көлсәгез генә инде; һәм ул бик урынлы булыр иде. Чыннан да шулай. Мисал өчен эш намус белән түгел, ә аны читләтеп алып барылса, менә бу чыннан да көлке!

Намус турында син теге,— диде түбәнсетеп сакалбайларның берсе,— бик ашыкма. Аның нәрсә икәнен без дә ярыйсы гына аңлыйбыз.

— Бер дә күренми әле. Хәтта бөтенләй киресенчә килеп чыга.

— Ну, бу хакта сүз куерту да синең эшең түгел... Сезнең юан баегыз утыз еллап инде җимеш сату белән шөгыльләнәдер, шуннан әнә ничек юанаеп китте. Без исә, Ходай уң күрсен, әле башлыйбыз гына, безнең йокларга вакытыбыз юк.

— Әгәр эшегезне шулай каракларча башлыйсыз икән, алга таба сездән берниндиди яхшылык та көтәргә ярамый.

— Ничек каракларча? Ничек син шундый сүзләр әйтергә җөрьәт итәсең!

— Әлбәттә, каракларча, мин аңламыйммы әллә?

— Тыныч кына сөйләшү кинәт кычкырышуга күчте.

— Сез әле бик масаймагыз! — дип кычкырды приказчик сәүдәгәргә.— Дәшмәгәч, сез мине бик басынкы дип уйлыйсызмы әллә? Ялгышасыз, мин сез уйлаганча түгел. Кара аны, кеше бакчасында ничек хуҗаларча җәелеп ятканнар! Ялкаулар сез, сәүдә кешеләре түгел, сезнең белән бәйләнгән татар да ахмак.

— Сакаллылар сугышырга әзерләнеп урыннарыннан сикереп тордылар; аларның йөзләре усалланды һәм куллары йодрыкланды. Сәүдәгәр приказчигы, сугыш була калганда ике кешегә каршы торырга туры киләчәген күрсә дә, куркып калмады, тегеләрнең ачуын кабартырдай позага басты һәм кирәк чыкса дип ныграк казык эзләп тиз генә тирә-юньгә күз салды. Ике яктан да бер-берсен мыскыллап тагын берничә сүз әйтелде, аннары чып-чынлап

тиргәшү башланды, әмма шулай да эш сугышуга барып җитмәде һәм ызгыш бер-берсенә дошман якларның төрле бакчаларга таралулары белән тәмамланды.

IV

Кичкә таба сәүдәгәр татар картыннан арендага алган кечкенә бакча күршесендәге зур җиләк-җимеш бакчасында гаять зур чикләвек агачы ботаклары астында келәмнәр җәелгән иде. Аларда китеп барган сәүдәгәрнең кичәге компаньоннары булган ике сакалбай һәм көнчыгышлылар тибындагы берничә шикле бәндә ятып тора иде. Алар янында шәраб шешәләре, ашамлык салынган тәрилкәләр һәм чәй эчү өчен кирәкле савыт-саба тезелгән. Читән янында кояшта янган һәм юынмаган яшь кенә татар үсмере инде өченче тапкыр самавыр кайната. Тагын да читтәрәк аның яшендәге берничә үсмер таптанып тора һәм бер-берсе белән нәрсәдер пышылдаша. Җәелеп үскән төче чия астында аның гаять юан кәүсәсенә сөялеп, зур карчыга борынлы кара кучкыл һәм ябык чегән, әле келәмнәрдә яткан сакалбайларга, әле аларның әңгәмәдәшләренә карый-карый скрипкасын рәхимсез игәүли. Яланаяклы ике йолкыш чегән малае скрипкачы алдында биегән булып кыланалар. Әледән-әле алар чинап алалар, үтә арык кулларын тырпайган чәчләренең өстенә күтәрәләр һәм шулай ук шешәләр тирәсендә утыручыларга күз агы белән карап-карап алалар.

Бакча хуҗасы, 40 яшьләр тирәсендәге озын буйлы, ябык, кара кучкыл йөзле татар, бакча капкасы янындагы алачык ниргәсендә утыра һәм бакчаның яңа вакытлы хуҗаларына игътибар итмичә уйланып трубкасын суыра иде. Бу көннән көз ахырына кадәр, ягъни җимешләрне җыеп бетергәнче бакча яңа хуҗалар карамагына күчә. Аның җилкәсе артында башларына кызыл төрек фескасы кигән ике кечкенә улы кайнаша һәм чегән балалары битенә кызыксынып карый иде. Сирәк-мирәк алар татарның каралган уйчан йөзенә карап һәм, күрәсең, аңардан нәрсәдер сорап сөйләштергәләделәр, әмма тегесе озаклап берни дә әйтмәде, ә бер-ике тапкыр хәтта аларны җикеренеп куркытты да, шул вакытта алар алачык эченә кереп качтылар: анда җир идәндә көрәкләр, китмәннәр һәм башка бакча кирәк-яраклары куелган иде.

Ике сакалбай сатып-алу эшләренең уңышлы нәтиҗәсен бәйрәм итә иде. Алар алдында торган шешәләр инде шактый дәрәҗәдә бушатылган; келәм янында бер-икесе бөтенләй буш иде. Бәйрәм итүчеләрнең йөзенә караганда, бигрәк тә чегән балаларының чинавына җавап биргәндәй әледән-әле кыргыйларча кычкырулары буенча бәйрәм итү үзенең иң югары ноктасына җиткән дигән нәтиҗә ясарга була иде.

— Таныш кеше, кил әле монда! — дип кычкырдылар сакалбайлар, алачык ягына исерек караш ташлап,— тагын чәй эч... Аракы да сал, зинһар...

— Минеке чәй эчте, рәхмәт. Минеке аракы теләми — закон кушмый! — дип кычкырды татар, ике кулы белән дә кире кагып.

Күренә ки, ул инде баштарак бу бәйрәмдә катнашырга чакырылган булган, әмма үз вакытында алачык янына китү ягын караган.

Урамда, бакча капкасы янында, ике ат җигелгән коляска тора иде. Кузлада утырган татар бөтенесенә битараф кыяфәттә чыбыркысы белән итегенә суккалый һәм нәзек тавышы белән ниндидер җырны әкрен генә көйли иде. Атлары аның, җигелеп торудан туеп, башларын боек кына иеп йокымсырыйлар. Бәйрәм итүче коммерсантларның күңелле компаниясе алпан-тилпән килеп, ниһаять, бакчадан чыгу тарафына кузгалганда кояш инде таулар сыртына якынлашкан һәм аның якты нурлары биек чикләвек агачларының көдрә башларын гына алтын төсенә кертеп яктырталар иде. Скрипкачы чегән үзенең скрипкасын элеккечә ярсып игәүләвен дәвам итте, ә чегән балалары чиный-чиный биеп аның алдыннан бардылар. Сакаллылар көч-хәл белән генә ко-

ляскага менеп аудылар һәм башка бәйрәм итүчеләрнең дә алар янына утыруларын таләп иттеләр. Юлдашлары, борыннары белән бер-берсенә төртелеп, экипажның бөтенесен дә сыйдыра алмавын, атларның да бу кадәр йөкне чаптырып алып бара алмауларын һәм, ниһаять, извозчикның моңа килешмәгәнен аңлатырга тырыштылар.

— Син килешмисеңме? — дип усалланып кычкырдылар сакаллылар.

— Туктагыз әле, сәүдәгәр әфәнделәр, шулай мөмкинме? Мондый авырлыкны экипаж күтәрә алмый.

— Без бөтенесе өчен дә түлибез. Скрипачны чегән балалары белән кузлага утырт, ә сез, агай-эне, ике яклап утырыгыз.

— Сәүдәгәр әфәнделәр, кичерегез! — дип үтенде извозчик,— монысы мөмкин түгел. Коляска өч йөз сум тора...

— Барысы өчен дә түлибез.

Көч-хәл белән, ниһаять, эш җайлана башлады. Скрипач кучер янына кузлага утырды һәм күңелле музыканы башларга теләп скрипкасының кылларын тарткалады, ә калган компания йолкыш чегән балалары артыннан коляскага ияреп җәяү барырга җыенган гына иде, кинәт сакаллылар үзләренең яңа дошманын искә төшереп коляскадан төштеләр. Каралган кулларын йодрыклап һәм аның хуҗасы арендага алган бакчага исерекләрчә кыргыйланып карап, әле берьюлы, әле аерым-аерым, берсе артыннан икенчесе, дошманнары күренмәгәнгә, аның белән ызгышкан бакчага үзләренең әр сүзләрен кычкырып белдерә башладылар.

— Ю-у-ук! Тукта әле, шайтан алгыры тукта, әйе! Эчмим, дисеңме, эчәрсең! Без әле синең муеныңа тутырып салырбыз, шулай.

— Ә мин сине, башкисәр, бер үзем шулай бөгәрмен ки, сөякләреңне дә җыя алмассың. Син үзеңне сәүдәгәр приказчигы, ә без сату-алу итүче мещаннар дип уйлыйсың, җен дә сиңа туган була алмый... Ю-ук, сиңа аның туганы булырга ерак әле!..

Ызгыш көчәя бару белән аларда күзгә күренмәгән дошманга нәфрәт хисе һәм аңардан хәзер үк үч алу теләге дә үсте. Шул максатта алар үзләрен озатып килгән компаниянең дә, сәүдәгәр приказчигын эзләп табу һәм аның белән «исәп-хисап ясау» өчен, күрше татар бакчасына баруын таләп итә башладылар. Әмма көнчыгыш кешесен хәтерләткән затлар, үтә шикле кыяфәттә булуларына һәм аякларында көчкә басып торуларына карамастан, акылларын бөтенләй җуймаганнар иде һәм сакалбайларны «исәп-хисап ясауны» киләсе көнгә калдырырга үгетли башладылар. Акылын саклап калган киңәшчеләрнең берсе, кызыл яңакларының артык шешенгән булуы һәм куркынган бәрән күзләрен хәтерләткән кабарынкы күзләре белән аерылып торганы, кузлада утырган скрипачка тиз генә күз кысып аның күңелле музыкасын дәвам иттерә алды.

— Тизрәк! Тизрәк! — дип, ул скрипка авазларына ияреп симез кулларын чегән балалары ягына селтәп җибәрде һәм үзенең авыр гәүдәсе булдыра алган кадәр җитезлек белән биеп китте.

Аның рухландыргыч үрнәген күреп, чегән балалары яңадан бөтерелеп биергә тотындылар һәм исерек сакалбайлар, моңа бирелеп карап, ничектер үзләренең дошманлык ниятләреннән аерылып тордылар.

— Типтер, типтер, кызый!.. И-их! — дип тагын кампаниядән кемдер, чегән балалары кебек үк, кулларын күтәреп болгый-болгый биеп китте.

Акыллы киңәшчеләрнең юаны, сакалбайларның исерек башларында күзгә күренмәгән приказчикка кабат ачу кабару мөмкинлеген дөрес чамалап, тегеләрне экипажга утырырга үгетли башлады.

— Трактирга барабыз, йөрәк маем! Без анда рәхәтләнеп күңел ачарбыз! У-у!.. Утыр, йөрәк маем! Анда шашлык әйбәт, рәхәт-лукум, кишмиш, теләсәң, кызыл шәраб, теләсәң, ак шәраб, буза бар... У-у!

Ул көчкә-көчкә сакалбайларны трактирдагы күңел ачу мөмкинлекләре

белән кызыктыра алды. Алар зур кулларын җәеп салып коляскага менеп яттылар һәм әледән-әле кычкырындылар:

— Чегән, башла!

Кара йөзле татар, бакча хуҗасы, озак кына капка янында басып торды һәм китеп баручы компания артыннан күзәтте. Аның балалары шунда ук бушалдылар һәм үзара нәрсә турындадыр бәхәсләштеләр. Алар бәхәснең озакка сузылуын, берсенең күз төбендә инде күгәргән урын барлыкка килгәнен һәм икесенең дә кызыл фәслүл җирдә аунап ятканын күрми-сизми иделәр. Әтиләре аларны шундый сугышчан кыяфәттә күргәч, тиз генә ачуланып нәрсәдер кычкырды. Малайлар кечкенә пычрак йодрыклары белән күзләрен сөртә-сөртә һәм елак тавыш белән аклана башладылар. Ерактарак кичке тын һавада әле һаман скрипка авазлары һәм биеп баручы чегән балаларының тавышлары ишетелә иде.

Юан сәүдәгәр арендага алган күрше бакчадан татар карты килеп чыкты һәм алар иңбашларын селкетеп һәм бәйрәм итүче коммерсантлар компаниясе китеп барган якка күз ташлый-ташлый нәрсәдер турында сөйләшә башладылар. Сүзнең нәкъ менә шулар турында барганы ачык иде. Бу сөйләшүне рус теленә күчергәндә, якынча менә нәрсә хасил була иде:

— Яңа сәүдәгәрләрме? — дип сорады карт.

— Юк, яңалары түгел. Узган ел алар инде килгәннәр иде, сатып алырга, ләкин алмадылар. Судакка киттеләр, анда алганнар...

— Әйбәт кешеме?

— Үзең күрдең...

— Шул, шул. Күп эчә, кычкырына — ничек әйбәт булсын!..

— Әйе!..— дип көрсенеп алды кара йөзлесе,— бик тә әйбәт түгел! Менә карыйм, карыйм — күңел тыныч түгел...

— Задашкага күпме алдың? Яртысынмы?

— Яртысыннан күбрәген алдым.

— Калганын кайчан?

— Җимешләрне җыеп бетергәч.

— Алай булса, нигә куркырга? Акча бирсә, җимешен алыр, бирмәсә, уңышны җыярга бирмә.

— Эх,— канәгатьсезлек белән кул селтәде кара йөзлесе,— ыгы-зыгы китәчәк, кычкырыначак... Яратмыйм мин моны!..

— Бәлки әле ыгы-зыгысыз хәл ителер...

— Ходай кушсын...

Кара йөзлесе балаларга карап алды һәм аяк типте.

— Тагын нәрсә маташасыз анда,— дип кычкырды ул, малайларның ыштан кесәләренә комны шыплап тутыруларын күреп,— бөтенесен кире бушатыгыз, ишетәсезме? Ах, сез наяннар!

Авыл тормышының тыныч тынлыгын бозган күңел ачучы компаниянең шау-шуы беткәндә инде ныклап караңгы төшкән иде. Әмма бер урында бетеп, шау-шу икенче урында дәвам итте: базардагы трактир янында арыган извозчик атлары таң атканчыга кадәр диярлек йокымсырап тордылар. Извозчик үзе коляскадагы мендәрләргә җәелеп ятып йоклады, ә трактирдан ябык тәрәзәләр аша скрипка авазлары ишетелә иде, әмма алар инде шактый көчсезләнгәннәр, сакалбайларның таныш тавышлары да шулай ук шактый карлыккан иде.

— Җибәр безнең исәпкә! Бөтен көчкә җибәр! — барысы өчен дә түлибез!

Урысчадан **ТӘНЗИЛӘ МУСИНА** тәрҗемә итте.
Текстны журналга академик **НАИЛ ВӘЛИЕВ** әзерләде.

ҖЕН КЫЗЫ ГӨЛБАНУ*

Борын заманда була бу хәл. Сөләйман пәйгамбәр үзе үлгән вакытта мөселман җен патшасын чакырта да әйтә:

— Мин үлгәч, берничә елдан соң дөньяга берәү туар. Үсеп җитеп, шул бәндә патшалык итәр. Шуңарга миннән бүләк итеп менә шушыларны бирерсең,— дип, бер ат, бер тун бирә.

Пәйгамбәр әйткәнчә, чыннан да берәү дөньяга килә. Әкияттәге гомер бит яшен тизлеге белән үтә. Бу да, үсеп җитеп, патша була. Теге җен Сөләйман пәйгамбәрнең бүләкләрен китереп тапшыра моңа.

Ярар. Патша булгач, вәзире дә була инде; вәзирнең дә, патшаның да малайлары туа. Ике малай бик дус булып үсәләр. Патша үз малаен ничек тәрбияләсә, вәзир малаен да шулай тәрбияли.

Бу малайлар бик тиз үсеп, унсигез яшькә җитәләр. Патша бу егетләрне Сөләйман пәйгамбәр калдырган бүләкләр белән бүләклисе килә.

— Кайсысын кайсысына бирик икән?— дип, хатыны белән киңәшә.

— Әгәр дә атны үзебезнең малайга бирсәк, вәзир малае кимсенер инде,— ди.

Хатыны әйтә:

— Үз балабызны ничек тә көйләрбез, атны вәзир малаена бирик,— ди.

Шулай итеп, атны вәзир малаена, ә тунны үз малайларына бирәләр.

Болар тунның кесәсенә тыгылып карамаган булганнар. Бу егет тыгылып караса, аннан бер мөһер һәм бер кызның фотокарточкасы килеп чыккан. Егет фотога карап бик гашыйк булган. Бу егет көннән-көн саргая икән. Атасы-анасы да тун кесәләрен карамаганга үкенеп беталмыйлар икән.

Бер көнне атасына әйтә бу:

— Әти, миңа рөхсәт бирегез, мин йөреп, әйләнеп кайтам,— ди.

Атасы җибәрсә дә, аптырый; җибәрмәсә дә, җәлли — җибәрергә булалар.

Вәзир малае әйтә:

— Мин иптәшемнән калмыйм, үлсәк бергә үләрбез,— ди.

Атасы боларга гаскәр бирә дә, болар корабль белән суда баралар.

Берничә көн барганнан соң, көчле давыл чыгып, корабльне әйләндереп каплый. Бар да су астына китәләр. Ничектер патша малае өстә кала. Суда йөзәйөзә бик арый. Су да бик киң, яр да ерак, шулай азапланып йөзә торгач, судан өскә чыгып торган бер карагайны күрә. Шунда йөзеп бара да, ул судан өскә чыгып торган бер таш була, шул таш өстенә утырып хәл җыя.

Бервакыт моның янына зур кара кош килә, моңарга һөҗүм ясамакчы була. Бу егет куллары белән селтәнгәләп байтак утырганнан соң, бер уйга килә: «Ул миңа һөҗүм иткәнче, мин үзем аңарга асылыныйм»,— ди. Теге кош моны эләктерим дигәндә, кошның тәпиләренә үзе асылына бу. Кош моны су өстеннән ярга таба алып оча. Яр да бик ерак калмады — кош та арыды, түбәнәйгәннән-түбәнәя. Хәзер бу егет яртылаш суда бара. Яр якынлаша башлагач, кулын ычкындыра да, кош күтәрелеп китә. Кош, яр башына кунып, егетнең чыкканын көтеп тора, егет тә судан чыкмыйча тора. Теге кош көтәкөтә дә очып китә. Егет тә, судан чыгып, яр буйлап китә.

Бара-бара урманга барып җитә егет. Урманга керсә, урман уртасында бер өй күрә, анда барып керсә, бер кыз елап утыра, ди. Бу кыз моңарга:

— Абзый кеше, син моннан тизрәк кит, диюнең хәзер кайтыр вакыты җитә, икебезне дә харап итәр,— ди.

Егет әйтә:

— Ул үзенең җаны кайда икәнен әйткәне булмадымы?— ди.

Кыз әйтә:

— Су төбендә — сандык, сандык эчендә — күгәрчен, шул күгәрчен — аның

---

* Сәйдә әби язып җибәргән икенче әкият. Бу турыда кара: «Мирас», 1996, № 10. 2 — Әбкәм әкият сөйләгән...

җаны,— ди.— Аны алыр өчен Сөләйман пәйгамбәрнең мөһере кирәк,— ди.

Егет үзе белән мөһерне дә алып килгән була. Әйдә киттек,— дип, кыз белән су буена китәләр.

— Сөләйман пәйгамбәрнең хакы хөрмәтенә су астыннан сандык чыкса иде,— дигәч, су ярыла да, сандык килеп чыга; сандык ачылуга, күгәрчен килеп чыга. Шул араны дию дә килеп җитә:

— Теләсәгез нишләгез — җаныма гына тимәгез! — дип ялынса да, күгәрченнең муенын борып ташлыйлар да, дию шунда ук егылып үлә.

Өйгә кереп хәлләрне сөйләп бетергәч, егет фотокарточканы күрсәтә. Кыз әйтә:

— Бу бит — минем дустым Гөлбану, мөселман җен патшасының кызы! — ди.

Егет әйтә:

— Син адәм затыннан булгач, ничек соң син җен кызы белән дус булдың? — ди.

Теге кыз сөйләп бирә:

— Җеннәр бит алар кояш баегач йөри торган булалар. Гөлбануны күтәреп, әнисе безнең тирәгә килгән дә, баласын калдырып, каядыр киткән икән. Гөлбануның бик елавына минем әни чыгып, җәлләп имезгән моны. Әнисе, килгәч, ачуланган, нигә имездең дип. Сөтне сөт белән кайтарам дип, аның әнисе мине имезгән. Шуннан без дус булып бергә йөрдек. Бервакыт бакчада күңел ачып йөргән вакытта Гөлбану үзен яшереп өлгерә алды, ә мине дию алып китте,— ди.

Шуннан соң егет белән кыз бу өйдән чыгып китәләр. Урман эче белән озак барганлыктан, боларның киемнәре дә ертылып беткән, ди. Кыз оялмасын диптер инде, егет әйтә:

— Мин синең туган абзаң булам, син минем туган сеңлем бул, икебездә күңел каралыгы булмасын,— ди.

Бара торгач, бер ачыклыкка барып чыкканнар. Ерак түгел юл күренгән. Юлдан кәрванчылар киләләр, ди. Бу егет ерактан кул белән ишарәләп сораган: «Сез мөселманмы?» — дип. Әлек заманда шулай сорый торган булганнар. Тегеләр мөселман дип ишарәләгәннәр. Бу егет алар янына барып, хәлне сөйләп биргәч:

— Безне дә үзегез белән алыгыз әле,— ди.

Тегеләр:

— Әйдә,— диләр.

Егет әйтә:

— Мин үзем генә түгел, сеңелем дә бар,— ди.

— Аны да алып кил,— диләр.

Егет килеп аны да алып бара. Сөйләшә торгач, бу кызга әйтәләр:

— Синең атаң белән бер туган абзаң безнең шәһәрнең башлыгы булып тора. Нишлик, кире борылыйкмы?— диләр.

Ничә көннәр килгәннәр, тагы шуның хәтле барасы бар икән. Егет әйтә:

— Вакытсыз чәчкә дә атмый, барасы җирегезгә барып җитик, аннан соң да өлгерербез,— ди.

Кәрванчыларның кәсепләре бик уңа. Боларны да тәрбиялиләр, киендерәләр.

Кайткан вакытларында араларыннан берсен патшага сөенчегә җибәрәләр. Патша аны сөенчесе өчен бер зур шәһәргә баш итеп куя. Бу егетне патша үз урынына патша итә.

Патша итеп куйгач, егет аларда тора бит инде. Кызның әнисе аптырый боларга: урынны бергә җәяргәме, аерыммы? — Шулхәтле озак гомерләр бергә булгач, бергәдер инде,— дип, кыз әйтә:

— Әни, күңелегезгә шик китермәгез, ул мине үз сеңлесеннән дә артык саклап алып кайтты. Аның күңеле миндә түгел, Гөлбанудa, аны эзләп йөреп миңа юлыкты ул,— ди. Кояш баткач, җеннәр килеп йөри башлый. Кызның әнисе женнәргә әйтә:

— Гөлбану килсен, Гөлҗамалны табып кайттылар,— ди.

Гөлбану әбисе белән килә. Гөлҗамал белән елашып күрешәләр. Гөлҗамал шундук бик күңелсезләнә. Гөлбану сорый:

— Сиңа ни булды, күңелсезләндең?— ди.

— Әй, дустым, минем антым бар бит. Мине коткарган егет сине эзләп йөреп, мине коткарды. Синең белән кавыштырам дип, вәгъдә бирдем.

— Юк, дустым, мин адәми затка бармыйм,— ди Гөлбану.

Шуннан соң Гөлҗамал тагы да күңелсезләнеп, еларга тотына. Гөлбану чыгып китә.

Тәрәзәләрдән карап йөргәндә, Гөлбану яшь патшаны күрә, егетнең инде вәзирләр белән сөйләшеп утыруы була. Егет тә, тәрәзәдәге шәүләне күреп калып, чыгып китә. Анда чыкса, пәрәнҗә ябынган бер кыз басып тора, ди. Егет бара да пәрәнҗәне ачып карый. Теге кыз әйтә:

— Әй, вөҗдансыз егет, нигә минем рөхсәтемнән башка ачып карыйсың?— ди.

Егет әйтә:

— Мин ни нужалар күреп сине эзләп килдем дә, син битеңне ачып карарга да рөхсәт итмисең,— ди.

Кыз әйтә:

— Ярый, безнең сөйләшкәнне беркем дә күрмәсен,— ди дә йөгереп кереп китә.

Керсә, Гөлҗамалның һаман елавы була.

— Ярар, дустым, елама инде, син дигәнчә булыр, ул егет үземә дә бик ошады,— ди.

Шуннан соң барысы да бергә җыелышып киңәш итәләр. Киңәштән соң барысы да Гөлбанулар белән китәләр кыз сорарга.

Кайтып кергәч, карчык картына әйтә:

— Карт,— ди,— Гөлҗамалны табып кайткан егет хәзер ул патша икән, шул безнең Гөлбануны сорый. Бирсәк ничек булыр икән?— ди.

Карт әйтә:

— Бик яхшы булыр,— ди.

Шуннан соң, бар да бергә җыелышып, Гөлбануның әтисенә китәләр. Боларга серне чишәләр. Атасы якын да килми:

— Мин кызымны адәми затка бирмим,— ди.

Җыйнаулашып ялына торгач, чыдый алмый — риза була.

Шуннан соң бик шәп кенә туй итәләр инде, пәри туе булса да. Кыз белән бергә патшалыгын да бирә атасы. Хәзер бу яшь кенә кешегә ике урында патша булырга туры килә.

Шуннан соң күпме гомер узгандыр — анысы билгесез. Бервакыт яшь патшаның вәзирләр белән бергә күңел ачып сәхрәдә, урманнарда йөрисе килә. Мылтык алып ауга чыгып китәләр. Киткән чакта боларның ишек төбендә сәләмә генә киенгән бер хәерче басып тора икән. Патша өйдәгеләрне дәшеп чыгарып:

— Менә шушы хәерчене ашатыгыз, өстенә кием бирегез,— дип, китеп бара.

Күңел ачып бик озак йөргәннән соң, кайталар. Кайткач сорый патша:

— Теге кешене ашаттыгызмы, ул кая китте?— ди.

— Китмәде әле, ул монда,— диләр.

— Китерегез минем янга,— ди.

Патша моңардан сораша — теге кеше бәйнәләп сөйләп бирә, каян килгәнен, кем булганын:

— Иптәшемне эзләп йөрим, ди. Сәяхәткә китеп бәлагә юлыктык та бер-беребезнең исәнме-юкмы икәнен дә белмибез,— ди.— Мин — вәзир малае идем, ул — патша малае иде. Исәндерме-юктырмы, мин аны эзләп йөрим,— ди.

Паша әйтә:

— Эзләсең дә, син аны табалмассың инде,— ди.

Теге әйтә:

— Табалмасам да, мин аның юлында үләрмен инде,— ди.

Патша:

— Син эзләгән кеше мин түгел микән, кара әле яхшылап,— ди.

Теге күрә дә һуштан язып егыла. Байтак ятканнан соң, аңына килеп, тора. Бер туйганчы кочаклашалар, елашар. Бернигә карамыйча, өч көн гүләйт итәләр. Аннары Гөлҗамалны аңарга кияүгә биреп, бөтен халыкны җыеп, туй итәләр. Мондагы патшалыгын да бирә дустына. Үзе хатыны ягына китә.

Ике дус ике патша булып, һаман яшиләр, ди әле.

Текстны журналга филология фәннәре
кандидаты **ЛЕНАР ҖАМАЛЕТДИНОВ** әзерләде.

Әбү Гали Сина

Табиблык фәне нигезләре

(Трактат)

БИСМИЛЛӘӘҺИР-РАХМӘӘНИР-РАХИИМ

Мәгълүмдер ки, җамигъ, ягъни барлык җан иясе өчен, җир өстендә үсүче үсемлекләр һава кеби барлык тереклекнең яшәвенә иң кирәкле нәрсә, нигез булып тора. Шуның өчен һәртөрле агачларны вә үләннәрне бәян кылучы фәннәрне табибларга белү ләземдер.

Билгеле ки, тыйбб дигәнебез адәмнең җисеменә гариз булган, ягъни килеп чыккан авыруларны белмәктән вә дәхи авыруларны дәва кылып, адәмнең бәдәненнән чыгара белмәктән гыйбарәттер. Әмма ул авыруларны бәян кылудан мөкаддәм (әүвәл) җисемнең тәркебен, ягъни һәрбер әгъзаның өлешләрен белмәк тиештер. Табибка һәрбер әгъзаның әҗзаларын (кисәкләрен) вә сихәт хәлендәге вазифаларын белмәк ләземдер.

Адәмнең җисеме бик күп төрле әнсәҗәдән, ягъни бик күп төрле кисәкләрдән җыелган мөрәккәб бер мөнҗәникыя урынындадыр, ягъни һәрбере Хак Тәгалә кушканча, үз урыннарында хезмәт итәләр. Һәрбер әгъза үзенең вазифасы иң мәшгуль хәлендә булганда әгъзаларда тәртип була. Аны белмәк табиб өчен важибтыр, моны белмәсә андый табиб авыруны сәламәт дияр.

Әгәр һәр авыруга үләннәрне кәмә һүә, ягъни кирәгенчә белмәкче булсак, әлбәттә, иң әүвәл шул җирдәге, шул мохиттагы булгучы үләннәрне вә аларның тамырларын, кабыкларын, чәчәкләрен, орлыкларын вә яфракларын яхшы тикшереп, файдалымы, зарарлымы икәнлеге белмәк ләземдер. Чөнки һәркем үз җиренең һавасына вә табигатенә мүнисләнгәнлек җәһатеннән, ягъни ияләшкәнлектән, үз җирендә үскән үләннәр аның табигатенә муафыйкъ булып, сырхавына үз җиренең гакыйре, ягъни дару үләннәре килешәрәк төшәдер. Табибка гына түгел, һәр бәндәгә үз җирлегенә үскән үләннәрнең хасиятләрен белмәк ләземдер. Һәркайсыбызга мәгълүмдер ки, Ходай рәхмәте илә, үзеннән-үзе, ягъни адәмнең гамәленнән башка кырларда вә сахраларда, вә урманнарда үскән һәрбер үлән инсан гамәле илән тәрбия кылып үстергән үләннәрдән хасиятлерәктер. Гавәм халкының тәҗрибәле адәмнәре дару үләннәрен җыйсалар, вакытын белеп җыялар вә дәхи аны саклый беләләр, болар моттагый табиблардан, ягъни үзләрен табиб санаучылардан күп тапкыр тәҗрибәлерәкләрдер. Табибларның бәгъзеләре, үзләреннән әүвәл язып калдырган тыйбб китапларына гына игътимад кылып, ягъни шуларга гына ышанып гавәм халкы туплаган тәҗрибәне кулланмыйлар. Гавәм халкының тәҗрибәсен кәма һүвә тәхсыйль, ягъни һәрьяклап өйрәнеп эш итәргә кирәк. Уйлап вә фикерләп карасак, Аллаһы Тәгалә һичбер үләнне вә үсемлекне, әлбәттә, габәс, ягъни файдасыз вә мәгънәсез яратмады. Гәрчә дәва җәһәтеннән шифалы булмаса да, икенче хосуста файдалары мөкаррәрдер, ягъни һәр кайсы бәндәләрнең файдасынадыр.

سُنبُل برى ПЕСИ ҮЛӘНЕ (ВАЛЕРИАНА) پسى اولەنى

Песи үләне — гарәпчә сүнбүль бәру. Күпьеллык үсемлек. Тамырчасы күпсанлы. Үсүенең беренче елында әле яфраклар җәелеше генә барлыкка килә, икенче елда исә 1 аршинга кадәр, сирәк кенә аршин ярымга кадәр җитә. Өсте тармакланучан, эче куыш сабак үсеп чыга. Яфраклары капма-каршы, 1 ка-

---

* Дәвамы. Башы журналның 1999 елгы 6, 7, 8, 9, 10, 11, 12, 2000 елгы 1 саннарында.

рыш озынлыкта, каурыйсыман булып үсәләр. Чәчәкләре вак, хуш исле, аксыл-шәмәхә төстә. Җимеше — бер оялы, бүрекле, көрән төстәге орлык. Июльдә чәчәк ата, җимешләре августта өлгерә. Болыннарда, дымлы җирләрдә, вак куаклык араларында, үләнле, сазлыклы җирләрдә үсә.

Дәва буларак валерианның тамырчаларын файдаланалар. Тамыр вә тамырчаларның төнәтмәләре файдаланыла. Төнәтмәне хәфәкан, ягъни йөрәк сикерүе вә йөрәк уйнавы вакытында, йокысызлыктан, илтиһабе мигъдә, ягъни ашказаны вә эчәклек кан тамырлары кысылганда китерә торган йөрәк-кан тамыры йөрешен көйли вә тынычландыра, шулай ук таррадүл дидан, ягъни эчтәге кортларны вә суалчаннарга каршы яхшы тәэсир итә торган дәва буларак киң кулланыла.

Төнәтмәне ясар өчен, 3 мыскал ваклап турап киптерелгән тамыр вә тамырчаларга бер чынаяк микъдарында кайнап торган су салып хәзерлиләр. Суынганнан соң төнәтмәне сөзәләр вә көнгә 3—4 тапкыр берәр аш кашыгы эчәләр. Бер чынаяк шундый төнәтмәне бер көн буена «Бисмиллә» әйтеп эчәләр.

Песи үләне тамырчаларын вә тамырларын аның сабаклары көрән төскә кереп кибә башлагач, сентябрь-октябрьдә хәзерләргә кирәк, бәгъзе бәндәләр аларны яз башында да җыялар. Казып алынган тамыр вә тамырчаларны агым суда юарга, яхшы җилләтә торган чоланнарда киптерергә кирәк.

Дәваны кулланыр алдыннан шифасы тисен өчен, камил тәһарәт илә «Нәхел» сүрәсенең 11 аять кәримәсе укылыр:

بِسْمِ اللّٰهِ الرَّحْمٰنِ الرَّحِيمِ ۝ يُنْبِتُ لَكُمْ بِهِ
الزَّرْعَ وَالزَّيْتُونَ وَالنَّخِيلَ وَالْأَعْنَابَ
وَمِنْ كُلِّ الثَّمَرَاتِ إِنَّ فِي ذٰلِكَ لَآيَةً لِقَوْمٍ يَتَفَكَّرُونَ ۝

«Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Йәмбәтү ләкүм биһиз-зәргә үәззәйтүүнә үәннәхыйлә үәл-әгнәәбә үә миң күллис-сәмәраат. Иннә фии зәәликә лә әәбәтәлликаумий-йәтәфәккәрүүн».

Мәгънәсе: «Вә ул су белән безләргә иген, зәйтүн, хөрмә, йөзем агачлары вә башка төрле җимешләрне үстерер. Фикерле белгән кешеләр өчен бу әйтелгән нәрсәләр вә дәхи Аллаһы Тәгаләне танып белү өчен дәресләр бар».

چيه **чия** شَجَرَةُ الْكَرَزِ

Чия агачы — гарәпчә шәҗәратүл кәрази. Кайрысы катламланган кара-соры яки соры-көрән төстәге биеклеге бик зур булмаган агач. Яфраклары киң, өске яклары ачыграк, кырыйлары тешле-тешле. Чәчәкләре ак, биш буынтыклы. Җимеше ачык кызыл төстә, шома түгәрәк, сусыл-баллы. Май аенда чәчәк ата, июльдә җимеш бирә. Адәмгә бик шифалы җимеш.

Дәва хәзерләү өчен җимешләрен, яшь ботакларын вә яфракларын файдаланалар. Чия җиләкләре мүдиррате бәвелия, ягъни сидекне чыгарыр вә бозык каннарны чистартыр. Хөммә, ягъни тәндә кан гадәти хәленнән артыграк вә зур тизлек илән саркылып, тәндә бертөрле авырлык, киерелү-сузылу кебек халәтләр пәйда булса, моны бизгәк дип атыйлар. Бу халәт җиңелчә бер бизгәк булып, тиз генә кирәк микъдарда чия ашасаң, бетеп китәр яки бераз тирләү илән чыгар. Шулай ук чия мөсһиләт, ягъни эчне йомшартучы вә дәхи мүкавиәт, ягъни әгъзаларга куәт бирүче, ныгытучы дәва итеп кулланыла. Өлгереп пешкән чия җиләкләре какырык чыгаргыч, сулыш юлларын дәвалаганда, зәңгелә зәхмәтеннән һ. б. бик күп төрле авыруларга дәва итеп кулланыла.

Чиянең яшь ботакчыкларын кайнатып шешенүләрдән, эчәк авыруларыннан вә дәхи сидек-таш авыруларыннан файдасы бик күп.

Кайнатма хәзерләү өчен бер кадак вакланган яшь ботакчыкларны бер чүлмәк суга салып 15—20 минут кайнатыла, суытыр өчен чоланга чыгарып куела, 2—3 сәгатьтән соң бу кайнатманы алып кереп сөзәргә һәм көнгә 3—4 тапкыр яртышар чынаяк итеп «Бисмиллә»не әйтеп эчәргә кирәк.

Чия агачының яшь яфракларын сөттә кайнатма ясау өчен файдаланалар:

яңа җыелган 4 мыскыл яфракны вә бер чынаяк сөтне 20 минут вакытка чүлмәккә салып кайнатырга кирәк, шушы кайнатма илән сары авыруын дәвалыйлар.

Туралган яшь яфракларны кан киткәндә, тән җәрәхәтләнгәндә ябалар. Дәваны кулланыр алдыннан, шифасы тисен өчен, камил тәһарәт илән ошбу аять кәримә укыла:

بِسْمِ اللَّهِ الرَّحْمَٰنِ الرَّحِيمِ وَمَا ذَرَأَ لَكُمْ فِي الْأَرْضِ مُخْتَلِفًا أَلْوَانُهُ إِنَّ فِي ذَٰلِكَ لَآيَةً لِقَوْمٍ يَذَّكَّرُونَ ١٣

«Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Үә мәә зәра әләкүм фил-әрдый мүхтәлифән әлүәәнүһ. Иннәә фии зәәликә лә-әәйәтәл-ликаумий-йәззәккәрун».

Мәгънәсе: «Вә җирдә сезнең өчен хайваннарның вә үсемлекләрнең төрле төстәгесен бар кылдык, әлбәттә, аларда вәгазьләнә белгән бәндәләргә хакыйкый могҗизалар бар». (К, 16:13)

قاز اوله نى КАЗ ҮЛӘНЕ جَبَلُ الطَّيْرُ

Каз үләне гарәпчә — җәбәлүт тайру, төрекләр — чыпчык аягы дип атыйлар. Берьеллык үлән. Тамыры каты вә озын, үрмәләп үсә торган үсемлек. Сабаклары йомшак, җәенке, ярты аршинга кадәр җитә. Мүтәгакыйб вәракъ, ягъни яфраклары бер-бер артлы, нәүбәтле, вак. Чәчәге дә бик вак, ак төстә. Һәр чәчәге яфрак төбеннән чыга. Бәләкәй генә бу «үлмәс» үлән һәрвакыт адәм балалары илән янәшә. Ничек кенә тапталмасын — бу үләннең Ходай рәхмәте бернигә дә исе китми үсә бирә. Июньнән августка кадәр чәчәк ата, исе юк, тәме бераз бөрештергеч.

Дәва буларак каз үләне кан туктаткыч, хөммәдән, ягъни бизгәктән, мүдирате бәвелия, ягъни сидерә торган, җәрәхәткә япсаң яраны бик тиз арада төзәтә, бөерләргә вә сидек куыгына ком һәм таш утырганда, зәйкыннәдә, ягъни ашказаны авыртканда кулланалар.

Кайнатмасын хәзерләү өчен 1 кадак каз үләнен юып чүлмәккә салыгыз, кайнап чыккач суытыр өчен чоланга куегыз, кайнатма суынгач алып кереп сөзегез. Көнгә өч мәртәбә ашар алдыннан берәр чынаяк шушы кайнатманы «Бисмиллә» әйтеп эчегез. Яшь үләннең сыек боткасы пешүләрдән, төзәлми торган җәрәхәтләрдән кулланалар.

Каз үләнен чәчәк ату вакытында хәзерлиләр. Сабакларның югарыгы өлешләрен кисеп җыярга кирәк, юка гына таратып, әледән-әле әйләндереп чормада киптерәләр.

Дәваны кулланыр алдыннан, шифасы тисен өчен, камил тәһарәт илә барыбызга дә мәгълүм булган «Фатихә» сүрәсе укыла.

Текстны журналга **МӨБРӘКШАҺ ТУЛБАЙЛЫ** әзерләде.

(Дәвамы бар.)

РЕДАКЦИЯДӘН: Хөрмәтле укучылар! Сез «Халык медицинасы» сәхифәсендә бирелә торган киңәшләрне табиблар күрсәтмәсеннән башка кулланырга ашыкмасагыз иде. Алар бирелә фәкать борынгы бабаларыбыз мирасы буларак кына тәкъдим ителәләр.

«МИРАС» ПОЧТАСЫ

ДАҺИ МИЛЛӘТЧЕ

Татарны бәйсезлеккә алып бару өчен Гаяз Исхакый фикерләре белән коралланырга кирәк! «Мирас» журналының 1999 елгы 10 санында басылган «Казан китүгә 383 ел үтте» дигән мәкаләне укыгач, ихтыярсыз, күңелгә шундый уй килә.

Мәкаләдә язылганча, Гаяз Исхакый үзенең яшәү дәверендә 15 октябрь көнен зур ачыну хисе белән йөрәгә аша уздырган. Әгәр шулай булмаса, ерак Мукденнан 1935 елны милләткә шундый эчтәлекле хат язар идеме?!

Гаяз Исхакыйның әлеге хатыннан соң 65 ел гомер узды, ә татар милләтенең хәле авырайганнан-авырая бара. Шуңа күрә ул мәкаләдәге фикерләр бүген дә актуаль.

Гаяз Исхакый иҗатын милләткә кайтару эшендә «Мирас» журналына тиңнәр юк. Алга таба да мираслылар әлеге изге эшләрен дәвам итәрләр, иншаллаһы, дигән өметтә калам.

ӘХӘТ ЙОСЫПОВ,
ТИҮнең президиум әгъзасы.

* * *

ХӨРМӘТЛЕ ТУГАННАР! МӨХТӘРӘМ ҖӘМӘГАТЬ!

Барыбыз да белгәнебезчә, моннан 447 ел элек канлы бәрелешләрдән соң Казан ханлыгы дәүләт буларак яшәүдән туктап рус дәүләтенә кушылды. Казан өчен аяусыз көрәш барганда һәр ике яктан да бик күп сугышчылар һәлак булды.

Казанны яулап алганда үлгән рус сугышчыларына 1823 елда һәйкәл куелган иде. Башкалабызны яклап шаһит киткән бабайларыбыз истәлегенә гади генә таш та куелмады. Ләкин халык хәтерендә аларның фидакарьлеге һәрвакыт кадерләп сакланып килде.

Ниһаять, шул хәтерне һәйкәл итеп сынландыру вакыты да җитте. Бик күп халык вәкилләре һәм җәмәгать оешмаларының мөрәҗәгатьләрен искә алып, Татарстан Республикасының Министрлар Кабинеты 1552 елда Казанны саклаганда һәлак булган каһарманнар истәлегенә багышлап һәйкәл төзү турында бу елның 26 февралендә карар кабул итте.

Шушы карарны үтәү йөзеннән һәйкәлне төзү өчен махсус фонд оештырылды. Бүгенге көндә ул фонд рәсми рәвештә теркәлеп, үзенең эшен башлап җибәрде.

Булачак һәйкәлнең проектына конкурс игълан ителде. Берничә проект инде жюри тарафыннан карап тикшерелде дә.

Һәйкәл 2000 елда төзелеп бетәр дип уйлыйбыз.

Төзелешне тизләтү өчен, әлбәттә, финанс чыгымнары кирәк. Һәйкәл халык хәтеренең символы булганга, аның чыгымнарын да җәмәгать белән күтәрербез дип өметләнәбез. Бу изге эштә һәрберебез дә хәлебездән килгәнчә катнашырбыз дип ышанабыз. Оешмалар, предприятиеләр дә читтә калмаслар дип уйлыйбыз.

Казанны яклап һәлак булучыларга һәйкәл кую мәсьәләсе күтәрелгәч, заманында төрле бәхәсләр дә булып алды. Бу турыда бүген дә берничә сүз әйтеп китәргә кирәктер. Һәйкәлнең зарурлыгына шик белдерүчеләр бар. Бераүләр, җиңелүебез хөрмәтенә һәйкәл төзү урынлы булырмы, дисә, икенчеләр, ул һәйкәл ике милләт арасында каршылык тудырмасмы дип борчылалар.

Безнең уебызча, андый шикләнүләргә нигез юк. Төзеләчәк һәйкәл халык хәтере символы булып, аның янына килүчеләрне уйландырыр. Үткәнебез, бүгенгебез, киләчәгебез турында уйланып, күпсанлы корбаннар бирмичә тату яшәүнең серенә төшенергә тырышырбыз. Һәр сугыш халык хәтерендә фаҗига булып саклана. Сугышны халыклар түгел, канга сусаган хәкимнәр башлый. Халык ул сугышларда корбан гына була.

Килер заман, кешеләр төрле низагларны, кан коеп сугышмыйча, акыл белән чишәргә өйрәнерләр. Дөнья белән идарә итәргә җыенучы тиран хәкимнәрнең нәфесләренә чик куя белерләр. Бөтен халыкларны тигез итеп күргән Җир-Анабыз бераү генә. Аны кан белән сугару зур гөнаһ икәнен кешеләр аңларлар.

Казансу елгасының бер ярында Казанны яклаучыларга һәйкәл торса, икенче ягында Казанны алганда үлгән рус сугышчыларына куелган һәйкәл бер-берсенә карашып сүзсез генә сөйләшерләр, аңлашырлар, татулыкка юл эзләрләр.

Безнең фонд рус сугышчылары истәлегенә салынган һәйкәлне төзекләндерүне дә күздә тота. Ул эшкә дә үз өлешләрен кертүчеләр булыр дип уйлыйбыз.

Хәерле сәгатьтә эшкә тотыныйк, җәмәгать!

1552 ЕЛДА КАЗАННЫ ЯКЛАГАНДА ҺӘЛАК БУЛГАННАРГА ҺӘЙКӘЛ КОРУ ФОНДЫ

ИНН 1654036144, Расчетный счет № 40703810900000000103 в КИТБ «Казанский» г. Казань, БИК 049205806, к/с 30101810300000000806

Акчаны түбәндәге адрес белән дә кертеп тапшырырга мөмкин: **Казан шәһәре, Кремль урамы, 9 нчы йорт, 2 нче кат, 13 нче бүлмә.**

Мәрхүм ата-аналарыбызны хөрмәт итик, истәлекләрен саклауга ярдәм кертик!

ТУФАН МИҢНУЛЛИН,
Фонд рәисе, драматург,
Татарстанның Г. Тукай исемендәге
Дәүләт бүләге, Станиславский
исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты.

РЕЗЮМЕ

Второй, февральский номер международного журнала «Мирас» («Наследие») за 2000 год открывается постоянной рубрикой «Слово главного редактора».

В постоянной рубрике «Литературное наследие» публикуется монография «Татарская рукописная книга» доктора филологических наук Марселя Ахметзянова.

В постоянной рубрике «Антология татарской поэзии начала XX века» публикуется стихи татарских поэтов Вакифа Жалала и других.

В постоянных рубриках «Национальная поэзия», «Языкознание», «Духовное наследие», «Библиотека «Мирас»а», «Народная медицина», «Историческое наследие», «Национальное искусство», «История татарской литературы», «История Золотой Орды», «История тюркских народов» с научно-популярными статьями, научными публикациями и литературными произведениями выступают такие известные ученые, писатели, публицисты и общественные деятели, как Гаяз Исхаки, Жагъфар Мубарак, Фирдаус Зариф, Энгель Нигъматуллин, Равиль Фахрутдинов, Накип Каштанов, Малик Хайруллин, Альфия Айдарская, Флюн Мусин, Алсу Каримова, Вакиф Нуруллин, Барлас Камалов, Каим Шайхутдин, Радмир Фаяз-Ураллы, Дания Гайнетдинова.

В постоянной рубрике «Почта «Мирас»а» публикуются письма читателей журнала, затрагивающие острые проблемы суровой действительности.

SUMMARY

The second, February issue of «Miras» international («Heritage») for 2000 opens with its constant rubric «The Editor-in-Chief's Word».

In our regular «Literary Legacy» rubric is published a monograph «The Tatar Manuscript» bu Marsel Akhmetjanov, doctor of philological sciences.

In the regular rubric «Anthology of the Tatar Lyric Poetry at beginning of the XX th century» we publish verses, written by Vakif Djalad and others.

In the redular rubrics «National Poetry», «Linguistics», «Spiritual Legacy», «The Library», of «Miras», «Folk medicine», «Historical Legacy», «National Art», «The History of the Tatar Literature», «The History of the golden Horde», «The History of the Turkic Peoples» are presented popular scientific articles, scientific information, works of art created by well-known scientists, writers, journalists, state and social men, such as Gaiaz Iskhaky, Djagfar Mubarak, Firdaus Zarif, Engel Nigmatullin, Ravil Fakhrutdinov, Nakip Kashtanov, Malik Khairullin Alfija Aidarskaia, Flun Musin, Alsu Karimova, Vakyf Nurullin, Barlas Kamalov, Kaim Shaihutdin, Radmir Faijaz-Yrally, Danija Gainetdinova.

In the constant rubric «The Mail of «Miras» are published readers' letters touching upon acute subjects of our severe reality.

ОБЪЕКТИВТА — ТӨРЕКСОЙ

Рәсемдә: ТӨРЕКСОЙ генераль директоры Полад Был-Был оглы һәм «Европа-Азия» Халыкара Гуманитар Академиясе Президенты, академик Энгель Таһиров.

Рәсемдә: ТӨРЕКСОЙның чираттагы утырышында катнашучы төрки халыкларның рәсми делегацияләре вәкилләре Казанда. Уңнан беренче Марсель Таишев.

Тышлыкның беренче битендә рәссам ИСКӘНДӘР РАФИКОВНЫҢ «Хан кызы» дигән рәсеме, икенче битендә академик ФӘРИТ ХАТИПОВНЫҢ фотосурәте, өченче битендә «Объективта — ТӨРЕКСОЙ» циклы, дүртенче битендә рәссам ЛӘЙСӘН СӘМИГУЛЛИНАНЫҢ шәмаиле.

Ваклап сатуда ирекле бәя

Индекс 73955